*Р.А. Юсупов*

# *Милләтебез иминлеге сагында*

---

# *За развитие нации*

Казань
"Слово"
2022

ББК 72
УДК 001
Ю91

Редактор *Д.М. Юсупова*

**Юсупов Р.А.**

Ю91 Милләтебез иминлеге сагында. За развитие нации. – Казань: Изд-во “Слово”, 2022. – 560 с.

Бу китапта академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның вакыйгаларга бай тормышы, нәтиҗәле гыйльми-педагогик, иҗтимагый эшләре сурәтләнә, бүгенге чынбарлыкка карата фикерләре бәян ителә, шулай ук хезмәтләренә бәяләмәләр, аның турында хатирәләр, китап һәм мәкаләләренең исемлеге урнаштырыла.

Данная книга содержит воспоминания академика Академии наук Республики Татарстан, заслуженного профессора Казанского федерального университета Рузаля Абдуллазяновича Юсупова о его богатой событиями жизни, административно-педагогической, научной и общественно-политической деятельности, размышления о сегодняшних реалиях нашей действительности, отзывы о деяниях ученого, а также перечень его научных трудов.

ISBN 978-5-98356-398-8
ISBN 978-5-98356-399-5

© Юсупов Р.А., 2022
© Оригинал-макет, ООО “Слово”, 2022

## КЕРЕШ СҮЗ

Минем турыда язылган китаплар бар инде. Әмма аларда күбесенчә минем һөнәри эшләрем сурәтләнгән, үзем кичергән кайбер вакыйгалар төшеп калган. Шуларны хәтеремдә яңартып, яшәү дәверемдә аралашкан күренекле шәхесләр турында мәгълүматлар өстәп, үткән тормыш маҗараларын тулырак бәян итәргә кирәк дип уйладым.

Гыйбрәтле озын гомер узган кеше белән бәйләнешле хәлләр, ул кылган игелекле гамәлләр, аның бүгенге көнкүрешкә караган фикерләре, тәкъдимнәре укучыларда кызыксыну уятсын һәм алар өчен файдалы булсын иде дигән теләк белдерәм.

## ПРЕДИСЛОВИЕ

Испытывая желание поделиться с читателями своими воспоминаниями, я решил описать отдельные этапы своей жизни и высказать соображения по некоторым животрепешущим вопросам сегодняшнего дня, которые не могут оставить равнодушными меня, вероятно, как и многих других.

При написании воспоминаний главная трудность заключается в том, чтобы, перебирая в своей памяти многочисленные эпизоды, среди них суметь выбрать лишь те, которые будут интересны, прежде всего для читателя. Определить грань между тем, что важно для автора, и тем, что имеет значение для читателя, довольно сложно.

Если где-то увлекся описанием сугубо личных или слишком мелких деталей, прошу меня извинить.

## БАЛАЧАК ҺӘМ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ

Мин дәһшәтле Икенче бөтендөнья сугышы башланырга ике ел ярым кала күренекле шагыйрь Габделҗаббар Кандалый, драматург Фатыйх Халиди, язучы Әхмәт Уразаев-Кормаши, мәгърифәтчеләр Мотыйгулла Төхфәтуллин, Таиб Яхин, Санкт-Петербург имамы Гатаулла Баязитов, Габдулла Тукайның әтисе имам-хатыйб Мөхәммәтгариф Тукаев һәм башка күренекле шәхесләр укыган мәдрәсәсе белән данлыклы Казан артындагы Кышкар (Наянгуш) авылында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килгәнмен. Ике абыем, ике энем белән биш малай үстек. Апаларыбыз, сеңелләребез булмады.

Әби-бабаларыбыз да, әти-әниләребез дә, гади крестьяннар буларак, авыр тормышта яшәгәннәр. Хәер, әтиебезнең атасы – Йосыф бабабыз укымышлы кеше булган һәм авылыбызның мөәзине вазыйфаларын башкарган. Ул иртә үлеп киткәнлектән, без аны күреп белмәдек. Әтиебезнең сөйләвенә караганда, Йосыф бабабыз гадел кеше булган, үзенә бирелгән сәдакаларын да бик авыр хәлле авылдашларына өләшә торган булган.

Йосыф бабай үлеп киткәч, аның тол калган хатыны, икенче кешегә кияүгә чыгып, ире белән каядыр чит җирләргә китеп барган. Йортта Сафа энесе белән икесе генә калган безнең булачак әтиебез Габдуллаҗан яшьли өйләнергә мәҗбүр булган. Аны Кышкардан сигез чакрымдагы Иске Мәңгәр авылының булдыклы Шәрифелҗамалның уңган кызы – безнең булачак әниебез Лотфикамалга димләп өйләндергәннәр. Алар – берсе 80гә, икенчесе 90га кадәр тату яшәп, крестьян тормышының бөтен ачысын-төчесен татып, безне, биш улны, исән-сау килеш, лаеклы кешеләр итеп үстереп, олы юлга чыгардылар.

Мин вакыйгаларга бай, гыйбрәтле, озын гомер кичердем. Башымнан узган хәлләрнең күбесе әле дә исемдә, әлбәттә, онытылганнары да бар. Төрле кешенең үзен белә башлавы төрлечәрәк була.

Мин вакыйгаларны кайчаннан бирле исемдә калдыра башлаганлыгымны төгаен генә хәтерли алмыйм. Иң беренче булып исемдә калган күренеш шул: мин кыш көне, уйнарга чыккач, өебез каршыннан печән төяп узып барган атлы чанадан бер-ике уч печән йолкып алып калдым. Үзебезнең малларга диптер инде. Шунда бу хәлне бер апа, күреп алып, шаян көлемсерәп, миңа: "Син нишләп монда печән чәлдереп йөрисең әле, бар тизрәк өеңә кер, әтиең кайткан бит!" диде. Мин йөгереп өйгә керсәм, форма кигән бер ир кеше мине күтәреп алып кочаклады. Үкенеч: шул күренешне исән чакта әниебездән сорап калырга башыма килмәгән: кайчан булган ул, әтиебез кайчан кайтып төшкән булган: әллә Финляндия сугышыннан, әллә Суслонгердан берәр көнгә генә булса да сорап кайтып килгән булган. Безнең әти финнар белән сугыштан яраланып кайткан һәм берникадәр вакыттан, Ватан сугышына алынып, күп кенә татар ирләре кебек, башта берничә ай Суслонгер урманнарында хәрби өйрәнүләрдә булып, фронтка киткәнче, җәфа чигеп яткан. Аларның ачлыктан, суыктан интегүләрен соңыннан әнинең сөйләве бераз исемдә калган.

Германия белән сугыш еллары минем хәтеремә куркыныч төшләр кебек сеңеп калган.

Кышын көннәр буена Әнәс энем белән икебез генә салкын өйдә сәкедә утырабыз. Әни, мин соңыннан белгәнчә, безнең авылдан 30 чакрымдагы Арчага чана тартып ашлык илтергә киткән була, ә Равил белән Наил абыйлар, мичкә ягарга кырдагы эскертләрдән салам йолкып алып кайталар яки инеш буендагы таллардан чыбык җыялар. Әниебез Арчадан кайчан әйләнеп кайткандыр, абыйлар ягулык әзерләү эшләре белән күпме вакыт шөгыльләнгәннәрдер, безгә кем кайчан нәрсә ашаткандыр, эчерткәндер, төгәл генә әйтә алмыйм, анысы исемдә калмаган, әмма моның сугыш елларындагы йөрәкне сыкратырлык хәлләрнең бер эпизоды икәнлеге билгеле.

Миңа 4-5 яшьләр булгандыр, абыйлар саламны кочаклап өйгә кертеп ташлыйлар да, мин аны мичкә ягып торам. Саламны, учлап, мич авызына төртеп кертеп җибәрәсең дә, ул шундук гөлт итеп кабынып китеп, минут та узганчы, янып та бетә. Берөзлексез тыгып торасың. Салам идәнгә тарала. Бервакыт, мичтән янып торган салам кисәге идәнгә очып төшеп, идән буенча ут тарала башлады. Ул арада кроватьтагы юрганга да кабып өлгерде. Ярый әле абыйлар ишегалдында ниләрдер эшләп йөриләр иде. Мин чыгып кычкыргач, йөгереп кереп, янгынны сүндереп өлгерә алдылар...

Сугыш шомлыгының бер хатирәсе: кайчакларны, шөбһәле булып (кайсы яктан икәнлеген абайламаганмын), саңгыраурак тавыш белән гөрселдәп, туп (орудие) аткан тавыш ишетелгәли торган иде. Кайдадыр хәрби өйрәнү яки заводта эшләгән коралны сынап карау булгандырмы ул, белмим, бәлки, бездән ерак түгел Мари урманнарындагы Суслонгер полигонында булгандыр. Ләкин ачык хәтерлим: туптан атканда була торган гөрселдәгән тавыш ишетелгәли иде.

Дәһшәтле сугышның тагын бер истәлеге: бервакытны тышкы яктан өй тәрәзәләрен каплатып йөрделәр. Бу Сталинградтагы дәһшәтле сугыш вакытында, немец самолетлары килеп, безнең тирәләрдәге завод-фабрикаларны, бигрәк тә корал җитештерә торган предприятиеләрне бомбага тотмасыннар өчен эшләнгән булгандыр.

Күңел түрләреннән актарылып чыккан хәсрәтле хатирәләрнең берсе: күрше-тирә хатын-кызлар, күбрәк ирләре сугышта булганнары, кичләрен, бер-берсенең өенә җыелып, кич утыралар иде. Болай, чиратлашып, әле берсендә, әле икенчесендә җыелып утыруларының бер сәбәбе, хәсрәтләрне уртаклашып, эчеңне бушату булса, икенчесе – бик кадерле керосинга экономия ясау булгандыр. Кызык карап, күңел ачып утырмыйлар, барысы да ниндидер кул эше (носки-бияләй, шәл бәйләү) белән шөгыльләнеп, күбрәк каһәр төшкән сугыш белән бәйләнешле хәлләр турында әңгәмә коралар. Сөйләшер сүзләре, уртаклашырлык моң-зарлары хәттин ашкан: кайсының ире яралануы турында, кайсының ире хәбәрсез югалуы, кайсыныкы сугыш кырында батырларча башын салуы хакында хәбәр килгән, каты яраланып, инвалид булып кайткан кешеләр турында да, яшәү шартларының чамасыз кыенлаша баруы турында да сүзләр була иде.

Мин бу хәлләрне күрше хатыннары безнең өйдә җыелышып утырганда ишеткәннәремә нигезләнеп сөйлим, әлбәттә. Вакыт-вакыт җырлашып та, елашып та алалар. Җырлары моңлы, сагышлы була. Безнең әнинең тавышы матур, шуңа күрә: “Лотфикамал, әйдә, син җырла әле”, – дип, аны да җырлаталар иде.

Бер көнне безнең әни елап кайтып керде. “Әй, балалар, әтисез калдыгыз бит, әтиегез үлгән!”, дип кенә әйтә алды, яшенә буылып. Мин әле ул чакта бу хәбәрнең безнең өчен никадәр зур фаҗига икәнлеген аңларлык яшьтә түгел идем. Шулай да, әниебезне кызганып булса кирәк, минем дә күзләрем яшьләнде. Әни “Ирегез

батырларча һәлак булды" дигән хат алган булган икән. Ярый әле, дөнья кайгылардан гына тормый, шатлыклы мизгелләре дә булгалый. Бездә дә шулай булды. Үлем хәбәре килеп, берникадәр вакыт үткәч, әтинең үзеннән хат килеп төште. Хәл болай булган. Немецлар белән каты бәрелештә безнең әти, каты яраланып, алар басып алган җирдә ятып калган. Ул хәрәкәтсез ятканлыктан, немецлар, аны үлгәнгә санап, игътибар итмәгәннәр. Күпмедер вакыттан әтиебез аңына килгән, һәм тиздән безнекеләр, контратака ясап, ул яткан җирне яңадан кайтарып алганнар. Әти, госпитальдә дәваланып, язарлык хәлгә килгәч, безгә хат җибәргән. Шулай итеп, шөкер, без яңадан әтиле булдык. Ләкин әле ул, шактый вакытлар фронтта булып, сугыш тәмамланыр алдыннанрак кына, тагын яраланып, инвалидлык алып, өйгә кайтты.

Аның кайтып керүе минә болай булып исемдә калган. Мин, мичкә салам ягып бетереп, идән себереп йөрим (ул вакытта андый вак эшләрнең күбесе минем өстә иде инде). Шулчак өйгә хәрби формадан бер ир кеше килеп керде. Мин аны танымадым. Әни белән кочаклашып күрешүеннән генә безнең әти икәнлеген аңладым. Дөресен әйтим, ул чакта мин бу хәлгә бик шатланганымны хәтерләмим: ул миңа әле чит кеше сыман тоела иде. Әмма алып кайткан матур тартмалы Америка шикәрен, бик кадерләп, аз-азлап кына чәй эчеп тотуыбыз исемдә.

Шунысы гаҗәп: 1945 елда мин, инде 6 яшемнән узып киткән малай буларак, күп нәрсәләрне аңларлык, белерлек халәттә булсам да, сугыш тәмамлануына авылыбыз халкының, хәзер телевизор экраннарыннан күрсәткәнчә, дау китереп, шашып сөенеп йөргәнен хәтерләмим. Күрәсең, җиңү шатлыгына караганда, сугыш газаплары көчлерәк булгандыр: авыл ир-егетләренең яртысының яу кырында ятып калуы, күпмесенең инвалид булып кайтуы, халыкның ач-ялангачлыгы, фәкыйрьлеге, авыл тормышының искиткеч авырлыгы хәтта җиңүгә дә нык шатланырлык урын калдырмагандыр.

Газаплы сугышның михнәтләре әле озак дәвам итте. Көнбатыштан көнчыгышка Калининградтан (элекке Кенигсберг-тан) Япониягә кадәр, төньягыннан көньягына поляр утрауларыннан Памир тауларына кадәр сузылган чамасыз зур илнең, бәлки, кайсыдыр өлешендә берникадәр генә җиңелрәк яшәүчеләр булгандыр, ләкин гомумән алганда СССР дип аталган бу дәүләттә халык әле 80 нче – 90 нчы елларга кадәр хәтта уртача гына дәрәҗәдәге муллыкта да яши алмады.

Сугыш нәтиҗәсендәге икътисадый бөлгенлек һәм дәүләтнең амбициоз сәясәте аркасында халыкның тормышын яхшырту мөмкинлеге булмады. Илнең промышленностен, авыл хуҗалыгын рәткә китерү белән бәйләнешле гаять зур бурычларны хәл итү проблемалары өстенә оборона куәтен тиз арада алдынгы капиталистик дәүләтләрнекеннән калышмаслык дәрәҗәгә җиткерүгә һәм барлык социалистик илләргә, шулай ук тагын берничә дәүләткә ярдәм итеп торуга юнәлтелгән искиткеч зур чыгымнар илнең үз халкына кешечә яшәргә җай калдырмады.

Мин, сугыш елларында ничек көн күргәнлегебезгә, әнинең берүзе безне – дүрт малайны ничек итеп ачка үтермичә саклап кала алганлыгына исем китеп, хәтта сугыштан соң да күп еллар буена ярым ач килеш, тишек-тошыклы, ямаулы кием киенеп яшәп, ничек итеп җан саклап калганбыз икән дип гаҗәпләнәм.

Елның күпчелек айларында иртә таңнан караңгы кичкә кадәр колхоз кырларында, фермаларда көненә бер хезмәт көне хакына эшләп, бөтен иген уңышын хөкүмәткә тапшырып бетергәннән соң калганыннан бер хезмәт көненә 600-700 грамм, иген әйбәт булса, 1 килограмм исәбеннән ашлык (күбесе арыш) алып, дәүләткә әллә никадәр ит, май, йомырка, йон налогы биреп, шуның өстенә заем түләп, беркайдан бер сум акча алмыйча яшәргә мәҗбүр булды авыл халкы. Моны мин үзебезнең гаилә мисалында яхшы беләм.

Әтиебез сугыштан куллары зәгыйфьләнеп кайтканлыктан, авыр физик эшләргә йөри алмады, бригадир булып эшләде, аның өчен түләү – бер хезмәт көне. Сыер, ике-өч, өч-дүрт сарык, унлап тавык, бер оя казлар тотабыз. Налог түләгәннән калган ит, майны Әтнә базарында яки Казанның колхоз базарында саткан акча 5 малайга (бишенчебез Мөнир сугыштан соң туганы), әти-әнигә кием алырга да җитми. Әниебез кичләрен йокымсырый-йокымсырый ямау ямап, кулыннан килгәнчә, иске Зингер машинкасында безгә күлмәк-ыштан тегеп утыра иде. Налог итеп дәүләткә тапшырганнан калган майны биреп, авылыбыз осталарыннан чиләк-чүмеч, арба-чана кебек әйберләр дә эшләтеп алырга туры килә иде әле. Шуннан соң безнең үзебезгә – җиде кешегә ашарга нәрсә калсын! Ит-май, күкәй кебек затлы ризыклар үзебезгә зур бәйрәмнәрдә генә эләкте. Төп ризык – бәрәңге, сепаратордан чыккан, судан аз гына аерылып торган сөтле аш; шундый ук сөттән оеткан катык.

Җәй җитеп, җир өсте яшелләнсә, безнең ризыгыбызны ашарга яраклы үләннәр берникадәр төрләндерә: кузгалак, акбаш, какы,

сәрдә яфрагы, тагын ниндидер үләннәрне бик теләп ашый башлый идек. Без әле сугыштан соң күп еллар угыч белән уган бәрәңге кушып пешерелгән ипи ашадык. Лыҗгырдап, җебеп торган сусыл, тәмсез була иде ул. Һәр атнаны, ипи пешерү өчен, тимерче алачыгында ясаткан ике зур чиләк бәрәңге уабыз. Берсен миннән 4 яшькә олырак Наил абый, икенчесен – мин уам. Калайны игәү сабы белән тишеп ясалган угычның тешләре, өскә калкып, ырҗаеп тора. Минем утырып кына эшләргә көчем җитмәгәнлектән, басып, көчәнеп уам. Угычның чәнечкеле тупас тешләре бармакларымны умырып-умырып ала. Инде тазарып килә дигәндә, бер атнадан тагын бер зур чиләк бәрәңге көтеп тора...

Кар эреп, җир чыккач, без, малайлар, узган елгы бәрәңге басуына, көздән, балчыкка күмелеп, күренми калган, өшеп чери башлаган бәрәңгене җыярга юнәләбез. Аны алып кайтып, чистартып, изеп, күмәч пешерәбез. Ярыйсы гына туклыклы ризык килеп чыга. Черегән бәрәңгене җыйганда, өшегән балчык аяк киемен суырып ала. Шуңа күрә чабатаны яки агач башмакны басу кырыенда салып калдырабыз да, бәрәңгене ялан аяк йөреп җыябыз. Кайбер урыннарда туң китеп бетмәгән була, шома боздан аяклар таеп-таеп китә. Шундый бозлы салкын җирдә, чиләкне бәрәңге белән тутырганчы, ялан аяк күпме вакыт йөрелгәндер дә, каты салкын тиеп, ничек авырып китмәгәнбездер. Хәер, без гомумән май башыннан алып сентябрьнең урталарына кадәр ялан аяк йөри торган идек. Аякларыбыз, яргаланып, “чебиләп” бетә иде. Әмма аяк киеменә зур экономия.

Экономия дигәннән, бу мәсьәләдә безнең гаиләдә тәртипләр бик кырыс иде. Әни безгә уенга чыгу буенча каты режим урнаштырды: урамга уйнарга атнасына бер чыксагыз җитә, дия иде ул. Яшереп тә тормады: күп уйнасаң, кием дә тиз туза, ашарга да күп китә. Уенны чикләүне бигрәк тә авыр кичерә идем, балага уен, бигрәк тә саф һавада хәрәкәтләнү сәламәтлек өчен, таза булып үсү өчен кирәк бит.

Җитмәүчелектән иза чиккән гомердән тагын бер-ике үзәкне өзгеч хатирә.

Авылга якынча айга бер тапкыр кино алып киләләр. Карыйсы бик килә. Акча юк, әлбәттә. Мин берничә мәртәбә, киномеханик тамашачыларны клуб ишегеннән билет тикшереп керткәндә, кешеләр арасыннан шома гына кереп киткәләп йөрдем. Әни, яманатыбызны чыгарып, билетсыз йөрисе юк дип, кино килгән көнне

өйдән чыгармый башлады. Бер тапкыр шулай да, җаен туры китереп, әнидән качып клубка бардым. Гадәттәге ысул белән кешеләр арасыннан яшеренеп кенә кереп киткәнемне киномеханик күреп өлгерде һәм, мине тотарга дип, артымнан куа китте. Кулындагы пряжкалы солдат каешын болгап килә. Эләктереп алса, минем аркага төшәсе мәгълүм. Мин, тоттырмас өчен, йөгереп барып, клубның сәхнәсе астына кереп киттем. Киномеханик та, тотам дип, минем арттан керде. Мин, тоттырмыйм дип, үрмәләп, тагын да эчкәрәк кереп киттем. Сәхнә асты клуб идәненең асты белән тоташкан. Кап-караңгы. Киномеханик кире чыгып китте. Идән аша килгән тавыштан кинофильмның башланып киткәнлеген ишетеп тордым һәм чыгу чарасына керештем. Ләкин дөм караңгыда, юнәлешне бутап (ориентирны югалтып), клуб идәне астыннан тагын да түргәрәк кереп киткәнмен, чыгу юлын табам дип бара-бара, әллә нинди чокырларга төшеп киттем. Тәмам адашканлыгымны аңлап, тагын да түргәрәк, сәхнәдән еракракка кереп китәрмен дип уйлап, бер урында утырып торырга һәм ярдәмгә киномеханикны чакырырга булдым. “Абый, чыгар, абый, чыгар!” – дип кычкырам, ләкин өстә клубта шау-шу, минем тавышны ишетүче юк. Кинофильм беткәнне көтеп утырдым. Салкында (кыш көне иде бу) ике сәгатьләп идән астында утыруның 10 яшьләр чамасындагы малай өчен нинди җәза икәнлеген аңларга буладыр. Ниһаять, ишетеп торам: кинофильм тәмамланды, механик, шалтыр-шолтыр китереп, кино лентасы тартмаларын җыя башлады, кем беләндер сөйләшә. Мин “Абый, чыгар!” дип кычкырам. Механик ишетеп алып, үзенең малайны сәхнә астына куып керткәнлеген исенә төшереп, кул фонарен яктыртып, мине клуб идәне астыннан алып чыкты.

Безнең тормышыбыздагы азык-төлек, кием-салым, акча кытлыгы белән бәйләнешле тагын бер драматик күренеш.

Минем 10-11 яшьләремдәге чагым. Җәй ае. Әни, сәгать 4-5ләрдә йокымнан уятып, миңа шундый эш кушты. Безнең авылдан 15 чакрымдагы район үзәге Әтнә базарында бер кадак (400 грамм) сарык йоны сатып кайтырга кирәк. 25 сумнан. Яулыкка төрелгән бер йомарлам йонны тотып, җәяүләп базарга юнәлдем. 4-5 сәгатьләр барганмындыр, базарга килеп җиттем. Йонны ачып куеп, базар буйлап йөрим. “Күпмедән сатасың?” – дип сораштыргалыйлар. “25 сумнан”, – дим. “Кыйммәт, 20 сумнан алам”, – диләр. Мин бирмим. Йөри торгач, шактый вакыт узып китеп, базар тарала башлады. Нишләргә икән? Кире алып кайтыргамы, 20 сумнан сатып

җибәрергәме? 20 сумнан сатып җибәрдем. Акчаны кесәмә салып, 15 чакрымны җәяүләп, кичкә генә кайтып җиттем. Ашамаган, эчмәгән, әлбәттә. Гел аяк өстендә.

Кайтып кереп, күпмегә сатканлыгымны белгәч, әни “рәхмәт”ен әйтте, шундый итеп әйтте: аның мине ачулануы, үзем картаеп беткәнче, колак төбемдә яңгырап тора сыман. “Йонны харап иткәнсең икән, мин сиңа 25 сумга сатарга куштым бит”... Мин гарьлегемнән әллә еладым, әллә еларга җитешеп тордым. Таң тишегеннән торып, 15 чакрым җиргә җәяү барып, базарда йөреп, көне буенча ашамыйча-эчмичә, җәяү әйләнеп кайткан малайны: “Рәхмәт улым, булдыргансың”, – дип мактыйсы урында, шулай хөкем ит! Әй, заманалар! Бер уйлаганда, артык кырыслык, хәтта рәхимсезлек бу. Икенче яктан караганда, бу ул чакта тормышның ни дәрәҗәдә авыр булганлыгын, зур фәкыйрьлек хөкем сөргәнлеген, һәр сумның, һәр тиеннең нинди кадерле булганлыгын күрсәтә торган гыйбрәтле хәл.

Ул чорда кешеләрнең михнәтле гомер кичерүен искә төшергәндә, дәүләт җитәкчеләренең үз халкына шулчаклы миһербансыз булуын, аны шулкадәр җәфаларга дучар итүен уйлап таң каласың. Әйтеп киткәнемчә, колхозчыларны көне буена 500-600 грамм, күп дигәндә 1 килограмм ашлык өчен эшләтеп, бер тиен акча алмыйча, бер-ике бөртек мал-туарыннан әллә- никадәр итен, сөтен, маен, йонын налог исәбенә дәүләткә бушлай бирдертеп, үзләренә ашарга калдырмыйча, шуның өстенә, кышкы салкыннарда өйләрен җылытырга урманнан утын кистертмичә, малларын асрарга печән җыйдыртмыйча, мыскыллап яшәттеләр бит. Боларны мин ул хәлләрнең шаһиты булып һәм, яшүсмер генә булсам да, күпмедер дәрәҗәдә үзем дә ул җәфаларны чигеп яшәдем.

Безнең Кышкар авылы фәкыйрь табигатьле җирдә урнашкан. Урман-болыннары да, зур суы да юк. Авыл тирәсендәге өч коры елганың берсендә колхоз көтүе, икенчесендә хуҗалык (колхозчылар) көтүе йөри, ә өченчесендә колхоз малына чабу өчен печән үстерәләр. Кешеләрнең үз малларына печән әзерләү урыны бөтенләй юк. Халык үзен ачка үлүдән саклап тора торган бер сыерын һәм бер-ике сарыгын кышын асрап чыгарга терлек азыгы әзерләү мөмкинлегеннән мәхрүм. Без, ягъни Әнәс энем белән мин, чалгы салган кул арбасын тартып, бөтен басуларны айкап, межаларда, иген кырыйларында, тегендә-монда посып калган печәнне,

тупас, каты үләннәрне дә чабып алып кайтып, малларыбыз өчен кышка әзерләдек.

Безнең ул елларда ничек яшәгәнлебезне, нинди шартларда гомер иткәнлегебезне хәзерге яшьләр күз алдына да китерә алмастыр. Шул чактагы тагын бер-ике күренеш.

Кечкенә генә өебез. Без җиде кеше. Түрдә тупас кына итеп ясалган агач кровать. Анда әти белән әни йоклый. Без, малайлар, кечкенә чакта почмак як дип йөртелә торган, бик кечкенә генә ашарга әзерләү бүлмәсендәге сәкедә йокладык. Үсә төшеп, аяклар сәкедән асылынып тора башлагач, идәндә йоклый башладык. Астыбызда каткан киез, өстебездә әллә ничә еллык каты юрган. Кыш көннәрендә өй салкын була. Ягарга аз, мич кирәгенчә җылынып җитми. Иртән тәрәзәләр бозланып каткан була.

Кышларын ярым караңгы өйдә яшәдек. Тәрәзәләр кечкенә, кышын, салкыннан саклану өчен, аларга тышкы яктан яртылаш такта кагып, тәрәзә пыяласы белән такта арасына арыш кибәге тутырып куела. Тәрәзәнең яктылык төшә торган өлеше бик кечкенә генә кала.

Кичләрен яндырган лампа да җиделе генә. Филтәсе унлы булса, яктырак булыр иде, әмма анысына керосин күп китә. Ә ул кыйммәт. Ничек итеп дәресләр әзерләп укыганбыздыр.

Апрель җиткәч, тәрәзәгә каккан такталар алына. Өй яктырып китә, язгы кояш төшә башлый. Бу без малайлар өчен зур шатлык.

Икенче шатлык кара каргалар очып килгәч була. Аларны беренче тапкыр күргәч, карга ятып ауныйбыз. Йоласы шундый.

Өченче шатлык сыерчыклар килгәч. Аларны беренче тапкыр күргәч, шатлыктан шулай ук карга ятып ауныйбыз.

Яз, аннары җәй килү гомумән безнең караңгы тормышыбызны бераз гына булса да бизәп җибәрә, күңелләребездә тормыш яхшыруга өмет уята иде. Җир кардан ачылып, үлән чыккач, безнең үтә бертөрле, кысыр ашларыбызга өстәмә ризык булып, ашарга яраклы төрле үсемлекләр дә пәйда була.

Малларга печән әзерләү кыйссасыннан. Ерак басулардан иңләп-буйлап, бөртекләп дигәндәй җыйган печәнебезне колхоз председателе яки бригадир тартып алып калмасын дип (андый хәлләр дә була торган иде), арткы, әйләнгеч урамнардан, тыкрыкларга кереп, качып-посып алып кайта идек. Әниебез уҗымнан утап җыйган чүп үләнен (ул елларда игеннәрдәге чүп үләннәрен утау эше бар иде) төргәкләп аркасына салып алып кайта торган иде.

Аны да, киптереп, печәнлеккә менгереп өеп куябыз. Кышкы озын кичләрен, бигрәк тә язга таба, әти белән әнинең, көтү чыкканчы печән җитмәсә, ни эшләрбез икән инде дип, еш кына борчылып сөйләшкәнен хәтерлим.

Мичкә ягарга утын әзерләү дә зур проблема булды. Сугыш вакытында салам, чи тал чыбыклары ягуыбыз турында язып киткән идем инде. Сугыштан соң әти утынны, Мари урманнарыннан юнәтеп, ат белән алып кайткалый иде. Рәсми рәвештә хакимият рөхсәте белән, утын әзерләү мөмкинлеге булмады. Дәүләт органнары, гражданнарының яшәү шартларын кайгыртасы урында һәр нәрсәне чикләү, тыю белән шөгыльләнгән. Халык ничек яши һәм яшәр икән дип уйлап караучы булмаган.

Дөнья каршылыклардан тора дигән философик төшенчә бар. Бу һәр нәрсәнең дә уңай ягы да, тискәре ягы да була дигән мәгънәне белдерә: уң як-сул як, көньяк-төньяк, җылы-салкын, яхшылык-начарлык, изгелек-яманлык, рәхәтлек-михнәтлек һ.б. шушы чиксез каршы якларның, сыйфат, үзенчәлек-ләрнең тартышуы, бер-берсенә тәэсире, кушылмасы тормышның бер уртача агымда баруына этәргеч ясый. Сугыш чорындагы һәм сугыштан соңгы зур авырлыкларның уңай ягын табу турында сөйләү дә мөмкин түгел кебек тоелса да, мин, үземнең озын гомерем тәҗрибәсенә таянып, бәлки, кемнәрдер өчен бик сәер тоелырлык фикер әйтергә батырчылык итәм. Бу фикер менә нәрсә турында.

Авырлыклар гомумән кешене кыенлыкларны җиңәргә күнектерә, чыныктыра һәм балаларны, яшьләрне хезмәт итәргә, эшләргә өйрәтә, аларда тырышлык, максатка омтылу сыйфатлары тәрбияли. Бу минем фикер генә түгел, әлбәттә, бәлки яшәүнең бер законы, аксиома. Уйлап карыйк: кырыс, кайчакта хәтта рәхимсез авырлык шартларында үскән авыл балалары, мөстәкыйль тормыш юлына баскач, гадәттә, авыр хезмәтсез, уңайлы шартларда тәрбияләнгән шәһәр балаларына һәм яшьләренә караганда, авырлыкларны тизрәк һәм азрак җәфалар чигеп җиңәләр, шулай ук еш кына зуррак уңышларга ирешәләр. Бу күренешнең физиологик һәм социологик нигезе бар. Менә шушы хәлне мин үзебезнең авыл кешеләре һәм үзебезнең гаилә мисалында да күрсәтә алам.

Хакыйкать шул: татарлар – тырыш, хезмәтчән халык. Минем туып-үскән җирем Кышкар кешеләре, шул исәптән Йосыф Абдуллаҗаны малайлары, ягъни без – биш малай да. Кырыс яшәү шартлары безне кечкенәдән үк авыр крестьян тормышында була

торган күп төрле эшләрдән, шактый авыр, четерекле, кара эшләрдән дә чирканмаска өйрәтте. Олы абыебыз Равил сугыш елларында, көче җитмәслек эш башкарып – ат белән сука сукалап, эчен төшерде, башка күп төрле авыр хезмәтләр дә башкарды. Кече абыебыз Наил дә уртак язмыштан читтә калмады, кечкенәдән үк төрле крестьян һөнәрләрен үзләштерде. Хәтта үгезме, сыермы җигеп (атлар җитми иде), йөк ташыды. Миннән бераз гына яшьрәк Әнәс энебез дә бик эшчән булды, әле хәзер дә, инде олы яшьтә булуына карамастан, күп төрле эшләргә маһир.

Мин үзем дә, авылда 14 яшемә кадәр генә яшәргә туры килсә дә, крестьян тормышының төрле шөгыльләрен татып карарга өлгердем. Минем авыл кешеләре хезмәтенә караган эшләремнең башка туганнарымныкыннан үзенчәлеге шунда: миңа, апа-сеңелләребез булмаганлыктан, уртанчы малай буларак, нигездә, хатын-кызлар башкара торган өй эшләрен күбрәк башкарырга туры килде. Ике абый күбесенчә тышкы хуҗалык эшләре белән мәшгуль булганлыктан, аннары югарырак классларда башка авыл мәктәпләренә йөреп укыганлыктан, өй эшләре минем өскә күбрәк төште. Аннары, Әнәс энем үсә төшкәч, кайбер эшләрне аның белән бергәләп эшли башладык. Ә ул чактагы крестьян хуҗалыгындагы эшләрне тавык та чүпләп бетерерлек түгел иде. Әнинең үзенә генә, колхоз эшенә дә йөреп, барлык өй эшләренә дә өлгерү һич кенә дә мөмкин түгел, әлбәттә. Кыскасы, мин үзем дә күндәмрәк малай булганмындыр, бәлки, миңа вак-төяк өй эшләрен 4-5 яшьтән үк бик күп башкарырга туры килде.

Җәй көннәрендә хәл бигрәк тә катлаулы булды. Әниебез иртән иртүк, колхоз эшенә киткәндә, мине уятып, көнлек задание биреп калдыра. Савыт-сабаларны юу, идән себерү, су буеннан ат кузгалагы алып кайтып, аның тузгып торган башын сыпырып төшереп, кибәк белән болгатып, каз-тавыкларга әчетке әзерләп бирү, бозауны инеш буена алып төшеп арканлап кую, аннары бакчада үсеп утырган бәрәңгенең төбен әкренләп кенә казып, өлгереп килгәннәрен генә аралап алып, төбен яңадан күмеп куеп (калган вагракларына үсәргә кирәк бит эле), бәрәңгене юып, әрчеп, казан астына ягып, пешереп, баздан катык-сөт алып чыгып, әти-әни кайтышка төшке аш табынын әзерләп кую...

Әниебез, ашык-пошык капкалап алып, тиз генә иң кирәкле керләрне юып ала да, эшкә китә. Мин аларны, инешкә алып төшеп чайкап алып кайтып, кибәргә элеп куям. Өйләдән соң тагын күп

эшләр кабатлана: ашка бәрәңге әзерләп кую, бозауны алып кайту, көтүне каршы алып, сыерны, сауганнан соң, авыл кырыендагы чирәмле җирләрдә ашатып кайту (маллар көтүдән туеп кайтмыйлар: җәй буе бер коры елгада йөри-йөри үләнне кимереп бетерәләр)...

Без авыл малайларының колхоз эшенә дә кирәгебез бар иде әле. Мин 14 яшемә кадәр авылда узган гомеремнең 4-5 елын колхоз эшләрендә дә катнашырга өлгердем. Баштагы бер-ике елда җиңел эшләр куштылар: атка атланып, саман кирпече измәсен әзерләү эшендә катнаштым. Су буендагы берникадәр җирне, түгәрәкләп алып, көрәк белән йомшартып чыгалар да, ваклаган салам салып, өстенә су сибеп, шуны ат белән таптатып издерәләр. Мин, атка атланган килеш, аны түгәрәк буенча йөртәм. Измә әзер булгач, аны, махсус ясалган такта формаларга салып, кояшта кибәргә куялар. Кипкәч, ул саман кирпеч дип аталган төзелеш материалы була. Аннан колхоз фермаларының стеналарын өяләр. Озакка чыдамый, әлбәттә. Өч-дүрт елга түзгәндер: әкренләп яңгырдан җимерелә. Ләкин кыйммәтле төзелеш материаллары алырга колхозның акчасы юк.

Аннары тагын бер кечкенә малайлар башкара торган җиңел эш: пираватта (*привод* сүзеннән) ат куып йөрү. Бу гамәл шуннан гыйбарәт.

Урак өсте вакытында игенне элегрәк хатын-кызлар урак белән урып, соңрак ат тартып йөртә торган ургыч (лабогрейка дип атала иде кебек) белән урдырталар да, урылган игенне көлтәләргә бәйләп (аны *учма бәйләү* дип атыйлар иде), көлтәләрне кибәннәргә өеп куялар. Аннары, көлтәләрне, ат арбаларына төяп, авыл читендәге әвенгә кайтарып бушаталар. Әвендә атлар тартып әйләндерә торган суктыргыч машина белән ашлыкны суктыралар. Әвен эчендә урнаштырып механик суктыргычтан тышта көйләп куелган приводка җәпләр булып беркетелгән дүрт озын юан колганың һәрберсенә берәр ат җигелеп, алар, түгәрәк буенча йөреп, приводны әйләндерә, привод механик суктыргычны эшләтә. Шул рәвешле көлтәдәге башакларның орлыгы суктыргыч астына җыелып бара, саламы аерылып чыга. Шул атларны түгәрәк буенча малайлар куып йөртә. Бер җәйне миңа да эләкте шул шөгыль.

Урак уру турында сүз чыккач, ул чактагы хатын-кызларның искиткеч авыр эшләре күренешен әйтеп китим. Мин кечкенә чагымда урак уру эшендәге әниебез, бала арбасын тартып (арбада Мөнир бәби иде), ерак басуга барганда, мине дә үзе белән алды.

Җәйге челләдә бала имезә торган ана көне буе урак белән ашлык ура, көлтә бәйли (болар бик авыр эш). Ул чакта аларның ашау-эчүләре нәрсә генә бит әле: ит-майлы ризык булса икән, кая инде ул андый ризыклар. Кайбер хатын-кызлар әле тагын шунда ураза да тоталар иде. Менә нинди икеләтә изү – дәүләт һәм дин изүе булды татар хатын-кызларын. Алар үзләре ничек түзгәндер дә, балалары ничек чыдагандыр!

Үсә төшкәч, мин җәйләрен колхозның җитдирәк эшләрендә катнаштым. Әвендә суктыргычтан чыккан салам өемнәрен атның камытына эләктергән озын аркан белән әйләндереп алып, әвеннән читтәрәк өелә торган эскертләргә ташу, кырдан әвенгә ашлык көлтәләрен алып кайту, ат көтүе көтү (берникадәр вакыт төнге ат көтүенә дә йөрдем) һәм башка төрле эшләр. Әнәс энем дә кечкенәдән колхоз эшенә катнашты. Иртән иртүк бригадир Хафиз абый безнең өйгә керә иде дә: “Рүзәл, сиңа Пионер (ат кушаматы) белән көлтә ташырга, Әнәс сиңа Миша (шулай ук ат кушаматы) белән эскерткә салам ташырга”, – дип эшкә наряд биреп чыгып китә тоган иде.

Колхоз эшенә, атлы эшкә без теләп йөрдек. Малайлар ат ярата бит. Аннан килеп, колхоз эше безне вак өй эшләреннән коткарып тора иде.

Менә шулай безгә бала чагыбызда уен уйнаулар белән шөгыльләнү бик аз эләкте. Эшкә пешеп үстек. Чыныгу яхшы булды. Хәтта артыгы белән. Шул рәвешле минем өй эшләре белән, җәйләрен шуңа колхоз эшләрен дә өстәп, балачагым узып та китте. Яшүсмер чорым башланды: мин, ундүрт яшем туларак, Кышкар мәктәбенең 7 классын тәмамлап, Казан кооперация техникумы укучысы булдым. Техникум чорын тасвирлый башлаганчы, үзебезнең авыл мәктәбендә укуым турында да бераз сөйләп китим әле.

Безнең әти-әниләр үзебезнең авыздан өзеп алырга мәҗбүр булып (кием-салым, керосин, тоз һәм башка иң кирәк әйберләрне алырга бер тиен дә акча юк бит), налог түләгәннән калган ит-май, йон кебек нәрсәләрне сатарга кайбер ял көннәрендә Әтнә базарына барып кайталар. Юл безнең әни туып-үскән, әби-бабабыз яши торган Иске Мәңгәр авылы аша уза. Без, малайлар, әби-бабабызны яратабыз, аларга кунакка барасыбыз килеп тора, әмма андый рәхәтлек сирәк эләгә. Хәер, алар үзләре дә безне, балаларны, чит итмиләр иде. Шулай кышкы бер ял көнне, мин бик ялынгач, без Әтнәгә барып кайтканчы гына торып торырсың, базардан кайтыш-

лый алып китәрбез дигән шарт белән, мине Иске Мәңгәргә кадәр алып барып, әби-бабайларда калдырып киттеләр.

Минем өйгә һич кенә кайтасым килми бит: анда мине эшләтәләр, монда әби тәмлерәк тә ашата, эшләтми дә. Мин кадерле кунак, янәсе. Әти-әниләрдән калу хәйләсенә керештем. Кичкә таба, әти-әниләр базардан кайтып җитәр вакытны чамалап, авыл эчендәге бер калкулыклы урында Өмәкәй тавы дип йөртелә торган җиргә чана шуарга киттем. Баш бераз эшләгән инде: әти-әниләр мине көтеп тормаслар, кайтып китәрләр дип уйлап, чананы озаклап шудым. План барып чыкты: мин кайтканда әти-әниләр киткән иде инде. Ура! Мин киләсе якшәмбегә, базар көненә кадәр әбиләрдә булам. Икенче якшәмбе җиткәч, шул хәйләне тагын кабатладым һәм тагын бер атнага калдым. Шулай итеп, икеме-өчме атна әби-бабайларда кунак булып яттым.

Ниһаять, мине алып киттеләр. Бу чакта инде укучыларның кышкы каникулы узып, уку елының икенче яртысы башланган иде. Мин әле укучы түгел, минем яшьтәгеләрнең берсе дә укымый. Ничектер минем мәктәпкә йөрисем килә башлады. Әти-әниләрне укыйсым килә дип бик алҗыткач (үҗәтлегем шул вакытта ук булган), әти бу хакта мәктәп мөдире белән сөйләшкән. Мөдир Әхәт абый: "Йөреп торсын, бераздан дәрте басылыр, киләсе елда укырга җиңел булыр", – дигән. Мин инде ул чакта укый-яза һәм саный белә идем. Наил абый, фанердан сумка ясап, аны кызылга буяп бирде. Менә бер көнне иртән, шул сумканы күтәреп, мәктәпкә киттем. Дәрес башланмаган иде әле. Беренче класс укучыларының кайсы бүлмәдә утырганлыгын сорап белдем дә, ишекне ачып кереп, беркемгә бер сүз дәшмичә, иң арттагы партага барып утырдым. Укучы балалар, бик гаҗәпләнеп, карап торалар. Бераздан укытучы Кәүсәрия апа керде. Ул минем киләсемне белгәндер инде, әлбәттә. Укучыларга бу уңайдан ниләр әйткәндер, беренче дәрес ничек башланып киткәндер дә, беренче сәгатьләрдә, беренче көннәрдә үземне ничек хис иткәнмендер, аяныч, болар исемдә калмаган.

Ләкин шунысын ачык хәтерлим: мәктәпкә ярты ел үткәч йөри башласам да, җәфаланып укымадым, беренче классны шул ук елны "бишле" билгеләренә тәмамлап чыктым һәм мәктәпне гомумән "бишле"гә тәмамладым. Мәктәп елларыннан кайбер күңелле истәлекләр.

Һәр елны 1 январь бәйрәме чыршысын клубта куялар иде. Аны кәгазьдән ясалган нәрсәләр белән бизәүдә без, мәктәп укучылары

да, катнаша идек. Бәйрәм көнендә, гадәттәгечә, балалар чыршы тирәсендә җырлыйлар, бииләр. Тамашага ата-аналарны да чакыралар. Мәктәп директоры ярты еллык уку нәтиҗәләренә йомгак ясый һәм алдынгы укучыларга китап-дәфтәр кебек нәрсәләр бүләк итә. Мине иң яхшы укучы буларак телгә ала торганнар иде.

Безнең класс укучыларына математика предметлары авыр бирелде. Математиканы, катлаулы фән буларак, кайбер кешеләр гомумән авыр үзләштерә. Шуның өстенә, укытучыбыз Шамил абыйның, бәлки, укыту тәҗрибәсе дә җитеп бетмәгәндер, чөнки ул меховой техникум тәмамлап эшли иде. Ләкин ул, тырышып, укучыларны белемле итим дип, намус белән эшләде. Ул чорда гомумән барлык укытучылар да, күңел биреп, үзләрен аямыйча эшләделәр. Дәрестә кат-кат аңлаталар, балалар кайсыдыр теманы дәрестә үзләштерә алмаса яки өйгә эшләрен эшли алмый килсәләр, алар өчен өстәмә дәресләр үткәрәләр. Хәзерге кебек репетиторлар яллап укыту дигән нәрсә юк иде.

Безнең Шамил абый фидакарь укытучы иде. Шундый хәлләр булгалады. Укытучы, геометриянең кайсыдыр темасыннан өйгә эшнең үтәлешеннән канәгать булмыйча, бөтен классны дәресләрдән соң калдырып, теманы яңадан аңлата, өйгә бирелгән биремне бергә эшлиләр. Мине берүземне генә дәрестән соң калдырмыйча кайтарып җибәрә иде.

7 нче классны тәмамлагач, без алгебрадан язма эш рәвешендә имтихан тапшырдык. Эш тәмамлангач, Шамил абый, контроль эшләрне җыеп алып, укучыларны кайтарып җибәрде, ә мине алып калды. Укучыларның контроль эшләрен бергәләп тикшердек. Бу минем математикадан белемемә зур бәя бирү иде. Шуңа күрә ул, минем, армиядән кайтып, Казан университетының филология бүлегенә укырга кергәнлегемне белгәч, “Син математик булырга тиеш идең бит”, – дип, ачуланды.

Ул еллардагы халыкның, шул исәптән мәктәп балаларының да, әлбәттә, ни дәрәҗәдә авыр яшәвен күрсәтә торган бер генә күренешне искә төшерми кала алмыйм. 5нче – 7 нче классларда 5 әр – 6 шар сәгать укый идек. Барыбызның да ашавы – аз калорияле ризык, ит-майлы түгел. Соңгы сәгатьләрдә эчне суырып карын ача. Кайбер малайлар сумкаларына салып алып килгән мичтә тәгәрәтеп пешергән бер-ике кабыклы бәрәңге белән тамак ялгап алалар иде. Мин нишләптер болай эшләмәдем. Ул елларда гомумән

күп вакытта ашыйсым килеп йөри торган идем. Ә хәзерге балалар нинди шартларда укыйлар! Җир белән күк аермасы.

Безнең Кышкар мәктәбенең 5-7 нче классларында күрше Симетбаш авылы балалары да йөреп укыды. Кышкы салкын, көчле буранлы көннәрдә кар күмеп киткән юлларда өч километр араны мәктәп балалары һәр көнне ничек барып-кайтып йөргәннәрдер. Котырган буранлы, 30-40 градуслы көннәрне дә хәзерге кебек мәктәпкә бармый калу тәртибе юк иде. Аеруча начар көннәрдә без, Кышкар укучыларының һәркайсы, Симетбаш малай-кызларының берәрсен үзебезгә кунарга алып кайта торган идек. Мин дә шундыйлар исәбендә идем, әлбәттә.

Безнең Равил белән Наил абыйларыбызның да уку шартлары аяныч иде. Алар 8-10 классларда безнең авылдан 15 чакрым ераклыктагы Кызыл юл районы үзәге Кенәр мәктәбендә интернатта яшәп укыдылар. Шимбә көнне дәресләрдән соң, җәяү өйгә кайтып, дүшәмбе көнне, дәресләр башланганчы барып җитү өчен, иртәнге сәгать 4ләрдә, аркаларына котомка асып, китеп баралар иде. Кыш көннәрендә, алар өйдән чыгып киткәндә, миңа, уянып китеп, тышта дулаган буран тавышын ишетеп яту да шомлы-шөбһәле, хәтта куркыныч булып тоела иде, ничек итеп барып җитәрләр икән болар дип, үземчә, борчылып кала идем.

## МӨСТӘКЫЙЛЬ ЯШИ БАШЛАУ

Ниһаять, 7 нче классны тәмамлаганлык таныклыгы кулымда. Минем алда өч төрле юл: яки, 15 километрдагы Кенәргә йөреп, 8-10 классларда укырга, яки, Казандагы һөнәр училищеларының берәрсендә укып, квалификацияле эшче булырга, яки берәр техникумда укырга. Безнең авыл малайлары, гадәттә, һөнәр училищесында укыйлар. Анда шартлар әйбәт: киендерәләр, ашаталар һәм тулай торакта яшәтәләр. Ләкин минем теләк икенче төрле – техникумда укып, махсус урта белемле белгеч булу.

Техникумнарда укырга керү дә, уку да авыр, яшәү шартлары да кыен. Кабул итү имтиханнары биреп керәләр, конкурс була. Ләкин мәктәпне “бишле”гә тәмамлаганнар имтиханнарсыз гына кабул ителә. Мин бу шартка туры киләм. Һәм мин ул чакта абруйлырак урта уку йортлары саналган авиация яки технология техникумына керергә исәп тота идем. Әмма бер тоткарлык килеп чыкты. Минем мәктәп таныклыгымда бер сүзне, ялгыш бозып, төзәтеп куйганнар. Шуңа күрә мәктәпне “бишле”гә тәмамлаганлыкны раслау өчен, Мактау грамотасы кирәк булды. Бу документны тутырып бирә торган мәктәп секретаре, отпуск алып, авылдан каядыр киткән булып чыкты. Ул, кайтып, минем грамотаны язып биргәнче, 1 нче август җитеп, техникумнарга гаризалар кабул итү вакыты узып киткән. Мин бу хәлне, ягъни барлык техникумнарда да документлар кабул итү вакыты узганлыгын белми идем һәм, тәвәккәлләп, Казанга барырга булдым. Миңа ул вакытта әле 14 яшь тә тулмаган иде әле.

Озата баручы булмады: авылда кызу урак өсте. Мин, тузган арзанлы пиджагымның кесәсенә таныклыгымны бөкләп тыгып, юлга чыктым. Казанга безнең авылдан Арча аша йөриләр. Арчага нәрсә туры килсә, шуңа утырып яки җәяү барасың. 30 чакрым. Безнең күрше Симетбаш авылы яныннан Мари урманнарыннан Арча станциясенә агач ташучы машиналар узып китә. Шуларның берәрсен, кул күтәреп туктатып, утыртсалар, шуның белән барасың. Мин өч бик юан бүрәнә салган прицеплы машинага утырып кит-

тем. Кабинасында бер пассажир бар иде инде, шунлыктан миңа урын машина өстендәге кабина белән бүрәнәләр арасында калган буш арада булды. Куыш ике кырыйдагы бүрәнәләр арасында бик кечкенә, уртадагы бүрәнә белән кабина арасында зуррак, иркенрәк. Шофер кая, ничек утырырга, дөресрәге, басып барырга, кирәклеген аңлатып тормады. Мин, үзем чамалап, уртадагы бүрәнә башына бастым. Юл начар, чокыр-чакырлы. Көпчәкләр чокырга эләккәндә, ике кырыйдагы бүрәнәләр, кабина тактасына зур көч белән килеп төрәлеп, тактада тирән эз калдыралар. Мин, абайламыйча, кырыйгарак килеп баскан булсам, бу юлларны язучы кеше булмаган булыр иде.

Арча поезды белән Казанга килеп төшкәч, барасы адресымны табу истәлекле булды.

Әти-әниләрем әйтеп җибәргән барып керәсе адресым: Колхоз базары урамы, түгәрәк баганалы капкалы йорт, Зөләйха апа. Бу апа безнең әти-әниләрнең Казанга эш белән барганда кереп кич кунып чыга торган танышлары икән. Үзләре барып керә беләләр, ләкин адресын хәтерләмиләр. Шунлыктан мине шул рәвешле өйрәтеп җибәрделәр. Шактый озак эзләдем мин ул йортны: түгәрәк баганалы капкалы йортлар берничә булып чыкты. Ниһаять, кич җитеп килгәндә, Нариман урамыннан поезд юлына таба баргандагы йортның капка төбендә бер хатын белән сөйләшеп торган чакта очраттым мин Зөләйха апаны. Көләч йөзле күркәм ханымга: “Зөләйха апа Сез түгелме?” – дип эндәштем. Ул: “Мин булам, ә син кем?” – ди, елмаеп. Мин кем икәнлегемне, ни өчен килгәнлегемне аңлатып бирдем. Ул мине уртача зурлыктагы агач өйләренә алып керде. Ике баласы: кызы һәм улы, берничә квартиранты бар. Районнардан базарга килгән кешеләрдән кунып чыгучылар да була икән. Ыгы-зыгылы йорт икәнлеге күренеп тора. Минем кереп сыенырлык башка урыным булмаганлыктан, хуҗа ханым тәкъдиме белән шунда торып калдым.

Шәһәр буйлап, сораштырып, эзләп йөри торгач, Казан кооперация техникумын таптым. Ул, сугышка кадәр эшләп, сугыш елларында ябылып торган да, шушы елны яңа гына ачылган икән. Эшли генә башлаганлыктан, аны кешеләр аз беләләр әле, шуңа күрә абитуриентлардан гаризаларны озаграк алырга булганнар. Башка техникумнарга ул елны инде гаризалар кабул итү тәмамланган иде. Минем сайланырга мөмкинлегем юк: шушы кооперация техникумына керергә булдым. Кооперация сүзенең нәрсә икәнлеген белмәсәм дә, техникум булгач, нинди булса да ярар инде дип, до-

кументларымны, гаризамны шушында бирергә булдым. Бу авыл сәүдәсе өчен белгечләр әзерли торган техникумда товар белгечләре (товароведлар), бухгалтерлар һәм плановиклар әзерләргә җыеналар иде. Мин товароведлар бүлеген сайлап алдым.

Техникумда уку минем тормышымдагы беренче җитди сынау булды. Беренчедән, уку шартлары, икенчедән, яшәү шартлары буенча.

Мин саф татар авылындагы 7 еллык мәктәпне тәмамлап килгән малай. Рус телен өйрәтү ул чакта бик йомшак иде. Техникумда беренче көннән үк русча укый башладык. Уку планы һәм режимы бик кырыс: башка барлык техникумнардан аермалы буларак, бу техникум өч кенә еллык. Шушы 3 елда 8-10 нчы классларда укый торган гомуми урта белем предметларын үзләштерергә, товаровед белгечлегенә караган дисциплиналарны өйрәнергә, һәр елны, югары уку йортындагы кебек, кышкы һәм җәйге имтихан сессияләрен узарга һәм икенче, өченче курсларның азагында ай ярымшар ике производство практикасын үтәргә кирәк. Һәр көнне 8әр дәрес. Шуның өстенә, минем кебек татар авылы мәктәбеннән килгән дүрт малай өчен атнасына икешәр тапкыр рус теленнән өстәмә дәрес. Рус телен начар белү аркасында беренче елны уку аеруча авыр булды. Тамара Лазаревна Чудновская, безгә рус телен өйрәтү өчен, аеруча тырышты. Кызыклы һәм аяныч күренешләр дә була торган иде баштагы чорда. Бервакыт, такта янына чыгарып, нәрсәләрдер сорады, сөйләтергә тырышты. Мин, күрәсең, ык-мык! Бу миңа: “Почему не знаешь, Юсупов?” – ди. Мин аңа: “Сам удивился”, – дип җавап бирәм. Группа рәхәтләнеп көлә. Миңа гына көлке түгел. Тамара Лазаревна беренче елның беренче семестры тәмамлангач, рус теленнән имтиханда миңа “өчле” билгесе куеп, мине бер семестр буена стипендия алудан мәхрүм итте. Техникумның тәртибе бик кырыс: сессиядә бер генә имтиханнан “өчле” билгесе алсаң да, семестр буена стипендия алмыйсың. Бик ачу чыкты, билгеле. Мине 7 класслы татар мәктәбеннән килгәнлегемне белеп, льгота биреп, аванс белән “дүртле” куйган булса да ярар иде бит. Минем бөтен яшәү чыганагым стипендия иде югыйсә. Юк, булмады. Ярый инде, әтигә рәхмәт: ул ярты елны ачтан үлмәслек итеп кенә булса да ярдәм итеп торды. Ул чакта авылда да хәлләр бик авыр иде. Шулай да минем Тамара Лазаревнага үпкәм онытылды. Чөнки ул өч ел буена рус теленнән ныклы белем бирде. Һәм мин уку мәсьәләсендәге сынауны уңышлы уздым: шуннан соң бер генә предметтан да беркайчан да өчле алмадым, бер тапкыр да стипендиясез дә калма-

дым. Дәүләт (чыгарылыш) имтиханында дүрт предметның өчесен “бишле”гә, берсен генә “дүртле”гә тапшырдым.

Яшәү шартларына килгәндә, әлбәттә, хәл шатланырлык түгел иде. Ничек яхшы булсын, мин техникумда укый башлаганда, коточкыч сугыштан котылып, 7 генә ел узган иде бит әле. Һәркайда – авылда да, шәһәрдә дә – бихисап җитешмәүчелек: ашау-эчүгә дә, кием-салымга да зур кытлык. Казанда торак мәсьәләсе дә бик авыр иде: күп кешеләр подвалларда яшәде, бер бүлмәдә әллә ничәшәр кеше торды.

Мин беренче елны яшәгән Колхоз базары урамындагы Зөләйха апаларның уртача зурлыктагы агач йортларында хуҗабикәнең үзе белән ике баласы – мәктәп яшендәге кызы һәм улы, авылдан килеп, аларда яшәп торучы өч җиткән кыз (мех фабрикасында эшлиләр иде), кыш көне, Дөбьяздан килеп, ат белән эшләүче ике ир кеше, Әзәрбайҗаннан килеп, алма сатучы бер кеше һәм мин яшәдек. Шуның өстенә, тагын кайбер көннәрне  Казан базарында азыктөлек сатарга килгән бер-ике кеше кунып кала иде.

Мин беренче елны икенче сменада укыдым, кичен укудан кайтып кергәндә, идәндә алма төшәрлек тә урын калмый торган иде: тезелешеп йоклыйлар. Ничек яшәгәнмендер, ничек итеп дәрес әзерләгәнмендер. Хәзер исемә төшкәндә гаҗәпләнәм. Крестьян баласы әрсез була, түзгәнмен.

Зөләйха апаның үз өендә шулчаклы кешеләр тотуын аңларга була. Аның бөтен кереме шулардан иде. Берүзе тәрбиясендә ике укучы баласы, ире һәм кызы Казаннан ерак түгел төрмәдә утыра, кимендә айга бер тапкыр (бәлки ешрак та булгандыр), аларга хәленнән килгәнчә, азык-төлек илтә. Төрмәдә утыра дигәннән, алар әллә ни зур җинаять кылып эләккәнәр дип уйларга кирәкми. Ул чакта Казанның күп кешеләре төрмәдә иде. Мин өч елда өч квартирда тордым, икесендә берәр, берсендә исә (Зөләйха апаларныкында), әйткәнемчә, хәтта берьюлы ике кеше төрмәдә утыра иде. Тормыш искиткеч авыр: халык урлый, хәзерге кебек миллион, миллиард сумлап түгел, әлбәттә, вак-төякләп кенә. Ул чакта законнар бик каты иде: кешеләрне кечкенә генә гаеп өчен дә төрмәгә тыкканнар. Ул елларда немецларда әсирлектә булган өчен утырган кешеләр дә күп иде. Мин алдагы елда яшәгән квартирдан бер кеше әсирлектә булган өчен 25 еллык срок белән төрмәдә утыра иде.

Җинаятьләр турында сүз чыккач, ул вакыттагы шуңа бәйләнешле бер-ике хәл турында әйтеп китим әле. Мин, беренче курста укып, Колхоз базары урамында яшәгәндә, И.В.Сталин үлгәннән соң,

хөкем ителгән күп кешеләргә амнистия булды, һәм төрмәдә утырганнар, минем аңлавымча, күп кенә кечкенә һәм зур җинаятьчеләр иреккә чыкты. Шулар халыкның тынычлыгын җуйдылар, шактый күп җинаятьләр кылдылар, тәртип бозулар, урлау, кешеләрне талау, үтерү, гарипләү күренешләре күбәйде. Шундый берничә күренеш мин яшәгән йорт тирәләрендә дә булды. Безнең белән яшәгән өч кыз мех фабрикасына төнге сменага бик куркышып китәләр иде...

Җәй җитеп, мин икенче квартирга күчәргә йөргәндә (чөнки монда, әйткәнемчә, бик кысан, тынычсыз иде), Зөләйха апаның хәләл җефете Сәхап абыйны да иреккә чыгардылар. Аны Казанның тимер юл станциясендә зурлап каршы алдылар. Туган-тумачаларыннан, дус-ишләреннән шактый күп кешеләр, вокзалда Сәхап абыйны каршы алып, Нариман урамы буйлап Колхоз базарына кадәр җырлашып кайттылар. Музыка да булды, гармунчы вазыйфасын миңа башкарырга туры килде. Мин ул чакта бераз гармун уйный белә идем. Кайдандыр тальян табып биреп, уйнарга куштылар. Уйнап-җырлап кайтканны күреп, бер милиционер бәйләнеп маташкан иде, аның белән каты гына сөйләшеп, гражданнарның законлы хокукларын исенә төшереп, аны тиз генә озатып җибәрделәр. Мин шунда милиционерлардан да курыкмый торган кыю кешеләр барлыгын беренче тапкыр күрдем.

Зөләйха апаны рәхмәт хисләре белән искә алам. Дөнья күрмәгән авыл малае берүзем зур шәһәргә килеп, мөстәкыйль яши башлавымның иң авыр вакытында үзенә сыендырды. Кыерсытмады, авыр сүз әйтмәде. Әмма моннан ары анда калып булмый инде: әйтеп киткәнемчә, яшәү өчен дә, дәресләргә әзерләнү өчен дә шартлар бик кыен иде. Шунлыктан мин икенче курстан икенче квартирга күчтем.

Икенче елдан яши башлаган квартирым Каюм Насыйри урамының Татарстан урамы чатындарак кына урнашкан ике катлы агач йортта иде. Элекке берәр байның үз йорты булгандыр, мөгаен. Бу йорт Казанның Иске бистә дип йөртелә торган урынында, нигездә, татарлар гына яшәгән өлешендә урнашкан. Монда яшәү минем өчен, элекке квартирдагыга караганда, уңайлырак та, күңеллерәк тә булды.

Бу йортта берничә гаилә яши. Мин урнашкан квартир ике бик кечкенә генә бүлмәдән һәм бер шактый иркен залдан гыйбарәт. Шундагы минем яшьләр чамасындагы ике улы, мәктәпкәчә яшьтәге бер кызы һәм иренең әнисе белән квартир хуҗасы Нажия ападан торган гаиләгә мин дә өстәлдем. Ул чакта чит кешеләрне

квартирда мохтаҗлыктан тоталар иде: аз булса да гаилә бюджетына өстәлә бит. Уйлап карасаң, ул вакытларда халыкның ничек авыр көн күргәнлегенә тагын бер инанасың. Бу мин торган Наҗия апалар мисалында да ачык күренә.

Наҗия апа – урта яшьләрдәге чибәр, күркәм ханым. Йөзендә ниндидер бер хәсрәт, сагыш чагыла. Казанда туып үскән. Сөйләме саф татарча. Әдәпле, зыялы, тыйнак. Йөзендә хәсрәт чагылу юкка гына түгел: ире төрмәдә утыра. Ни өчен икәнен белмәдем. Сорарга кыймадым. Гаилә әгъзаларына караганда, зур җинаять түгелдер. Барысы да тәрбияле кешеләр.

Наҗия апа Соцгородтагы китап кибетендә эшли. Аның карамагында, әйткәнемчә, өч бала: мәктәпнең югары классларында укучы җиткән уллары, кечкенә кызы. Иренең карт әнисе. Һәрвакыт үзенең бер читлек кадәр генә бүлмәсендә ята, аннан чыкканын да күреп булмый иде. Авыру булгандыр, ахрысы. Пенсия алгандырмы, юкмы. Китап кибетендә эшләгән бер кешенең хезмәт хакына ничек яшәгәннәрдер алар. Ит-май ризыклары, итле аш ашаганнарын күрмәдем мин аларның, күбрәк, минем кебек, ипигә, булкига маргарин ягып, песок белән чәй эчәләр иде...

Шулай да берсенең дә сыкранып зарланганнарын күрмәдем һәм ишетмәдем. Хәер, миңа – чит малай кешегә нишләп хисләрен белдереп торсыннар инде. Әмма Наҗия апа соңгы вакытларда берничә мәртәбә ире Заманның тиздән кайтачагын шатланып сөйләгән иде һәм ул чыннан да әйләнеп кайтты. Ул кайткач, инде мин кысанлык тудырырмын дип уңайсызланып, икенче квартирга күчтем. Наҗия апаның җибәрәсе килмәгән иде. Мин аларның уллары белән бериш булып, дус булып яшәдем.

Гомумән, Казанның үзәгендәге татарлар бистәсендә яшәү миңа үзебезнең халыкка хөрмәт белән карарга этәргеч бирде, ахрысы. Анда ниндидер бер күңелгә якын мохит хөкем сөрә иде. Матди яктан авыр заманнар булса да,  ул чакта халыкта милли рух көчлерәк булды. Шәһәрдә берничә алдынгы саф татар мәктәбе бар иде. Наҗия апаның икенче улы Шамил Кабан күле буендагы күренекле 12 нче мәктәптә укыды (хәзер ул еврей мәктәбе). Күрше квартирдагы кызлар шулай ук мәртәбәле 80 нче татар мәктәбендә белем алдылар. Ул тирәдәге барлык кешеләр дә диярлек саф татар телендә сөйләшәләр һәм милли мәдәниятне олылап, татарча гореф-гадәтләрне, матур традицияләрне саклап яшиләр иде. Миңа күп еллардан соң яңадан шул тирәдә, Татар бистәсендә яшәргә насыйп булды, хәзер дә шул урыннардан еш узам һәм күз алдыннан шул

елларда шаулап торган саф татарча яшәү рәвешен сагынып искә алам. Хәзер кайберәүләр урынлы-урынсыз яманлап торган Сталин заманында татар теле һәм мәдәнияте үсеше өчен мөмкинлекләр хәзергегә караганда күбрәк, мәктәптә татар телен атнасына ике сәгать кенә укытырга дигән хурлыклы закон юк иде.

Гомумән ул елларда коточкыч сугыш җимерекләреннән арыну, промышленностьны, авыл хуҗалыгын моңарчы тиңе булмаган темплар белән алга җибәргән, икътисадый хәл бик авыр чорда да дәүләт балаларны укыту һәм тәрбияләү белән җитди шөгыльләнә иде. Төрле сәнгать мәктәпләре, түгәрәкләре, спорт секцияләре барлык укучы яшьләр өчен түләүсез эшләде, спорт формалары һәм инвентаре бушлай бирелде. Бу хәлләрне үзем күреп тордым һәм, техникум укучысы буларак, шундый мөмкинлекләрдән үзем дә файдаландым. Тормыш авыр булса да, халыкның күңеле күтәренке, кәефе әйбәт иде, кешеләр киләчәккә өмет белән карады.

Мәктәп һәм урта, югары уку йортларында укучыларга уңай шартлар тудырыла иде. Мәсәлән, транспортта йөрү өчен махсус арзанлы билетлар, уку йортлары ашханәләрендә ашамлыкларның бәяләрен түбәнрәк итеп кую, икмәкне бушлай бирү һәм башка льготалар бар иде. Шуңа күрә, башка күп укучылар кебек, мин дә, билне кысып булса да, бары бер стипендиягә яшәдем. Авылдан, өйдән бернинди дә ярдәм булмады: үз хәлләре мөшкел иде.

Өченче курста укыганда минем торак мәсьәләсе шәптән булмады. Островский урамының элекке Республика ДАИ (ГАИ) янындагы бер йортның ярым подвалындагы квартирда торырга мәҗбүр булдым. Форточкасыз, ике катлы ишекле (берсен ачканда икенчесе ябык була: тыштан һава керә алмый), квартирда һава даими рәвештә бик бөркү, тынчу булды. Кышын аяктан нык салкын тидереп, бронхларны зарарлаганмын, беравык төннәр буе йоклап китә алмыйча, йөткереп ята идем.

Шул начар гына кечкенә торакта да урын өстеннән төшми ятып торган хуҗа хатын (ире әсирлектә булганы өчен 25 еллык төрмәдә), аның мәктәптә укучы буй җиткән ике улы, иренең олы яшьтәге әти-әнисе һәм авылдан килеп кайсыдыр заводта эшләүче ике кыз яшәп ята иде, шулар янына мин дә өстәлдем. Кыен булды, бик кыен. Артыгын сөйләп тормыйм, болай да күп зарландым. Ул елларда Казан кешеләренең күбесенең шундый авыр шартларда яшәгәнлеген әйтергә теләвем бу.

Техникумда укыган бу өч елда мин инде бераз үсеп киттем, мөстәкыйль яшәргә, кыенлыкларны җиңәргә өйрәндем. Казанның

тәртипсез малайларына (үзләре юкка гына бәйләнгәндә) каршы торырга, кирәк чакта, курыкмыйча бәргәләшергә дә кирәклеген аңладым, һәм бу мәсьәләдә үземә дә һөҗүмнәргә җавап биргәләргә туры килде. Яшь егеткә әвереләдем дияргә буладыр. Кызларның матурлыгын күрә башладым. Тукай урамындагы Спартак стадионында, Горький урамындагы Динамо стадионында һәм Черек күлдә катоклар эшли иде. Каюм Насыйри урамындагы йортта яшәгәндә, квартир хуҗасының уллары һәм күрше малайлары белән шул катокларга баргалый идек. Билет алмыйча, койма аркылы сикереп керәбез (стипендия акчасын нәрсәгә генә җиткерәсең). Милиционер күреп алса, тотып, артка тибеп чыгарып җибәрә, без икенче яктан тагын сикереп керәбез. Малайлык шаярулары да, акча җитмәү бәлаләре дә дияргә була. Мондый "шаянлыклар" фаҗига белән тәмамланып кала язган хәлләр дә булды. Трамвайда да күбесенчә билет алмыйча йөри идем. Трамвайларның ишекләре үзең ачып яба торган. Билет тикшерергә алдагы ишектән контролер килеп керсә, аңа тоттырмас өчен (тотса милициягә алып китәргә мөмкин), трамвай барган көйгә арттагы ишектән сикереп төшеп каласың. Бер тапкыр кыш көнендә, шулай сикереп төшеп, трамвай астына эләгә яздым: трамвай юлы кырыенда өелеп торган бозлы кардан аякларым таеп, рельска төшеп киттем дигәндә, ниндидер бер илаһи көч белән, пружина кебек, сикереп чыгып өлгердем...

Кабан күле ул чакта бик җанлы, күңелле урын иде. Җәйләрен күл өсте тулган көймәләр, ике як яр буенда, берничә су станциясе урнашкан. Кешеләр су коеналар, көймәдә йөриләр, балык тоталар. Җилкәнле көймәләр бигрәк тә ямьле күренә. Нәҗия апаның олы улы көймәле спорт белән шөгыльләнүче спортчы иде. Бер-ике мәртәбә мине дә утыртып йөртте.

Су коенганда, мин, кодрәтләнеп, күлнең Насыйри урамына каршы яктагы элекке Спартак фабрикасы турысындагы ярга һәм кире бу якка йөзеп чыктым. Үзебезнең авылдагы инеш суында гына йөзеп өйрәнгән малай өчен бу тәвәккәллек кылу иде. Руслар "риск – благородное дело" диләр. Минем тормышымда андый тәвәкәллек гамәлләре шактый булды.

Кабан күлендә кышларын чаңгы шуалар һәм чаңгы ярышлары уздыралар, ягъни бу күл өстендә кышларын да җанлылык хөкем сөрә иде.

Тагын бер истәлекле күренеш: хәзер Г.Камал исемендәге татар академия театры урнашкан яр буенда хатын-кызлар Кабан суында кер чайкыйлар иде.

Күптәнге хәлләрнең хатирәләрен яңартканда, элекке кайбер уңай гамәлләрнең хәзер булмавы аяныч хисләр тудыра. Мәсәлән, моннан 70 ел элек хәзерге кебек кар чистарту техникасы юк чакта кышын ишек алды һәм урам җыештыручылар ишек алларын һәм тротуарларны карлы килеш тотмыйлар, хәтта төннәрен һәм иртән иртүк торып, көрәк белән чистартып куялар иде. Хәзер еш кына машина белән дә, кул белән дә чистартмыйлар. Көчле кар явып китсә, шактый вакытлар җәяү йөреп булмый.

Күңелдә икенче һәм өченче курсларда икенче семестр азагында (җәй көне) узган практика хатирәләре саклана. Икенче курс тәмамлангач, безнең группа студентларын практикага төрле районнарга җибәрделәр. Мин хәзерге Әгерҗе районына кергән Красный борга (элекке район үзәге) эләктем. Бу Кама елгасы буендагы, исеменнән үк күренгәнчә, нигездә, руслар яшәгән зур авыл. Беренче практикада кибетче һөнәрен үзләштерәсең. Мине азык-төлек кибетенә куйдылар. Кибетче – бер күркәм татар хатыны. Мин – 15 яшьлек малай – аның ярдәмчесе, практикант. Халат киеп, прилавка артына бастым. Хәзерге кебек, сатып алучы залда матур, пөхтә итеп төрелгән продуктны, корзинга салып килеп, кассада акчасын гына түләп китү тәртибе юк. Сатып алучы сораган продуктны, кәгазь пакетка салып, ул теләгән күләмдә үлчәүдә үлчәп бирәсең, исәп-хисап ясыйсың. Товароведение дәресләрендә пакет ясарга өйрәткәннәр иде. Кайбер продуктны ящиктан яки капчыктан алып, пакетка салып үлчәп бирү шактый мәшәкатьле, товар өчен сатып алучыдан акча исәпләп алу да җиңел эш түгел. Ярый әле янәшә кибетче апа үзе бар, кирәк чакта ул үзе ярдәмгә килә. Кайбер сатып алучылар минем маташканны елмаеп карап торалар, кибетчедән: “Малаеңмы әллә бу?” – дип сорыйлар. “Юк, ул практикант”, – дип җавап бирә апа.

Бер тапкыр Кама буйлап Красный бор сельпосы өчен баржа белән тоз китерделәр. Аны бушатканда эшчеләргә булышырга миңа да куштылар. Булыштым. Тиеш түгел дип, тарткалашып тормадым. Шуны күреп тору сәер булды: эшчеләр баржаның трюмындагы тоз өстендә аяк киемнәре белән йөриләр, төкереп тә куялар...

Мине яшәп торырга бер апаларга урнаштырдылар. Гаҗәп: нәрсә ашап, кайда ашап, ничек һәм кайда йоклап торганмындыр, берсе дә хәтеремдә калмаган. Тик бер күңелле мизгел исемдә: мин яшәгән йорт хуҗасының миннән шактый олырак Сайра исемле ягымлы кызы бар иде. Аңа исемне белеп кушкан булганнар, ахрысы: тавышы матур, һәм еш кына аның өйдә җырлап йөргәнен

күрә идем. Тагын шунысы бар: мин кичке якта кибеттән (янәсе эштән) кайтып кергәндә, елмаеп җырлап, нindидер иркәле сүзләр әйтеп каршы ала иде. Яшь башыннан ялгызы авыр эшләп йөри дип кызганып, бераз күңелен күтәрим дию булгандыр инде, рәхмәт төшкеренең.

Өченче курс дәресләре тәмамлангач узган икенче практика катлаулырак һәм җаваплырак булды. Анысы Азнакай районының административ үзәге Азнакай поселогында узды. Хәзерге, зур булмаса да, шактый төзек, матур шәһәр әле кайчан гына зур авыл иде. Хәтта салам түбәле өйләр дә бар иде.

Без анда өч укучы егет (дип әйтик инде) бер гаиләдә яшәдек. Райпотребсоюзда товаровед ярдәмчесе статусында практика уздык. Районның сельполарында йөрдек, кибетләре белән таныштык, нәрсәләрдер майтардык шунда, кистереп сөйләрлек җитди эшләр башкардык дип әйтә алмыйм. Формаль гына узды булса кирәк ул практика дигәнебез. Әмма анда бер группадан өч кеше, бергә яшәп, бергә йөргәнлектән, күңелле булды. Өчебезнең берсе – Казахстанның Павлодар өлкәсеннән килеп укыган Раил (Нигъмәтуллин) исемле татар егете, безнең группаның старостасы иде, икенчесе – Красный бор районы егете Галиәсгар Шәрифуллин. Икесе дә миннән бер-ике яшькә олырак та, тазарак, биегрәк гәүдәле дә. Раил, шуның өстенә, чибәр, кызларның күзләре төшә иде кебек. Әйбәт, акыллы егет. Миңа казакъчалап: "Жакшы (яхшы) малай", – дип дәшкәли иде.

Галиәсгар да – калку гәүдәле, үткен, өлгергән егет. Соңыннан Татпотребсоюзда җитди эшләр башкарды. Гомумән, минем белән бергә техникумда укыган егетләр һәм кызлар, диплом алгач, потребкооперация системасында җаваплы эшләрдә эшләделәр.

Ниһаять, чыгарылыш дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырдык. Минем нәтиҗәләрем шатланырлык. Татар мәктәбенең 7 классын тәмамлап килеп, өч елда рус телен шактый әйбәт итеп өйрәнү, урта гомуми белем алу һәм белгечлек һөнәрен үзләштерү миннән күп көч, тырышлык һәм максатка омтылыш үҗәтлеге таләп итте. Һәм бу таләп җиренә җиткереп үтәлде. Моны дәүләт имтиханнарының өчесен бишле, берсен дүртле билгеләренә тапшыру да ачык раслыйдыр.

Кырыс вакытлар иде. Диплом алуны зур кичәләр үткәреп бәйрәм итү булмады. Берничә группадаш дус белән тыйнак кына итеп билгеләп үттек ул вакыйганы...

## МИН – ТОВАРОВЕД

Товаровед дипломы белән бергә булачак эшебезгә юллама да бирделәр. Минем алдагы эшем – Курган өлкәсендәге Усть-Уйка райпотребсоюзының товароведы. Юл чыгымнары өчен аз гына акча да бирделәр. Мин, авылга кайтып, берничә генә көн тордым да, юлга чыктым. Мәскәүдән Арча станциясе аша уза торган поездга утырып Курган шәһәренә киттем. Үзем белән алган әйберләрем: иске чемодандагы әни биргән мендәр һәм тамак ялгарлык ниндидер ризыклар. Өстә киелеп таушалган гади генә костюм. Өскә җылы киемем дә, көзге-кышкы аяк киемем дә, баш киемем дә юк.

Курган шәһәренә килеп төшкәч, облпотребсоюз дигән оешманы эзләп таптым. Андагы кадрлар бүлегендә минем кайсы райпотребсоюзда эшләячәгемне хәл итәчәкләр. Моны ике көн көтеп торырга туры килде. Гостиницага урнашу уе да килмәде: акча бик исәпле генә. Кадрлар бүлегендә, баш астына документлы папкалар куеп, өстәл өстендә уздырдым ике төнне.

Ниһаять, кадрлар бүлеге башлыгы кабинетына чакырып алды. Мине күргәч, гаҗәпләнеп карап: “Бигрәк яшь товаровед җибәргәннәр икән”, – дип әйтеп куйды. Шулай иде шул: миңа әле 17 яшь тә тулмаган иде. Аннары минем кая барасымны әйтте: “Сине иң интернациональ районга җибәрәбез, анда күп төрле милләт вәкиләре яши”, – диде. Ул дөрес әйткән булып чыкты. Анда төп халык руслардан тыш, украиннар да, молдован, немец, казахлар, Себер татарлары да, тагын нидидер халыклар яши икән.

Курганга башта Шумиха дигән кечерәк кенә бер шәһәргә кадәр поезд белән, аннары Казахстан чигендә урнашкан Усть-Уйка районының 100 чакрымдагы административ үзәге Ново-Кочердык дигән авылга йөк машинасына утырып барып җиттем.

Усть-Уйка районының административ үзәге элекке казак станицасы Усть-Уйкадан Ново-Кочердыкка мин килгән елны гына күчерелгән булган. Шунлыктан әле ул төзек һәм тиешле

уңайлыклары булган үзәк авыл булып җитешмәгән. Административ һәм торак биналар мәсьәләсендә проблемалар бар иде.

Мин килгән көн – якшәмбе, райпотребсоюз ял итә. Курганнан товаровед киләсен әйтеп телефоннан шалтыратып куйганнар булса кирәк: райпотребсоюз бинасында бер җан иясе бар иде. Күркәм кыяфәтле яшь ир кеше. Ул райпотребсоюз председателенең урынбасары – сәүдә мөдире Анатолий Александрович Катаев булып чыкты. Мин, исем-фамилиямне атап, товаровед икәнлегемне әйттем. Ишеткәч, елмаеп куйды. Җылы каршылады. Миндә беренче күрүдән үк уңай тәэсир калдырды. Бу хис алдамаган: соңрак Анатолий Александрович, анда эшләү дәверемдә гадел кеше икәнлеген күрсәтте, минем яклаучым булды.

Мине монда яңа эш, яңа тормыш шартлары, яңа кыенлыклар һәм сынаулар көтә иде.

Тору урыны итеп, миңа берничә квартиралы барак рәвешендәге агач йорттан бер бүлмә бирделәр. Бүлмәдә утын яга торган мичтән башка бернәрсә дә юк, хәтта өстәл, урындык та, кровать та, башкасын әйткән дә юк. Кайдандыр бер иске тимер кровать юнәтеп алып кайтып куйдым. Райпотребсоюз складында кырыйлары умырылып ертылган матрас белән юрган күреп алдым да, аларны списать итү өчен акт төзеп, алып кайтып ямап куйдым (әни биреп җибәргән мендәрнең дә кирәге чыкты). Йокларлык урынҗир булды. Ул арада, сентярбь җитеп, салкын җилләр исә башлады. Өйне җылытырга кирәк булачагы искә төште. Райпотребсоюзда упаковщик булып эшләүче Равил исемле Себер татары егете белән танышып, аның белән урманга барып, каеннар кисеп алып кайттык. Аннары, аларны ваклап турап, кышка әзерләп куйдык.

Өскә-аякка җылы кием кирәк иде әле. Аны сатып алырлык акча юк: хезмәт хакы алмаган. Председательгә кереп, аванс итеп акча сорыйм, бирми. Тупас йөзле, сөмсере коелган бер бәндә – Калугин Николай (Петровичмы шунда: инде онытыла да башлаган). Юньле кеше булып чыкмады ул, миңа соңрак зур зыяны тиде. Ләкин дөньяда яхшы кешеләр дә бар бит. Минем акчасыз икәнлегемне белеп, баш бухгалтер, председательдән яшереп кенә, берничә сум аванс бирде. Мин шул акчага телогрейка белән кирза итек алып кидем, яхшырак киемгә акча җитмәде. Ашарга-эчәргә дә кирәк бит әле. Яшь белгечнең яңа урында эшләве шундый шартларда башланды. Мичурин бабай “Мы от природы милостей ждать не можем” дип, дөрес әйткән булган.

Минем эш шундый вазыйфалар башкарудан гыйбарәт иде. Райпотребсоюз складларына кайта торган товарны счет-фактура буенча тикшереп кабул итүне оештыру. Җитмәгән яки бозылган, ватылган-җимерелгән әйберләргә акт төзү, вакыт-вакыт Шумиха һәм Курган шәһәрләренә барып товар алып кайту, сельподагы эшләр белән танышып тору, магазиннар тикшерү, сатып алучыларга, нинди товарлар кирәклекне (ихтыяҗ барлыгын) өйрәнү һәм башка төрле гамәлләр. Шумихадагы районара базадан миллионлаган сумлык берничә машина товар яздырып, аны райпотребсоюзга алып кайткан чаклар булды. Соңыннан гына белдем: әле миңа 17 генә яшь, ягъни балигълыкка җитмәгән булганлыктан, үземә товар җаваплылыгы алырга тиеш тә булмаганмын икән.

Усть-Уйка райпотребсоюзында эшләгән ел ярым вакытта берничә еллык вакыйгалар кичерергә туры килде. Һәм берсе дә кызыгырлык түгел. Мине, ялгыз яшь егет буларак, ерак юл кыенлыклары белән бәйләнгән сәфәрләргә җибәргәлиләр иде. Мәсәлән, 150 километрлы Курган шәһәренә, 100 километрлы Шумихага районара сәүдә базасына, Шадринск шәһәренә товар алып кайтырга. Хәзерге алдынгы техникалы, асфальт юллар заманы өчен бу, бәлки, бик авыр эш булмас та иде. Ә ул чакта, моннан 66 ел элек, кабиналары ярык-тишекле, җылытылмый торган ГАЗ, ЗИС йөк машиналары, грунт (балчык) юллар... Кышын берничә тапкыр Шумихага җибәрделәр. Юлны буран күмеп китә, чистартырга трактор килеп җиткәнче, сәгатьләр буенча салкын кабинада катып утырасың. Аягыңдагы, өстеңдәге киемең дә әллә ни җылы сакларлык түгел. Трактор юлны бер машина барырлык кына итеп чистартып китә, каршыга килгән машинадан читкәрәк тайпылыйм дигәндә, кырыйдагы биек кар көртенә кереп батасың... Себердә (Курган өлкәсе Көнбатыш Себергә керә) авыллар бер-берсеннән ерак: 10 ар, 20шәр километр, тиз генә барып ярдәм сорап килерлек түгел.

Бер драматик хәл булды. Март азагы, апрель башы. Язгы кояш карап, юлларны җебетә башлаган вакыт. Мин, Шумиха базасында өч машина товар төяп, үзебезнең Н.Кочердыкка кайту юлына чыктым. Башта төнге салкында ныгыган юлдан ярыйсы гына бардык та, көн уртасында, кояш җылыткач, юл, җебеп, кар боткасына әйләнде. Мең бәла белән бата-бата бардык. Төн керде. Безнең район үзәгенә 30-40 чакрымнар ераклыктагы Половинное дигән зур авылга җитәрәк, машиналар бөтенләй туктап калды. Ул авылда шушы машиналарның автохуҗалыгы урнашкан. Шоферлар үзләре

дә шул авылдан. Һәм алар шул хуҗалыктан, машиналарга юл ачып, һәм, кирәк булса, тартырып алып кайтырга куәтле техника алып киләбез дип, Половинноега җәяүләп кайтып киттеләр. Мин машиналарның берсендә утырып калдым. Ташлап китә алмыйм: өч машина товар минем исемдә, ягъни минем җаваплылыкта бит. Иртәдән бирле ашамаган-эчмәгән килеш юлда, салкын җелекләргә үтте. Тегеләр (шоферлар) һаман да юк. Таң атты. Чыдар хәл калмагач, мин дә, товарлы машиналарны калдырып, Половинноега киттем. Автохуҗалыкка керсәм, күрәм: мин ничә сәгать буенча көтеп утырган шоферлар, өйләренә кайтып, ашап-эчеп, бәлки йоклап та алганнардыр, калдырып киткән машиналары янына барырга җыенып кына йөриләр әле. Минем ни хәлдә булуыма кемнең исе киткән, кем борчылган! Бер татар малае туңып-катып үлүдән кемгә зыян килгән, ди! Шундый әхлак нык утыра әле кайбер кешеләрдә.

Машиналарны Половинноега алып кайтылар. Н.Кочердыкка кайтып җитәрлек түгел иде инде: юл өзелде. Ул авылда безнең райпотребсоюзга караган сельпо бар. Машиналардан товарны шул сельпо базасына: бозылмый торган әйберләрне ишек алдына, тукыма тюкларын чолан кебек бер кечкенә генә складка урнаштырдык. Мине вездеход дигән машина белән кайтарып куйдылар. Бик кыйммәтле кайбер әйберләрне дә алып кайттым. Шул вакыйгадан соң берничә көн үткәч, Половинное сельпосыннан миңа телефоннан шалтыраталар: “Тизрәк кил, тукымалы тюклар урнаштырылган складка кар суы кергән”. Складның ачкычы миндә, товар өчен мин җаваплы.

Мин, шундук, атка атланып юлга чыктым. Юыртып та, атлатып та барып җиттем. Складка кергән су тукымалы тюкларны чылата башлаган иде. Асларына агачлар салып күтәртеп, җайлап куйдым да, килгәндәге атым белән кайту юлына чыктым. Ияләнмәгән килеш атка атланып йөрү арт шәрәфләрен эштән чыгарган: минем ботларым һәм шул тирәләр нык авырта. Атны чаптырып барып булмый. Әкрен генә атлатып, төнлә соң гына кайтып җиттем. Берничә көн, температурам күтәрелеп, авырып яттым. Сельпода калдырган товарны, җир кибеп, юл төшкәч алып кайттык.

Хәзер исемә төшкәндә исем китә. Ниндидер аңлашылмый торган кыен хәлләр хөкем сөрде кайчакта минем эштә. Алар миңа карата гына булгандырмы, белмим. Ләкин үзем дучар булганнары онытылмый.

Шумиха базасына райпотребсоюз машинасы белән барам да, аңа складлардан товар алып төяп, ул салынган ящик, капчыклар исәбен күрсәтеп язган накладнойга шофердан кул куйдырып, машинаны Н.Кочердыкка райпотребсоюзга кайтарып җибәрәм. Үзем калам. Товарны машинага төяргә ярдәмчем юк. Безнең районнан йөк китереп калдырган машиналарны шәһәр буйлап (кечкенә булса да, шәһәр дип атала) эзләп, шоферларны ялынып дигәндәй ризалатып базага алып барып, товар төяп (накладной язып, аңа кул куйдыртып), райпотребсоюзга җибәрәм. Базада унлап склад бар. Шуларның төрлесеннән күп төрле товарга (энәдән алып, ат камытына кадәр дияргә була) счет-фактура яздырып, шул әйберләрне үзем карап, исәпләп, үзем төяп җибәрәм. Көненә җидешәр-сигезәр машина төяп җибәргән көннәр булды. Шулай берничә көн буена базадан товар озатып ятып, райпотребсоюзның анда даими торып эшләгән экспедиторы Иван Бабушкинның өй-конторасында кунып, счет-фактура яздырып алган товарны озатып бетергәч, соңгы машинага утырып, үзем дә кайтам. Кайткач, базадан төяп җибәргән берничә машина товарны, счет-фактура буенча тикшереп, райпотребсоюз склады мөдиренә тапшырам. Минем өчен үзенә бертөрле эпопеяга тиң шундый гамәл Курган өлкәсендә яшәү дәверендә берничә тапкыр булды. Хәзер уйлап гаҗәпләнәм: Шумиха базасында райпотребсоюзның товар җибәреп тора торган махсус экспедиторы була торып, мине, яшем буенча хәтта андый зур суммалы товар белән эшләргә тиеш тә булмаган яшь егетне, ни өчен шулай җәфаларга кирәк булды икән?

Курганда эшләгәндә беренче тапкыр үзем белән бәйләнешле суд процедурасын да кичерергә туры килде. Аның кыскача гына тарихы шуннан гыйбарәт. Мин яз башында Шумиха базасыннан үзебезнең райпотребсоюзга, шоферларга накладнойларга кул куйдырып, ике машина чүпрә төяп җибәрдем. Бу вакытта урамда минус градуслы салкын һәм чүпрә бозылмаган иде. Үзем базадан башка төрле товарлар алып җибәрергә калдым. Чүпрә җылыда бозыла торган әйбер булганлыктан, аны, шоферлар кайтарып калдыргач та, сельполарга (кибетләргә) озатырга тиешләр иде. Ләкин склад мөдире, ваемсызланып, товарга игътибар итмәгән. Тиздән көннәр җылытып җибәреп, чүпрә җебегән, ящиклардан склад идәненә агып чыккан. Мин кайткач, чүпрәнең бозылуы хакында, аның бозылу сәбәбен райпотребсоюз складында озак саклану дип күрсәтеп, акт төзедем (андый актлар төзү минем вазыйфала-

рыма кирә иде). Гадәттә мондый очракларда товар суммасын райпотребсоюз үзе списать итә. Бу юлы да шулай булыр дип уйладым. Әмма берникадәр вакыттан райпотребсоюз идарәсе утырышында, председатель тәкъдиме белән, бозылган чүпрә суммасын миннән түләтергә дигән карар чыгарылганлыгы турында хәбәр иттеләр. Бу миңа аяз көндә яшен суккандай булды. Мин гаепсез килеш ул бозылган товар суммасын түләү өчен ярты ел бушлай эшләргә тиеш булыр идем. Әлбәттә, түләүдән баш тарттым. Андый очракта мәсьәлә суд карары белән хәл ителә, һәм райпотребсоюз миңа үзенең дәгъвасы (иск) белән судка мөрәҗәгать итте. Мин судка әзерләндем: метеорология станциясеннән чүпрә алып җибәргән көнне салкын көн булганлыкны раслый торган документ алдым, Шумиха базасында да чүпрәнең әйбәт булганлыгын расларлык справка бирделәр һәм бик әһәмиятлесе: мин базада машинага чүпрә төяп ятканда, Шумихага ниндидер үз эше белән килеп чыккан (мин хикәяләвем башында әйтеп киткән) председатель урынбасары Анатолий Александрович Катаев килеп күреп торган иде. Һәм ул минем гаепсез икәнлегемне расларга шаһит булырга ризалыгын бирде.

Һәм тиздән суд булды. Судья минем анкета белешмәләре белән танышканда: “Бигрәк яшь товаровед икән”, – дип елмаеп әйтеп куйды. Шаһит Анатолий Александрович тәэсирле генә итеп мине яклап һәм аклап сөйләде, чүпрәнең бозылуында чын гаепле кешеләрне күрсәтте. Менә мине нинди авыр хәлгә куярга теләгән кара эчле председатель Н.Калугин һәм яхшы күңелле, игелекле кеше А.А.Катаев.

Суд мине аклап карар чыгарды: бозылган товар өчен түләүдән азат итте. Кайчакта гаделлек тә җиңә икән.

Алга китеп әйтәм: минем үз гомеремдә тагын бер тапкыр, ректор булып эшләгәндә, Мәскәү судында эшем каралды. Анысында да суд мине аклап хөкем чыгарды (бу турыда соңрак сөйләнер).

Русларда “И смешно, и грешно”, татарларда шул мәгънәдәге “Көләрсең дә, еларсың да” дигән әйтелмәләр бар. Минем Курган өлкәсендәге яшәвем дәверендә шуларга туры килерлек вакыйга да булды. Курган облпотребсоюзыннан райпотребсоюзларга, барлык кибетчеләрне сәүдә эшенең теоретик нигезләре белән таныштыру өчен, кыска вакытлы курс оештырырга дигән боерык бирелгән. Һәм безнең председатель Николай Калугин, бу боерыкны үтәү йөзеннән, райпотребсоюзда эшләгән урта махсус белем-

ле белгечләрнең һәркайсын, шундый курсны үткәрү өчен, берәр сельпога беркетеп чыкты. Бу курсның программасы да бар иде. Мине, шундый белгечләрнең берсе буларак, Н.Кочердыктан унмыунбишме чакрымда урнашкан Матвеевка сельпосына беркеттеләр. Райпотребсоюздагы миннән башка белгечләр дә, кибетчеләр дә рус теле ияләре. Мин генә татар һәм, шуның өстенә, җиде классны татар мәктәбеннән соң техникумда бары өч ел гына русча укыган. Матвеевка сельпосына караган унлап кибетчеләрнең барысы да марҗалар. Мин, татар авылында яшәп, татар мәктәбендә укып, өч кенә ел русча укыган унҗиде яшьлек егет русча дәресләр бирергә тиеш. Минем әле ул чакта рус телем дә камил булмагандыр, әлбәттә, үземнең оялчанлыгым да бар иде. Минем өчен бу гамәл райпотребсоюзда башкарган иң авыр эшләрдән булды. Нишлисең бит, башыңа төшкәч, башмакчы буласың, диләр. Кайдандыр кайбер һөнәри кулланмалар табып, техникумда алган барлы-юклы белемнәрне зиһенемдә яңартып, эшкә керештем. Берничә мәртәбә атнасына берәр тапкыр, үзем җиккән атлы чанага утырып, Матвеевкага барып, төрле авыллардан белем күтәрү курсына дип махсус җыелган кибетче апалар белән очрашып кайттым. Ояла-ояла гына нәрсәләрдер сөйләгән булдым инде шунда. Ханымнар, кызлар минем хәлне аңлагандыр инде, көлеп утырмадылар, тыңлаган булдылар. Нишләсеннәр, аларны да йөрергә, тыңларга мәҗбүр иткәннәр бит. Бәхетемә, ул курс озак дәвам итмәде. Ниндидер сәбәп яки сылтау белән туктап калды. Шулай итеп, мин беренче тапкыр педагоглык һөнәреннән чирканчык алырга мәҗбүр булдым.

Курган өлкәсендә, димәк Көнбатыш Себердә, дәһшәтле сугыш узып, ун гына ел узган чорда тормыш гомумән алганда, безнең Татарстандагыга караганда, җиңелрәк иде. Бу халыкның ашауэчүендә дә, кием-салымында да, йорт хуҗалыкларында да, кохозсовхозларның икътисадый хәлендә дә күренә иде. Ул чакта, мәсәлән, безнең Татарстан колхозларында, һәрхәлдә Арча, Әтнә якларында, йөк автомобильләре юк иде әле. Ә Курган колхоз-совхозларының кайберләрендә берничәшәр автомобиль бар иде инде. Мине бер тапкыр райпотребсоюзда эшләүче Равил өйләренә чәй эчәргә чакырды. Әнисе пилмән белән сыйлады. Мин, рәхмәт әйтеп, самимилегем аркасында: “Тәмле булды, ит пилмәне ашаганым юк иде әле, бездә эремчек пилмәне генә пешерәләр”, – дип әйтеп куйдым (бу чыннан да шулай иде: пилмән пешерерлек ит булмады). Минем бу сүзләремә бик аптырадылар. Себердә табигать тә баерак, халык та

бик үк изелмәгән булган, күрәсең. Мин соңрак моның сәбәпләрен дә аңладым.

Курганда, озак яшәмәсәм дә, мин кичергән вакыйгалар, тормыш сынаулары шактый күп булды. Барысын да тасвирлау кирәкмәстер. Шулай да минем яшьтәге кеше өчен тагын бер җаваплы һәм авыр эш турында сөйләп китүнең артыгы булмастыр бәлки.

Кыш көннәренең берсендә райпотребсоюз председателе Николай Калугин мине кабинетына чакырып алды да шундый ашыгыч эш кушты. Кайсыдыр авыл (исемен хәтерләмим) кибетендә зур тәртипсезлек хөкем сөрә: кибетче әйберләрнең бәяләрен төгәл белми, башка авыл кибетләрендәгегә караганда кыйммәтрәккә сата икән. Хәзер үк барып, шунда ревизия үткәрергә кирәк. Минем белән районның милиция башлыгы урынбасары капитан да (фамилиясе исемдә түгел) бара. Тиз генә җыенып, атлы чанага утырып чыгып киттек. Ревизияне комиссия башкарырга тиеш. Авылларда, гадәттә, лавочная комиссия члены дигән кеше була. Шуның белән бергә капитан һәм мин комиссия төзеп (мин председателе) эшкә керештек. Бу минем өчен бик җаваплы һәм четерекле эш. Прейскурант китабын райпотребсоюздан алып килгән идем. Ләкин аның буенча гына кибеттәге һәр товарның бәясен билгеләү мөмкин эш түгел. Ә кибетче күп әйберләрнең бәясен тәгаен белми (сельподан алган накладнойларын, бәлки, махсус юкка чыгаргандыр).

Район үзәгеннән ревизия килгәнен белгәч, халык, кибеттән кыйммәтрәккә сатып алганмын дип исәпләгән әйберләрен күтәреп, безнең янга, ягъни ревизия комиссиясе членнары янына, килә башлады. Кайберләре хәтта ящиклары белән суыкта каткан дуңгыз майларын да күтәреп килделәр. Мин, товарның чын бәясен һәм кибетче саткан бәяләрен күрсәтеп, акт төзергә тиеш. Миннән булмый бу эш дип торып булмый. Җәфаландым, ләкин ермачлап чыктым кебек... Ревизия ике-өч көнгә сузылды. Актларны төзеп, капитан боерыгы буенча, үзебез белән кибетче ханымны да алып, Н.Кочердыкка кайттык. Аннары кибетче белән милиция шөгыльләнде.

Бер кичне капитан мине шул авылда яшәгән бер таныш казак кешесенә милли ризыклары бишбармак ашарга кунакка алып барды. Истәлекле хәл булды ул. Казак гаиләсенең ничек яшәвен, ничек итеп бишбармак пешереп, кунак сыйлауларын күреп кайттым.

Шулай итеп, минем Кургандагы бер елдан артык гомерем узып китте. Мин, отпуск алып, туган йортыма кайтырга әзерләнә башладым. Күңелемдә кире килмәскә дигән уем бар иде. Аның мәгънәсе дә юк иде, чөнки армиягә китәргә күп вакыт калмаган иде инде. Ләкин мине эштән үз теләгем белән җибәрмәячәкләрен белеп тордым. Шунлыктан отпусктан соң анда кабат бармам дип уйладым.

Мөстәкыйль тормышымның бу чоры, озак вакытлы булмаса да, алдагы эшләремә, яшәвемә әзерлек этабы булды. Курган өлкәсендә мин тормыш тәҗрибәсе алдым, авырлыкларны җиңәргә өйрәндем, Себер халыкларының яшәү рәвешен күрдем, сәүдә эшенең серләренә дә берникадәр төшендем, кешеләр белән аралашу күнекмәсе алдым, рус телен белүем дәрәҗәсе дә арткандыр. Кыскасы, аз вакытлы, ләкин хатирәләргә бай Көнбатыш Себер тормышым киләчәктәге җаваплы эшләрем өчен файдалы булды, дип саныйм.

## СОЛДАТТА БУЛГАН ДИЛӘР...

Шулай итеп, мин яңадан туган җиремдә, үз авылымда. Әти-әниләрең, туганнарың янында булу куанычлы, әлбәттә. Ләкин күңел тыныч түгел. Минем хезмәт кенәгәсе Усть-Уйка райпотребсоюзында, паспортта яшәгән урынымнан учеттан төшкәнлеккә тамга да юк. Ансыз монда пропискага кереп булмаячак, хезмәт кенәгәсеннән башка яңа эшкә керүдә уңайсызлыклар килеп чыгачак. Мин заказлы хатка паспортымны тыгып, Анатолий Александрович Катаевка хезмәт кенәгәсен һәм, пропискадан төшереп, паспортымны кире җибәрүен үтенеп яздым. Игелекле зат Анатолий Александрович, гозеремне үтәп, документларымны миңа җибәрде. Гомеремдә үтәлми калган теләкләремнең берсе шул: Курганга барып, үземнең беренче хезмәт урынымда булып, Анатолий Александровичны һәм башка андагы танышларымны күреп кайтырга дип, вакыт-вакыт ымсынып куя идем. Тәки шуны эшли алмадым. Исемә төшкән саен, шуның өчен үземне битәрлим.

Армиягә алынырга ярты еллап вакыт бар иде әле, һәм мин, әлбәттә, берәр җирдә эшләп торырга булдым. Мине Казанның икенче азык-төлек сәүдәсе оешмасына (пищеторгка) товаровед итеп эшкә алдылар. Курган маҗараларын кичереп кайтканнан соң, бу эш минем өчен авыр булмады. Аның турында сөйләп тормыйм. Бу чакта безнең олы абыебыз Равил, армиядән кайтып, заводта эшли, аның тулай торагында яши иде. Мин ярым легаль рәвештә шуның янында тордым.

Һәм тиздән минем армиягә китү әзерлегем башланды. Август ае иде. Хәрби комиссариатта, медицина комиссиясен узганнан соң, бер офицер минем белән әңгәмә ясый: анкета мәгълүматларын карап, үзем белән танышып, мине кая, кайсы гаскәргә җибәрәсен хәл итә. Мин аннан: “Әйтегезче, мине кая, кем булып хезмәт итәргә җибәрергә җыенасыз?” – дип сорыйм. “Әфганстан чигендә кавалерист булып хезмәт итәчәксең”, – ди ул. Мин ул шаярып әйтәдер

дип уйлап: “Хәзерге заманда кавалерия хезмәте юк бит инде”, – дим. “Менә күрерсең әле”, – ди капитан. Ул шаярып әйтмәгән булып чыкты. Мине чыннан да, атка атланып, СССР–Әфганстан чиген саклау хезмәте көтеп торган булып чыкты.

Армия хезмәтенең җиңел түгеллеген ишетеп белә идем инде. Әмма минем яшәү принципларымның берсе тормышны һәрьяклап белү, авырлыкларны да күрү иде. Шуңа күрә армиядән калырга кирәк дигән уй булмады. Югыйсә, тырышсам, берәр югары уку йортына кереп, армиядән кала алган булыр идем. Тагын шунысы да бар: ул чакта армиядә булу егетлек саналды, армиягә бармый калганнарга ничектер берникадәр сәерсенеп карау гадәте дә бар иде. Безнең гаилә егетләре, тәртип буенча, бер-бер артлы армиягә барып, хезмәт итеп кайта тордылар. Равил абый кайтты, ул кайтуга, Наил абый китте, ул кайтуга мин киттем, мин кайтуга, Әнәс энем китте. Әти дә сугышта булган. Әйтерсең, безнең гаилә – хәрбиләр подразделениесе.

Миңа армиягә авыллардан һәм башка шәһәрләрдән килүче егетләр кебек, хезмәт итү урынына җибәргәнче, республика хәрби комиссариатының казармаларында берничәшәр көн көтеп ятарга туры килмәде. Мин турыдан-туры Казан тимер юл станциясенә безне алып китәсе поездга килдем. Китәр алдыннан кичерәк кенә озату кичәсе уздырдылар. Казандагы бертуган ике абый, берничә агай-эне, апа-абыйлар озата килделәр. Кичке як иде. Товар поезды вагонына (“телячий вагон” диләр) утырып киттек. Өч елга хуш, Казан! Хезмәт итәсе җиргә бару шартлары армиядә хезмәт итүемнең беренче сынавы булды. Безнең вагон армиягә баручылар өчен махсус ике катлы сәндәрә кебек итеп такта шүрлекләр (полкалар) белән бүлеп әзерләнгән. Сәндәрәләр арасыннан үрмәләп кенә кереп, ятып яки утырып кына торасың, утырганда, баш өске кат такталарына тия. Өстән чүп коела. Ашарга коры ризык (сухой паек), җылы ашлар бирелми. Юыну урыны һәм бәдрәф юк. Андый гамәлләрне станцияләрдә туктап торганда гына җаен табып башкарабыз. Бөркү, тынчу. Шундый шартларда Кыргызстанның Ош шәһәренә кадәр, төрле җирләрдә озак туктап тора-тора, ун тәүлек бардык. Бу шәһәрдә поезддан төштек тә, безгә иске туннар, искергән итекләр кидертеп, йөк машиналарының берсендә дә утыргычлар куелмаган кузовларына менгереп утырттылар. Август аенда Кыргызстанда ничек инде тун кисеннәр дигән сорау, әлбәттә, һәркемнең дә башына килер. Тиздән бу сорауга җавап табылды. Безнең хезмәт

итәсе урыныбыз Хорог шәһәренә (шәһәр димәсәң, хәтере калыр: нибары 7 мең кешеле) кадәр мәһабәт Памир тауларының дүртәрбишәр километр биеклектәге перевallары аша 738 чакрым барасы икән. Ә ул перевалларда кар төшкәләп тора иде инде.

Бу юлны узу армиядә хезмәт итүемнең иң кыены булып исемдә калды. Туннар кигәч, машинага тыгызланып, кысылып утырдык. Минем урын кузовның артына туры килде. Юл биек таукыяларны кисеп ясалган, бормалы-бормалы, бер аска төшә, бер өскә менә. Машинаның газы кузовка керә, баш әйләнә, укшыта, костыра. Шул рәвешле ике тәүлек ярым бардык. Ике торак пунктта туктап, төн кундык. Беренчесе – ниндидер бер чечен авылында (депортацияләнгән булганнардыр), машина кузовында утырган килеш, икенчесе – Мургаб исемле чик буе отряды клубының коры идәнендә.

Шундый мөнәсәбәт иде безнең илдә солдат халкына.

Йөзәр километр узгач, туктап, машиналардан төшеп, хәл алабыз. Шунда юл кырыйларында басмачылар белән сугышканда һәлак булган хәрбиләрнең каберләрен күрдек. Кабер өстендәге балчыгы убылып төшеп, кеше сөякләре күренеп ята иде кайберләрендә. Аннан килеп, берничә урында юл кырыйларында кабер ташлары тора. Алар аварияләрдә һәлак булган шоферлар каберләренә куелган, диделәр. Тау юллары бик хәтәр: һәлакәтләр еш булып тора икән. Өстән аска карасаң, башың әйләнерлек биек тау башларыннан узып бардык. Йә, алла! Килеп җиттек. Як-яктан галәмәт биек кыя-таулар белән әйләндереп алынган тар гына үзәнлектәге Таҗикстан республикасына караган Тау Бадахшаны автономияле өлкәсенең административ үзәге Хорог шәһәрендә Урта Азия чик буе округының Хорог отряды урнашкан.

Без бу отрядта ике-өч айлык өйрәнү курсы узачакбыз.

Өстебездәге иске-москы киемнәрне салдырып, чәчләрне машинка белән төптән алдырып, мунчага керттеләр. Озаклап, иркенләп юынып утыра алмыйсың. Тиздән чыгарга команда була. Пограничниклар формасына киенәбез. Яшел погонлы гимнастерка, чалбар, яшел фуражка, калын күн (яловый) итек. Гимнастерка гадәти генә түгел: аркылы-торкылы тасма-ременьнәр белән чолгап алынган. Монысы кылыч тагу өчен эшләнгән җайланма. Кылычны икенче көннән үк тактылар, һәм аны өйрәнү курсын узып беткәнче асып йөрдек. Ул йөргәндә, чайкалып, аякка бәрелеп, комачаулап тора.

Без хәзер чик буе хезмәтенә өйрәнә торган курсантлар дип аталабыз. Безнең отряд (хәрби часть), Хорог шәһәренең (шәһәр дип аталса да, поселок зурлыгында гына) кырыенда урнашып, гадәттәгечә, тимер чыбык койма белән әйләндереп алынган. Җирле халык – Тау Бадахшаны таҗикларының йортлары, административ хуҗалык биналары күренеп тора, тышкы яктан койма буеннан, букчаларын асып, укучылар узып йөри. Буй җиткән кызлары, малай-егетләре дә чибәр. Мондагы тау таҗиклары тау астындагы җирләрдә яшәгән күпчелек таҗикларга караганда матуррак күренде. Имеш, моның сере шунда икән: кайчандыр бу җирләрдә Македонский гаскәрләре озак итеп тукталып торган. Шуннан соң җирле халыкта физик яктан үзгәрешләр булып калган (шулай дип сөйләделәр).

Кызлары бигрәк тә матур: ак йөзле, кап-кара күзле, нечкә кара кашлы, озын толымлы чәч, бизәкле матур күлмәкләр, тубыгына хәтле төшкән бизәкле шароварлар киеп йөриләр. Ул чакта таҗик хатын-кызлары барысы да шаровар киеп йөри иде: аяк балтырын күрсәтеп йөрү шәригать законы белән тыелган.

Отрядта яшәү һәм хезмәткә өйрәнү шартлары артыгы белән кырыс булды. Вакытлыча торырга көйләнгән автомобиль гаражларында яшәдек. Төннәрен шактый салкын. Хорог диңгез тигезлегеннән 2500 метр биеклектә урнашкан. Димәк, без торган урында, тау астындагыга караганда, салкынрак һәм һаваның кислороды да азрак (русча разряженный воздух диләр). Кислород аз булган җирдә тән җәрәхәте әкренрәк, озаграк тазара. Без бу күренештән өйрәнүләр вакытында шактый җәфа чиктек. Атка атланып, чаптырып барган килеш, киртәләрдән сикереп чыкканда, төрле күнегүләр эшләгәндә һәм кылыч чапканда (пограничник-кавалерист бит), арт шәрәфләре бозылып, озак вакытлар канап йөрде. Кул-аяклар сыдырылганда, тырналганда, андагы җәрәхәтләр дә тиз генә тазармады.

Кичке проверка дип аталган нәрсә вакытында гимнастеркадан гына салкын, туңасың. Октябрь аена кадәр өскә кияргә шинель бирмәделәр. Иртән арык суында (өстен юка гына боз каплаган була) юынабыз.

Кая барсаң, кайтсаң да стройга тезелеп кенә йөрисең. Юл һәркайда ташлы, атлау кыен. Кылыч, карабин таккан килеш, шул ташлы юллардан йөгертәләр яки җырлатып йөртәләр. Йөгерү дә авыр, җырлыйсы да килми...

Армиядә командирга каршы дәшү, зарлану дигән нәрсә юк. Хәлең бетеп егылганчы куалар. Үтәмәсәң, сине җәза – наряд, гаупвахта көтә. Кирәкмәгән артык кырыслык, рәхимсезлек.

Бик авыр шартлар хөкем сөргәнлектән, күп курсантлар авырды. Миңа да туры килде ул язмыш. Кичтән температурам күтәрелде. Иртән командирга әйтәм бу хакта, санчастька барыйм, дим. Юк, анда өйләдән соң гына кабул итәләр, ди. Безнең учебная застава дип йөртелә торган подразделение төз атарга күнегүләр ясарга (стрельбищега) барырга тиеш. Мин өйләгә кадәр санчастька да бара алмыйм, казармада да калырга ярамый икән. Димәк, миңа да стрельбищега  барырга туры килә. Бардым, җәфаланып атып кайттым.

Төшке ашка үзебезнекеләр белән бергә, гадәттәгечә, стройга тезелеп бардык. Рәтләп ашамадым да: температура югары. Санчасть ашханә янында гына. Ашханәдән чыккач, шунда кереп кенә каласы. “Юк, – ди командир, –  башкалар белән стройга тезелеп кайт, аннан соң барырсың санчастька”. Казарма белән санчасть арасы шактый. Менә шундый җүләрлекләр була анда. Температурам 40 градуска якынлашкан иде. Берничә көн дәваланып яттым... 39 градуска кадәр санчастька алмыйлар да.

Солдат түзә инде барысына да. Миңа да чыдарга туры килде. Чикне биек тауларда атларга атланып йөреп саклыйлар икән. Һәркайсыбызга берәр ат беркеттеләр. Һәркем атын үзе карый: ашатабыз, эчертәбез, чистартабыз. Һәм атнага ике-өч тапкыр үзебезнең атлар белән күнегүләр ясыйбыз, атка атланып чик сакларга өйрәнәбез. Ат белән йөгертеп барган көйгә, махсус ясап куйган  4-5 шактый биек киртә аркылы сикереп чыгабыз. Бу шактый авыр гамәл. Сикергәндә кипшенеп тазара башлаган ас яңадан каный, яңадан чиләнә... Атта шулай ук йөгертеп барганда, төрле күнегүләр эшлибез, аннары кылыч белән казыкларга беркетеп куелган чыбыкларны чабып чыгабыз. Чын кавалерист!

Чик саклау әзерлеге (погранподготовка), төз атарга өйрәнү (огневая подготовка), политдәрес (политподготовка) дигән әзерлекдәресләр уздык. Шулай итеп, әзерлек курсы тәмамланды. Һәр әзерлек төре буенча йомгак ясап, билгеләр куйдылар. Минем барысыннан да бишле булды. Мине мактап, молния язып элделәр.

Отряд җитәкчеләре – офицерлар курс тәмамлану уңае белән бөтен курсантларны тезелү мәйданына (стройплацка) җыеп бастырдылар. Безне курсны тәмамлавыбыз белән котлап, нәтиҗә

ясадылар. Аннары кемнәрнең чик сакларга кайсы заставаларга билгеләнүен әйттеләр. Һәм 50 кешене Сталинабадка (хәзерге Таҗикстан республикасы башкаласы Дүшәмбегә) сержантлар мәктәбенә җибәрәкчәкләрен хәбәр иттеләр. Теләгән кешеләр биш метр алга чыксын дип команда бирделәр. Шунда бер кызык хәл булды. Безнең курс төп ике җирдән килгән солдатлардан тора иде: бер яртысы Татарстаннан, икенче яртысы Кубань, Дон тирәләреннән китерелгән кешеләр иде. Якынча ике як та тигез санлы булуга карамастан, тегеләр төркеменнән күп кеше, теләк белдереп, алга чыгып басты, ә безнекеннән беркем дә чыкмады. Безнең застава начальнигы капитан мине стройдан чакырып чыгарды: "Юсупов, выходи, из тебя хороший командир должен получиться", – диде. Яхшы командир булдым, дип әйтә алмыйм. Ләкин Дон, Кубань егетләре белән сержантлар мәктәбендә укырга Сталинабадка китеп бардым. СССРда гынамы, әллә дөньядагымы иң биек саналган Ош-Хорог трассасын тагын бер тапкыр узарга туры килде.

Сталинабад – елның күпчелек вакытында яшеллеккә күмелеп утырган матур, тыныч шәһәр. Зур булмаганлыктан, анда машиналар да күп түгел, шалтор-шолтыр тавыш чыгарып йөргән трамвайлар да юк иде. Хәзер автомобильләр арткандыр инде, әлбәттә. Сталинабад ул чакта көнчыгыштагы чит илләр шәһәре кебегрәк тәэсир калдыра иде. Анда элеккечә яшәү тәртибе нык сакланган. Бу кешеләрнең үз-үзләрен тотышларында да, кием-салымнарында да, үзара мөнәсәбәтләрендә дә ачык чагыла. Алар әдәплелек, олыларга зур ихтирамлы караш һәм башка әхлаклылык сыйфатлары белән ул вакыттагы СССРның башка республикалары халыкларыннан аерылып торалар иде.

Сталинабадта 5-6 ай бик эссе була, температура күләгәдә 40 градустан арта. Апрельдән алып ноябрьгә кадәр бер бөртек тә яңгыр яумый. Халык шәһәрдән күренеп торган биек таулардан канаулар (каналлар) казып китерелгән арык суларыннан файдалана. Кыш сезоны дип аталган декабрь-февраль айларында сирәк кенә кар төшкәләп ала, ләкин тиздән эреп бетә. Бу чорда яңгырлар да ява.

Безнең хезмәт итәсе хәрби часть – сержантлар мәктәбе шәһәрдән 7-8 чакрымнардагы Риссовхоз дигән бистәдә. Часть кыреннан кечкенә генә елга ага. Җәй көне кибеп бетә яза, кыш көне суы арта.

Сержантлар мәктәбенең кайбер яклары буенча Хорогтагы әзерлек курсы белән охшашлыгы бар. Монда хәрби подразделениеләр шулай ук өйрәнү заставалары (учебные заставы) дип йөртелә, бу мәктәпләрдәге солдатлар да курсантлар дип атала һәм аларның һәркайсына берәр ат беркетелә. Өйрәнү дәресләрендә дә охшашлык бар. Ләкин монда бурычлары катлаулырак, зуррак.

Мин билгеләнгән заставаның начальнигы капитан акыллы, күркәм кеше иде. Һәм ул миңа баштан ук җылы мөнәсәбәттә булды. Ягымлы итеп, *милок* дип эндәшә. "Татарлар яхшы хезмәт итәләр, гадел егетләр, мин аларны хөрмәт итәм", – дип әйтә иде. Миңа ул тәрбияләргә һәм күнегүләр эшләргә үзенең атын биреп торды. Ул данлыклы, спорт ярышларында зур күрсәткечләргә ирешкән ат булып чыкты.

Без, курсантлар, мәктәпне (өйрәнүләрне) тәмамлагач, яңадан Хорог отрядындагы заставаларда чикне саклау буенча хезмәт итәргә тиеш идек. Андагы 4әр-5әр километр биеклектәге заставаларда хезмәт итү бик авыр, әлбәттә. Шартлар бик катлаулы булганлыктан, Хорог отрядындагы заставаларда хезмәт иткән солдатларга хезмәт срогы ике генә ел, башка җирләрдә исә – өч ел. Авыр булса да түзәрмен, аның каравы тизрәк өйгә кайтырмын дип, үземне тынычландырып йөрдем. Ләкин миңа яңадан Хорогка китәргә насыйп булмады. Курсант булып берничә ай йөргәннән соң, мине часть командиры полковник Чабаненко (полковникның фамилиясен дә онытмаганмын икән әле) үзенә чакырып алды. "Без сине офицерлар белән бергә җитди эшләр башкарырга штабка алабыз", – ди. Мин аңа, сержантлар мәктәбен тәмамлагач, яңадан Памирга Хорогка китәргә тиеш икәнлегемне әйттем. Ул мине елмаеп кына тыңлады да: "Син монда минем приказ буенча калачаксың, ә армиядә приказны тикшереп тормыйлар, үтиләр генә", – диде. Шулай итеп, минем мондагы хезмәтем икенче төрлегә әверелде. Полковник минем турында мәгълүмат алган, армиягә кадәр нинди уку йортын тәмамлаганлыгымны һәм кайда нинди эштә эшләгәнлегемне белешкән булган. Аларга штабта исәп-хисап, оештыру эшләрен белгән, тиешле белеме һәм эш тәҗрибәсе булган кеше кирәк икән. Хәерле булсын дип, штабта эшли башладым. Эштән буш вакытта башка солдатлар белән бергә, казармада, армия режимы буенча яшәдем, әлбәттә. Эшем күбесенчә язу-сызудан гыйбарәт, ләкин җитди генә оештыру эшләре дә башкарырга туры килде.

Сталинабадтагы хезмәтем ике ел булды. Начар хезмәт итмәдем булса кирәк. Гадәтем буенча, эшемне җиренә җиткереп башкардым, устав буенча тиешле вазыйфаларымны да тәртипле итеп үтәдем. Һәм бөтен аңлы тормышымда кызыл җеп булып сузылган үзенчәлекле сыйфат: җәмәгать эшләрендә актив катнаштым. Армиядә актив кешеләрне тиз күреп алалар: комсомол бюросына сайлап куйдылар, стена газетасын чыгару вазыйфасын йөкләделәр. Ул чакта комсомол – һәркайда яшьләрнең алдынгы отряды, армиядә дә шулай. Подразделениедә устав тәртибен, әхлак нормаларын саклау кебек гамәлләрдә актив катнаштым, җыелышларда чыгышлар ясый идем. Кыскасы, активист. Шуңа күрә, бер ел узуга, мине Коммунистлар партиясе членлыгына кандидат итеп, ә тагын бер елдан партия члены итеп кабул иттеләр. Ул чакта партиянең роле зур, һәм яшь солдатны аның сафларына алу аның уңышларын тану һәм зур ышаныч белдерү булып санала иде. Шунысы игътибарга лаек: миңа партиягә рекомендацияләрне зур чинлы офицерлар бирде һәм частьның, нигездә, офицерлардан торган партия оешмасының җыелышында минем турыда тәҗрибәле командирлар җылы сүзләр сөйләделәр.

Сталинабадтагы сержантлар мәктәбендә минем белән Татарстанның Актаныш районыннан Фәнис исемле егет хезмәт итте. Армиядә үз милләтең кешесе, бигрәк тә бер яктан булса, туганың кебек якын була. Фәнис белән мин дә шундый дуслар идек. Әйбәт, тырыш, акыллы егет иде ул. Аның күп төрле һөнәрләре арасында армия өчен бик әһәмиятле итекче һөнәре барлыгы билгеле булды. Ә анда курсантларның итекләре тиз туза, тишелә. Ямарга, итеккә баш куйдырырга кирәк. Фәнисне шул эшкә җәлеп иттеләр. Көне буенча 40 градуслы эсседә “айт-два”га телеңне чыгарып йөгереп йөрүгә караганда, мастерскойда эшләп утыруың хәерлерәк. Фәнис бик кирәкле белгеч булып китте. Аңа солдатлардан тыш, офицерлар, старшиналар да итекләренә яңа баш куйдырталар иде. Миңа да ярдәме тиде Фәнис дусның. Берничә айга бер пар күн итек бирәләр. Минем итекнең кунычы тузмый, башы гына бераз таушала. Фәнис аны яңа күннән тегеп бирә, яңа итек килеп чыга. Складтан алган итек янга кала. Аны Фәнис белән часть коймасының теге ягында якында гына яшәгән таҗикларга чыгарып сатабыз. Минем товароведлык һөнәрем ярап куйды. Бу җинаять түгел, үзебезнең итек бит. Увольнениегә чыгарга акча була. Таҗикларның ничек яшәгәнлеген дә күрәбез. Алар үзбәкчә белә, без дә кардәш телне ярыйсы гына

сукалыйбыз. Безне чәй белән сыйлыйлар, әңгәмә корабыз. Чәй эчү тәртибе үзенчәлекле. Алар гаиләсе белән келәм җәйгән идәнгә аякларын бөкләп табын тирәсенә түгәрәкләнеп утыралар. Безне дә яннарына чакырып утырталар. Аякларны җәфалый-җәфалый бөкләп утырабыз без дә. Бер өлкән кеше чәйне касәнең төбенә генә агызып бирә дә, табында утырганнарның һәркайсы аны, эчеп бушатып, күршесенә бирә. Анысы, шул ук касәгә яңа чәй салдырып эчеп куя да, икенче күршесенә бирә. Шулай бер касә түгәрәк буенча йөри. Без дә алар белән бергә шулай итеп эчтек. Кирәкми дип утыра алмыйсың. Кунак булсаң, тыйнак бул, диләр бит. Итек сатып, акча эшлисең килсә, бигрәк тә дустанә булырга туры килә сатып алучы белән.

Армиядән кайткач, кызык хәл булды. Үзара сүз куешмаган килеш, Фәнисләр улларына Рүзәл исемен кушканнар, ә без улыбызга Фәнис исемен бирдек.

Сталинабад (Дүшәмбе), яшеллекле, матур шәһәр булса да, солдат халкына яшәү җиңел түгел. Бик эссе. Көндез күп вакытта температура күләгәдә 40 градустан артып китә, ә кояш астында күпме буладыр! Ә без һәрвакыт гимнастерка-чалбардан, калын күн итектән, фуражкадан яки пограничник панамасыннан. Кояш иртә таңнан кояш батканчы кыздыра. Болыт әсәре күренми. Җил дә юк, яңгыр да юк. Шундый көннәр апрельдән октябрь-ноябрьләргә кадәр дәвам итә. Кайбер көннәрдә шул якларга гына хас әфган өермәсе (афганка) була. Күк йөзен ком тузаны басып ала, кояш та тонык кына күренә. Сулыш алу авырая, ком тузаны күзгә, авызга керә. Шундый мәхшәр берничә сәгать дәвам итә. Аннары һава әкренләп чистара. Ул ком өере әкрен генә җил белән Әфганстан якларыннан килә, дип сөйләделәр.

Казарма тәбәнәк түшәмле, һава җитми, бик бөркү. Кроватьлар ике катлы. Төннәрен йоклау кыен, озак йоклап китә алмый ятасың. Дневальныйдан өскә ябынган җәймәгә су сиптертәбез, бераз гына рәхәт булып тора, ләкин дым тиз кибеп бетә. Иртәнгә таба һава бераз гына салкынаеп, тәмләп йоклап китәсең, ул арада “подъем” командасы яңгырый: йокы туймый.

Курсант солдатларга бигрәк тә авырга туры килә. Алар яндырып торган кояш астында ачык далада чик саклау дәресләре үткәрәләр, төрле күнегүләр эшлиләр, йөгерәләр, гимнастеркаларының җилкәләре тирдән җыелган тоз белән агарып каткан була.

Безнең часть янында экскаватор белән казып ясалган бассейн бар иде. Суны шуннан ерак түгел аккан кечкенә елгадан җирне казып кертеп тутыралар. Шул бассейнда без кайчакта су коенабыз. Бер кызык нәрсә: суда бик күп еланнар йөри. Безнең тирәдә чылт-чылт итеп башларын чыгарып алалар. Хәлебезне белешергә яки танышырга телиләр, ахрысы. Башта куркынычрак иде. Аннары ияләндек. Безгә тимәделәр, рәхмәт төшкерләре.

Солдат тормышының бераз гына рәхимле яклары да бар. Кичләрен часть клубында кинофильмнар күрсәтәләр. Кайчакларда шәһәрдән төрле уку йортларыннан, завод-фабрикалардан яшьләр, безнең частька килеп, очрашулар, кичәләр оештыралар. Күренекле шәхесләр белән очрашулар да булгалады. Мәсәлән, йөзләгән чик бозучыларын тоткан данлыклы полковник Карацупа безгә килеп чыгыш ясады. Бик кызыксынып тыңладык.

Айга бер тапкыр увольнениегә чыгасың. Тәртип бозсаң, анысыннан да мәхрүм буласың. Армия армия инде ул, ирекле тормыш түгел. Аның “рәхәтлекләрен” хезмәт иткән кеше үзе генә белә.

Мин хезмәт иткән еллар илнең икътисад хәле авыр чак иде әле. Шуңа күрә ашау-эчү дә мактанырлык түгел. Солдат ашы өй ашы түгел инде ул, бик кырыс, бертөрле, тәмле итеп пешермиләр, аш төрләндерү, ризыкны тәмлерәк итеп әзерләү дигән төшенчә юктыр. Безгә, мәсәлән, компотны да бәйрәмнәрдә генә бирәләр иде.

Хәзерге солдатларның хәле, ишетеп, экраннан карап белүебезчә, ул вакытлардагылар белән чагыштырганда, күп яхшырак. Шулай булсын. Шулай булырга тиеш тә.

Армия хезмәтендәге вакыйгалар турындагы хатирәләргә караган бер үзенчәлекле күренеш: пропорция буенча исәпләгәндә СССР армиясендә руслардан кала иң күбе украиннар булгандыр. Мин хезмәт иткән частьтә дә алар күп булды. Минем белән штабта эшләгән офицерлардан гына да полковник Чабаненко, подполковник Тараненко, майор Лысенко, старшина (фамилиясен оныттым, шулай ук “ко”га тәмамлана), сержант Проценко... тагын кемнәрдер бар иде. Сүз уңаенда әйтим: миндә украиннар табигатьләре белән, армия хезмәтендә булып, хәрби исемнәргә (званиеләргә) һәм бүләкләргә ия булырга ярата торган халык дигән тәэсир калды. Аларның 1941-45 нче елгы Ватан сугышында зур исемнәр алган кешеләр булуы да очраклы хәл түгелдер.

Һәм менә хәзер Россия сәясәтчеләренең шул Украина халкы белән җитди сәбәпсез, төрле уйдырмалар белән территориаль ни-

загка керүен һәм ике тугандаш халык арасында мөнәсәбәтләрне бозуларын аңлап булмый. Хакимият ияләре зирәк акыл белән эш итсеннәр иде. Россиягә ни җитми икән? Курил утрауларыннан Калининградка кадәр иксез-чиксез территория һәм хисапсыз күп табигать байлыклары! Шул колачлап бетермәслек территориядәге эшкәртелмичә яткан миллионлаган гектар уңдырышлы җирләрдән, әрәм-шәрәм ителгән бихисап байлыклардан үз халкың өчен акыллы файдаланырга кирәк, лабаса! Гаҗәп зур байлыкларыбыз, зур мөмкинлекләребез булган илебездәге күпчелек халыкның кыенлык белән көн күрүен һәм тормыш хәленең көннән-көн кыенлаша баруын күреп, йөрәк әрни...

Ярый, төп темага, ягъни минем хәрби тормышыма әйләнеп кайтыйк.

Сталинабадтагы солдат тормышы үз җаена барганда, радио репродукторыннан көн-төн колакны тондырырлык итеп яңгырап торган таҗик-үзбәк музыкасын ишетеп туеп, кайчан кайтыр вакытлар җитәр икән дип, Татарстанны сагынып йөргән көннәрнең берсендә бер мавыктыргыч яңалык белдем. Урта Азия чик буе хәрби округының Ташкенттагы бер частен мөстәкыйль подразделение буларак бетерергә дигән карар кабул ителгән. Ләкин ул частьтә бөтен округның чик буе заставаларындагы хәрби персоналны тукландырып (ашлар һәм икмәк пешереп) торучыларны әзерли торган кечкенә подразделение калдырып, аны безнең Сталинабадтагы сержантлар мәктәбенә кушарга булганнар. Шул уңай белән анда исәп-хисап, хуҗалык эшләрен оештыручы бер кеше кирәк булып чыкты. Бу хәбәрне ишетеп, минем башыма бер шәп фикер килде. Шул вазыйфаны башкарырга мине җибәрмәсләрме икән?! Һәм кыюлыгымны җыеп, үземнең турыдан-туры начальнигым майор Лысенкодан шушы теләгемне үтәгезче, дип гозерләндем. Бу үтенечемнең җитди нигезе бар: Ташкентта минем туганнарым (агай-энеләрем) һәм малай чактагы күрше дустым Фәрит яши. Рәхмәт яугыры – майор минем гозеремне кабул итте. Аның кул астында тырышып хезмәт иткән булуымның ярдәме тигәндер, мөгаен.

Шулай итеп, мин Ташкент шәһәренә Сталинабадтагы сержантлар мәктәбенең чик буенда хезмәт итүчеләргә ашарга пешерүчеләр (повара-хлебопекы) әзерли торган бүлегенә киттем. Мине бу бүлекнең начальнигы – майор җылы каршы алды. Аңа телефоннан минем киләсен хәбәр итеп куйган булганнар.

Часть яңа гына бетерелгән булганлыктан, берничә бина бушап калган килеш тора. Бер бинада ашарга пешерү һөнәренә өйрәнүчеләр солдатлар яши (чик буендагы заставаларда барлык хуҗалык эшләрен дә, шул исәптән ашау-эчү ризыкларын әзерләүне дә солдатлар үзләре башкара), подразделение начальнигы майор һәм старшиналар эшли. Миңа тиешле җиһазлары, телефоны, мебеле белән бер кабинет бирделәр. Минем вазыйфаларым: подразделение тормышы белән бәйләнешле документация эшләрен башкару, солдат-курсантларны азык-төлек белән тәэмин итү (китерелгән продуктларны складка кабул итеп алу (складка мин үзем җаваплы), яшелчә продуктларын колхоз-совхозларга барып алып кайту, продуктны ашханәгә бирү). Кыскасы, минем өстә үзенә күрә шактый гына җаваплы вазыйфалар. Миңа, Кургандагы Усть-Уйка райпотребсоюзында эшләп килгән кешегә, бу эшләр авырдан саналмый иде инде.

Ташкентта мин октябрь аеннан киләсе елның маена кадәр булдым. Бу ярты елдан артык дәвер минем армия хезмәтемнең иң уңай вакыты булды. Чөнки мин монда асылда начальнигыбыз майорның уң кулы – исәп-хисап, хуҗалык эшләре буенча урынбасары кебегрәк халәттә идем. Хәтта Сталинабадтагы хәрби частьнең дубль печатен (төп печатьнең хуҗалык эшләре өчен яраклы экземплярын) миңа ышанып тапшырдылар. Миңа хәтта хезмәтемнән буш вакытта тору өчен аерым бүлмә бирделәр. Кыскасы, шактый зур мөстәкыйльлеккә ирештем. Мин, әлбәттә, артык иркенләп, тәртипсезләнеп, армиядә икәнемне онытып йөрмәдем.

Сталинабадтан килгәндәге хыялым да тормышка ашты: ял көннәрендә Ташкенттагы һәм аннан 30 гына чакрымда урнашкан Чирчик шәһәрендәге туганнарыбызга (әнинең ике сеңелесе һәм әбиебезнең сеңелесе гаиләләренә) барып йөрү мөмкинлеге булды. Авылдаш дустым Фәрит белән дә очрашкалап тордым.

Минем бәхетемә, 1960 нчы елны армиядән өч-дүрт айга алданрак кайту мөмкинлеге чыкты. Мин май аенда үзебезнең Казанда әти-әниләрем, туганнарым янында идем инде. Ул чакта олы абыебыз Равилдән соң Наил абый да, армиядән кайтып, Казанда урнашкан, энем Әнәс тә Казанда укый һәм төпчек энебез Мөнир белән әти-әниләребез дә авылдан күченеп килгәннәр иде. Барыбыз да Северный поселогында Равил абыебыз төзегән зур йортта тупландык. Равил абый үз семьясы белән, калган егетләр – ялгызаклар кайсысы эшли, кайсысы укый.

## ЗУР ГЫЙЛЕМ ЙОРТЫНДА

Мин армиядә үк, кайткач укыячакмын дип, план корып куйган идем. Казан университетына укырга керү өчен, әзерләнә башладым. Югары уку йортына керүем үзенчәлекле, оригиналь булды, дисәм дә ярый торгандыр. Хикмәт шунда: мин, татар мәктәбенең 8-10 нчы классларында укымаган килеш кенә, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керергә булдым. Бу тәвәккәл адым иде. Чөнки монда конкурс зур, бер урынга биш кеше һәм татар теленнән урта белем күләмендә кабул итү имтиханнары бирәсе. Өч-дүрт айда нык кына әзерләндем. Ләкин бу өч ел укыйсы өчен азрак иде, әлбәттә. Шөкер, планым барып чыкты: имтиханнарны яхшы һәм бик яхшы билгеләргә тапшырып, университет студенты булып кабул ителдем. В.И.Ульянов укыган Ленин исемен алган уку йорты бик шөһрәтлеләрдән. Шуңа күрә анда, бик теләп, лаеклы егет-кызлар укырга килә иде.

Мин кергән бүлектә җитди яшьләр җыелган, егетләрнең күбесе армиядә хезмәт итеп кайткан, кызлар ике-өч ел эшләп килгән. Соңыннан аларның барысы да диярлек республикабызның алдынгы белгечләре, абруйлы шәхесләре булдылар: Фирдәвес Гарипова, Флера Әхмәтова-Баязитова – фән докторлары, күренекле галимәләр, Роза Ханнанова – Татарстанның китап палатасы директоры, Равил Фәйзуллин – Татарстанның халык шагыйре, парламент депутаты, Тукай премиясе лауреаты, Фарсель Зыятдинов – икътисад фәннәре докторы, язучы, журналист, күренекле бакчачы, Әнвәр Шәрипов – фәннәр докторы, шагыйрь, Шамил Маннапов – күренекле шагыйрь, журналист, Шәрифҗан Асылгәрәев – галим, Тел, әдәбият, тарих институтының директоры урынбасары, Лениза Галиева – Татарстанның атказанган укытучысы...

Группабыз махсус сайлап алган кебек: бөтенесе дә бик тырышып укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, барысы да тиешле белем алып, лаеклы белгечләр һәм күркәм шәхесләр булыйк дигән рух белән сугарылган затлар. Без укыган елларда югары уку

йортларында, Казан университетында бигрәк тә, белгечләрне эрудицияле, һәрьяклы итеп әзерләүгә, тиешле белем бирүгә, яшьләрне җитди тормышка яраклы итеп тәрбияләүгә зур игътибар бирелә, югары таләпләр куела иде. Безнең группа студентлары бердәм һәм тырыш булулары белән тарих-филология факультетында гына түгел, бөтен университетта башкалардан аерылып торды. Без җәй көннәрендә һәм көзләрен колхоз-совхозларга иген җыярга, бәрәңге алырга булышып, ярыша-ярыша эшләдек. Кичләрен авыл кешеләренә концертлар куйдык. Группабыз үзе бер концерт бригадасы сыман: җырчыларыбыз да, биючеләребез дә, шигырь укучыларыбыз да бар. Лениза Галиева матур итеп җырлый, бии дә, Ленар Җамалетдинов – группа старостасы – интермедия остасы, концертны алып баручы, Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов үз шигырьләрен укыйлар, Әнвәр Шәрипов бии, Роза Ханнанова – комсорг, оештыручы. Ленар үзе музыка да язды, без аны хор белән җырладык. Мин дә эшсез калмадым: концерт алдыннан халыкара темаларга лекция сөйлим, концертта гармун уйныйм һәм биим...

Бик актив булдык. Шуа күрә группабыз, бөтен университет буенча конкурста икенче урынга лаек булып, Ленинградка экскурсиягә бару өчен бушлай путевка белән бүләкләнде.

Минем үземә беренче курстан ук җаваплы эш йөкләделәр: безнең татар филологиясе бүлеге, тарих бүлеге, рус филологиясе бүлеге һәм рус-татар филологиясе бүлекләрен берләштергән тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре урынбасары, ә икенче курстан аның секретаре итеп сайлап куйдылар. Комсомол ул елларда бик актив сәяси көч иде. Без күп төрле эшләр башкардык. Миңа һәр көнне, укудан тыш, төрле чаралар үткәрергә туры килә иде. Уку да күп вакытны ала. Дәресләрдән соң университет һәм республика китапханәләрендә төнгә кадәр утырып, өйгә соң гына кайта торган идем. Китапханәләргә ял көннәрендә дә барып йөрдем. Укуым уңышлы барды: беренче көннәрдән алып университетны тәмамлаганчы, сессияләрдә барлык имтиханнарны да бишлегә генә тапшырып бардым: дипломымда барлык предметлардан да бишле билгеләре генә. Бик яхшы уку белән бергә зур җәмәгать эшләре башкаруым өчен, Россия министры приказы белән өченче курстан Ленин стипендиясе алып килдем. Ул стипендия күп меңләгән студентлар укыган университеттан 3-4 кешегә генә бирелә иде.

Җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып, бөтен предметлардан да бишлегә генә уку зур көч һәм түземлек таләп итә. Әмма

болай укуыма үкенмим. Шулай эшләгәндә генә яшәвең мәгънәле, хезмәтең югары нәтиҗәле була.

Өченче курстан безнең группадан дүрт студентка: Ленар Җамалетдинов, Фарсель Зыятдинов, Шәрифҗан Асылгәрәев һәм миңа индивидуаль план белән укырга рөхсәт иттеләр. Һәркем, фәннең теләгән тармагын сайлап алып, үзе өчен генә махсус уку планы төзеп укыды. Мин тәрҗемә теориясе һәм практикасы дигән белгечлекне сайлап алдым һәм шуның буенча өстәмә предметлардан имтиханнар тапшырдым. Дипломыма, татар теле һәм әдәбияты белгечлегенә өстәп, филолог-тәрҗемәче квалификациясе бирелде дип тә язылган.

Дүртенче курста, авыл мәктәпләрендә укытучылар җитешмәү сәбәпле, безнең группа студентларын, читтән торып уку системасына күчереп, бер уку елында укытучылар итеп эшләргә район мәктәпләренә җибәрделәр. Безне, индивидуаль план белән укучыларны Казанда калдырдылар. Һәм без кызыклы тәҗрибә ясадык: дүртенче курс зачет-имтиханнарын үзлегебездән әзерләнеп тапшырдык, бишенче курс студентлары дәресләренә йөреп, алар белән бергә бишенче курс имтихан-зачетларын да бирдек. Шулай итеп, соңгы ике курсның уку планын бер елда үтәдек. Диплом язып яклыйсы гына калды. Анысын үзебезнең группа белән башкардык. Университетта уку срогын тәмамлаганчы, бушап калган бер елыбызда кайдадыр эшләп торырга булдык. Башта Фарсель Зыятдинов радиога корреспондент булып эшкә урнашты. Шул чакта радионың музыкаль тапшырулар редакциясендә урын бушаган да, шунда Ленар Җамалетдинов урнашты. Ул арада радиода күп еллар тәрҗемәче булып эшләгән Абдулла абый Төхфәтуллин пенсиягә чыгарга карар кылган. Мин, индивидуаль план буенча тәрҗемәче белгечлегенә әзерләнгән кеше буларак, шулай ук радиодагы бушаган урынга тәрҗемәче булып эшкә керергә булдым. Мине бер айлык сынау срогы белән алдылар.

Радиодагы яңа эшем турында сөйли башлаганчы, безне университетта укыткан хөрмәтле укытучыларыбызны искә алып китим әле.

Югары уку йортының абруе, даны һәм студентлар белеменең сыйфаты аның укытучыларының дәрәҗәсенә, күренекле галим-педагоглар булуына бәйләнгән. Безне укыткан укытучылар, нигездә, шундый югары дәрәҗәле гыйлем ияләре. Ул елларда әле аларның күбесе – фронтта булып кайткан урта һәм өлкән яшьтәге кешеләр иде. Безнең факультетның деканы – сугышта булган абзый, рус әдәбияты профессоры Николай Александрович Гуляев,

аның урынбасары – соңыннан республикабызның хөрмәтле зур җитәкчеләреннән берсе, Татарстан фәннәр академиясенә нигез салган олуг галим Мансур Хәсәнович Хәсәнов, татар әдәбияты кафедрасы мөдире – элекке фронтовик, язучы-профессор Хатыйп Усманович Усманов, татар әдәбияты кафедрасы профессоры – сугышта аягын калдырып кайткан язучы Ибраһим Зиннәтович Нуруллин, татар теле кафедрасы профессоры – Ленинградта дөнья күләмендә мәгълүм галимнәрдән белем алган профессор, соңыннан Татарстан фәннәр академиясе академигы Диләрә Гарифовна Тумашева, фәнни коммунизм дигән предмет укытучысы, Татарстанның партия өлкә комитеты секретаре, профессор Камил Фатыйхович Фасеев. Безне укыткан бу күренекле шәхесләрнең исемлеген дәвам иттерергә мөмкин. Алар арасыннан Камил Фатыйхович белән танышлыгым аеруча җылы истәлек булып саклана. Фәнни коммунизмнан рус телендә лекцияләр укыганда, тәнәфесләрдә ул безнең белән татарча сөйләшеп ала иде. Имтихан биргәндә: “Егетләр, кайсыгыз татарча сөйләргә тели?” – дип мөрәҗәгать итә безгә. Русча укып, иҗтимагый-философик темага татарча сөйләү җиңел эш түгел. Безнең егетләр дәшми. Шунда мин, батырчылык итеп: “Мин сөйләп карыйм”, – дидем. Материалны белә идем. Әмма татарча бик үк шома сөйли алмадым бугай. Камил Фатыйховичка үзебезчә җавап бирү ошады булса кирәк, миңа бишле билгесе куйды. Ул гына да түгел, үзенә шушы фәннән аспирантурага керергә тәкъдим итте. Мин, рәхмәт әйтеп, әдәпле генә баш тарттым, чөнки мин ул чакта инде радиода эшли башлаган идем. Без аның белән соңыннан да очрашкаладык, миңа үзенең бер китабын да бүләк итеп бирде. Аның кызы Роза исемле күркәм ханым мин ректор чагында безнең педагогика институтында (университетында) чит телләр укытучысы булды.

Соңыннан миңа шул мәгълүм булды: Камил Фатыйхович Фасеев бик милләт җанлы җитәкче һәм галим булган икән. Ул Татарстан өлкә комитетының идеология буенча секретаре булып эшләгәндә, татар халкы өчен бик файдалы фидакарьлек гамәлләре кылган. Аның инициативасы белән, татар теленең кулланылышын җәелдерү, татар телен өйрәтү-укытуның сыйфатын күтәрү, татар мәктәпләренең эшен яхшыртуга багышлап, бик әһәмиятле махсус зур җыелыш уздырылган һәм бу үтә мөһим эшләрне тамырдан яхшыртуны күздә тоткан карар кабул ителгән. Ул авыр заманнарда халкыбызны алга җибәрү, аның телен, мәдәниятен җанландыру, үстерү хакына кылынган бу күркәм эшләр – туган телебезнең яшәешенә шартлар кыryслана барган хәзерге чорда республика җитәкчеләре өчен лаеклы үрнәк.

## ТӘРҖЕМӘЧЕҺӘМ ЖУРНАЛИСТ

Бер айлык сынау шарты белән радиога тәрҗемәче итеп эшкә алдылар дигән идем. Тәрҗемә ул – җиңел эш түгел, оригиналның мәгънәсен дә төгәл белдерерлек итеп, тәрҗемә телен дә бозмыйча тәрҗемә итү бигрәк тә. Мин, язып киткәнемчә, университетта бу эшнең теориясен үзләштереп, берникадәр язып тәрҗемә итү күнекмәсен дә алган идем: газеталарга тәрҗемә иткәләдем һәм берике кечкенә китап та тәрҗемә итеп бастырган идем. Ләкин җайлап кына язып тәрҗемә итү бер нәрсә, ә, оригиналдан укып тәрҗемә итеп, бастырып тору икенче нәрсә. Монысы бермә-бер авыррак.

Минем, оригиналны укып, шунда ук телдән тәрҗемә итү тәҗрибәм бөтенләй юк. Ә радиода телетайптан алган ашыгыч хәбәрләрне, шундук тәрҗемә итеп, эфирга чыгарырга кирәк. Абдулла абый бу эшнең "ас"ы, утызмы-кырыкмы еллык тәҗрибәсе бар. "Син әле бер елсыз да телдән тәрҗемә итәрлек була алмыйсың", – диделәр кайберәүләр. Ә миңа бу һөнәрне бер айда үзләштерергә кирәк. Югыйсә, соң булачак.

Теш-тырнагым белән ябышып дигәндәй тырыштым. Телетайп аппаратыннан текстны алып карап чыгам да машбюрога керәм, машинистка Суфия апа янына утырам. Ул күркәм, миһербанлы ханым. Искиткеч оста һәм тиз баса. Әллә инде машинка төймәләренә карамыйча да баса ала: тәрәзәдән ишегалдына карый-карый, сөйләшә-сөйләшә эшли. Мин җөмләне әйтеп кенә бетерәм, ул шундук басып та куя. Кайсыдыр сүзне, тәгъбирне ялгышрак итеп әйткәнемне абайлап алам да: "Суфия апа, гафу итегез, шуны төзәтик инде", – дим, бик уңайсызланып кына. Акыллы кеше иде шул, рәхмәт яугыры. Минем хәлне аңлап: "Ярый, ярый, зыян юк, хәзер үзгәртербез", – дип төзәтеп басып та куя.

Көндез ашыгыч хәбәрләрне машинисткага әйтеп торып (телдән) тәрҗемә итәм, кичен башка хезмәткәрләр кайтып киткәч тә калып, кайбер материалларны язып тәрҗемә итәм. Мин тәрҗемә

иткән текстларны редактор – язучы Барлас Камалов редакцияли. Мин тәрҗемә итеп биргән текстларны редакцияләү аңа Абдулла абый эшләп биргән такстларны төзәтүгә караганда мәшәкатьлерәк булгандыр, мөгаен: ихтимал, минем хаталар күбрәк булгандыр. Табигый хәл.

Кичләрен өйгә соң гына кайтам. Еракта, Северный поселогында яшибез. Берничә транспортта йөрим. Бер елда ике курс имтихан-зачетларын тапшыру (барысын да бишлегә генә) һәм бу яңа авыр эш минем сәламәтлегемә яман эзләр салган: күзләрем авырта башлады һәм кич эштән өйгә кайтканда юлда берничә мәртәбә борынымнан шыбырдап кан акты. Бер тапкыр канны поликлиникада врачлар гына туктата алды: борыныма бер метрлап марля тутырдылар.

Минем бер айлык сынау һәм рәхимсез сыналу чоры узып китте. Мине Татарстан АССР Министрлар Советының радио һәм телевидение комитетының радио бүлеге директоры Фәтхи Фазылҗанович Фазылҗанов кабинетына чакырып алды. Ипле генә сөйләшә торган өлкән яшьтәге күркәм абзый (чыгышы белән безнең Әтнә районыннан) миңа әйтә: “Энем син әйбәт егет, ләкин без сине штатка кертеп эшкә ала алмыйбыз, үпкәләмә. Безгә тәҗрибәле тәрҗемәче кирәк”. Бу карарның идеясен редактор Барлас Камалов әйткәндер. Берсенә дә үпкәм юк. Дөресе шулайдыр. Күңелем тулды, әлбәттә. Дөнья шулайдыр инде, һәрвакыт уңышлар гына булып тормый, уңышсызлыклар да очрый, аларны да кичерә белергә кирәк, дип уйлыйм.

Шул ук көнне (мин өйгә кайтып китәргә өлгермәгән идем әле) радиода тәрҗемәче Абдулла абыйны пенсиягә рәсми рәвештә озату утырышын үткәрделәр. Мине дә чакырып керттеләр. Гадәттәгечә, аңа җылы сүзләр, рәхмәтләр әйттеләр, мактадылар. Абдулла абый җавап сүзен әйтте. Сүзенең азагында: “Минем урыныма ышанычлы егет кала”, – диде, миңа карап. Мин аның бу сүзләренә каршы: “Ышанычыгыз өчен рәхмәт, Абдулла абый, ләкин мине калдырмаска булдылар бит инде”, – дидем. Абдулла абый, моны ишеткәч, кабынып китеп: “Кем әйтте алай дип, нишләп минем белән киңәшмәгәннәр, син эшли аласың”, – диде һәм директорга карап: “Әгәр дә бу егетне җибәрсәгез, мин риза түгел”, – дип өстәде.

Һәм минем эштә калу-калмавым мәсьәләсе шуның белән хәл ителде. Мине приказ белән эшкә алдылар, һәм мин радионың штаттагы тәрҗемәчесе булып эшли башладым.

Тәрҗемә эшен үзләштердем. Ярыйсы гына эшләдем кебек. Зарланучы, гаепләүчеләр булмады. Үзем белмәгән хәлләр булса гына инде. Хәер, начар эшләү гадәтем юк иде. Шул вакытта һәм соңрак та мин берничә җитди әсәр тәрҗемә итеп бастырдым. Иң җитдие һәм иң авыры – В.И.Ленин әсәрләренең 4 нче басмасыннан 44 нче һәм 45 нче томнарын татарчага тәрҗемә итү булды. Шулай ук Маркс, Энгельс, Ленинның әдәбият, сәнгать һәм дин турындагы китапларын тәрҗемә итеп бастырдым. Һәм тагын фәнни-техник эчтәлекле берничә китапны русчадан татарчага тәрҗемә иттем. Тәрҗемә эшендәге тәҗрибәм миңа соңыннан диссертацияләр язганда ярдәм итте.

Радио коллективына ияләшеп килә идем инде. Ярты елдан миңа телевидениедә редактор булып эшләргә тәкъдим булды. Телевидение минем өчен өр-яңа өлкә булса да, ризалык бирдем. Хәтеремдә: көзге бер көнне мине радиодан телевидениегә машина белән телевидениенең баш редакторы Итфал Исхакович Ихсанов алып китте. Яңа эш, яңа коллектив. Тәвәккәл таш яра, ди бит халык. Мин дә тәвәккәлләдем. Тормышымда аннан соң да тәвәккәллек белән бәйләнгән гамәлләр кылырга туры килде.

Мине пропаганда редакциясенә татарча тапшырулар редакторы итеп куйдылар. Бу телевидениедәге башка редакцияләр арасында аеруча күп төрле тематикалы тапшырулар редакциясе иде. Монда пропаганда һәм агитациягә, мәгарифкә караган, тарихи эчтәлекле материаллар, хокук саклау органнарының эшләре, хәрби тематика, төрле бәйрәмнәр һәм башка төрле темаларга багышланган тапшырулар әзерләнеп эфирга чыгарыла иде. Мин, артык иза чикмичә, бу яңа эшемне үзләштердем һәм тиздән аңа күңелемне биреп хезмәт итә башладым.

Телевидениедә эшләү минем рухи тормышымны баетты, белемемне, эрудициямне арттырды һәм телевизион журналистика эшенә өйрәтте. Тапшырулар планын төзү, әһәмиятле тапшыруларны әзерләп, эфирга чыгару өчен лаеклы авторлар, катнашучылар, чыгыш ясаучылар эзләп табып җәлеп итү, шулай ук тапшыру текстларын редакцияләү һәм башка кайбер эшләр минем вазыйфаларыма керә иде. Болардан тыш, мин турыдан-туры үземнең авторлыгымдагы тапшырулар да әзерләдем. Шушы гамәлләрне башкару уңаеннан миңа төрле оешмаларда, промышленность предприятиеләрендә, колхоз-совхозларда булырга, күренекле

шәхесләр белән очрашырга туры килде. Кайбер тапшыруларымда үзем дә эфирга чыгып сөйли идем.

Шулай ук беренче ел эшләгәндә, университетта диплом эше язып, аны якладым. Русчадан татарчага тәрҗемәнең лексика мәсьәләләренә багышланган хезмәт булды ул. Мактанып әйтмим, дөресе шул: ул диплом эшем шактый җитди һәм зур күләмле булып чыкты. Аны яклагандагы рецензентым профессор Фоат Әшрәфович Ганиев, эшемә югары бәя биреп, бу диплом кандидатлык диссертациясенә якын, дигән иде. Дипломымның җитәкчесе профессор М.З.Зәкиев, университетны тәмамлап, диплом алгач, үзе җитәкчелегендә аспирантурага керергә тәкъдим итте. Мин әдәпле генә итеп баш тарттым, берничә ел эшләргә кирәк миңа, дидем һәм берникадәр вакыттан тәрҗемә теориясе буенча фәнни эшемне дәвам иттерергә вәгъдә бирдем. Вузны тәмамлагач та, аспирантурага кермәвемнең сәбәбе гаиләнең икътисади нигезен җайга салу ихтыяҗы иде.

Казан телевидениесенең коллективы, анда хөкем сөргән мохит һәм нәтиҗәле эшләү өчен шартлар уңай иде, һәм мин анда теләп, канәгать булып эшләдем.

Мәгълүм ки, һәркемнең эше уңышлы булуы өчен, җитәкчеләр белән коллектив арасында һәм коллектив членнарының үзара тыныч, тату, мәрхәмәтле мөнәсәбәт, ягъни фәннирәк итеп әйткәндә, яхшы микроклимат булуы мөһим. Мин бу шартның бик әһәмиятле икәнлеген аңлап, Казан педагогика университетының җитәкчесе булып эшләгәндә, үзебезнең күп санлы укытучылар һәм хезмәткәрләр коллективында шундый мохит булдырырга тырыштым һәм моның хәерле нәтиҗәсен күрдем. Коллективта бер-береңә кешелекле, игелекле мөнәсәбәт булдыру барыннан да бигрәк, җитәкченең акыллы эш итүенә бәйле. Ул коллективны аның членнарында гаделсезлек, ризасызлык, аңлашылмаучылык мөнәсәбәтләре килеп чыгудан сакларга, андый күренеш сизелә башлауга ук, аны зурга җибәрмәү, туктату чараларын күрергә тиеш. Үзара хәерхаһлы мөнәсәбәт урнаштыруда җитәкче үзе үрнәк булырга, коллектив кешеләренә үзе игелекле мөнәсәбәттә булырга тиеш.

Мин берникадәр вакыт эшләп алган радио коллективында да һәм телевидение коллективында да, нигездә, үзара тату, бер-береңә игелекле мөнәсәбәт хөкем сөргәнлеген һәм бу һәр ике коллективның җитәкчелегендә дөрес, акыллы җитәкчелек итү стилен күрдем.

Радио һәм телевидение комитеты председателенең телевидение буенча урынбасары Хәйдәр Сөләйманович Шакирҗанов беренче күреп сөйләшүдән үк уңай тәэсир калдыра. Урта яшьләрдәге күркәм ир, әңгәмәдәшен игътибар белән тыңлый белә, сүзләрен ашыкмыйча, уйлап кына сөйли, шуңа күрә ул, теге яки бу мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә ялгышса да, бик сирәк ялгыша торгандыр. Безнең татарлар андый кешене төпле кеше диләр.

Иҗтимагый-сәяси тапшырулар буенча баш редактор, безнең редакциянең дә шефы Итфал Исхакович Ихсанов та – Хәйдәр Сөләймановичка охшаш акыллы һәм җитди, вазыйфаларына бик җитди карый торган кеше. Безнең пропаганда редакциясе әзерли торган тапшырулар аның күзәтүендә, аның җаваплылыгында булды һәм аның безнең эшебезгә игътибарлы булып, ярдәм итеп торуы без әзерләгән тапшыруларның сыйфатлы булуына гарантия иде.

Мин эшләгән пропаганда редакциясенең өлкән редакторы, рус тапшырулары өчен җаваплы Людмила Михайловна Пивоварова да – лаеклы журналист. Ул, педагогика югары уку йортын тәмамлап, институтта укыткан, педагогика фәннәре кандидаты, рус телен, әлбәттә, яхшы белә. Минем, телевидение өлкәсендә яңа кеше буларак, тәҗрибәсез булуыма түбәнсетеп карамады, мине сабырлык белән, тыныч кына өйрәтте. Хәер, мин үзем дә аны бик интектермәдем кебек, эшнең рәтенә шактый тиз төшендем. Аның белән бер бүлмәдә кара-каршы утырып эшләдек. Соңыннан Людмила Михайловна Казан университетының журналистика кафедрасына укытучы булып күчте. Хәзерге Казан телевидениесендә аның эшен улы Дмитрий Пивоваров лаеклы дәвам иттерә.

Безнең редакция штатында, ике редактордан тыш, режиссер, режиссер ассистенты һәм режиссер ярдәмчесе бар иде. Режиссер – тәҗрибәле хезмәткәр Калерия Ивановна Косарева – тапшыру сценариесен (текстын) күрсәтү материаллары белән бизәп, аны эфирга чыгару өчен төп җаваплы кеше. Аның театрдагы режиссер һөнәре белән уртаклыгы шактый. Калерия Ивановна үз эшенә җаваплы карый иде. Аның һәм башка редакцияләр режиссерларының да ул вакыттагы эш алымнарыннан бик әһәмиятлесе шул: режиссер, тапшыруны эфирга чыгарганчы, анда катнашучыларны – сөйләүчеләрне алдан яхшылап әзерли, алар белән иренмичә репетиция ясый. Репетициядә чыгыш ясыйсы кешенең сөйләмендәге хилафлыкларны күрсәтеп, төзәтергә тырыша. Начар сөйләүчеләрне ташырудан читләштерергә дә мөмкин иде ул. Хәер, тапшыруда катнашучы-

ларны, табып, телевидениегә чакырып китерү белән, гадәттә, без, редакторлар шөгыльләнәбез. Һәм, димәк, без сөйли белмәгән, начар сөйләгән кешеләрне чакырмый да идек, әлбәттә.

Телевидение тапшыруларында катнашучыларның телләренә, сөйләмнәренә игътибар бирү – бик мөһим гамәл. Ул телевидение тапшыруларында бозык телле кешеләрне катнаштырмас өчен бик кирәкле эш методы иде. Аяныч, хәзер татарча телевидение ташырулары теленең сыйфатына тиешле игътибар бирелми, режиссер тапшыруда катнашучы белән алдан шөгыльләнми, репетиция ясап азапланмый, шуңа күрә татарча тапшыруларда катнашучыларның телләре ташка үлчим дәрәҗәсендә генә, телне бозып куллану күренешләре тулып ята.

Казан телевидениесе оешкан вакытыннан бирле үзенә күп сәләтле, күркәм каләм һәм сүз ияләрен җәлеп иткән. Күренекле язучыларның күбесе анда хезмәт иткән. Мин эшләгәндә дә мәгълүм шәхесләр булды. Мәшһүр Туфан Миңнуллин әдәби тапшырулар редакциясе редакторы иде. Бервакыт аның белән икәү төшке аш ашарга Гагарин урамындагы Фуккерман ашханәсенә киттек. Сөйләшә торгач, минем кебек, аның да заманында Казан кооперация техникумында укыганлыгы мәгълүм булды. Тик ул ун классны тәмамлап, ике еллык бухгалтерлар бүлегендә, ә мин инде, язып киткәнемчә, 7 класстан соң өч еллык товаровед белгечлегенә укыдым. Туфанның кискен итеп турысын әйтү гадәте ул вакытта ук бар иде. Бер эпизод. Атналык тапшыруларга анализ ясап, бәя бирә торган “летучка” (киңәшмә) бара. Рецензент Туфан Миңнуллинның бер тапшыруына карата ниндидер бер тәнкыйтьле фикер әйтте. Туфан, кабынып китеп, каты итеп: “Сез беләсезме, мин төннәр буенча язып (иҗат итеп) утырам”. Аның, чыннан да, бик бирелеп, иҗат белән шөгыльләнә башлаган вакыты булган. Сүз уңаенда: миңа Туфан белән соңрак, мин Югары Совет депутаты булганда да, аннан соң да күп тапкырлар очрашып, төрле чараларда катнашып якын, җылы мөнәсәбәттә яшәргә туры килде. Аның кызы Әлфия дә мин ректор чагында безнең педагогика университетында укытучы булып эшләп алды.

Летучка турында сүз чыккач, шуны әйтим әле: мин эшләгән чорда һәр атнаның дүшәмбе көнендә телестудиянең махсус бер бүлмәсендә редакторлар һәм режиссерлар (ассистентлары белән) җыелып, узган атнада булган тапшыруларга анализ ясау тәртибе бар иде. Татар тапшыруларына бер татар рецензенты, рус телендәге

тапшыруларга бер рус кешесе билгеләнә. Рецензентлар – редакторлар һәм режиссерлар график буенча куела. Бу тапшыруларга анализ ясап, бәя биреп бару эфир продукциясенең сыйфатлы булуына ирешүгә юнәлтелгән акыллы гамәл иде. Хәзер ни өчендер ул юк дип беләм. Ни өчен уңай нәрсәләрне бетерергә? Безнең илдә мондый күренеш башка өлкәләрдә дә хөкем сөрә. Әйбәт кенә, файдалы нәрсәне, кайсыдыр бер җитәкченең яки хакимият әһеленең башына бер уй килә дә (башына тай тибә дә), кирәкле, әһәмиятле нәрсәне юкка чыгаралар яки үзгәртәләр дә куялар. Белгечләр, акыллы кешеләр, коллектив белән киңәшләшү юк, бу нәрсәне, тәртипне, системаны, оешма, предприятиене кемнәрдер төптән уйлап, файдалы булганга оештырганнардыр бит дигән фикер килми башларына. Бик кирәкле Казан педагогика университетын да шулай мәгънәсез рәвештә бетерделәр.

Телевидениедә хезмәт иткән күркәм шәхесләрдән данлыклы диктор, тапшырулар алып баручы, Татарстанның атказанган артисты Айрат Арыслановны искә алмыйча китсәң, илтифатсызлык булыр иде. Сирәк очрый торган күркәм кеше иде ул. Мәһабәт сынлы, чибәр кыяфәтле, матур тавышлы ир. Тыныч кына, ипле генә сөйли. Ул татарча да, русча да бик яхшы белгәнлектән, аны һәр редакция редактор-журналистлары үз тапшыруларын алып барырга җәлеп итәргә тырышалар иде. Мин дә, үзем әзерләгән тапшыруларны алып бару өчен, аңа мөрәҗәгать итә идем, каршы килмәде, рәхмәт төшкере.

Абдулла Дубин, Иркә Сакаева, Әминә Сафиуллина да яхшы дикторлар булды. Соңыннан туган телебезнең сафлыгы, дөреслеге өчен җан атып йөргән игелекле зат – Рөстәм Нәбиуллин татарча тапшыруларның дәрәҗәсен күтәрерлек диктор булып эшләде.

Татарстан телевидениесендә хезмәт итү еллары – минем тормышымдагы бик бәрәкәтле чор. Мин анда ярыйсы гына тәҗрибәле эфир журналисты булып җитешкәнмендер, дип уйлыйм. Мине анда эшләгәндә СССР журналистлар союзына кабул иттеләр.

Шул ук вакытта Казан педагогика иститутында, рөхсәт алып, аспирантурада укыганда тапшырыла торган ике җитди имтиханны – кандидатлык минимумнарын алдан биреп куйдым.

Гаилә коруга, яшәү урынымны будыру мәсьәләсендә дә кайбер эшләр майтардым. Әти-әниләрем, туганнарым ярдәме белән Северный поселогында Наил абый белән икебезгә бер җир участогында үз көчебез белән кечерәк кенә урталай бүленгән йорт салып

куйдык. Хәер, абый алдан өйләнәсе кеше дип, аның ягын бергәләп эшләп бетердек. Йортның миңа буласы ярты ягының стеналары белән түбәсе генә бар иде. Анысын минем үземә генә эшләргә туры килде. Анысын төзеп бетергәнче, хатыным белән бер ел өйнең кухнясында гына яшәп тордык. Үз көчең белән, тиенләп җыйган хәләл акчаңа җитештергән торак та, башка нәрсәләр дә кадерле була. Эшкә, иҗтиһат итәргә өйрәнәсең. Йорт салганда миңа да төзүчеләр һөнәрен үзләштерергә туры килде.

Шулай әйбәт кенә телевидение редакторы булып эшләп, өч ел узып китте. Бер көнне миңа Казан педагогика институты ректоры, минем диплом эшемнең җитәкчесе, профессор Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев телефоннан шалтырата. Үзе җитәкчелегендә аспирантурага керергә тәкъдим итә. Әйтеп киткәнемчә, ул миңа андый тәкъдимне университетны тәмамлаганда ук ясаган иде. Хәзер инде икенче тапкыр шундый җитди шөгыль тәкъдим иткәч, ныклап уйларга кирәк иде. Дөресен әйткәндә, мин Мирфатыйх Зәкиевичнең миңа ул хакта әйткән сүзләрен онытып бетермәгән идем, тормышымда андый үзгәреш булачагына әзер идем. Шундый ихтималны уйлап, кандидатлык минимумнарын да тапшырып куйган идем. Булачак гыйльми эшемнең темасы да башымда иде инде.

## ФӘН ЮЛЫНДА

Шулай итеп, мин 1964 нче елның көзеннән Казан педагогика институтының профессор М.З.Зәкиев җитәкчелегендәге аспиранты булып киттем. Телевидение һәм радио комитеты председателе Фаик Газизович Надыров (әйбәт кеше иде, мин аны рәхмәт хисләре белән искә алам), минем телевидениедән китәргә җыенганымны белгәч, үпкә белдереп алды. Мин аңа рәхмәт әйтеп, минем алда җитди перспектива – фән юлы торганлыгын белгәч, каршы килмәде, уңышлар теләп калды. Минем үземә дә инде ияләнеп беткән коллективтан китү ямансу булды. Әмма карар кабул ителгән: күңелемне фән, мәгариф, педагогика өлкәләрендәге хезмәткә баглаган идем инде.

Аспирантурада уку дип әйтү гадәткә кергән. Ләкин ул мәктәптә, урта һәм югары уку йортларындагы кебек уку түгел. Анда өч елда белгечлек, чит тел, философия буенча зур имтиханнар (кандидатлык минимумнары) бирәсең, педагогикадан дәресләр үткәреп маташтылар (монысының кирәге икеле иде), калган вакыт синең карамакта: диссертациягә материал туплап, язып, аны яклап чык. Болары – мөстәкыйль эшләр. Җитәкче – киңәшче, эшләреңә күз-колак булып торучы, кирәк булса, бераз ярдәм итәргә мөмкин.

Минем чит телдән һәм философиядән кандидатлык имтиханнары (минимумнары) телевидениедә эшләгән вакытта бирелгән, билгечлек буенча гына тапшырасы бар иде. Анысы формаль генә дияргә була. Диссертациям темасы билгеле: рус теленнән татарчага тәрҗемә итү мәсьәләләре (теориясе). Минем бу темадан әзерлегем, материалым бар иде. Шунлыктан мин диссертациямне вакытыннан күп алдан язып бетердем. Мирфатыйх Зәкиевич – ректор, эше күп, укырга вакыты юк. Мин берничә ай китап нәшриятында редактор булып эшләп алдым. Җитәкчем укып чыккач, диссертациямне яклау чарасына керештем. Шөкер, аны ярты ел алдан яклагач, ректор М.З.Зәкиев мине үзе җитәкләгән татар теле кафедрасына укытучы итеп эшкә алды.

Аспирантурада булганда диссертация язып кына утырмадым, китап нәшриятында үзем тәрҗемә иткән һәм үзем язган берничә китап чыгардым, нәшриятта тәрҗемәләргә рецензияләр язгалап һәм газеталарда мәкаләләр бастыргалап тордым. Ул чакта бу эшләр өчен әйбәт кенә суммада гонорарлар түләнә иде. Бу безнең семья бюджетына ярдәм булды, югыйсә аспирант стипендиясенә генә бик җәелеп яшәп булмый.

Шул чорда инде мин өйләнеп тә җибәрдем. Яшь бара бит. Кәләшем – үзебезнең якташ, авылыбыздан ерак түгел генә данлыклы Олы Мәңгәрдән Дилара исемле кыз. Мин армиядән кайтканнан бирле яшәгән Северный поселогындагы әти-әниләр, олы абый йортында артык зурдан купмыйча гына туй иттек. Хәзерге кебек артык кыйммәтле туйлар уздырырлык хәл юк иде, әлбәттә, аның кирәге дә юктыр дип уйлыйм. Бәхет кыйммәтле туй итүдә түгел, тату яшәүдә. Мин хатынымнан уңдым дип саныйм. Гомумән алганда тату яшәдек. Ике бала – ул һәм кыз үстердек. Аның авырлыгы күбрәк Дилара өстенә төште. Рәхмәт аңа. Минем кандидатлык һәм докторлык диссертацияләремне язганда, китаплар, мәкаләләр язып бастырганда да аның ярдәме зур булды. Шулай бер-береңә ярдәм итеп, аңлашып яшәгәндә генә тормыш уңышлы була.

Мин институтта беренче көннәрдән үк эшкә чумдым, дөресрәге – чумдырдылар.

Беренчедән, кафедра мөдире М.З.Зәкиев, миңа укыту өчен, мин университетта укымаган курсларны (предметларны) тапшырды, һәм аларны өр-яңадан үземә әзерләргә туры килде.

Икенчедән, миңа баштан ук күп вакытны сарыф итә торган җәмәгать эшләрен йөкләделәр. Мәсәлән, эшли башлагач та, факультетның партия бюросы члены, тиздән секретареның урынбасары, аннары партия оешмасының секретаре итеп сайлап куйдылар. Мин эшләгән тарих-филология факультеты исә бик зур, үзе бер кечерәк вуз кадәр, дүрт бүлектән – татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, рус-татар филологиясе һәм тарих бүлекләреннән тора. Укытучылар да, укучылар да күп, димәк эше дә мулдан. Ул вакытта әле партиянең роле зур, һәм аңа йөкләнгән бурычлар да җаваплы, вазыйфалары күп төрле иде. Тарткан атка йөкне күп төйиләр бит. Минем белән дә шулай булды. Көз көне мине студентлар белән, алар өчен җаваплы кеше итеп, районнарга бәрәңге алырга җибәрәләр. Ул елларда институт өчен ике зур тулай торак төзеделәр. Ректор мине төзелешкә ярдәм итү өчен оештырылган

төзүчеләр штабы члены итеп билгеләп куйды. Ул төзелештә көзге яңгырлы көннәрдә дә, итек белән пычрак изеп, төрле оештыру эшләрен башкарып йөрергә туры килде. Кыскасы, аврал урыннарга ректор, синең тәҗрибәң бар дип (минем андый эшләрдән чыннан да тәҗрибәм бар иде), мине җибәрә иде. Мин, карулашмыйча, үземә йөкләнгән эшләрне җиренә җиткереп башкарып килдем.

Бу чорда миңа СССР Мәгариф министрлыгының бер шактый җаваплы заданиесе белән Үзбәкстанга барып кайтырга туры килде. Аның тарихы һәм сәбәбе менә нәрсәләрдән гыйбарәт.

Сәяси хәлләрдән хәбәрдар булган кешеләргә мәгълүмдер: 1944 елның язында, төрле юньсез кешеләрнең уйдырмалары аркасында, Кырымда яшәгән йөзләрчә мең татарларны, карачай, чечен, ингушларны һәм тагын кайбер халыкларны берничә сәгать эчендә, йорт-җирләреннән куып чыгарып, барлык мал-мөлкәтләрен калдыртып, товар вагоннарына төяп, төрле җирләргә сөрәләр. Бу ул вакыттагы Совет хакимиятенең коточкыч әшәкелеге, кайбер аз санлы милләтләргә карата кылган рәхимсезлеге, геноциды була. Сөрелгән кешеләрнең күбесе юлда һәм, тиешле урыннарга килеп җиткәч, ачлыктан, авырулардан үлгән.

Кырым татарларының исән калганнарының күпчелек өлешен Үзбәкстанга һәм СССРның башка җирләренә китереп урнаштыралар. Алар, күп михнәт-газаплар чигеп, яңа җирләрдә төпләнеп яши башлыйлар. Тырыш халык буларак, әкренләп тормышларын җайга салалар, кардәш үзбәк халкының ярдәме белән, ярыйсы гына итеп гомер кичерә башлыйлар: яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр, дәүләт предприятиеләрендә эшлиләр, балалары мәктәпләрдә белем ала.

Советлар Союзында 70 нче еллардан демократия җилләре исә башлагач, Үзбәкстандагы Кырым татарларының урта һәм яшь буыны үзләренең мәгърифәт-мәдәниятләрен үстерү өчен мөмкинлекләр яулап алуга керешәләр һәм бу юлда күпмедер дәрәҗәдә уңышка да ирешәләр. Мәсәлән, аларның тырышлыклары, принципиальлек-үҗәтлекләре, кыюлыклары нәтиҗәсендә Ташкент педагогика институтында татар филологиясе бүлеге (факультеты) ачыла, кырым татарлары телендә “Ленин байрагы” исемле республика газетасы, ике өлкә газетасы, “Йылдыз” дигән әдәби-иҗтимагый журналлары чыга һәм атнага өч тапкыр радио тапшырулары бирелә.

Ләкин ничек кенә булмасын, Үзбәкстандагы Кырым татарлары туган җирләрен онытa алмыйлар, Ватаннарына әйләнеп кайту

уеннан ваз кичмиләр һәм, бу изге максатларынаирешү өчен, сәяси көрәшкә күтәреләләр.

Хокукларын яклап көрәшүчеләрнең, халыкара прогрессив оешмаларның куәтле басымы нәтиҗәсендә совет хөкүмәте 1944 елда, нахак бәла тагып, сөргенгә сөрелгән халыкларны реабилитацияләргә, ягъни фашист илбасарларына хезмәт күрсәткән дигән хурлыклы тамганы бетерергә мәҗбүр була, ләкин аларга ватаннарына кайтырга рөхсәт бирә торган указ чыгарылмый. Шуңа таянып, Кырым хакимияте бу ярымутырауның элекке төп халкын үз җирләренә кайтармас өчен җан тартыша, законга сыймаслык әшәке чаралар күрә: мең бәла белән кайткан берникадәр татарларны авыл-шәһәрләргә кертмәскә тырышалар, йортлар салырга җир бирмиләр, качып-посып ашыгыч кына җитештергән өйләрен җимертәләр, пропискага алмыйлар һәм башка этлекләр эшлиләр.

СССР хөкүмәте, татарларның Кырымга кайту идеясен юкка чыгару өчен, мәкерле ният кора: аларга Үзбәкстанның яшәү өчен иң кырыс, иң уңайсыз җиреннән, комлы чүленнән урын билгеләп, шунда Кырым татарларының автономияле өлкәсен төзергә тәкъдим итә һәм, хакимиятнең бөтен көчләрен туплап, татарларны шунда күчерергә тырышалар. Бөтен Кырым татарлары СССР хөкүмәтенең бу рәхимсез карарына каршы ташкын булып күтәрелә. Ташкентта һәм Үзбәкстанның башка шәһәрләрендә Кырым татарларының үз ватаннары Кырымга кайтаруларын таләп итү, Үзбәкстанның кеше яшәү өчен иң җайсыз җирендә автономия оештыруга каршылык күрсәтү хәрәкәте башлана.

Ташкент педагогика институтының Кырым татарлары филологиясе студентлары да бу көрәштән читтә калмый. Алар, хөкүмәтнең бу гаделсез карарына каршылык күрсәтүләрен белдереп, үзләре укыган факультетның бинасына кереп бикләнеп, анда беркемне дә кертмичә, берничә көн оборона тоталар. Бу аларның ул елларда тиңдәшсез тәвәккәл гамәлләре була. Бу турыдагы хәбәр тиз арада Мәскәү каласына килеп җитә, һәм үзәк хакимият тәртип урнаштыру чарасына керешә. Мине ашыгыч рәвештә Ташкентка командировкага җибәрүләре дә шушы чаралар кысасындагы эшләрнең берсе була.

Миңа, Ташкент пединститутының Кырым татарлары филологиясе факультеты кебек Казан педагогика югары уку йортының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә эшләүче укытучы, татар милләте вәкиле буларак, андагы хәлләрне ачыклап, килеп чыккан җитди

конфликтны мөмкин булганча җайга салырга ярдәм итү бурычы йөкләнгән иде. Кырым татарлары филологиясе студентлары һәм укытучылары белән очрашып, ачыктан-ачык, дустанә мөнәсәбәттә әңгәмә коруларым, аларның уку-укыту шартлары, яшәү рәвешләре белән танышу, югарыда әйтелгән хәлләрнең асылына төшенеп, илдәге социаль-сәяси хәлләр уңаеннан аларның уй-фикерләрен белү минем өчен гыйбрәтле, әһәмиятле булды һәм сәяси аңымны баетырга ярдәм итте.

Мин Кырымдагы кардәшләребезнең кыю, фидакарь, батыр халык икәнлеген ишетеп белә идем, үзләре белән аралашкач, бу фикерем тагын да ныгыды. Аларның, күп җәфалар чигеп тә, кыйблаларыннан тайпылмый, үз халкы, Ватаны өчен үзләрен аямый торган кешеләр булуына тагын бер кат инандым. Мин ул чакта андагы татарларның безгә, Татарстан халкына туганнарча мөнәсәбәттә булуын күрдем, шәхсән үземә дә укыту, гыйлемлек буенча якын коллегалары итеп карауларын тойдым: мине факультет җитәкчеләренең, институтта очрашулар белән генә чикләнмичә, өйләренә чакырып, чәйле әңгәмә ясаулары да күркәм күренеш булды. Студентлары да минем белән очрашуларда безнең Казан педагогика институтындагы хәлләр, уку процессы, студентлар тормышы белән кызыксындылар. Мин Кырым кардәшләребезнең, аяныч язмышлары аркасында, ерак Үзбәкстан республикасында инде шактый вакыт төпләнеп яшәсәләр дә, үз Ватаннарына әйләнеп кайтулары турында хыяллануларын, моның иртәме-соңмы гамәлгә ашачагына өметләрен өзмәүләрен аңладым. Һәм үзем дә, аларның бу хыял-өметләренең тормышка ашуын теләп, күңелем белән алар яклы идем.

Хәзерге Россиядә руслардан башка халыкларның милли телләре, мәдәниятләре үсеше өчен мәйдан тарая барган көннәрдә Кырым татарларының үз хокуклары өчен батырларча көрәшкәнлекләрен искә төшерәм һәм аларның кыюлыкларыннан, фидакарьлекләреннән гыйбрәт алам.

Дүрт ел рәттән тарих-филология факультетының партоешмасы секретаре вазыйфаларын башкардым. Хәтта докторлык диссертациясен яклаган елны да бу эштән азат итмәделәр. Укытуны, зур җәмәгать эшләре белән бергә башкару күп көч тә, вакыт та таләп итә. Мин, дәресләр тәмамланганчы, күрәсе кешеләрне күреп калыйм дип, факультетта төшке ашны, гадәттә, соңарып, сәгать өчдүртләрдә генә ашый идем. Эш күп булганлыктан, өйгә дә соң кайтасың. Ә минем Северный поселогы белән шәһәрдәге эшләгән

урын арасын өч транспортта йөрисе. Северный песелогына автобуслар аз һәм тәртипсез йөри. Кайчакта яртышар сәгать һәм күбрәк тә көтеп торырга туры килә. Кышкы салкын, буранлы көннәрдә җәфа чигүләр аз булмады. Кечкенә улыбыз Фәнисне (без аны 6 айдан яслегә бирдек) Северный поселок маршрутындагы 9нчы номерлы автобуста яслегә йөртү – үзе бер аерым кыйсса сөйләрлек була.

Докторлык диссертациясе язарга кирәк дигән карарга килдем. Мин, тәрҗемә эше белән шөгыльләнгәндә, төрле төзелешле рус һәм татар телләрендә үзенчәлекле яклар белән бергә гомуми сыйфатлар да булуына игътибар итеп, шушы күренешне расларлык мисалларны теркәп бардым. Бу гомумилек һәм үзенчәлекләрнең нигезен диалектик материализмдагы “Общее и единичное” дигән философик категория белән бәйләп ачыкларга кирәк дигән фикергә килдем. Һәм, җиң сызганып, эшкә керештем.

Диссертация язу җиңел эш түгел, докторлыкны – бигрәк тә. Тема да шактый катлаулы булды. Шулай да тәмамлап чыктым. Аны яклау өчен, мәкаләләрең һәм монографияң басылып чыккан булырга тиеш. Алары да эшләнде. Ниһаять, яклау процедурасы башланды. Минем тема буенча яклау советлары юк икәнлеге ачыкланды. Бәхетемә, кандидатлык диссертациясен яклагандагы бер оппонентым – Мәскәүдәге зур галим – академик Әдһәм Рәхимович Тенишев, СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институты директоры Ф.Филин белән сөйләшеп, мине шул институтның советында яклатырга дигән карарга килделәр. Минем диссертациям рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнү темасына караган булганлыктан, аны, рус теле советына берничә төрки тел галимен кертеп, бу өстәмә кешеләр кертелгән советны СССР хөкүмәте карамагындагы Югары аттестация комиссиясе карары белән генә якларга мөмкин иде. Шулай эшләделәр дә. Бу процедура бик катлаулы булды. Күп дулкынланулар, борчылулар кичерергә туры килде. Шөкер, изге җан Әдһәм Рәхимович Тенишевның ярдәме зур булды, Рус теле институты директорының урынбасары Валерий Васильевич Иванов, яклау советының секретаре Вячеслав Белоусов та ярдәм иттеләр. Институтның башка хезмәткәрләре дә миңа теләктәшлек күрсәтеп тордылар.

Югары аттестация комиссиясенең якларга рөхсәтен ярты елга якын көтеп торырга туры килде. Ул арада билгеләп куелган өч оппонентымның берсе чит илгә озак сроклы командировкага китеп

барган. Ярый әле бәяләмәсен язып биргән иде инде. Аның урынына икенче кеше эзләп табарга кирәк булды. Шулай итеп, минем дүрт оппонентым булып чыкты. Алар барысы да күренекле галимнәр. Берсе Россиядә генә түгел, бөтен дөнья тел галимнәренә мәгълүм академик Николай Максимович Шанский. Ул мине шактый гына хәсрәткә салып алды: диссертациямә бәяләмәне яклауга кимендә ике атна алдан бирәсе урында иртәгә яклыйсы дигән көнне кич кенә бирде. Миңа аның бәяләмәсенә җавапны әзерләргә бер төн генә калган иде инде. Ярый әле минем белән Мәскәүгә Дилара килгән иде. Ул минем җавапны тиз генә гостиницада үзебез белән алып килгән машинкада басып бирде. Яклау буласы көнне иртән аз йоклаудан һәм борчылудан минем башым тубал кебек иде. Дилара, ниндидер дару биреп, хәлемне җиңеләйтте.

Бераз арткарак китеп әйтеп китим әле. Кайчакта уйламаган чит кешеләр дә ярдәм кулларын суза. Ә кайчакта якын кешеләр дә сине авыр хәлгә куярга мөмкин.

Диссертация яклау өчен, оппонентларның бәяләмәләреннән (отзывларыннан) тыш, берәр гыйльми учреждение яки югары уку йорты (ведущее учреждение дип атала) диссертациягә оешма исеменнән бәяләмә бирергә тиеш. Оппонентларның һәм оешмаларның исемнәре диссертациянең авторефератында алдан ук язып куелган була. Мин үзем укыган вуз ышанычлырак булыр дип, бәя бирүче оешма итеп үзебезнең Казан университетын тәкъдим иткән идем. Яклау вакыты җитеп килә, ә университетта бәяләмә язарга җыенган кеше юк. Аны гыйльми эшләре минем диссертациям темасына якын кеше язарга тиеш. Андый кешеләр университетның рус теле кафедрасында икәү генә: профессор Ә.М.Ахунҗанов һәм доцент Л.К.Бәйрәмова. Әнвәр Мәхмүтович минем вакытым юк, Луиза язсын ди, ә Луиза Кәримовна мин бит доктор түгел, Әнвәр Мәхмүтович язсын, ди. Мин хафага төштем. Шуннан соң, фәнни эше турыдан-туры минем темага туры килмәсә дә, кафедраның доценты Гөлшат Касыймовна Хәмзинага мөрәҗәгать иттем. Рәхмәт төшкере, Гөлшат, минем хәлне аңлап, язарга булды. Шулай итеп, ул зур бәладән коткарды. Бәяләмәне бастырып, куллар куйдырып, печать суктырып, Мәскәүгә җибәрдем.

Ниһаять, СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институты советында мин “Общее и специфическое в лексико-фразеологической системе русского и татарского языков” дигән темага докторлык диссертациямне уңышлы яклап. Миңа, кайчандыр җиде

классны татар мәктәбендә укып киткән кешегә, башкаланың мондый абруйлы рус теле советында докторлык диссертациясен яклау зур шатлык һәм горурлык иде, әлбәттә. Соңыннан профессор М.З.Зәкиев “Мин сине мондый катлаулы темалы диссертацияне яклый алырсың дип уйламаган идем”, – дип әйтте.

Тиздән Мәскәүдәге аттестация комиссиясе миңа “филология фәннәре докторы” дигән гыйльми дәрәҗә бирү турында карар чыгарды һәм берникадәр вакыттан шул ук Югары аттестация комиссиясе профессор исеме бирде.

Мин татар теле кафедрасының профессоры булып эшләвемне дәвам иттердем. Тагын бер җәмәгать эше йөкләделәр: бер студентлар группасының җитәкчесе (кураторы) итеп билгеләделәр. Миңа студентлар белән эшләү ошый, студентлар мине яраталар иде кебек.

Ул арада минем тарафка салкын җилләр исә башлады. Факультет деканы, элек институтның парткомы секретаре булып эшләгән, инде олыгаеп килгән ханым, юк-бар сәбәп табарга тырышып, миңа бәйләнә башлады. Бер сылтау табып, хәтта ректор приказы белән миңа шелтә белдерүгә дә иреште. Мин, гаебем юклыгын аңлатып язып, ректор янына кердем. “Нигә миңа карата андый административ чара кулландыгыз, минем гаебем юк бит”, – дип әйтәм. Ул моңа каршы: “Әгәр дә мин шулай эшләмәсәм, үзенең кешесен яклый дип әйтерләр иде”, – ди. Мондый логикага каршы килә торган сүзләргә нәрсә дип әйтәсең инде. Якын кешеңә, үзеңә сүз ишеттермәсеннәр өчен, гаебе булмаса да, җәза бирергә дә ярый икән. Хәер, декан белән ректорның бу гамәлләренең һәм тискәре карашларының сере бар иде. Декан үзе урынына мине куярлар дип курка, ректорга, бәлки бер кафедрада үзе белән тагын бер доктор (диссертациясен Мәскәүдә Рус теле советында яклап кайткан һәм үзеннән яшьрәк) булу ошап бетмәгәндер (бер казанга ике тәкә башы сыймый, диләр бит).

Кыскасы, мин институтта артык кеше, ахры, дип уйлап, проблеманы хәл итү чарасына керештем.

Казан университетының бер үк факультетында миннән берникадәр элегрәк укыган Җәмил Сафиуллин, инде үзе рус әдәбияты кафедрасы укытучысы һәм Казан университетының партоешмасы секретаре, мине яхшы белә. Мин аңа үземнең хәлне сөйләп бирдем. Ул акыллы егет, мәсьәләне тиз аңлап алды һәм ректор А.И.Коновалов белән миңа эш табу хакында сөйләшергә вәгъдә

бирде. Һәм сөйләшкән дә. Минем белемемне, тәҗрибәмне, фәнни юнәлешемне исәпкә алып, татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты бүлеге укытучыларына рус теле кафедрасы ачып, мине үзләренә шуның мөдире итеп алырга булганнар. Бу, әлбәттә, миңа яраклы эш буласы иде.

Әмма тиздән безнең ректор, минем шеф, Казан университеты ректорыннан безнең бу ниятебезне белеп алып, мине үзенә чакырып алды. "Син кая китмәкче булып йөрисең, без сине тарих-филология факультетының деканы итәргә җыенабыз бит", – ди. Мин, рәхмәт әйтеп, аның бу тәкъдименнән баш тарттым. Сәбәбен сорый ректор. Мин аңа факультетта һәм институтта бөтен көчемне биреп, югары нәтиҗәле итеп эшләгәнлегемне һәм, хаксыз гаепләп, мине кимсетүләренә риза булып тормаячыгымны әйттем. Ул моны үзе дә аңлый иде, әлбәттә. "Мин үз тәкъдимемдә калам, син тагын бер кат яхшылап уйла әле", – диде. Берникадәр вакыттан мине яңадан чакырды. Минем белән, якын итеп, йомшак кына сөйләште, деканлык вазыйфасына керешергә яңадан тәкъдим итте..

Мине факультетта яхшы беләләр, мин дә коллективны әйбәт беләм, төрле җәмәгать эшләрен башкарып, дүрт ел факультетның партия оешмасы секретаре булып эшләдем. Укытучыларның һәм укучыларның миңа мөнәсәбәте уңай. Ягъни факультет коллективы миңа якын, укыту-тәрбия эше дә яхшы таныш. Шуларның барысын да исәпкә алып, ректорның тәкъдименә риза булдым.

## ҖИТӘКЧЕЛЕК ЭШЕНДӘ

Тиздән мине декан итеп кую турында приказ да булды. Шулай итеп, эшемдә шактый зур үзгәреш булды, миңа җаваплы вазифа йөкләнде.

Деканлык эшен башкару минем өчен авыр булмады. Чөнки мин факультет коллективын, укыту-тәрбия эшләрен дә яхшы беләм, алда торган бурычларны да аңлыйм кебек. Үзеңне аямыйча, акыл белән эшләргә генә кирәк. Коллегаларым миңа уңай караштa. Зыян китерергә теләүчеләр дә күренми сыман.

Шулай җайлап кына эшләп йөргәндә, институтта җитди үзгәреш булып куйды. Ректорыбызны Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, тарих институтына директор итеп күчерделәр. Аның урынына куярга кеше эзләү башланды. Ул вакытларда бу эш белән партиянең өлкә комитеты шөгыльләнә иде. Көннәрдән бер көнне мине шунда чакырып алдылар. Институттагы хәлләр турында сораштылар. Аннары ректорлыкка кемнәрне тәкъдим итә аласың, дип сорадылар. Мин ике-өч кешенең исемнәрен атадым. Берничә көннән тагын чакыртып алдылар. Бу юлы инде миннән ректор итеп сине тәкъдим итсәк, ничек уйлыйсың дип сорадылар. Мин андый зур җаваплы эшкә әзер түгел дип җавап бирдем. “Шулай да уйлап кара әле”, – дип әйтеп җибәрделәр. Ике-өч көннән партия өлкә комитеты секретаре Рәис Кыямович Беляев үзенә чакырып алды. Миңа ректор булып эшкә керешергә тәкъдим итте. Мин бу юлы да мондый зур эшне булдыра алырмынмы икән дигән шигемне белдердем. “Син булдыра алырсың, Рүзәл, мин сиңа ышанам”, – ди Рәис Кыямович. Зур җитәкченең ышанычын акларга тырышып карыйм инде, алай булгач, дип уйлап, ризалыгымны бирдем. Һәм мондый карарга килеп ялгышмаганмындыр, Рәис Кыямовичның ышанычын акладым кебек. Казан дәүләт педагогика институтының, аннары университетының ректоры вазифаларын уналты ел ярым буена уңышлы гына башкарып килдем. Әмма минем ихтыяр көчемне сыный торган хәлләр дә булмый калмады.

Ректор итеп кую тиз һәм җиңел генә кылына торган гамәл түгел икән. Партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре Рәис Кыямович Беляев белән сөйләшкәннән соң, беренче секретарь Гомәр Исмәгыйлевич Усманов белән әңгәмә корып, аның хәер-фатихасын алырга кирәк иде әле. “Первый” минем белән озак сөйләшеп торуның кирәген тапмады кебек, берничә сорау бирде дә, шуның белән вәссәлам (ул алдан минем турында мәгълүмат белән танышкан була инде). Шуннан соң Г.И.Усманов кул куйган юллама, Р.К.Беляев имзасы салынган характеристика белән мин Мәскәүгә безнең институт кергән югары оешма – Россиянең мәгариф министрлыгына юл тоттым. РСФСР мәгариф министрлыгында мине андагы бүлекләргә алып кереп таныштырып чыктылар, министрның урынбасары тарафыннан кабул ителдем. Аннары, алдан хәбәр итеп куеп, югарырак ведомствога – СССР мәгариф министрлыгына җибәрделәр. Анда министр һәм аның урынбасарлары белән аерым-аерым очрашу оештырдылар. Моннан ары юнәлеш СССРның Югары һәм урта махсус белем бирү министрлыгына иде. Монда да берничә җитәкче минем белән әңгәмә ясады һәм, ниһаять, минем өчен тагын да дәһшәтлерәк сынау булды: минем кандидатураны министрлыкның коллегиясе утырышында тикшерделәр. Зал тулы берсеннән-берсе җитдирәк кыяфәтле әфәнделәр һәм ханымнар утыра. Берсе мине коллегия әгъзаларына тәкъдим итте. Моңарчы булган министрлыклардагы кебек берничә сорау: студентларга югары белем бирүне яхшыртуның нинди юлларын күрәсең, югары белемнең сыйфатын күтәрүнең концепциясе һәм башка сораулар. Шундый кешеләр алдында мондый сорауларга югалып калмыйча җавап бирүнең ничек кыен икәнлеген бер үзең генә беләсең. Берничә көн буена министрлык кабинетларының ишекләре төбендә көтеп утырып, аннары шундый сорау алуларга дучар ителү – үзенә бер төрле җәзага тарту рәвешен алган һәм минем бу хәлләрдән гайрәтем чигә башлаган иде инде. Шуңа күрә коллегия утырышында берсе “Бу эшкә теләп барасыңмы?”, – дип сорагач, “Теләгем зур дип әйтә алмыйм”, – дип җавап бирдем. Елмаешып куйдылар да, бәйләнеп тормадылар тагын.

Коллегия утырышыннан соң мине министр кабул итте. Әмма ректор итеп кую одиссеясе моның белән генә тәмамланмады әле. Юл РСФСРның Министрлар Кабинетында дәвам итте. Анда минем белән элегрәк Татарстан хөкүмәтендә бүлек мөдире булып эшләгән

Андриянов фамилияле кеше әңгәмә ясады. Кайчандыр үзе безнең республикадан киткән кеше булгач, минем белән җылы мөгамәләдә булып, иркенләп сөйләште, Татарстан хәлләрен сорашты.

РСФСР Министрлар Кабинетыннан соң тагын да дәһшәтлерәк орган СССР Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты булды. Анда керү ниндидер бер шомлы, гаҗәеп хисләр уята. Аерым-аерым пропусклар белән берничә пост аша узып, Үзәк Комитетның РСФСР бюросы дигән бүлегенә кердем. Анда кайсыдыр бер бүлек мөдире белән әңгәмә булды. Сөйләшү коры, рәсми тонда барды. Ул әңгәмәдән күңелемдә җылы хисләр калмады.

Ниһаять, санап чыккан барлык инстанцияләрне узгач, минем белән РСФСР Мәгариф министры әңгәмә ясады һәм ректор итеп билгеләп кую турында приказ чыгарачагын игълан итте. Һәм мин, приказ кәгазен алып, Казаныбызга кайтып киттем. Приказ алып кайтып килүем турында ректорат секретарена телефоннан хәбәр иттем. Һәм менә беренче истә калырлык тәэсир: поездан төшүгә мине ректор машинасы белән каршы алалар. Каршы алсыннар дип әйтергә башыма да килмәгән иде. Ректорат секретаре Мәймүнә Закировна шундый инициатива күрсәткән. Җиңел машина белән йөртүләре күңелле һәм рәхәт, әлбәттә. Ләкин мин моның тәэсиренә хозурланып тормадым, алдагы җаваплы, зур эшләрем турында уйлый идем. Уйламый булмый икән шул. Өстеңә төшкән зур йөкне тарта алырмынмы, үземә күрсәткән ышанычны аклый алырмынмы дип уйланасың да, борчыласың да.

Мәскәүдән кайткан көнне үк партия өлкә комитеты секретаре Рәис Кыямович Беляев мине, яңа эшем белән котлап, коллективка тәкъдим итте. Ректор бүлмәсенә проректорлар, деканнар һәм кайбер кафедра мөдирләрен җыйганнар. Шәһәрнең һәм районның партия оешмалары секретарьларын да чакырганнар. Элекке ректор да шунда. Рәис Кыямович бу вакыйга уңае белән берничә сүз әйтте дә, уңышлар теләп, миңа ректор креслосына барып утырырга тәкъдим итте. Мин, ниндидер ярамаган эш эшләгәндәй, кыяр-кыймас кына, уңайсызланып барып утырдым. Шулай итеп, тормыш китабымның яңа сәхифәсе языла башлады.

Эшли башлавымның беренче көннәрендә бер-ике кызыклы хәл булып алды. Минем ректорлык эшемне расларга дип партиянең Бауман райкомы бюросы утырышына чакырдылар. Аннары тагын шундый ук гамәл кылу максаты белән партиянең Казан шәһәре комитеты бюросы утырышына чакырдылар. Менә ул чыйкылдаган

формализм, партия җитәкчеләренең эшендәге амбициялелекнең югары дәрәҗәсе! Мине инде, партиянең Үзәк Комитетында булып, Россия мәгариф министры үзенең приказы белән ректор итеп билгеләп куйганнан соң, җирле партия органнары яңа эшемдә раслап маташалар! Көлкенең теге ягындагы күренеш. Танышырга дип чакырсалар, бер хәл, "расларга" диләр бит. Коммунистлар партиясенең зур һәм кечкенә җитәкчеләре, узган гасырның азагында, шулай чамасыз кыланып, үзләренең яман атларын чыгарып, партиянең абруен югалттылар.

Кечкенәдән тәрбияләнгән эшне җиренә җиткереп, яхшы итеп эшләү сыйфатым минем бу яңа эшемдә – институт ректоры булып эшләвемдә дә чагылыш тапты.

Бөтен көчемне биреп, булган барлык тәҗрибәмнән файдаланып, яңа эшкә керештем. Казан педагогика институты бай тарихлы, үтә абруйлы югары педагогик йорты. Ул 1876 елда, Санкт-Петербург һәм Мәскәү институтларыннан кала өченче булып, Укытучылар институты исеме белән оештырыла. Шул вакыттан бирле ул, данлы юл узып, бихисап күп санлы югары квалификацияле белгечләр – педагог хезмәте осталары, мәгариф җитәкчеләре, галимнәр һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерли торган шөһрәтле уку йортына әверелә. Еллар узу белән аның исеме берничә тапкыр үзгәрсә дә, асылы, эчтәлеге бертөрле булып – мәгърифәт, фән һәм мәдәният эшенә хезмәт итү булып кала.

Казан педагогика институты ачылган вакытыннан ук Казан, Вятка, Сембер, Самара, Астрахань губерналары кергән Казан уку округындагы гимназияләр һәм өяз училищелары өчен укытучылар әзерләргә тиеш була һәм бу мактаулы бурычны, ул өлкәләрнең үзләрендә педагогика институтлары оештырылганчыга кадәр, уңышлы рәвештә башкарып килә. Ул Идел һәм Урал төбәкләрендәге милли республикаларның педагогика уку йортларын төзүдә нигез ролен үти.

Казан укытучылар институты беренче елларыннан ук чит илләрдәге һәм Россиянең үзендәге педагогик фикернең яхшы үрнәкләреннән файдаланырга тырыша. Институт укытучылары белемнәрен чит илләрдә – Франция, Германия, Италия, Австриядә дә, Россиядә Казан университетында да күтәрәләр. Мәгълүм ки, монда инде зур гыйльми мәктәпләр (мәсәлән, күренекле тел галиме Бодуэн де Куртенэ мәктәбе) булган.

1922 елда Казан дәүләт педагогика институты нигезендә Көнчыгыш педагогика институты төзелә. Аның составына 1921 елны Төньяк Көнчыгыш һәм этнография институты базасында оештырылган Көнчыгыш академиясе кертелә. Көнчыгыш педагогика институтының материаль базасы ныгытыла, аңа яңа биналар бирелә. Вуз шул елларда тел-тарих, физика-математика, биология-география һәм көнчыгыш бүлекләреннән тора. Монда, Татарстан республикасы яшьләреннән тыш, үзләренең педвузлары булмаган Башкортстан, Чувашстан, Казахстан, Мари һәм Удмурт автономияле республикалары егет һәм кызлары да укыйлар. Институт укытучылар, музей хезмәткәрләре һәм милли мәдәниятләрне өйрәнүчеләр әзерли.

Көнчыгыш педагогика институтында тюркологиягә зур игътибар бирелә. Булачак галимнәр, стажировка узу өчен, тюркология белгечләре – профессорлар В.В.Бартольд һәм А.Н.Самойловичлар янына Ленинградка җибәрелә. 1926 елда булачак аспирантураның беренче үрнәге – практикант-ассистентлар институты барлыкка килә.

1923–1925 елларда мондагы татар-төрки рабфагында булачак герой шагыйрь Муса Җәлил укый.

Татар, мари, чуваш, удмурт бүлекләренең укытучылары булып профессорлар Н.И.Ашмарин, Габдрахман Сәгъди, В.А.Богородицкий, доцентлар Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, В.Е.Егоров, Н.В.Никольский, Галимҗан Шәрәф, Н.Мөхетдиновлар һәм башка галимнәр эшли. Көнчыгыш педагогика институтының базасында 30нчы елларда Чебоксар, Йошкар-Ола, Ижевск шәһәрләрендә педагогика институтлары төзелә башлый. Казан югары педагогика мәктәбе аларга иң яхшы кадрлар белән ярдәм итеп тора, профессорлар, доцентларны командировкага җибәрә, гыйльми-методик әдәбият бирә һәм Идел буе, Урал тирәсе республикаларының милли мәктәпләре өчен укытучылар әзерләвен дәвам иттерә.

Бөек Ватан сугышы елларында уку процессы тигез һәм җайлы гына бара алмый. Студентлар һәм сотрудниклар айлар буена республика районнарында эшлиләр, колхозчыларга булышалар, оборона объектлары төзүдә катнашалар. Шәһәрдә дә сугыш белән бәйле эшләр аз булмый. Укытучыларның саны сугыш вакытында Мәскәүдән, Ленинградтан һәм башка шәһәрләрдән Казанга эвакуацияләнгән күренекле галимнәр белән тулылындырыла. Казан педагогика институтында СССР Фәннәр академиясе академик-

лары Н.С.Державин, С.П.Обнорский, Б.Д.Греков, Е.Косминский, В.Мосолов, Е.Тарле, А.Е.Арбузов һәм башка зур галимнәр укытып йөриләр.

Вуз укытучыларны барыннан да бигрәк Татарстан өчен әзерләгәнлектән, укыту эшенә төп милләт кешеләрен җәлеп итү бурычы барлыкка килә. Һәм 1946 елда татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү бүлеге оештырыла. Ә 1948 елда татар теле һәм әдәбияты факультеты вуз эчендә мөстәкыйль статус ала. 1949 елда физик тәрбия һәм спорт факультеты ачыла.

1948–1958 елларда Казан педагогика институты илдәге дипломлы белгечләр әзерли торган халыкара үзәкләрнең берсенә әверелә. Монда Венгрия, Чехословакия һәм Корея республикасы студентлары белем ала. Институт галимнәренең халыкара бәйләнешләре өчен мөмкинлекләр арта, АКШ, Румыния, Кытайдан һәм башка илләрдән делегацияләр килә.

“Яшьләрне тәрбияләү өчен белем нигезләренең зур галимнәр тарафыннан бирелүе әһәмиятле”, – дип яза академик П.Капица. КДПИ һәрвакытта да шушы принципка нигезләнеп эш итә. Мәсәлән, 50 нче елларда физика кафедрасында парамагнит резонансы теориясе өлкәсендә нәтиҗәле тикшеренү эшләре башкарыла. Бу эшнең талантлы оештыручысы кафедра мөдире профессор К.Ә.Вәлиев була. Соңрак ул илебездәге иң зур галимнәрнең берсенә әверелә (Россия һәм Татарстан академияләре академигы, Мәскәүдәге бик әһәмиятле, зур гыйльми тикшеренү институты директоры һ.б.). Камил Әхмәтович күп кенә талантлы яшь галимнәр тәрбияли.

1960 елда КДПИ “гаиләсе” яңа факультет – музыка-педагогика факультеты белән тулыландырыла. Әкренләп институтның хуҗалыгы зурая: аңа яңа биналар бирелә.

Казан дәүләт университетында узган гасырның 50 нче елларында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылганчыга кадәр, Казан педагогика институты татар язучыларын әзерли торган төп югары уку йорты була. Халкыбызның күренекле әдипләренең күбесе шушы институтта укып чыккан.

Мондый бай традицияле күркәм уку йортының ректоры начар эшләсә, институтны тагын да зуррак уңышларга ирештермәсә, мондый җитәкчене гафу итмәсләр иде.

Мин бу җаваплылыкны һәрвакыт тоеп эшләдем. Вузны иң алдынгы югары педагогик уку йортлары сафына бастыруны макса-

тым итеп куйдым. Казан педагогика институты ул – күп төрле тармаклы, зур хуҗалыклы югары уку йорты. Укыту, тәрбия, гыйльми эшләр – уку йортында педагогика белгечләре әзерләүнең хәлиткеч өлкәләре. Аларның берсенә генә игътибарны киметсәң дә, институт үз бурычларын тулысынча үти алмаячак. Моны мин яхшы аңлый идем. Казан педагогика институтында инде ике дистә елдан артык укыткан һәм эшләгән булганлыктан, миңа бу югары уку йортының уңышлары да, үзгәртәсе, яхшыртасы яклары һәм проблемалары да мәгълүм иде.

Укыту-тәрбия системасын, укытучылар эшенең сыйфатын камилләштерү, фән эшләрен җәелдерү, педагогика югары уку йортының дәрәҗәсен күтәрү, материаль базасын ныгыту һәм башка әһәмиятле эшләр көтә иде яңа ректорны.

Мин эшемне, кайбер башка җитәкчеләр кебек, вуздагы төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрне алмаштырудан башламадым. Тәҗрибәле кадрларның оештыру осталыгын, уңай эш алымнарын акыл белән файдаланырга тырыштым, үзем дә өйрәндем. Минем төп принцибым – сыйфатлы эш таләп итүне кешеләргә яхшы мөнәсәбәт, кайгыртучанлык белән бертигез тоту. Җитәкче өчен иң әһәмиятле сыйфат – кешелекле булу, масаймау, бер кешене дә түбәнсетмәү. Һәркем үзенә күрә бер шәхес. Һәркемнең үз горурлыгы бар, беркемнең дә бүтәннәрне кимсетергә хакы юк.

Үземнең иң әһәмиятле бурычларымның берсе итеп коллективта үзара аңлашу, татулык мөнәсәбәтләре булдыруны һәм саклауны санадым. Гомуми җыелышларда, утырышларда һәрвакыт искәртеп килдем: “Иптәшләр, мөмкин кадәр эчкерсезлек, татулык һәм бер-беребезнең сүзенә колак салып эшләү, үзара таләпчәнлек һәм мәрхәмәтлелек мохите булдырырга тырышыйк. Мактап һәм мактанып кына яшәсәк, алга китеп булмаячак, киресенчә, ирешкән уңышларыбызны да югалтырга мөмкин”.

Отчет җыелышларында, башка төрле җыелышып сөйләшүләрдә җитәкчелекнең, шул исәптән ректорның, кимчелекле якларын, эшләнмәгән, эшлисе эшләрен күрсәтүдән тартынмадым. Үземә дә таләпчән булдым, башкалардан да таләп иттем.

Ләкин миңа ректорлыкның беренче елларында яңа җаваплы эшемдә, бөтен көчемне биреп, зур нәтиҗәләргә ирешерлек итеп эшләргә комачауларлык вакыйгаларны кичереп, кайбер юньсез кешеләрнең әшәкелекләрен фаш итү белән шөгыльләнергә дә туры килде. Кайчакта, яңа җитәкче куелуга риза булмыйча, аңа яла ягып,

нахак гаепләр тагып, әхлаксыз ысуллар белән исемен пычратып, аны эшеннән алдыртуга ирешергә теләүчеләр табыла икән. Мин нәкъ менә шушындый хәлгә тап булдым.

Безнең педагогика институтының тарих кафедрасында бер профессор бар иде. Ул кызык биографияле, сәләтле кеше. Заманында зур уңышларга ирешкән: партия өлкә комитетында бүлек мөдире булган, аннан киткәч, аз гына вакыт министр булып та эшләп алган. Ләкин, минем белгәнемчә, ул уңышлы эшләп, республикага файда китерде һәм кешеләргә игелекле булды, дип әйтә алмыйм. Профессор булуы һәм өлкә комитетында эшләп алуы аның Ленин методологиясе буенча (кем каршы сүз әйтсен!) бер зур җитәкче кеше консультантлыгында яшь килеш җиңел генә докторлык диссертациясе яклавы һәм тагын бер җитәкченең, күп уйлап тормыйча, моны, яшь татар профессоры дип, абруйлы эшкә билгеләп куюы белән бәйле.

Бу профессор минем белән университетның бер факультетында укыды. Миннән ике курс алдан. Ул, бишле билгеләренә генә укып, Ленин стипендиясе алуга исәп тоткан булган. Ләкин аның зур җәмәгать эше булмаганлыктан, ә мин шулай ук, гел бишлегә генә укып, шуның өстенә, зур факультетның комсомол оешмасы секретаре булганлыктан, Ленин стипендиясен миңа бирергә булганнар. Минем аңа бу зур исемле стипендия эләкмәвенә бернинди гаебем булмаса да, теге егетнең эченә миңа карата ачу кереп утырган. Аның миңа ачуы, мин ректор булгач, тагын да ныграк кабарган. Моның тарихы менә болай.

Элекке ректор, югарыдан аңа бу эшеннән китәргә тәкъдим булгач, үз урынына проректорны тәкъдим иткән. Беренче карашка, дөрес фикер кебек: ул начар егет түгел, ә хатынының әтисе – республикада дәрәҗәле мәгълүм кеше – республикадагы рәсми баш газетаның редакторы, партия өлкә комитеты бюросы әгъзасы. Булачак җитәкче турында институттагы кешеләр беләләр, барысы да, шул исәптән мин үзем дә, тиздән ул ректор булып эшли башлаячак, дип йөрделәр. Ләкин партия өлкә комитетында ректор мәсьәләсендәге фикерләр икенче төрлерәк булган.

Ректор кандидатурасын эзләп табу процедурасы башланган. Минем фамилияне искә алганнар. Аннан соң мине ничек итеп бу яңа эшкә куюлары турында язып киткән идем инде.

Теге мине яратмаган профессорның ашына таракан төшкән: әлеге проректор ректор булса, ул аның урынбасары – проректор булачак, дип план корылган булган. Һәм мине ректорлыктан җибәрү өчен

кара эш башлаганнар. Аны башкаручы төп кеше – шушы профессор. Әмма аның оештыручылары да бар иде. Миңа алар билгеле. Һәм алар гади, көчсез бәндәләр түгел, бәлки шактый зур мөмкинлекләргә ия кешеләр.

Минем хәл җиңел түгел иде: эшли генә башлаган, берүзем диярлек, әле ышанычлы команда тупланып бетмәгән. Минем нинди җитәкче буласымны аз беләләр, ә ректор булачак дип йөргән кеше инде шактый вакыт проректор булып эшләгән, терәге дә бар. Теге профессорның да элемтәләре зур: өлкә комитетында һәм министр булып эшләгән. Шуның өстенә ул пычрак ысуллар белән оста эш итә, бернинди юньсезлек эшләүдән дә чирканып тормый, күзгә карап ялганлый, яла яга, аноним шикаятьләрне төрле инстанцияләргә – Мәскәүгә Мәгариф министрлыкларына, КПСС Үзәк комитетына, аның Контроль комиссиясенә һәм башка урыннарга яудырып кына тора. Белеп яудыра. Партиянең властьта нык утырган вакыты. Һәр аноним шикаятьне һичшиксез җентекләп тикшерәләр. Шикаятьләр, әлбәттә, ялганнан әвәләнгән, шакшы. Менә, мәсәлән, бер-икесе.

Педагогика уку йорты әзерләп чыгара торган белгечләр сыйфатлы булсын өчен, институтка мәктәптә яхшы укып чыккан яшьләр килү әһәмиятле: өчкә көчкә укып килгән егет һәм кызлардан юньле укытучылар чыгуы шикле. Шуңа күрә ректорат төрле юллар белән профориентация – сыйфатлы абитуриентлар әзерләү эше белән нәтиҗәле шөгыльләнергә тырыша. Бу төрле юлларның берсе – вуз педагогларының, районнарга барып, андагы укытучылар белән очрашып, алар ярдәме белән әйбәт абитуриентлар әзерләү.

Шундый изге максат белән, мин ректор булып эшли башлаганның беренче кышында, алдан сөйләшеп, Кама буендагы бер район үзәгендә, укытучыларны җыеп, ректоратның күчмә утырышын үткәрергә булдык. Проректорлар, деканнар, кайбер кафедра мөдирләре (чакырылмаган булса да, компромат җыярга теге профессор да ияргән), автобуска төялеп, шул районга киттек. Каманы боз өстеннән җәяүләп чыктык: машина белән керү куркыныч. Елганың теге ягыннан транспорт белән каршы алдылар.

Культура сараенда зур залда бөтен район укытучылары һәм район җитәкчеләре белән вуз кешеләренең әһәмиятле, файдалы сөйләшүе булды. Мин дә чыгыш ясадым, әлбәттә. Районның яхшы укып чыккан яшьләрен педагогика институтына укырга җибәрү буенча конкрет чаралар планы корылды.

Көндезге аш ашаганнан соң, мәктәпләргә барып, дәресләрдә булып, укытучыларның эш тәҗрибәсе белән таныштык. Кышкы көн кыска: тиз караңгы төшә. Бу төнне, монда кунып, иртәгесен кайтып китәргә булдык. Киткәндә, күчтәнәч итеп, һәркайсыбызга яңа тоткан берәр балык биреп җибәрделәр (зур елга буенда яшиләр бит).

Андагы өч тапкыр ашауны һәм район гостиницасында кунып чыгуны түләү өчен тиешле акчаны, читтән торып укыту проректоры В.З.Закиров сөйләшүе буенча, әллә профсоюз өлкә комитеты, әллә Мәгариф министрлыгы карамагындагы ниндидер фонд күчергән.

Шуннан соң күп тә үтми, РСФСР Мәгариф министрлыгына, КПСС Үзәк комитетына ректорны пычрату максаты белән язылган күләмле шикаять китә. Эчтәлеге болай: имеш, мәктәп балаларына тиешле акчага бушлай ашаган-эчкәнбез, гостиницада торганбыз, ректор балык продуктларыннан торган бүләк алып кайткан. Ректор шулкадәр сыйланган, хәтта автобуска менә алмаган, күтәреп утыртканнар. Шикаять хатында мондый эчтәлекле хәбәр дә булган: янәсе, ректор, эшкә керешкәч тә, үз мәнфәгатьләрен кайгырта башлаган, мәсәлән, ректоратка керә торган идәнгә мәрмәр җәйдергән. Мәрмәр дигәне чынлыкта мәрмәрнең кыйпылчыклары гына. Коридордан ректоратка керә торган ашъяулык кадәр генә урынга җәелгән линолиум, тузып, ертылып беткән, шуның урынына, цемент измәсенә бутап, мәрмәр ватыклары җәйдергән идек. Ректорат каршындагы фән бүлеге урнашкан бүлмә ишеге алдындагы идәнгә дә җәйдердек.

Күп еллар – университетта укыганда да, телевидениедә эшләгәндә, институтта укытканда да – башта әти-әниләр белән, аннары, өйләнгәч, гаиләм белән Северный поселогында үзебез салып чыккан өйдә яшәдем. Шәһәргә өчәр транспортта йөрдем. Ул елларда транспортның нинди булганлыгын үзе йөргән кеше генә белә. Җәфаланып йөрдек.

Ректор булып эшли башлагач та, бер ел шунда яшәдем. Өйнең шәһәр йортларындагы уңайлыклары юк: туалет ишек алдында, җылы су юк, телефон да юк. Шуның өстенә бик ерак – шәһәр читендә. Миңа башта ук, чиратка басып, уңайлыклары булган шәһәр квартиры алырга мөмкин булган. Ректор: “Синең торыр урының бар бит”, – дип, квартир алу өчен чиратка бастырмады. Квартир алырга хакым барлыгын белгәч, ректор булып эшли башлаганчы берничә ел элек, торак алу чиратына бастым. Яңа эшкә күчкәч,

Мәскәүгә барып, министрлыктан үтенечемне исәпкә алып, миңа квартир төзетү өчен, Казанга тиешле суммада акча күчертелде. Партиянең өлкә комитеты секретаре, мин аңа шушы мәсьәлә белән мөрәҗәгать иткәч, гаҗәпләнеп: “Сиңа әлегә кадәр квартир бирмәделәрмени”, – дип, минем гаризага “Квартир белән тәэмин итәргә” дигән виза куйды. Гаризаны Казан башкарма комитетының торак-коммуналь бүлегенә илтеп бирдем. Илле яшемә җитеп, профессор, ректор булып, Мәскәү махсус акча күчереп һәм партиянең өлкә комитеты секретаре рөхсәт итеп, гомеремдә беренче тапкыр квартир алдым. Кечкенә метражлы. Дүрт кешегә (хатыным белән мин, улыбыз белән кызыбыз) 48 квадрат метрлы квартир.

Һәм бу хәл минем “дус” профессорга, минем өстемнән язып салыр өчен, материал булган. КПСС Үзәк Комитетының контроль комиссиясенә шикаять китә. Имеш, ректор Р.Юсупов, үзенең йорты була торып, квартир алган. Тишкерү эшләре башланып китте. Безнең институт караган Бауман райкомының парткомиссиясе дигән дәһшәтле органы шөгыльләнде бу эш белән. Мин квартир алганда, Северный поселогындагы, барлы-юклы акчаны тотып, туган-тумачалар ярдәме белән үзебез төзеп чыккан кечерәк кенә йортның мин гаиләм белән яшәгән ярты ягы минем исемдә түгел иде инде.

Райкомның парткомиссиясенә минем бу квартир мәсьәләсен озак еллар үзем эшләгән тарих-филология факультетының ачык партия җылышында тикшерергә тәкъдим иттем. Парткомиссия председателе – бер зәһәр ханым үзе дә катнашты. Халык күп: бөтен укытучылар да килгән. Җыелышны алып баручы партоешма секретаре халыкка мәсьәләнең асылын аңлатты, шикаятьнең эчтәлеге белән таныштырды. Чыгыш ясаган барлык кешеләр дә аноним шикаятьнең авторына (ә ул үзе шушында халык арасында посып кына утыра) хурлык тамгасы тактылар, минем казанышларымны сөйләделәр. Р.Юсупов та квартир алмаса, аны кемнәр генә алырга тиеш соң, дип нәфрәтләнделәр. Райком инструкторлары, мәсәлән, ике-өч ел эшләгәч тә, менә дигән яңа квартирлар алып яшиләр бит.

Парткомиссия председателе дип аталган бәндә җыелышның ул теләгән рухта бармавын күреп, елан кебек агуын чәчә: һәр сөйләгән кешегә “Сез нинди җәза бирергә кирәклеген әйтегез”, – дип, ысылдап утыра. “Җәза бирү турында нинди сүз булырга мөмкин!” дип нәфрәтләрен белдерәләр җыелышта катнашучылар.

Җыелыш мине тулысынча яклап чыкты. Рәхмәт инде минем күп еллар эшләгән коллективыма! Сынатмадылар, райком басымына бирешмәделәр. Парткомиссия председателе, җыелыш бетеп, институттан киткәндә: “Мин барыбер аңа җәза бирдертәчәкмен”, – дип әйтте, карасына көеп.

Бу җыелышка “Советская Россия” газетасы корреспонденты кереп утырды. Һәм тиздән шул газетада мине пычратып язган мәкалә бастырып чыгарды. Русларда “Ларьчик открывается очень просто” дигән әйтем бар. Бу очракка ул бик туры килеп тора.

Әлеге корреспондентның дачасы элекке ректор тарафыннан үз урынына тәкъдим ителгән проректор хатынының әтисенеке белән янәшә. Алар якын дуслар, һәрвакыт бергә күңелле генә ял итәләр. Бу мәкаләнең максаты – Р.Юсуповны ректорлыктан җибәреп, аның урынына проректорны кую. Пычрак эш алдан уйланылган сценарий буенча бара.

Тиздән мине партиянең Бауман райкомы бюросы утырышына чакырып алдылар. Көн тәртибендә – минем квартир алуыма кагылышлы шикаять мәсьәләсен тикшерү. Гаепләрлек эш юк, ләкин барыбер шелтә белдерделәр (выговор бирделәр). Нишлисең бит, көчле һәрвакыт хаклы. Партия әле куәтле иде. Әмма тиздән, ул таралып беткәнче, миңа аның кызык һәм аяныч якларын берникадәр күреп калырга насыйб булды. Кызык ягы: миңа выговор биргән райком бюросы бер елдан мине бюро члены итеп сайлап куйды. Бюро утырышлары үзенә күрә бер трагикомедия иде. Бервакыт партиядән чыгу шаукымы башланды. Берәр ел сәбәпсез-нисез партия җыелышларына йөрми, партия взносын түләми һәм үзләре теләп партиядән чыгу турында гариза яза торган кешеләр күбәеп китте. Мәсьәләне тикшерү өчен, гариза авторын райком бюросы утырышына чакыралар. Менә шунда тамаша башлана инде. Чакырылган кешене оялтырга, хурларга маташалар, сүгәләр. Чыкмаска үгетлиләр. Теге кеше нык тора: “Теләмим булгач, теләмим!”. Болары барып чыкмагач, атакага күчәләр, гаепләргә керешәләр: “Чыгасы булгач, нигә кергән идең соң, янәсе?”. Менә шулай, көчләп, тотып буламы соң инде партиядә кешене? Мин, бу хәлне карап, эчемнән генә көлеп утырам. Хәер, минем үземнең дә ул партиядән китеп барачагыма күп калмаган иде инде.

Аннан килеп мине, ректор буларак, партия райкомының Менжинский клубына ике-өч атнага бер үткәрелә торган партия-производство киңәшмәләренә чакыралар иде. Бик күңелсез күренешләргә

тап була идем мин анда. Райком секретаре – яшь кенә ханым үзенең әтисе яшендәге абзый кешеләрне – район территориясендәге төрле предприятие җитәкчеләрен – бик тупас кыланып, бастырып сүгә торган иде: “Нишләп үтәмисең планны, партия билетыңны чыгарып салмыйсың бит!”

Бераз гына читкә китеп барганмын икән. Теге профессорның миңа карата кылган гамәлләре һәм аларның ничек булып тәмамлануы турында сөйләп бетерим инде.

Шулай яшертен рәвештә этлек эшләве бер-ике елга сузылды моның. Белеп торам бу эшләрнең аның кулы икәнлеген. Шулкадәр әшәке, җир бит: кайчак мин кичке якта үзем генә эшләп утырганда, кабинетка килеп керә дә миңа ниндидер мәгънәсез сүзләр лыгырдый башлый, махсус минем ачуны чыгара. Мин дә әйтәм моңа кирәклесен, тозлап-борычлап. “Син эшләгәнне белеп торам бит мин бу юньсезлекләрне, моның чиге булыр бер барыбер”, – дим. Икәүдән-икәү генә булгач, яшереп тормый, курыкмый бу. “Мин сине тар-мар итми торып туктамыйм әле”, – ди, оятсыз күзләрен акайтып.

Ниһаять, ходайның бу кабәхәтлекне туктатырга дигән сәгате сукты. Институтның офсет лабораториясендә машинистка булып эшләүче бер ханымга бастырып йөри икән теге профессор аноним шикаятьләрен. Ул ханым төп эшенә өстәмә түләү белән аның хуҗалык договоры дип аталган язу-сызу эшләрен башкарып килгән. Чираттагы пычрак язуын алып килә бу бастырырга. Дөньяда әйбәт, игелекле кешеләр дә бар бит. Машинистка белән бергә эшләүче икенче бер ханым бу профессорның яшертен кара эшләр белән шөгыльләнүен күреп йөри. Ул аның мондый юньсезлекләренә башка түзеп тора алмыйча, миңа ярдәм итәргә карар кылган. Анонимщикка сиздермичә генә, машинкага моңарчы бер дә басылмаган копировка кәгазе куялар. Профессор басылган текстын ала да чыгып китә. Машинистка белән эшләүче ханым копировка кәгазьләрен миңа китереп бирә. Теге юньсезнең бастырган һәр сүзен аермачык укып була. Миңа чираттагы пычрак, яла, ялган.

Машинистканы, аның гаепле түгеллеген әйтеп, аңа бернинди дә зыян тимәячәгенә инандырып, аннан бу һәм башка шундый ялган эчтәлекле текстларны теге профессор биреп бастырганлыгы турында расписка яздырып алдым. Сүземдә тордым, әлбәттә. Ул әле күп еллар тыныч кына эшләвен дәвам иттерде. Миңа копировка кәгазен китереп биргән ханымны да сер итеп тоттым. Копиров-

ка кәгазьләреннән исә теге профессорның тыелган гамәл кылуын раслый торган документ буларак файдаландым. Пычрак бәндәне фаш итүдә ул кәгазьләр зур роль уйнады.

Әмма бу процедура шактый озакка сузылды һәм мине шактый зур психологик киеренкелектә булырга мәҗбүр итте.

Ул вакыттагы тәртипләр буенча, әхлаксызлык кылган кешене, әгәр ул партия члены булса, башта партия линиясе буенча тикшереп, тиешле карар чыгаралар иде. Профессор, әлбәттә, партия члены. Шулай булгач, аның бу кыек эшен факультетның партия бюросы утырышында, аннары партия җыелышында тикшерергә кирәк, җыелыш карары исә институтның партия комитетында, район комитетында һәм ниһаять шәһәр партия комитетында расланырга тиеш.

Профессорны утырыш, җыелышларга китереп булмый: больницага кереп качып кала. Шулай берничә тапкыр кабатланганнан соң, миңа больницаның баш врачы белән ныклап сөйләшергә, аңа мәсьәләнең асылын төшендерергә туры килде. Ул, ярый әле, аңлы кеше булып чыкты: врачларга хәлне аңлаткан. Аның бик еш "авыруын" җентекләп тикшерә башлаганнар һәм теге "пациент" больницага кереп качудан туктады. Шулай да партбюро утырышыннан берничә мәртәбә дәррәү чабып чыгып киткәләде. Ниһаять, тарткалашу тәмамланды, партбюро секретаре һәм партком секретаре бергәләп тиешле чаралар күрә торгач, профессорны җыелышка китерүгә ирештеләр. Көн тәртибендә – аның партия әгъзасы буларак, әхлаксызлык гамәлләре буенча персональ эше.

Җыелыш ике ел буе бернинди дә гаебе булмаган кешегә астыртын рәвештә ялган дәлилләр белән тупас яла ягып йөргән, аноним шикаятьләр җибәреп, аңа җитди мораль зыян китергән профессорны фаш итү, зур нәфрәтләнү рухында барды. Күп кешеләр принципиаль чыгыш ясады. Барысы да мондый кешегә партия сафларында урын юк, дигән фикер белдерде. Җыелышта катнашкан коммунистлар бердәм рәвештә анонимщик һәм яла ягучыны партиядән чыгарырга дигән карар кабул итте.

Карар тиздән парткомда һәм партия райкомында расланды, ләкин шәһәр комитетында, профессорның әхлакый гаебе фаш ителсә дә, аның элек партиянең өлкә комитетында бүлек мөдире булып эшләвен исәпкә алып, дөресрәге, күрәсең, элекке коллегалары өчен уңайсызланып, партиядән чыгару карарын катгый шелтә (строгий выговор) белән алмаштырдылар. Әмма андый әхлаксыз

кешенең педагогика уку йортында эшләргә хакы була алмый иде инде. Һәм ул приказ нигезендә эштән чыгарылды.

Ләкин профессорның тартышуы әле дәвам итте. Ул, институт карары белән риза түгеллеген белдереп, РСФСРның мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итә. Һәм аны анда министрлык җитәкчеләре арасыннан якларга маташучылар табыла, чөнки профессор, элекке министрның канаты астында ышыкланып, аның белән якын мөнәсәбәтләре дә булуыннан файдаланып, бик иркен яшәгән, русчадан тәрҗемә итеп әйткәндә, министр кабинетына ишекне аягы белән төртеп кенә ачып керә торган булган. Ләкин хакыйкать җиңеп чыкты. Аның чын әшәке йөзе ахырынача ачылды. Аны яңадан эшендә торгызу мәсьәләсенә тулысынча чик куелды. Юньсез бәндәгә карата кырыс административ чараның дөрес, законлы гамәл икәнлеген раслау, дәлилләү өчен, безнең институтның ул чагындагы кадрлар бүлеге начальнигы, соңыннан проректор, профессор, лаеклы, күркәм педагог Фираз Фахразович Харисов күп көч түкте. Зур рәхмәт инде аңа!

Шулай итеп, минем өчен бу авыр сынау уңышлы узды, исемемне пычратудан сакланып кала алдым. Алда торган сынауларда да сынмас, сыгылмас өчен, үзеңнең лаеклы урыныңны какшата алмасыннар, исемеңә тап төшермәсеннәр өчен, бөтен көч-куәтеңне биреп, үзеңне аямыйча эшләргә дә эшләргә кирәк иде. Һәм мин шулай эшләгәнмендер дә дип уйлыйм.

1986–2002 еллар – минем ректорлык чорым – Казан педагогика институты (университеты) өчен чын мәгънәсендә реформа еллары булды. Вуз нык үзгәрде, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да күзгә күренеп үсеп китте. Үсеш аның бөтен өлкәләрендә дә барды, ул, дәрәҗәсе (рейтингы) буенча йөз педагогика вузының беренче унлыгына кереп, Россиянең һәм Татарстанның әйдәп баручы вузларының берсенә әверелде.

Институт коллективы алдында авыр, ләкин изге бурыч – югары квалификацияле, мәдәниятле педагог-укытучылар әзерләү, эштә югары сыйфатка ирешү бурычы куелды.

Бу чорда факультетлар һәм кафедраларның саны икеләтә күбәйде: 6 факультет иде – 12 булды, 30 кафедра 60 ка җитте, студентлар һәм укытучылар контингенты да күпкә артты, яңа белгечлекләр кертелде. Казан дәүләт педагогика университетының Яр Чаллысы филиалы оештырылды, бу уку йорты тарихында беренче мәртәбә вузның чит ил вузлары белән элемтәләре булдырылды,

һәм алар, елдан-ел киңәйде, ныгыды; докторлык диссертацияләре яклау советлары ачылды, укыту өчен материаль база ныгыды, хезмәткәрләрнең һәм укытучыларның тормыш хәле яхшыра төште. Бу елларда вузның фәнни потенциалы да ныгыды: 1986 елда фән докторлары һәм профессорлар саны 16 булса, 2002 елда алар 60 ка җитте. Фән кандидатлары һәм доцентларның, мактаулы исемнәргә лаеклы укытучыларның, фәннәр академияләре әгъзалары, Сорос профессорлары һәм доцентларының саны күбәйде.

Казан педагогика институтының күп меңле коллективының киеренке һәм тырыш хезмәте нәтиҗәсе буларак, 1994 елда вуз яңа статус алды – педагогика университетына әверелде.

Республиканы зур белемле, тәрбия эшенә тагын да әзерлекләрәк, киң кырлы укытучы-тәрбиячеләр белән тәэмин итү бурычы педагогика уку йортларыннан яңа белгечлекләр һәм дисциплиналар кертүне, уку планнарын, программаларын камилләштерүне һәм үзгәртүне, булачак белгечләрнең белемнәренең сыйфатын күтәрүне таләп итә иде. Миңа шушы төп бурычны гамәлгә ашыру эшенә җиң сызганып керешергә, коллективны шушы бурычны үтәүгә тупларга, һәр эшкә төшенеп, кирәк чакта һәркемгә ярдәм итәргә, кешеләргә дә, үземә дә таләпләрне арттыра барырга туры килде. Бу чорда барлык белгечлекләрнең дә уку планнарына минем инициатива белән яшь буынны өйрәтү һәм тәрбияләү өчен аеруча кирәкле дисциплиналар, мәсәлән, музыка тәрбиясе нигезләре, сөйләм культурасы, сөйләм техникасы, риторика, хореография кертелде һәм тиешле кафедралар ачылды.

Уку планнарына бу һәм башка культурология дисциплиналары кертелү булачак укытучыларга эстетик тәрбия бирү һәм аларны гомумән профессиональ яктан әзерләү бурычын уңышлы хәл итү мөмкинлеге бирде. Казан педагогика университетының педагогика һәм башлангыч белем бирү методикасы, педагогика һәм мәктәпкәчә белем бирү, психология, педагогик юнәлешле юриспруденция белгечләре әзерли башлавы да төптән уйланып һәм тормыш практикасын исәпкә алып кылган гамәл булды. Ул белгечлекләр республикада тиз арада популярлык казанды, һәм Казан педагогика университетына, бу белгечлекләрне үзләштерү өчен, елдан-ел күбрәк егет-кызлар килә иде.

Миңа кадәр Казан педагогика институтында традицион рәвештә өч Көнбатыш – инглиз, немец, француз телләре белгечләре

әзерләнеп килгән. Соңгы елларда, илебезнең көнчыгыш дәүләтләре белән бәйләнеше киңәя баруын исәпкә алып, без, инглиз теле белән бергә, көнчыгыш халыклары телләрен – гарәп, төрек, фарсы, һинд, кытай, япон телен дә белә торган белгечләр әзерли башладык. Көнчыгыш илләрендә бездә укып чыккан белгечләрнең эшләве гадәти күренешкә әверелде.

Ректор булып эшли башлавымның беренче көннәреннән үк, кафедраларның, хуҗалык бүлекләренең эшләрен якыннан белеп торуны үземә җитәкчелек итүнең әһәмиятле алымы итеп кабул иттем. Урыннарда күп булырга, укытучылар, студентлар, хезмәткәр-эшчеләр белән мөмкин кадәр күбрәк очрашырга тырыша идем. Факультет җыелышларында, гыйльми советларның, кайчакта кафедраларның утырышларында, студентлар җыелышларында катнашырга, кешеләр белән турыдан-туры сөйләшергә кирәк дип санадым. Һәр елны факультет студентлары белән очрашып, ачыктан-ачык сөйләшүне практикага керттем. Урыннардагы хәлне белеп тору уңышлы эшләвемә нык ярдәм итте.

Студентларның тулай торакларында һәр бүлмәгә, кухняюыну бүлмәләренә, кирәк дип тапканда, һәр туалетка кереп йөреп, аларның яшәү шартларын якыннан белешеп тордым. Бу кызыклык өчен түгел, бәлки андагы тәртипсезлекләрне, җитешсезлекләрне бетерү өчен эшләнә иде. Студентларның тулай торакта үз-үзләрен тотышларын һәрвакыт күз уңында тоттык, студентларның үзидарә системасын камилләштерә, активистларны стимуллаштыра бардык. Кыскасы, студентларның – булачак укытучыларның яшәүләре тәртипле, үзләре әдәпле, культуралы булсын өчен, төрле чаралар күреп килдек. Шуңа күрә дә безнең вузның тулай торагы башка вузларныкы арасында күп еллар үрнәк булып, конкурсларда призлы урыннар алып килде. Имтихан сессияләре вакытында, факультетларда барган төрле экзаменнарга кереп, җавап бирүчеләрне тыңлаштыргалап чыга торган идем. Бу миңа студентлар белеменең сыйфаты хакында кыйммәтле информация бирде.

Җитәкче кешегә коллектив алдында күп тапкырлар чыгыш ясарга туры килә. Мин баштан ук үземнең урынбасарлар әзерләп биргән текст буенча сөйләргә түгел (әзерләргә кушмый да торган идем), бәлки докладларны үзем әзерләп, үзем язып сөйләүне принцип итеп куйдым.

Һәр елны традицион рәвештә 31 август яки 1 сентябрь көнне, бөтен укытучыларны җыеп, актлар залында гыйльми советның

киңәйтелгән утырышын үткәрә торган идем. Узган уку елындагы укыту, тәрбия, фән һәм хуҗалык эшләренә анализ ясап, уңышларны да, җитешсезлекләрне дә күрсәтеп, эшне яхшыртуга юнәлтелгән тәкъдимнәр ясап, доклад сөйли идем. Күп еллар чираттагы ялыма бары ике атна вакыт кына эләгә иде (өч-дүрт ел, гомумән, отпуск ала алмадым). Шул вакытта берәр җиргә ял итәргә китсәм, чемодан тутырып, кирәкле информация текстларын алып барып, отчет докладын язып ята идем.

Шундый кырыс режимда эшләдем. Мин моны дөрес режим, дөрес эш стиледер дип әйтмим, әмма мин җайлап кына, иркенләп, үземә кыенлык китермичә генә эшли алмадым. Максатым – бөтен көчемне биреп, вузның дәрәҗәсен күтәрү, эшне яхшы итеп, мөмкин булса, хәтта бик яхшы итеп эшләү иде. Бу максатка ни дәрәҗәдә ирешкәнмендер, монысын халык беләдер. Әмма минем үкенечтә калмады: кулымнан килгәннең барысын да эшләдем, үземне аямадым.

Фәнни-тикшеренү эшләренең сыйфаты вуз тормышында бик әһәмиятле күрсәткеч икәнлеген аңлап, мин Казан педагогика университеты укытучыларының гыйльми үсешенә мөмкин булганча ярдәм итәргә тырыштым.

Казан педагогика университеты рейтинг буенча беренче ун вуз арасында булды. Бу, димәк, югары уку йортында фәнни-тикшеренү эше белән нәтиҗәле шөгыльләнәләр дигән сүз, һәм бу өлкәдә уңышлар шактый зур иде.

Фән докторлары һәм профессорлар барлык укытучыларның 10 проценттан артыграгын тәшкил итә. Гыйльми дәрәҗәле һәм исемле укытучылар 60 проценттан күбрәк. Фәнни-педагогик кадрлар әзерләүнең төп чыганагы – аспирантура. Шуның өстенә, берничә белгечлек буенча докторантура ачуга ирештек.

Фәнни дәрәҗәле укытучыларга ия булу өчен, вузның үзендә докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре советлары булу бик әһәмиятле. Шуны истә тотып, без өч докторлык советы ачтык. Болар: педагогика советы (председателе – профессор Җ.Г.Нигъмәтов), физиология советы (председателе – профессор Ф.Г.Ситдыйков), телләрне чагыштырып өйрәнү советы (председателе – профессор Р.А.Юсупов).

Фәнни-тикшеренү эшенең нәтиҗәлелеге шактый югары булды. Университет галимнәре һәр елны уннарча монографияләр, сту-

дентлар һәм мәктәп укучылары өчен дистәләрчә дәреслек һәм уку ярдәмлекләре бастырып чыгаралар иде.

Мин ректор булып эшләгән чорда Казан педагогика университеты спорт Олимпына күтәрелә барды. XX гасырның 90 нчы елларында КДПУ спортта яңа үрләр яулый торды. Соңгы ун елда исә бу өлкәдә уңышлар аеруча зур булды: педагогика университеты командасы республика спартакиадасында спортның барлык төрләре буенча да диярлек һәрвакыт призлы урыннар алып килде. Апрельдә үткәрелә торган традицион җиңел атлетика эстафетасында спортчы педагоглар һәр елны да беренче булдылар. Шушы ук елларда Казан педагогика университеты студентлары күп кенә бөтенроссия, халыкара спорт ярышларында, шулай ук Австралиядәге бөтендөнья олимпиадасында призлар алдылар.

КДПУда ректорат, партком һәм деканатлар тарафыннан студентларның культуралы көнкүрешенә, аларның мораль-этик халәтенә һәм тулай торакларда үз-үзләрен тотышына зур игътибар бирелеп килде. Мин ректор булып эшли башлаганда, интитутта студентларның үз-үзләрен тотышында, тулай торакларда яшәү рәвешендә проблемалар бар иде. Мәсәлән, минем ректорлыкка кадәр табигать фәннәре – география факультетында укучылар яши торган тулай торакта бер егетнең, террор оештырып, кызларны куркытып, пистолеттан атып йөрүе хәбәре үзәк газеталар аша бөтен илгә таралды. Бу студентлар арасында тәрбия эшендә җитди кимчелекләр булганлыгының чагылышы. Ул чакта югары партия органнарының Казан педагогика институтындагы хәлләр белән җитди шөгыльләнүе, укучылар белән эшләүдәге кимчелекләр өчен факультет деканының эшеннән азат ителүе, партком секретарена катгый шелтә белдерелү һәм башка кайбер партия-административ чаралар күрелү пединститут өстенә шактый зур күләгә төшерде. Шул вакыйгалардан соң ректорның тиз генә икенче урынга эшкә күчүе дә очраклы булмагандыр. Ул үзе мин Тел, әдәбият, тарих институтына, аның статусын күтәреп, шуның нигезендә Гуманитар фәннәр академиясе төзү өчен күчтем дисә дә, мондый белдерүнең чынбарлыкка туры килүендә шик зур иде. Мондый ният тормышка да ашмады: андый академия төзелмәде дә.

Казан педагогика институтының мораль климатына физик культура факультеты студентлары шактый зур тискәре йогынты ясый иде. Ректоратка еш-еш шул факультетта укучы егетләрнең җинаятьчел гамәлләре турында хәбәрләр килеп тора: әле, сугышып,

кемнедер каты имгәткәннәр, әле кайсыдыр кызны көчләгәннәр һ.б. Бу бит педагогика уку йорты өчен хурлык. Мондый хәл булырга тиеш түгел. Факультетка барып, укытучыларны, студентларны җыеп, бер сөйләшәм, ике сөйләшәм, каты итеп кисәтәм. Укучыларга мөрәҗәгать итеп: “Сез, күренекле спортчылар булсагыз да, беренче чиратта пединститут студентлары һәм без сезне барыннан да бигрәк укытучылар итеп әзерлибез, димәк, сезнең арада җинаять кылучылар гына түгел, бернинди тәртип бозучылар да булырга тиеш түгел”, – дим. Һәм шунда ук деканга карап әйтәм: “Ринат Абзалович, мин Сезне тырыш, уңган егет дип беләм, фәндәге һәм башка өлкәләрдәге уңышларыгызны да күреп торам һәм хөрмәт итәм, ләкин барыбер тиз арада факультетта, тәртип урнаштырып, тәрбия эшен яхшыртмасагыз, тиздән үткәреләчәк декан сайлавында кандидатурагызны күрсәтерсез һәм ректорат та, партком да Сезне яклар, дип уйламыйм”. Һәм бу җитди сөйләшүдән соң факультетта хәлләр уңай якка җитди үзгәрде, студентларның үз-үзләрен тотышында моңарчы булган хурлыклы күренешләр бетте. Факультет бөтен яктан да уңышлы алга барды, укытуда, фәндә, спортта зур казанышларга иреште.

Моннан соң институтта студентларны тәрбияләү эшенә зур уңай үзгәрешләр кертелде. Бу эшнең эзлекле системасы булдырылды. Ректорат, деканатлар, кафедралар һәм барлык укытучыларның гомумән тәрбия эше өчен, студентларның тулай торакта тәртипле яшәве өчен җаваплылыгы арттырылды. “Педагогика институты укытучыларының белем бирүдән кала җитди бурычы – студентларны тәрбияләү” дигән девиз белән яши башладык. Тулай торакта эшләү өчен, махсус декан урынбасарын билгеләп куя торган булдык.

Студентларга тулай торакта әйбәт яшәү өчен, тиешле шартлар булдырылды, биналарга вакытында ремонт ясалып торды.

Республикада үткәрелгән смотр-конкурсларда Казан педагогика университетының тулай торакларына берничә ел рәттән призлы урыннар бирелде.

Университетның чит ил уку йортлары, фәнни оешмалары һәм мәдәният учреждениеләре белән хезмәттәшлегенең активлыгы һәм нәтиҗәлелеге – вузның рейтингын билгеләнгәндә әһәмиятле критерийларның берсе.

Шуны истә тотып, ректорлык вазифасын башкаруның башыннан ук КДПУның чит илләр белән бәйләнешләрен җәелдерүгә

җитди игътибар иттек. Халыкара бүлек оештырдык, күп кенә илләрнең университетлары белән нәтиҗәле контактлар урнаштырдык.

КДПУның хәзерлек бүлегендә Европа, Азия, Африканың төрле илләреннән килгән егетләр һәм кызлар рус телен өйрәнде.

Чит ил кешеләре Казан педагогика университетында төрле белгечлекләр буенча аспирантура уздылар, кайберләре КДПУ советларында диссертация яклады. Мәсәлән, Кытайдан килеп, безнең университетта кытай телен укытучы Хе Хуа, рус-кытай телләрен чагыштырып өйрәнеп, минем җитәкчелектәге советта диссертация яклады.

КДПУ студентлары, аспирантлары, докторантлары һәм укытучыларының чит илләр белән элемтәләренең масштаблары да нык киңәйде. Аларның чит илләрдә булуының сәбәпләре төрлечә: кайбер студентлар чит ил университетларында укыйлар, стажировка узалар, кыска вакытлы командировкаларда булып кайталар. КДПУ һәм чит ил университетлары җитәкчеләре һәм укытучылары үзара делегацияләр алмашып тора. Хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзелә. Казан педагогика университетында чит илләрдән зур җитәкчеләр булды. Миңа Франция һәм Иран илчеләрен, Япония һәм гарәп илләренең культура мәсьәләләре буенча атташеларын һәм чит илләрнең башка күренекле кешеләрен кабул итәргә туры килде.

2001 нче елда Татарстан Республикасы Президенты аппаратының тышкы элемтәләр департаменты тәкъдиме белән Казан педагогика университеты базасында Идел буе Иран үзәге төзелде. Бу үзәкнең максаты Татарстан һәм гомумән Россия белән Иран арасындагы хезмәттәшлекне үстерүгә ярдәм итү иде.

Әйтергә кирәк: чит илләр белән бәйләнешләр урнаштыру һәм җәелдерү җиңел эш булмады. Казан педагогика университетында (институтында) чит ил уку йортлары белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе дә, моның өчен тиешле шартлар һәм материаль база да юк иде. Алдынгы илләргә тиң булып хезмәттәшлек итү аеруча авыр. Шуңа да карамастан ректорат халыкара мөнәсәбәтләрне киңәйтү юлына нык басты һәм шул юлдан тайпылмады.

Минем җитәкчелек чорында университетның материаль базасын ныгыту өчен күп нәрсәләр эшләнде. Хәлбуки, КДПУ финанс мәсьәләсендә бик авыр чор кичерде: биш-алты ел рәттән Мәскәү акчаны бары тик хезмәт хакы һәм стипендия түләү өчен чикләп кенә

биреп килде. Башка максатларда миллионнарча сумны үзебезгә табарга туры килде. Һәм бу елларда, башка күп вузларның материаль базасы таркалып барганда, Казан педагогика университеты зарарланып калмады гына түгел, киресенчә, ныгый барды.

Мин табигатем белән хуҗалык кешесе, төзүче: үземә йорт салып чыктым, гаражлар, бакчалар кордым. Үзем җаваплы вузның төзеклеге өчен, гаиләм өчен эшләгәнгә караганда, күбрәк көч салдым дисәм, ялгыш булмастыр.

Мин үземә принцип итеп алдым: уку-укыту, эшләү урыннары төзек, чиста, пөхтә, матур, кыш көне җылы булырга тиеш. Бу принципның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлегенә коллегаларымны да инандырдым кебек. Санап киткән таләпләрне гамәлгә ашыру өчен, без, вуз җитәкчеләре, хезмәткәрләре һәм эшчеләре, күп нәрсәләр эшләдек. Искәртеп китәм: Казан педагогика институты сугыш вакытында, элекке бик яхшы биналарны Суворов училищесына калдырып, үзе иске-москы, ярым-йорты биналарда төпләнеп калырга мәҗбүр булган. Вуз шәһәрнең төрле җирләрендәге унлап иске бинага урнашкан. Шуның өстенә, берничә тулай торагы, “Яльчик” спорт-ял базасы, Победилово авылы янындагы агробиостанциясе бар. Шушындый хуҗалыкны тәртиптә, төзек итеп тотуның җиңел эш түгел икәнлеге аңлашыладыр. Ярый әле, элекке ректор, Рәис Кыямович Беляевның турыдан-туры зур ярдәме белән, ике тулай торак төзетеп калган.

Кыскасы, мин ректорлык эшенә керешкәндә, биналарны ремонтлау һәм тәртиптә тоту проблемасы бик зур иде.

Болак буендагы тарих-филология факультеты урнашкан бинаның эченә керерлек түгел иде: аудиторияләрнең түшәмнәреннән штукатуркалары кубып-кубып төшкән, стеналары кап-кара, корым сөртелгән кебек. Ничә ел ремонт ясалганы булмагандыр!

Институтның төп бинасы фасадының аскы өлешендә метрдан артык киңлектәге полоса корым кебек кап-кара ямьсез буяу белән буялган. Вестибюль стенасының аскы өлеше дә киң полоса итеп карага буяп куелган. Ректор бүлмәсенең түшәмендә тимер юл рельслары кебек гаять зур дүрт швеллер асылынып тора. Стеналары ниндидер ямьсез тупас материал белән капланган (тышланган). Ләкин мин, сүз булмасын өчен, баштагы берничә ел ректор бүлмәсенә ремонт ясатмадым, соңрак адәм рәтле итеп эшләттердем.

Башка уку биналарында да күренеш ямьсез, кайгыртучан хуҗа барлыгы сизелми иде.

“Яльчик” спорт-ял базасында күп өйләр ташландык хәлдә, яшәрлек түгел, берничә дистә ел ремонт булмаган. Кыскасы, институтның материаль базасын ныгыту белән җитди шөгыльләнергә кирәк иде. Бу эшнең уку-укыту процессына йогынтысы барлыгын истә тотып, мин хуҗалык эшләрен даими рәвештә игътибар үзәгендә тоттым һәм бу эшләрне оештыруга, уңышлы гамәлгә ашыруга коллективны туплауга ирештем.

Күп санлы биналарны төзек хәлдә тоту өчен, даими эшләүче берничә бригададан торган эшче-ремонтчылар группасы һәм ике төзүче-ремонтчылар фирмасы оештырдык. Нәтиҗәләр шатландырырлык булды. Ремонт күрмәгән биналар, бүлмәләр калмады. Ике-өч, күп дигәндә, дүрт-биш ел саен һәр аудиториядә, лаборатория, кабинет, коридор, вестибюль, холлда һ.б. матурлык таләпләре исәпкә алынган, заманча, зәвыклы ремонт ясатып тордык.

Биш уку бинасының фасадларын шундый итеп бояттык: алар шәһәрдәге иң матур биналар исәбенә керделәр. Шәһәр мэры Камил Шамилевич Исхаков моның өчен безне мактап, рәхмәт әйтте.

“Яльчик” спорт-сәламәтләндерү лагерен тәртипкә китерү өчен күп эшләргә туры килде. Заманында студентлар һәм укытучылар көче белән генә төзелгән бу ял-спорт базасы бик искергән, күп өйләрнең торырлыгы да калмаган иде. Лагерьны яңарту бурычы куелды, һәм эш башланды: яңа өйләр салынды, торырлыкларына ремонт ясалды, башка күп төрле эшләр башкарылды.

Казан янында табигатьнең матур урынында урнашкан агробиостанцияне генә теләгәнчә тәртипкә китереп өлгереп булмады. Анда да күп нәрсә ярым җимерек хәлдә. Кайбер чаралар күрдек, ләкин минем корган планнарым үтәлеп бетмәде, өлгермәдем: ректорлыктан китәргә туры килде.

Материаль базаның икенче әһәмиятле өлеше – уку-укыту җиһазлары, приборлар, инвентарь, уку әдәбияты. Кризис елларында вузны укыту өчен тиешле техник чаралар, әдәбият белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итү бик катлаулы эш иде. Шулай да бу өлкәдә шактый алга китеш булды: физика факультетын, нигездә, барлык кирәкле укыту-фән җиһазлары белән тәэмин иттек, математика факультетын да игътибардан читтә калдырмадык. Химия кафедрасы өчен заманча кыйммәтле лабораторияләр булдырдык. Күп кенә приборлар, укыту өчен техник чаралар, җиһазлар һәм башка кафедралар өчен дә уку кирәк-яраклары сатып алдык.

Педагогика уку йортының изге максаты укытучы буласы студентларга белем бирү генә түгел, бәлки аларны тәрбияләү дә. Казан педагогика институты (университеты) коллективы үзенә йөкләнгән җаваплы бурычларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотты.

Ректорат, деканатлар һәм кафедралар, 90 нчы еллардагы демократлашу идеясе белән артык мавыгып китмичә, студентларны тәрбияләү эшенең заман тарафыннан сыналган формаларыннан ваз кичмәделәр, бу эшнең уйланылган ныклы системасын бозмадылар. Киресенчә, университет җитәкчелеге тәрбия эшен тагын да ныграк яхшырта, камилләштерә бару, бу эштә таләпне укытучыларга да, студентларга да көчәйтә бару юлына басты.

КДПУ студентларын тәрбияләү эше максатчан, комплекслы, масштаблы итеп башкарыла, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, педагог-студентлар башка вуз студентларыннан тыйнаграк, әдәпле һәм культуралырак булулары белән аерылып торалар иде.

Ректоратның тәрбия эшендә җитди чаралар күрүе аркасында Казан дәүләт педагогика институты (университеты) студентларының мораль-этик йөзе яхшы якка нык үзгәрде. Без эшләгән елларда наркомания күренеше булмады, коллективта яшәү кагыйдәләрен тупас бозулар юк иде диярлек, тәртип, чисталык, пөхтәлек хөкем сөрде. Тикшерүне көчәйтеп, таләпләрне, җаваплылыкны арттырып, студентларның язып, сызып, төрле ямьсез рәсемнәр ясап, өстәлләрне, башка төрле җиһазларны пычрату күренешеннән арындык. Вакыт-вакыт аудитория, лабораторияләрне үзем йөреп тикшереп чыга торган идем.

Студентлар укытучыларга, хезмәткәр-эшчеләргә әдәпле, ягымлы, хөрмәт белән карыйлар.

Минем тормышымдагы иҗтимагый шәхес буларак җитлеккән чорның үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: миңа, язмыш кушуы буенча, үземнең көчемне һәм сәләтемне шактый актив рәвештә төп өч өлкәдә гамәлгә ашырырга туры килде. Бу, беренчедән, административ (җитәкчелек) вазифалар белән бергә үрелеп барган укытучылык шөгыле, икенчедән, фәнни эшләр һәм, өченчедән, иҗтимагый-сәяси гамәлләр.

Һәм миңа узган тормыш юлына анализ ясаганда, үземнең күп эшләремне, кичерешләремне зиһенемдә яңартканда, энергиямне, белемемне һәм тәҗрибәмне бу өлкәләрнең кайсысында күбрәк кулланганлыгымны, минем өчен аларның кайсысы аеруча әһәмиятле, нәтиҗәле булганлыгын билгеләү җиңел булмый.

Уйлап карасаң, кызык хәл килеп чыга. Укытучылык һәм җитәкчелек эше ул – төп вазифаларым, түләүле эшләр, гыйльми эш шулай ук вуз укытучысының вазифаларына керә. Иҗтимагый эшкә (аны җәмәгать эше дип тә атыйлар) килгәндә исә, ул, минемчә, фидакарь, энтузиаст кешеләр шөгыльләнә торган эш. Ул күңел кушуы, җан таләбе буенча, хезмәт хакы алмыйча башкарыла.

Иҗтимагый-сәяси эшләремә шундый карашка нигезләнеп бәя бирсәң, минем үз гомеремдә энергиямнең һәм көчемнең күпчелек өлеше түләүсез, намусым кушканлыктан, бөек идеаллар өчен сарыф ителгән, дип әйтергә хакым бар.

Минем җәмәгать эшеннән яшьтән үк гомерем буенча бәхетем булды дияргә мөмкин.

Мин, армиядә хезмәт иткәндә үк, подразделениебезнең иҗтимагый тормышында актив катнаштым: комсорг, стена газетасы редакторы булдым, күп төрле чаралар үткәрдек. Мине анда, армиядә, партиягә алганда иҗтимагый тормыштагы активлыгым исәпкә алынмый калмагандыр, әлбәттә.

Пролетар революция юлбашчысы В.И.Ульянов (Ленин) исемен йөрткән данлы университет студенты булуым белән илһамланып, мин укуның беренче көннәреннән үк кайнап торган студент тормышына чумдым. Шактый гына мөстәкыйль тормыш юлы узган, кайбер сынаулар кичкән кеше буларак, мине беренче курста ук тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретареның урынбасары (секретаре Индус Ризакович Таһиров иде) итеп билгеләделәр, ә икенче курстан комсомол бюросы секретаре итеп сайлап куйдылар.

Комсомол ул чакта Ленин университетында аеруча зур көчкә ия иде. Ул елларда ВЛКСМ членнары, республикадагы иҗтимагый тормышның алдынгы сафларында барып, күп кенә файдалы эшләр башкардылар. Нинди генә эшләр белән шөгыльләнергә туры килмәде безгә ул вакытларда! Истәлекле даталарны билгеләп үтү, төрле политик кампанияләрдә, Ленин өмәләрендә катнашу, балалар йортларына шефлык ярдәме күрсәтү, җәен, көзен урып-җыю эшләрендә катнашу, Оргсинтез төзелешендә эшләү һәм башка күп төрле эшләр.

Безнең группа бигрәк тә актив булды. Шундый егет-кызлар җыелган иде: барысы да, сайлап алган кебек, бик тә тырыш, инициативалы. Безнең җәй һәм көз көннәрендә күп тапкырлар, республикабыз колхоз-совхозларына барып, авыл халкына урып-җыю эшләрендә ярдәм итүебез турында аеруча матур истәлекләр саклана. Без анда, җиң сызганып эшләп кенә калмый идек, кичләрен клубта халыкка группабыз белән бушлай концертлар куйдык, концерт алдыннан халыкара хәл турында лекцияләр укыдык. Лекция уку миңа йөкләтелгән иде.

Группа старостасы – Ленар Җамалетдинов – концертны алып баручы, интермедияләр остасы. Лениза Галиева җырлый, бии. Равил Фәйзуллин, Фарсель Зыятдинов, Шамил Маннаповлар үзләре язган шигырьләрен сөйлиләр. Һәркем үз һөнәрен күрсәтә. Мин дә читтә калмадым. Гармун уйнау һәм бию минем вазифаларга керде. Кыскасы, безнең группа сәләтле, ялкынлы йөрәкле егетләр һәм кызлардан тора иде.

Шуңа күрә дә безнең академик группа, университетта үткәрелгән конкурста призлы урын алып, Ленинградка экскурсиягә барырга бушлай путевка белән бүләкләнде.

Студент елларындагы комсомол активлыгы, яшьлек ялкыны минем соңыннан Казан педагогика институтында (университетын-

да) укытучы булып эшләү дәверендә җитди эшләр башкару өчен әзерлек булды. Монда мине эшли башлавымның беренче елларында ук партия бюросының члены итеп сайладылар, һәм миңа дүрт ел (хәтта докторлык диссертациясен яклаган елны да) тарих-филология факультетының партия оешмасын җитәкләргә туры килде.

Күп профильле зур факультетның партия оешмасы секретаре булу, җәмәгать эше саналса да, күләме, мәшәкатьлелеге белән түләүле, штаттагы эштән һич кенә калышмый иде. Ул минем энергия һәм көчемне фәнни эшкә сарыф иткәннән күбрәк алды. Факультеттагы бөтен тәрбия, иҗтимагый-сәяси эш партия бюросына һәм, әлбәттә, беренче чиратта аның секретарена йөкләтелгән иде.

Миңа, зур җәмәгать эше башкаруым аркасында, һәр көнне иртәдән кичкә чаклы факультетта булырга туры килде. Шуның өстенә, студентларга дәресләр үткәрергә дә, фән белән шөгыльләнергә дә вакыт табарга кирәк. Мин төшке ашны сәгать өч-дүртләрсез ашый алмый идем: укытучылар факультетта чагында, күрәсе кешене күреп, мәсьәләләрне хәл итеп калырга кирәк бит.

Факультеттагы җәмәгать эше, берничә ел партия оешмасына җитәкчелек итү минем Казан педагогика университеты ректоры буларак эшлисе эшләремә яхшы әзерлек булды.

Ректор булып эшли башлагач, тиздән мин халык депутатларының Казан шәһәр советына депутат булып сайландым һәм анда мәгариф комиссиясе председателе итеп билгеләндем. Ике ел буена (бер чакырылыш срогы) мин депутатлык һәм комиссия председателе вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәп барырга тырыштым.

Комиссиядә Казан югары артиллерия училищесы начальнигы генерал Фомин, Казан газ җиһазлары заводы директоры кебек җитди кешеләр бар иде. Председатель урынбасары Любовь Петровна Кочнева, инициативалы, белемле ханым, миңа зур ярдәм итте. Соңыннан ул район мәгариф мөдире булып эшләде, хәзер Казан шәһәрендәге бик алдынгы 7 нче гимназия директоры, фәннәр кандидаты, яңа эш алымнары белән бөтен Россиягә мәгълүм мәгариф хезмәткәре.

Без, мәгариф комиссиясе членнары, Казан шәһәренең мәктәпләре, балалар бакчалары һәм башка төрле мәгариф учреждениеләренең эшен яхшырту буенча шактый күп игелекле эшләр эшләдек.

Минем тормышымның аеруча мәгънәле, матур сәхифәләре Татарстанның Югары Советы депутаты булып эшләү (бу да минем җәмәгать эшем) чорына туры килде дисәм, ялгыш булмастыр.

Татарстанның 1990–1995 еллардагы Югары Советы республикабыз тормышында чын цивилизацияле илләрдәге кебек сайланган һәм демократик принциплар белән эш иткән бердәнбер парламент булды. Горурланып әйтә алам: мин депутатлыкка җиде кандидат арасыннан альтернатив нигездә сайландым, һәм без гомумән алганда демократик шартларда эшләдек.

Мин республика парламентындагы эшләремне тасвирлауга хөрмәтле укучыларның игътибарын күбрәк җәлеп итәрмен, чөнки истәлекле 1990–1995 еллардагы Югары Совет Татарстанда һәм бөтен Россиядә хәлиткеч мәсьәләләрнең демократик юл белән хәл ителүенең матур үрнәген тәшкил итә.

Узган гасырдагы 90 нчы елларның башы – Советлар Союзы халыкларының уянуы, милли үзаңы үсүе чоры. Илдә тормышның социаль шартларын нигездән яхшырту, республикаларның политик статусын үзгәртү, демократияне үстерү өчен халык хәрәкәте куәтле дулкын булып күтәрелде.

Бу вакыйгаларны Татарстан республикасы, татар халкы бик теләп һәм көтеп алган иде.

Татарстан җәмәгатьчелеге республиканың статусын күтәрү өчен көрәшне бервакытта да туктатып тормаган. Татар халкы үзенең 1552 елда Казан ханлыгы җимерелгәннән бирле югалган дәүләтенең торгызылуы турында йөзләрчә еллар хыялланып килгән.

Татарстан республикасына карата, башка союздаш республикалар белән чагыштырганда, социаль-политик гаделсезлек бик зур иде. Предприятиеләре 25 миллиард сумлык продукция биргән Татарстанның үзенең бер генә дә промышленность министрлыгы булмады, барлык предприятиеләрнең 80 проценты Союз карамагында (буйсынуында), 18 проценты РСФСРныкы һәм бары тик 2 проценты гына автономияле республиканыкы, ягъни үзенеке булды. Союз һәм Россия бюджетларына күчергәннән соң, Татарстан республикасының үзенә бөтен табышның кыйпылчыклары гына эләгә иде.

Татарстан республикасына икенчел дәрәҗәдәге итеп карауның зур гаделсезлеге аның потенциалын союздаш республикаларның экономик күрсәткечләре белән гади генә чагыштыруда да ачык

күренә. Мәсәлән, территориясе һәм халык саны буенча Татарстан белән бер чама булган, милли табышының (доходының) күләме буенча аннан калыша да торган Литвада җан башына керем 1500 сум тәшкил итсә, безнең республикада – нибары 212 сум. Татарстан республикасы экономик һәм политик хокуксызлыктан иза чигә. Республика нефтьне күбрәк чыгарган саен, аның халкының тормышы начарая бара. Аз гына вакытта аның җире куеныннан 205 миллиард долларлык 2,5 миллиард тонна нефть суыртып алына. Татарстан чыгарган (суырткан) нефть аның үзенә зыянга гына килә. Шуның өстенә, экология коточкыч рәвештә начарая бара. Көннән-көн ныграк шул ачыклана: моннан ары болай яшәү мөмкин булмый. Җитди экономик реформалар ясау белән генә хәлне төзәтү мөмкинлеге калмый, политик системаның үзен үзгәртеп корырга кирәк була. СССРда башланган үзгәртеп кору шартларында яңадан автономияле Татарстанның статусын союздаш республикалар статусына кадәр күтәрү бурычы куела.

1990 нчы елның 12 нче июнендә Россия Федерациясенең Югары Советы Россиянең дәүләт суверенитеты турында декларация кабул итә. Бу акт “суверенитетлар парадын” ачып җибәрә. Россия декларациясендә, үзе өчен гаять зур хокуклар һәм вәкаләтләр күздә тотылып, аның составындагы республикаларга аларның политик статусын күтәрү мөмкинлекләре хакында сүз булмаганлыктан, республикалар үзләренең хокуклары һәм ирекe өчен көрәш башлап җибәрделәр. Бу көрәшнең алгы сафына Татарстан чыкты. Тарихның көн тәртибенә Татарстан республикасында тиешле декларация кабул итү мәсьәләсе куелды.

Югары Совет Президиумы Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы декларациясенең проекты турында карар кабул итте һәм бу проектны әзерләү буенча эш группасы оештырды. Бу группага, Татарстан АССР Югары Советының милли мәсьәләләр һәм культура комиссиясе председателе буларак, мине дә керттеләр. Бу миңа зур ышаныч белдерү һәм җаваплылык йөкләү иде. Безгә, комиссия членнарына, үзебезнең белемебезне һәм тәҗрибәбезне кулланып, декларация проектын төзү буенча шактый күп эшләргә туры килде.

Һәм менә 1990 елның 27 нче августында Татарстан АССРның уникенче чакырылыш Югары Советының тарихи икенче сессиясе ачылды. Ул үзенең эшен 30 нчы августта Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул итеп тәмамлады.

Бу Татарстан халкының язмышы хәл ителә торган бик авыр сессия булды. Берничә көн буена көчле, кискен фикер алышулар, бәхәсләр барды. Депутатларның бер өлеше декларацияне кабул итүгә төрлечә каршы килде, төрле киртәләр корды. Аларның кайберләре төрле сылтаулар белән декларация кабул итү мәсьәләсен кичектереп торырга тырышты. Мәсәлән, янәсе, авыл җирендә кызу урып-җыю эшләре бара, ә без монда вакыт уздырабыз, шуның өчен, бу мәсьәләне карауны, туктатып, икенче вакытка күчерү хәерле булыр.

Республикада, татарлар яшәгән башка өлкәләрдә дә хәл кискенләшә бара. Төрле шәһәр-авыллардан Югары Советка суверенитет турындагы декларацияне һичшиксез кабул итәргә дигән телеграммалар килә. Ирек мәйданында тоташтан берничә көн меңнәрчә кешеләр – сайлаучылар гөжләп тора: депутатлардан суверенитет мәсьәләсен кичектермичә хәл итүләрен таләп итәләр.

Депутат В.А.Курылев, мәйданнан халык таралганчы, сессия эшен туктатып торыйк дигән тәкъдим кертә. Югыйсә, янәсе, митингтагы халык, шаулашып, депутатлар эшенә комачаулый. Хәлнең кискенләшә баруын сизеп, мин сүз алып: “Минемчә, митинг безнең эшкә комачаулык ясамый, андагы халык бөтен җәмәгатьчелекне, республиканың барлык халкын борчыган төп мәсьәлә буенча үзенең теләктәшлеген күрсәтә, бердәмлеген белдерә”, – дидем. Аннары сессияне алып баручыга: “Минтимер Шәрипович, сез депутатларга сессияне туктатып торырга тәкъдим итәргә җыенмыйсызмы икән әле?” дип әйтеп, аны кисәтеп куюны кирәк дип таптым.

Мин, сессияне алып баручыдан Югары Совет исеменә килгән 600 телеграмманың да эчтәлеге белән депутатларны таныштыруларын таләп иттем, ул телеграммаларда суверенитет мәсьәләсен уңай хәл итәргә дигән таләпләр язылганлыгын белә идем. Ләкин нигәдер аларның эчтәлеген депутатларга җиткерми килделәр. Минем бу таләбемне депутат А.П.Васильев һәм башкалар да яклап чыкты. М.Шәймиев секретариатка телеграммаларның эчтәлеген игълан итәргә дигән күрсәтмә бирде, һәм тиздән аның бу әмере үтәлде дә.

Ниһаять, сессия республиканың дәүләт суверенитеты турындагы мәсьәләне карауга кереште. Утырышлар залыннан радио буенча турыдан-туры трансляция ясарга дигән карар кабул ителде.

Мәсьәләне карау Югары Совет Председателе Минтимер Шәрипович Шәймиев чыгышы белән башланды. Аның чыгышыннан соң сүз миңа бирелде. Менә ул минем чыгышымның тексты:

*Хөрмәтле депутатлар!*

*Татарстан рспубликасының дәүләт суверенитетын игълан итү ул – объектив зарурлык, хокукый дәүләт төзү, татар халкын милләт буларак тергезү һәм үстерү юлында иң мөһим этап. Безнең республикада гына түгел, бәлки аннан читтә яшәүче миллионлаган татарлар бүген үзләренең лаеклы халык икәнлекләрен раслауга, чын бәйсезлек алуга, чын тигезлеккә һәм прогресска ирешүгә булган хыялларын тарихи әһәмияткә ия шушы документны кабул итү белән бәйли. Хәзер акыллы һәм намуслы кешеләрнең берсе генә дә әлегә кадәр хөкем сөргән унитар, тоталитар дәүләт системасының татарларның чын тигез хокуклылыгын, культураларын һәм телләрен үстерү өчен барлык кирәкле шартларны булдыра алмавын күрми кала алмый. Автономияле республикаларның хәле союздаш республикаларныкы белән чагыштырганда бигрәк тә уңайсыз. Уйлап кына карыйк әле, бу хәлне ничек аңлатырга мөмкин: халыкның саны һәм икътисадый потенциалы буенча кайбер союздаш республикалардан өстен торган Татарстанның башкаласында һәм башка шәһәрләрендә, поселокларында һәм район үзәкләрендә татар мәктәпләре калмаган, республиканың үзенең фәннәр академиясе, нәфис фильмнар студиясе юк, татар телендәге телевизион һәм радио тапшырулар җитәрлек түгел. Китап нәшрияты да берәү генә, дәреслекләр, методик әдәбият, уку-укыту әсбаплары җитми, татар телендә газета-журналлар аз чыга. Төп халыкның туган теленең кулланылыш өлкәсе елдан-ел тарая бара, шәһәрдә яшәүче татар яшьләренең күбесе ана телләрен бөтенләй белми яки начар белә. Күргәнебезчә, татар җәмәгатьчелегенең борчылуы һич кенә дә урынсыз түгел. Бу һәм башка күп санлы проблемаларны хәл итүнең юлы бер генә – суверенитетка ирешү.*

*Үз проблемаларыбызны без, бөтен Татарстан халкы, үзебез генә, мөстәкыйль, бәйсез булганда гына хәл итә алачакбыз. Суверенитет игълан итү республикада социаль, икътисадый тормышны яхшырту өчен зур мәйдан ачачак. Республиканың җирләрен, табигый ресурсларын, бөтен техник-экокномик потенциалын, аның территриясендәге предприятие, учреждение, оешмаларын үз милке итеп игълан итеп, халык үз икътисадын үзе кору, җитештерүдән табыш алу һәм үз байлыкларыннан үзе теләгәнчә*

*файдалану мөмкинлеге алачак. Яшәү шартларын нигездән яхшырту, халыкны җитәрлек күләмдә һәм ассортиментта азык һәм промышленность товарлары, бөтен уңайлыклары булган яхшы торак һ.б. белән тәэмин итү шулай ук тулы экономик һәм политик бәйсезлек булганда гына мөмкин.*

*Республикабызның экономик яктан мөстәкыйль була алуына, аның хуҗалык тормышын уңышлы кору өчен, икътисадый куәте җитәчәгенә шикләнеп караучыларга шуны әйтергә телим: безнең республиканың табигать ресурслары җитәрлек һәм аның бәһаләп бетерә алмаслык байлыклары, хезмәт сөючән гүзәл халкы бар. Татарстан куллануына караганда шактый күбрәк җитештерә. Безнең уңдырышлы җирләребез, мул урман-суларыбыз, файдалы казылмаларыбыз һәм миллиардларча тонналап бушлай дип әйтерлек бирелеп килгән нефтебез бар. Хәзер дәүләт безгә бер тонна нефть өчен 25 сум түли, аның үзкыйммәте исә 24 сум тәшкил итә. Димәк, табыш бер сумлык дигән сүз. Нефть хәтта безгә зыян китерә дигән фикер дә йөри. Хәлбуки, дөнья базарында нефтьнең тоннасы 150 доллардан да кыйммәтрәк, һәм ул бәя көннән-көн арта бара.*

*Шуны да искә төшерергә кирәк: Татарстандагы барлык предприятие-ләрнең 98 процентын Союзга һәм Федерациягә буйсына торган предприятиеләр тәшкил итә. Алар исә үз табышларынан җирле бюджетка бик аз өлеш чыгара. Ә Татарстан икеләтә налог түли. Менә шуңа күрә республикабыздагы йөзләрчә мең кешеләр әлегә кадәр иске, җимерек йортларда яшиләр. Менә шуның өчен бездәге юллар да начар. Менә шуңа күрә бездә мәктәпләр, балалар бакчалары, ясләләр җитми.*

*Хөрмәтле депутатлар! Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы декларациянең матбугатта бастырып чыгарылган рәсми проектын сессиядә нигездә кабул итәргә мөмкин. Ләкин аның беренче пунктындагы Татарстан, суверен дәүләт буларак, ике федерация – РСФСР һәм СССР субъекты дигән сүзләрдән башка гына.*

*Аңлашыла ки, ике дәүләтнең субъекты булган хәлдә суверен дәүләт булу мөмкин түгел. Монда логика юк. Шуны исәпкә алып, ТАССР Югары Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе үзенең утырышында бу сессиягә Декларациянең берникадәр үзгәреш кертелгән проектын тәкъдим итәргә дигән карар кабул итте. Анда Татарстан, ике федерациянең субъекты булмыйча гына, суверен дәүләт дип игълан ителә. Мин сезне,*

*иптәшләр, Декларациянең шушы вариантын яклап чыгарга өндим.*

*ТАССРның халык депутатларының кайберләренең, шулай ук халыкның бер өлешенең, нигездә, рус телендә сөйләшүчеләрнең, Татарстанның дәүләт суверенитеты алуы идеясен якламауларын яки ярым-йорты карар кабул итү ягында торуларын истә тотып, мин шуны әйтергә тиеш: халыкара хокук документларында язылганча (аларда исә СССРның да имзасы бар), һәр милләтнең үзбилгеләнүгә, дәүләт суверенитетына ия булуга хокукы бар, һәм, димәк, татар халкының бәйсезлек алу, тигез хокуклы булу теләгенә нинди дә булса комачаулык ясау һәм каршылык күрсәтү халыкара хокукны тупас бозу, илдә хокукый дәүләт төзүне тоткарлау һәм татар халкына карата гаделсезлек кылу дип каралачак.*

*Татарстанның суверенитетын игълан итү, янәсе, татарларның милләтчелегенә, Татарстанда яшәүче башка милләт вәкилләренең хокукларын чикләүгә китерәчәк, дип сөйләнүләр алар – империячел фикер йөртүдән арынмаган һәр халык та башкалар белән тигез хокуклы булып яшәргә тели һәм яши дә ала дигән фикер белән килешергә теләмәгән кешеләрнең уйдырмалары. Мин,Татарстан Югары Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе председателе, ягъни милләтләр арасында дустанә мөнәсәбәтләр саклау өчен җаваплы кешеләрнең берсе буларак, шуны белдерәм: татар халкы, бәйсезлек, суверенлык алып, башка халыкларга хөрмәт белән караудан туктамаячак. Республикабыз халыклары арасындагы дуслык ныгый барачак. Әгәр дә ТАССР халык депутатлары арасында суверенитетка каршы кешеләр күбрәк булып чыкса яки сессия ярым-йорты, ягъни Татарстан ике федерация субъекты дигән, димәк, ялган суверенитет турында карар кабул итсә, бу татар халкының хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен нык чикләү булачак, һәм бу республикабыз халыклары арасындагы дуслыкны ныгытуга ярдәм итмәячәк. Чын дуслык тигез хокуклылар арасында гына була.*

*Мин, беренче чиратта республикабыздагы төрле милләт вәкилләре арасында яхшы күршелек, дуслык мөнәсәбәтләрен булдыру һәм ныгыту өчен җаваплы депутат буларак, ТАССР парламентындагы коллегаларыма шундый өндәмә белән мөрәҗәгать итүне бурычым дип саныйм: Декларация өчен тавыш биргәндә, мәсьәләнең бөтен якларын да исәпкә алып, җитди уйлап, күп миллионлы татар халкының язмышы өчен зур җаваплылык хисе тоеп,*

*тавышыбызны Татарстан халкының чын суверенитеты өчен бирик".*

Фикер алышуда күп депутатлар катнашты: мәсьәлә үтә әһәмиятле булганлыктан, теләгән кешеләрнең барысына да сүз бирергә дигән карарга килдек.

Татар иҗтимагый үзәге (ТОЦ) председателе, Татар халкының ирекле яшәве өчен көрәшче депутат М.А.Мөлековның чыгышы зур кызыксыну белән тыңланды. Аның, гражданлык килешүгә ирешеп, 30 нчы август суверен Татарстан көне булырлык итеп тавыш бирик дигән өндәмәсе бик урынлы һәм вакытлы булды.

Тәэсирле һәм мәгънәле итеп, депутат Фәндәс Шакирович Сафиуллин чыгыш ясады. Ул чыгышын бер-беребезгә юл куя торган булыйк дигән өндәмә белән тәмамлады: "Бер яктан, акыллылык, икенче яктан, юл куючанлык. Мин үзем рус халкының акыллы юл куючанлыгыннан башка татар халкының суверенитеты мөмкин түгел, дип саныйм. Татар халкы рус халкының бу акыллы гамәленә карата беркайчан да начарлык эшләмәячәк, бәлки, икеләтә, өчләтә дуслык белән җавап бирәчәк".

Республикабызның дәүләт суверенитетының зур әһәмияте хакында "Нижнекамскнефтехим" җитештерү берләшмәсенең генераль директоры депутат Г.З.Сәхәпов бик инандырырлык фактлар белән нигезләп сөйләде. Ул үзенең чыгышын: "Бер нәрсә бик ачык мәгълүм: моннан ары болай яшәү мөмкин түгел, һәм безгә артка чигенергә дә юл юк. Без, нинди юлдан барып, киң мәйданга чыга, кешечә яши, эшли алачакбыз? Бу предприятиеләрнең бәйсезлегенә, милекнең төрле формаларына, базарга, суверенитет һәм территориянең үзидарәсенә ирешү юлы. Һәм кемгәдер буйсынган хәлдә, кемнеңдер составында түгел, бәлки кемнәрдер белән бергә, суверен республикалар белән, договор нигезендә, тигез хокуклы, лаеклы, эшлекле партнерлар буларак", дигән сүзләр белән тәмамлады.

Аннары, гадәттәгечә, бик хисле, тәэсирле итеп, Фәүзия ханым Бәйрәмова чыгыш ясады. "Бу җирләр, телебез, динебез, – диде ул. – Безгә, татарларга күп мең еллар элек Аллаһ тарафыннан бирелгән. Без монда беркемне дә яулап алмадык һәм яулап алырга җыенмыйбыз да. Без бары тик үзебезнең хокукларыбыз өчен, милләтебезне саклап калу өчен көрәшәбез".

Политик һәм экономик суверенитет мәсьәләләре буенча фикер алышуда Татарстан хөкүмәте дә һәм беренче чиратта аның предсе-

дателе Мөхәммәт Галләмович Сабиров үзе катнашты. Хөкүмәтнең экономик программасы турында махсус доклад белән Министрлар Советы председателе урынбасары Филзә Гарифович Хәмидуллин чыгыш ясады. Менә ул чыгышның кайбер аеруча игътибарга лаеклы өлешләре:

“Татарстан республикасы җан башына промышленность продукциясенең күләме буенча автономияле республикалар арасында беренче урында тора һәм Россиянең уртача күрсәткечләреннән күпкә югарырак саннарга ия. Республикабызда җан башына авыл хуҗалыгы продукциясенең күрсәткечләре дә Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак. Шул ук вакытта, диде Ф.Г.Хәмидуллин, Татарстан Россиянең башка регионнарыннан социаль өлкәдә шактый арттарак бара. Мәсәлән, больницада урыннар белән тәэмин итү буенча ул бары тик 61 нче урында, торак белән тәэмин ителү буенча 37 нче урында. Суверенитет шартларында хөкүмәт политикасының асылы күп милләтле халыкның республиканың экономик потенциалыннан тулысынча файдалануыннан гыйбарәт булачак.

Суверенитет идеясен, бигрәк тә аның экономикасына караган өлешен яклап, тәэсирле итеп, СССР Югары Советы депутаты Ю.Г.Красильников чыгыш ясады. Депутатларга аның бигрәк тә шушы сүзләре нык тәэсир итте: “Татарстан бүген промышленность потенциалы милкенең ничә процентына ия? Ничә процентына? Бер ярым процентына! Бер генә колониянең дә беркайчан да үзенең милкендә шулкадәр кечкенә капиталы булмаган... Мин Татарстанга, аны халыкара хокук субъекты итеп танып, тулы суверенитет бирү ягында”.

Утырыш барышында председательлек итүче М.Ш.Шәймиев тәкъдиме белән, Декларация текстын ахырынача әзерләп бетерү өчен, килешү комиссиясе төзелде. Анда мине дә керттеләр.

Комиссия озак эшләде. Кайбер пунктлар буенча төрле фикерләр бар иде. Шулай да уңышлы эшләү һәм үзара килешүгә ирешә алу нәтиҗәсендә комиссия, бердәм фикергә килеп, Декларациянең соңгы текстын тәкъдим итә алды.

Сессиянең утырышын алып баручы, Декларациянең бу проектын игълан итү өчен, сүзне Ф.Ш.Сафиуллинга бирде.

Ниһаять, Декларацияне кабул итү буенча тавыш бирү процедурасы булды. Декларацияне хуплап, 242 депутатның 241е тавыш бирде, бер кеше нейтраль (битараф) булды. Шулай итеп, Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы зур кыенлыклар

нәтиҗәсендә барлыкка килгән декларациясе бертавыштан диярлек кабул ителде. Бу гаять зур җиңү, акыл җиңүе иде.

Без, триумфаль сессияне тәмамлап, Югары Совет бинасыннан чыкканда, инде төн уртасы булуга карамастан, безне, шатланышып, гөжләп торган йөзләрчә кешеләр каршы алды. Безне тәбриклиләр, кулларыбызны кысалар, рәхмәтләр әйтәләр... Бу күп меңнәрчә татарларның һәм Татарстандагы башка милләт кешеләренең чиксез зур шатлыгы иде.

Менә ул парламент депутатларының һәм халык язмышына битараф булмаган бик күп башка кешеләрнең киеренке көрәше нәтиҗәсендә барлыкка килгән документ тексты:

***“Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югары Советы,***

***– республиканың күп милләтле халкы язмышы өчен тарихи җаваплылыкны аңлап;***

***– Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республикалар Союзында яшәүче барлык халыкларның суверен хокукларына ихтирам белдереп;***

***– автономияле республика статусының күп милләтле халкының киләчәктә сәяси, экономик, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтеп үтеп;***

***– татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашырып;***

***– демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып,***

***1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны Татарстан Совет Социалистик Республикасы – Татарстан Республикасы итеп үзгәртә.***

***2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм җир асты байлыклары, табигать байлыклары һәм башка ресурслары бары тик – аның халкының милке.***

***3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга, нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, политик карашлары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешенең тигез хокукларын һәм ирекләрен гарантияли. Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт телләре сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.***

***4. Киләчәктә Конституциядә, башка хокукый норматив актларда, дәүләт тормышында дәүләтнең рәсми исемен “Та-***

***тарстан Совет Социалистик Республикасы” (Татарстан ССР) яки “Татарстан Республикасы” дип кулланырга.***

***Республика дәүләт властеның югары органын – “Татарстан Совет Социалистик Республикасының Югары Советы” дип, ә ул кабул итә торган актларны – Татарстан Совет Социалистик Республикасының Югары Советы актлары дип исемләргә.***

***5. Бу Декларация Татарстан ССР законнарын үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз договорын, РСФСР һәм башка республикалар белән договорлар әзерләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен, Татарстан ССР дәүләт төзелешенең аеруча мөһим мәсьәләләрен һәм аның ССР Союзы, РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсәбәтләрен аның халкы тикшерүенә чыгару өчен нигез булып тора.***

***Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлеккә ия.***

***6. Татарстан ССРның яңа Конституциясен, башка законнарын һәм норматив актларын кабул иткәнгә кадәр, Татарстан ССР территориясендә Татарстан ССРның, РСФСР һәм ССР Союзының Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килми торган законнары һәм закон актлары гамәлдә булуын дәвам иттерә.***

***Бу Декларация аны кабул итү вакытыннан көченә керә”.***

Декларация кабул ителде, ләкин алда аны гамәлгә ашыру белән бәйләнешле зур кыенлыклар тора иде әле.

Декларацияне тормышка ашыруның менә шундый алшартлары бар иде: Татарстан белән Россия Федерациясе арасында ике яклы договор төзү, Татарстанның статусы буенча бөтен халык референдумы үткәрү, республиканың яңа Конституциясен, Татарстан Республикасы халыкларының дәүләт телләре турында закон кабул итү һәм башка төрле чаралар.

Дәүләт суверенитетын игълан иткәннән соң, Татарстан өчен тарихи әһәмияткә ия икенче политик вакыйга ул – Татарстанның дәүләт суверенитетын бөтен халык тарафыннан беркетеп куя торган республика статусы турында референдум булды.

Референдумны әзерләү һәм үткәрү бик катлаулы иҗтимагый-политик хәлдә барды. Татарстан халкының ирекле, демократик рәвештә ихтыярын белдерүгә хокукы проблемасы буенча чын көрәш башланып китте. Бу бөтен халык плебисцитын үткәрттермәү максатында Россиянең билгеле бер политик көчләре тарафыннан

бик нык басым ясалды. Эш турыдан-туры куркыту һәм шантажга барып җитте.

Шушындый гадәти булмаган шартларда республикада халыкка референдумның изге максатын аңлату буенча зур эшләр башкарылды, мәгълүмат чараларында күп санлы чыгышлар ясалды. Минем үземә, Югары Совет депутаты һәм Казан педагогика университеты ректоры буларак, халыкны, алда торган референдумда актив катнашып, Татарстанның демократик, ирекле яшәве, аның суверенитеты өчен тавыш бирергә өндәп, радио, телевидениедә, матбугатта күп тапкырлар чыгыш ясарга туры килде.

1992 нче елның 21 нче мартында референдум булды. Сайлау пунктларына килгән республика гражданнарының күбесе Татарстанның суверенитеты һәм Россия белән договор мөнәсәбәтләре өчен тавыш бирде. Монда шунысы игътибарга лаек: референдумдагы сорауга уңай җавап биргән кешеләр татарлардан да, руслардан да бер чама булган. Шулай итеп, бөтен халык күләмендә тавыш бирү суверен дәүләт барлыкка килү фактын юридик яктан раслады. Моның нигезе исә республиканың дәүләт суверенитеты турындагы декларациядә салынган иде.

Чираттагы җитди политик акт суверен Татарстанның яңа Конституциясен кабул итү булды. Төп законның текстын язуда миңа, конституция комиссиясе члены буларак, актив катнашырга туры килде. Бу бик әһәмиятле документ проектына, Югары Совет сессиясендә карауга тәкъдим ителгәнче, күп тапкырлар тикшерелеп, тиешле үзгәрешләр кертелде.

Шунысы шатландырды: парламент сессиясендә төп законны кабул итү мәсьәләсе дә уңай хәл ителде.

1992 нче елның 6 нчы ноябрендә гражданнарның референдумда республиканы суверен дәүләткә әверелдерергә дигән ихтыярын юридик яктан беркеткән төп закон – Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителде.

Бу документта: “Конституция Татарстан Республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) нәтиҗәләре нигезендә игълан ителә”, – диелә. Аның беренче статьясы Декларациянең һәм референдумның асылын тәгъбир итә: “Татарстан Республикасы – республикадагы барлык күп милләтле халыкның ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыра торган суверен демократик дәүләт. Дәүләтнең суверенитеты һәм вәкаләтләре халыктан килә. Дәүләт суверенитеты – Татар-

стан республикасының аерылгысыз сыйфаты”. Конституциянең 59 статьясында: “Татарстан Республикасының законнары, әгәр дә алар аның халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә өстенлеккә ия”, – диелә. 61 статья Россия белән Татарстанның үзара мөнәсәбәтләрен шундый рәвештә беркетә: “Татарстан Республикасы – вәкаләтләрен һәм идарә итү предметларын бүлешү турында договор нигезендә Россия Федерациясе – Россия белән ассоциясләнгән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты”. Монда шуны искәртү мөһим: бу статья ике яклы договорга кул куелганчы ук барлыкка килгән.

Татарстан Республикасының җитәкчелеге Россия белән Татарстан арасында ике яклы договор төзү буенча озак вакытлар бик киеренке әзерлек эше башкарды. Бу мәсьәлә республика парламентында да каралды. Мин бу договордагы кайбер бик әһәмиятле мәсьәләләр буенча Татарстан ягыннан зур ташламалар ясалуы уңаеннан ризасызлык белдерүчеләр арасында булдым. Миңа, элек килешенгән проекттан аермалы буларак, Россиягә бергәләп идарә итүдә артык күп вәкаләтләр бирелү уңаеннан республика җитәкчелеген тәнкыйтьләргә туры килде. Аянычлы хәл: милиция, суд, прокуратура Россия карамагында калды. Россиягә – 17, Татарстанга 15 вакәләт беркетелде. Бергәләп идарә итүгә – 23 вәкаләт. Шулай да, ничек кенә булмасын, Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасындагы договор тарихка Россиядә чын федерализм башлануга юл ачкан һәм суверен Татарстан төзелү юлында әһәмиятле адымны тәшкил иткән документ буларак кереп калачак.

Парламентның “Татарстан Республикасы халыкларының дәүләт телләре турындагы” закон кабул итүе республикабызның рухи тормышында әһәмиятле вакыйга булды. Минем милли мәсьәләләр һәм культура буенча даими комиссия председателе дигән статусым, Казан педагогика университеты ректоры һәм татар теле гыйлеме кафедрасы мөдире булып эшләвем, шулай ук филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә һәм профессор исеменә ия булуым табигый рәвештә миңа бу гаять әһәмиятле документы әзерләүдә һәм кабул итүдә актив катнашу бурычын йөкли иде.

Без академик Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев, профессор Фоат Әшрәпович Ганиев һәм башка кайбер белгечләр белән бергә, суверенитет турындагы Декларацияне кабул иткәнче үк, телләр турын-

да законның проектын эшләргә керешкән идек инде. Дәүләт суверенитетын игълан иткәннән соң һәм Татарстан Республикасының яңа Конститутциясен кабул иткәч, телләр турындагы законны кабул итү кичектергесез хәл ителергә тиешле эшкә әверелде.

Югары Советта "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы" закон проектын әзерләү буенча махсус комиссия төзелде. Аның составында мин дә бар идем. Бу закон проектын парламентның барлык даими комиссияләрендә тикшереп фикер алышуны оештыру һәм, ул комиссияләрдә яраклы дип табылганнан соң, аны сессиягә тәкъдим итү миңа тапшырылды.

Бу закон проектын парламент сессиясендә карау өчен әзерләү җиңел эш булып чыкмады: миңа, аны кабул иткәнче, филологик һәм педагогик белемнәремнән файдаланып, шактый нык тырышырга туры килде.

Телләр турындагы закон проектын сессиядә караганда, бу мәсьәлә буенча доклад ясау миңа тапшырылган иде. Минем доклдтан соң, гадәттәгечә, проект буенча актив һәм кызыксынулы фикер алышу булды. Һәм "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы" закон депутатларның иң зур күпчелегенең уңай тавыш бирүе нәтиҗәсендә кабул ителде.

Мин актив депутат булдым. Ихтимал, хәтта артык актив та булганмындыр. Чын суверенитетка ирешү идеясенә ышанып һәм моның тормышка ашырылуына өметләнеп, мин үземнең чыгышларымда дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең хәлиткеч пунктларын һәм Конституциянең аеруча әһәмиятле статьяларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән мәсьәләләрне шактый кискен куя һәм башкарма хакимияттән Декларация идеяләрен тормышка ашыру буенча җитдирәк гамәлләр кылуын таләп итеп килдем.

Соңрак мин шуны аңладым: хакимият ияләренә үз фикерләрен һәм идеяләрен ачыктан-ачык һәм кыю рәвештә әйтә торган кешеләр кирәк түгел икән: ул идея һәм фикерләрне гамәлгә ашыру, янәсе, кайбер кешеләр өчен артык эш, мәшәкатьләр китереп чыгара бит.

Үземнең көчемнән, узган тормыш юлым һәм парламенттагы эшем тәҗрибәсеннән, шулай ук белемнәремнән файдалану нияте белән, мин чираттагы чакырылыш парламентына сайланырга ризалыгымны бирдем. Теоретик яктан караганда, минем сайлану мөмкинлекләрем җитәрлек иде: мине ул чагында элекке чакырылыш парламентында актив депутат буларак та, мин җитәкчелек

иткән чорда зур уңышларга ирешкән югары уку йорты ректоры буларак та республикада яхшы беләләр иде.

Шуның өстенә, мин эшләгән вузның күп меңләгән укытучылары һәм студентлары сайлау алды компаниясендә үзләренең җитәкчеләрен сайлату өчен күп көч куйдылар.

Әмма минем һәм коллегаларымның өметләре акланмады. Чөнки сайлау гадел итеп уздырылмады. Безнең илдә – Россиядә дә, Татарстанда да – әлегә гадел сайлауларның булганы юк. XII чакырылыш Югары Советын моннан бердәнбер чыгарма итеп карарга мөмкин. Мин үзем катнашкан ике сайлау компаниясендә парламентка сайлау законының һәм кагыйдәләренең тупас бозылуы хәлләренә шаһит булдым, һәм андый тәртипсезлекләр, закон бозулар аркасында үзем дә җитди мораль зыян күрдем.

Бездәге сайлау системасының гадел түгеллеген күрсәтә торган бер гыйбрәтле мисал. 1990–1995 еллардагы иң актив, нәтиҗәле эшләгән депутатларның берсе дә Татарстанның алдагы чакырылышлар Дәүләт Советына сайлана алмады: сайлау югарыдан аларның берсе дә сайлана алмаслык итеп оештырылган иде.

Дәшми торган, уңайлы депутатлар эшенең нәтиҗәсе күз алдында. Хәзер парламент сессияләрендә без эшләгәндәге кебек прогресска ирешүгә юнәлтелгән җанлы, кыю фикер алышулар, бәхәсләр юк, бер көндә бәхәссез-нисез дистәләгән мәсьәләләр хәл ителеп куела.

Бик тә гаҗәп хәл: соңгы 10–15 елда Дәүләт Советы депутатлары Мәскәү күрсәтмәсе буенча 1990–1995 еллардагы Югары Совет кабул иткән законнарны Россия Федерациясе законнарына туры китерерлек итеп үзгәртү белән шөгыльләнделәр. Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе законнары белән бертөрле булырга тиеш дигән принцип белән эш итсәң, республика законнарының кирәге каламы соң, алай булгач, Дәүләт Советының үзенең дә кирәге каламы икән соң дигән хаклы сорау туа.

Татарстан Республикасының мин кабул ителү тарихын әлерәк кенә тасвирлап узган Конституциясе – безнең, Татарстан халкының, яшәешенең асылын тәшкил итә торган иң беренче, төп закон. Безнең өчен моннан да зуррак закон юк: башка күп дистәләрчә, йөзләрчә законнар, моның белән чгыштырганда, икенчел дәрәҗәдәгеләр, шул төп законны гамәлгә ашыруга хезмәт итә торганнар. Шуңа күрә дә бөтен дөньядагы цивилизацияле дәүләтләрдә Конституция,

бик кирәк хәлләрдә, дистәләрчә, йөзләрчә елларга бер тапкыр гына үзгәртелә. Моның ачык мисалы – Америка Кушма Штатлары.

Ә менә безнең, зур өметләр багълап, җан атып кабул иткән Конституциябез – Татарстан Республикасының Югары Советы тарафыннан 1992 нче елның 6нчы ноябрендә кабул ителгән Конституциясе белән нәрсә килеп чыккан соң? Ул нинди булган да хәзер ниндигә әверелгән?

1992 нче елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституция төпле белемнәре булган, әзерлекле, тәҗрибәле кешеләр тарафыннан уйлап эшләнелгән, Дәүләт суверенитетын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән җитди документ иде. Суверенитет идеясе аның башында: 1 нче статьясында ук ачык итеп белдерелгән: "Татарстан – Республиканың бөтен күп милләтле халкының теләкләрен һәм ихтыяҗларын чагылдыручы суверен, демократик дәүләт".

Иҗтимгый-сәяси система бүлегендәге барлык статьялар да суверенитет рухы белән сугарылган. Мәсәлән, 2 нче статьяда: "Татарстан Республикасында бөтен власть халыкка карый. Халык дәүләт властен турыдан-туры, шул исәптән референдум үткәрү юлы белән, һәм, шушы Конституциягә туры китереп, дәүләт органары системасы аша гамәлгә ашыра", – диелгән. Конституциянең 4 нче статьясы татар һәм рус телләрен тигез хокуклы дәүләт телләре дип игълан итә. 5 нче статья дәүләтебезнең юридик эчтәлеген болай дип билгели: "Татарстан Республикасында дәүләт органнары эше хокукый дәүләт принципларында: законнарның өстенлеге, аларның һичшиксез үтәлергә тиешлеге, закон чыгару, башкару һәм суд властьларының бүленгән булуы җирлегендә тормышка ашырыла".

Конституциянең "Экономик (икътисадый) системасы" бүлегендә суверен дәүләтнең хәлиткеч принцибы билгеләнә: "Җир, аның байлыклары, урманнар һәм башка төрле табигать ресурслары, хайваннар һәм үсемлек дөньясы, дәүләт банкларының активлары, Татарстан халыкларының культура, тарихи хәзинәләре һәм республиканың хуҗалык мөстәкыйльлеген, материаль һәм рухи культурасының саклануын тәшкил иткән башка төрле милек гомумхалыкныкы булып санала".

Татарстан Конституциясенең 1992 елның 6 ноябрендә, ягъни беренче тапкыр кабул ителгән варианты – нигездә, тулысы белән республиканың үз законы беренче чиратта, аның үз халкының ихтыяҗларын канәгать-ләндерүне күздә тотып эшләнгән иде.

Мәсәлән, 20 нче статьяда әйтелгәнчә, гражданнарның хокуклары, иреге һәм вазифалары республиканың үз Конституциясе тарафыннан карала һәм шуның җирлегендә гамәлгә ашырыла.

Конституциянең безнең өчен, ягъни Татарстан халкы өчен иң әһәмиятле статьясы ул – “Татарстан Республикасы – суверен дәүләт” дигән бүлегендәге 59 нчы статья. Анда болай дип язылган: “Татарстан Республикасы үзенең дәүләт статусын мөстәкыйль рәвештә билгели, сәяси, икътисади, социаль-культура төзелеше мәсьәләләрен үзе хәл итә. Татарстан Республикасының законары аның бөтен территориясендә өстенлеккә ия. Тик алар Татарстан Республикасының халыкара таләпләренә генә каршы килмәсен”.

Татарстанның яңа Конституциясе без аны беренче тапкыр кабул иткән чакта нык уйлап язылган һәм барыбызны да шатландырырлык иде. Әмма бүген... Мин хәзерге Дәүләт Советының Төп Закон кабул ителүнең 20 еллыгын билгеләп үтәргә җыенганын белгәч, дөресрәге, бу дата уңаеннан үткәреләчәк конференциягә чакыру алгач, Конституция текстының 1993 елда басылып чыкканын һәм соңгы тапкыр чыгарылганын алып, аларны чагыштырып карагач, иңеп киттем. Болар икесе ике Конституция дисәң, бу чынбарыкка күбрәк туры киләдер. Соңгысын чын-чынлап Татарстан Конституциясе дип әйтү кыен, аны Русия-Татарстан Конституциясе дип атарга туры килә. Чөнки ул без теге вакытта һәр пункт, һәр җөмлә һәм һәр сүз өчен көрәшеп кабул иткән Төп Закон түгел инде. Татарстан Конституциясенең соңгы вариантында республикабызың суверенлыгын тәшкил иткән статьяларның күбесе алып ташланган, нык үзгәртелгән.

Без мәгълүмат чараларындагы хәбәрләрдән Югары Совет сессияләрендә Татарстан Конституциясен, Русия хакимиятләре таләбен үтәп, үзгәрткәнлекләрен белеп тордык. Ләкин мин бу дәрәҗәдә үк үзгәртелгәндер, дип башыма да китерми идем. Уйлап кына карыйк:

**Безнең Конституция беренче кабул ителгәннән соң 16 тапкыр үзгәртелгән!**

Татарстан Конституциясенең соңгы тапкыр төзәтелгәнен укыган саен кәеф ныграк кырыла бара: аның һәр статьясында, һәр пунктында Татарстанның роле, дәрәҗәсе кечерәйтелгән. Анда Татарстанның үзенә генә хас, аның үз халкының ихтыяҗларын күздә тоткан статьялар аз.

Минем ишетеп белүемчә, Татарстан парламенты депутат-

ларын республикабыз Конституциясен үзгәртергә Россиянең Конституция суды һәм тагын ниндидер органнар мәҗбүр иткән. Әмма шулай да безнең депутатларыбыз Татарстан Конституциясен Росссиянеке белән тәңгәлләштерә-тәңгәлләштерә артык тырышып җибәргәннәр. Бу очракта алар иң әһәмиятле нәрсәне онытып җибәргән. 1992нче елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституциянең иң беренче пунктында болай дип язылган иде: “Бу Конституция Татарстан Республикасының дәүләт (суверен дәүләт күздә тотыла иде – *Р.Ю.*) статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) нәтиҗәләре буенча кабул ителде һәи игълан ителә”.

1992 елның 21 мартында уздырылган референдумда Татарстан ватандашлары (татарлар да, урыслар да һәм башка милләт кешеләре дә) республикабызның дәүләт суверенитеты өчен тавыш биргән иде. Референдум нәтиҗәләре исә, мәгълүм булганча, иң зур хокукка ия. Димәк, референдумның төп нәтиҗәсен – халыкның суверен дәүләт өчен тавыш бирүен беркем дә, хәтта Президент та, парламент та үз карары белән генә юкка чыгара алмый. Татарстан халкы, беренче чиратта, республиканың үз Төп Законы – референдум нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән Конституциясе буенча яшәргә тиеш.

Мәгълүм булганча, узган чирек гасырдан артык елда Дәүләт суверенитеты турындагы декларациянең иң әһәмиятле пунктларыннан күп нәрсәне гамәлгә ашырып булмады һәм хәтта республикадагы суверенитет казанышларының беренче елларында булган нәрсәләрнең дә кайберләрен югалтып өлгердек. Соңгы елларда Декларациядә һәм Конституциядә беркетелгән позицияләрдән җитди чигенүләр булып тора.

Мондый күренешнең объектив сәбәпләре дә, субъектив сәбәпләре дә бар. Мин моны аңларга тырышам, хәлбуки, катлаулы дәүләт политикасының бөтен нәрсәләрен дә, ихтимал, аңлап та бетермимдер. Әмма мин бер нәрсәгә инанам: Декларациянең әһәмиятле пунктларының үтәлмәве өчен җаваплылык барыннан да бигрәк Дәүләт Советына төшә. Чөнки парламент ул – коллектив рәвештә законнар чыгару органы һәм аның вазифаларына кабул ителгән законнарның үтәлешен контрольдә тоту да керә. Шуңа күрә ул хөкүмәтнең, кирәк булса, президентның да төгәл һәм нәтиҗәле эшләве өчен җаваплы.

Минем Югары Совет депутаты булып эшләвемне сугышчан характерым формалашу чоры дияргә мөмкин. Шул чакта мин теге

яки бу мәсьәләгә карата үз фикеремне булдырырга һәм аны ачыктан-ачык кыю рәвештә белдерергә өйрәндем. Югары Советның сессияләрендә, парламентның президиумы һәм аның комиссияләре утырышларында миңа төрле мәсьәләләр буенча күп тапкырлар киеренке бәхәсләрдә катнашырга, кыю рәвештә үз фикеремне әйтергә һәм нәтиҗәдә парламент җитәкчесенең, ә соңрак республика башлыгының канәгатьсезлегенә дучар булырга туры килә иде. Ләкин ул чакта минем халык тормышын яхшыртуның хәлиткеч мәсьәләләренә карашымны беркем дә үзгәртә, дөрес юлдан тайпылдыра алмады һәм хәзер дә үзгәртә һәм тайпылдыра алмый.

Югары Совет сессиясендә вәкаләтләрне бүлешү турында Россия Федерациясе белән Татарстан арасындагы договор проектын тикшергәндә аның турында фикер алышканда, миңа кайбер депутатлар белән бергә республикабызга күбрәк хокуклар алуны яклап чыгарга туры килде. Үземнең чыгышларымда мин республикадагы хокук саклау органнары Татарстан юрисдикциясендә булырга тиешлеген һәм республикабызда милли мәсьәләләр министрлыгын оештырырга кирәклеген белдердем.

Республикабыз парламенты сессияләренең стенограммаларында минем Татарстан язмышы өчен бик әһәмиятле мәсьәләләр буенча ясаган чыгышларымның текстлары сакланадыр. Ул чыгышларымда мин авылларда фермер хуҗалыкларын оештыру һәм җәелдерү өчен шартлар булдырырга кирәк, балалар һәм яшьләрне тәрбияләүгә ныграк игътибар итәлергә һәм дәүләт тарафыннан күбрәк акча бүлеп бирелергә тиеш, җинаятьчелекнең, эчүчелекнең арта баруын, радио-телевидениедә, кинода һәм матбугатта порнографияне пропагандалауны туктату өчен дәүләтнең хокук саклау органнары нәтиҗәлерәк эшләргә тиеш, дип сөйләдем.

Татарстанның суверенитеты турындагы Декларацияне, Татарстан Республикасы халыкларының дәүләт телләре турындагы законны һәм хөкүмәт карарын, шулай ук башка әһәмиятле закон һәм карарларны тормышка ашыруга ярдәм итү теләге мине, җәмәгать эшлеклесе, зур вуз ректоры һәм галим буларак, мәгълүмат чараларында – матбугатта, радио һәм телевидениедә – актив рәвештә чыгышлар ясарга этәрде. Мин әһәмиятле мәсьәләләр буенча күп тапкырлар татар һәм рус телләрендә газета-журналларда, радиотелевидениедә чыгышлар ясадым. Алар җәмәгатьчелектә кызыксыну уята иде, һәм мине кабат-кабат чакырып тордылар.

Әгәр дә мин иҗтимагый-политик тормышымдагы күп төрле

эшләремнең берсен сөйләми калдырсам, хикәям тулы булмас иде. Бу – партия эше. Ләкин сүз коммунистлар партиясе турында түгел, ә икенче бер партия турында.

Хәер, мин коммунистлар партиясенә шактый хезмәт итеп өлгердем. Мин ул партиягә, армиядә хезмәт иткәндә, егерме яшемдә үк кереп, аның актив члены булдым. Бу хакта мин югарыда сөйләгән идем инде: кабатлап тормыйм. Коммунистлар партиясе, һичшиксез, куәтле идеология коралы хезмәтен уңышлы үтәп килде. Әмма, мәгълүм булганча, 80 нче еллар азагында ул банкротлыкка чыкты, һәм аның идеаллары якты киләчәккә өнди алмас булды. Дөресрәге, гаеп партиянең идеалларында түгел, бәлки, ул идеалларны бозган кешеләрдә, партия җитәкчеләрендә иде. Сүз уңаенда әйтеп китим: бозык репутацияле партия җитәкчеләре яңа стройда дәүләт органнарында җитәкче булып эшләргә тиеш тә түгелләр иде кебек. Бөтен дөньяда шулай, тик безнең Россиядә генә алай түгел.

Мин Коммунистлар партиясеннән үз теләгем белән киттем. Ләкин, кайберәүләр кебек, партияне каргап, сүгеп йөрмәдем һәм йөрмим. Минем өчен шул нәрсә бик сәер: элекке партиянең актив члennарының, бигрәк тә җитәкчеләренең күбесе хәзер шул партиянең яманатын сатып йөриләр. Аның җитешсез яклары бар, ләкин андагы бар нәрсә дә начар түгел иде бит: ул чорда, хәзергегә караганда, тәртип ныграк, халык тәрбиялерәк, яшәү максатчан, геделлек зуррак иде. Хәер, бу фикер йөртү өчен үзе бер зур тема.

Ул чакта ректорның партиядән китүе сенсация һәм шактый хәтәр күренеш иде. Ярый әле миңа зур зыян тимәде.

Республикабызда демократияне җәелдерү, дәүләтебезне тергезү һәм ныгыту, мәдәниятебезне, рухи тормышыбызны алга җибәрү максатында, шулай ук халыкның тормыш шартларын яхшырту нияте белән, 1992 нче елның азагында Татарстанның республика партиясе оештырылды. Бу изге эшне башлап җибәргән кешеләр – Марат Мөлеков, Гаял Мортазин, Фарсель Зыятдинов, Кави Латыйпов, Әгъзам Фәйзрахманов, Рагъде Халитов, Фираз Харисов, Әмир Мәхмүдов һәм башкалар үз халкының чын патриотлары иде. Оештыру җыелышында мине партиянең председателе итеп сайлап куйдылар. Бу хәл, һичшиксез, минем тормышымда зур вакыйга, рухи борылыш булды.

Миңа бу партиянең программасын, уставын төзү һәм партияне юстиция министрлыгында теркәү эшләре белән күп шөгыль-

ләнергә туры килде. Министрлыкта теркәлү өчен, республика районнарының ким дигәндә яртысында партиянең башлангыч оешмалары булырга тиеш. Бу безнең өчен бик катлаулы эш булды: хакимият органнары, партияне теркәтмәс өчен, төрле юллар белән комачауларга тырыштылар. Ләкин без үзебезнең максатка ирештек: Татарстанннның юстиция министрлыгында партияне теркәттек. Бу эштә безнең коллегабыз профессор Фираз Фахразович Харисовның роле зур булды.

Тиздән без партиябезнең басма органы “Татарстан Республикасы” газетасын оештырдык. Аны да юстиция министрлыгында теркәттек. Бу газета татар һәм рус телләрендә чыгып килде.

Татарстанның республика партиясе изге максатларга ирешүне күздә тотып эш итә торган центристик партия иде. Бу партия суверен Татарстанның алга баруында күпмедер дәрәҗәдә уңай роль уйнады. Ул үзенең членнарын, алар аша республиканың башка кешеләрен дә Татарстан халыкларының демократик казанышларын саклауга һәм ныгытуга туплау, кайберәүләрнең суверенитет идеясеннән баш тартырга омтылуларын фаш итү белән шөгыльләнде. Партиянең җитәкче органы – Даими комитет үзенең газетасында республика Конституциясенең төп статьяларын тупас бозулары уңае белән җитди белдерүләр бастырып чыгарды. Татарстанның республика партиясе халыкның тормыш дәрәҗәсе начарая, әхлак нормаларының какшый баруына зур борчылу белдереп килде. Партия шулай ук Америка Кушма Штатларының Иракны варварларча бомбага тотуына кискен каршы чыкты, Чечен республикасына карата җинаятьчел гамәлләр кылуы өчен Россия хөкүмәтен тәнкыйтьләде.

Татарстанның республика партиясенең матбугатта “Конституцияне бозуларга юл куймаска” дигән чыгышы аеруча игътибарга лаек. Анда республика җитәкчелегенең суверенитет турындагы Декларацияне һәм республиканың төп законы Конституцияне гамәлгә ашыру белән акрын шөгыльләнүенә борчылу белдерелә, республиканың мөстәкыйльлегенә һәм алга баруына юнәлдерелгән позицияләрдән чигенү булырга тиеш түгел икәнлеге кисәтелә.

Партиянең бу һәм башка игелекле эшләре, аңлашыла ки, аның җитәкчеләре тарафынан оештырыла һәм башкарыла. Безгә, партиянең активистларына, шактый нәтиҗәле гамәлләр кылырга туры килде.

Миңа ректорлар корпусында да шактый җитди җәмәгать эшләре башкарырга насыйб булды.

“Татарстан республикасы халыкларының телләре турындагы” закон кабул ителгәннән соң, студентларга кайбер дисциплиналарны татар телендә укыту ихтыяҗы һәм мөмкинлеге барлыкка килде. Шуны исәпкә алып, Татарстан вузларының (югары уку йортларының) ректорлары советы карамагында татарча укыту һәм татар теленә өйрәтү мәсьәләләре буенча махсус гыйльми-методик совет төзелде. Аның председателе итеп мине билгеләделәр.

90 нчы елларда бу совет татар теленең вузлардагы статусын күтәрүдә әһәмиятле роль уйнады. Татар теленә өйрәтү һәм татарча укыту өчен уку-укыту әдәбияты сыйфатында вуз укытучылары язган дәреслекләргә, уку ярдәмлекләренә, сүзлекләргә, аларны басарга тапшырганчы, шушы советта гыйльми-методик экспертиза уздырыла иде.

Будучи специалистом в области татарского и русского языков, ученым и руководителем педагогического вуза, мне пришлось несколько лет подряд участвовать в работе Комитета по реализации закона о языках народов Республики Татарстан при Кабинете Министров Республики Татарстан.

Являясь членом исполкома Всемирного Конгресса татар, я в какой-то степени внес свой вклад и в его деятельность.

Меня, как человека, активно выступающего на страницах печати, и как члена Союза журналистов, ввели в состав редколлегий таких газет и журналов, как “Мәгариф”, “Татарстан”, “Шәһри Казан”, “Мәгърифәт”, “Заман”, “Фән һәм тел”, “Милли мәдәният”.

И, наконец, еще одна общественная работа: в 1992 году по инициативе Казанского педагогического университета было организовано общество дружбы “Татарстан – Арабский Восток”. Оно несколько лет успешно работало на укрепление дружбы между арабскими странами и Татарстаном, и его руководителем также считался я. Однако инициатором и автором многих начинаний был А.С.Михеев – специалист по арабскому языку и прекрасный организатор. К сожалению, он рано ушел из жизни.

# ПАРЛАМЕНТКА САЙЛАУ ҺӘМ ТАТАРСТАННЫҢ РЕСПУБЛИКА ПАРТИЯСЕ ЭШЕНӘ КАРАГАН ЯЗМАЛАР
# ПУБЛИКАЦИИ, ОТНОСЯЩИЕСЯ К ВЫБОРАМ В ПАРЛАМЕНТ И ДЕЯТЕЛЬНОСТИ РЕСПУБЛИКАНСКОЙ ПАРТИИ ТАТАРСТАНА

## ВОТ ТАКИХ ЛЮДЕЙ НАДО ВЫБИРАТЬ

Скоро нам предстоит выбирать депутатов в республиканские, городские и районные органы власти.

Каждый раз после выборов, когда не выполняется то, что нам обещали депутаты, мы думаем о том, что ведь, сами их выбирали. Значит, надо было хорошенько подумать, за кого голосовать. Вот сейчас по квартирам разнесли много листовок с биографиями и программами кандидатов в депутаты. Прочитали мы их и задумались, кому отдать свои голоса.

Одни предлагают то, что и по своей должности они обязаны делать, занимая административный пост – обеспечивать район теплом, электроэнергией и т.д. Если он не будет этого делать, какой же он администратор и за что он получает солидную зарплату?

В другой листовке наше внимание привлекло то, что ректор Казанского педагогического университета, кандидат в народные депутаты Государственного Совета республики по Московскому административно-территориальному округу № 5 Юсупов Рузаль Абдуллазянович выступает за то, чтобы Татарстан оставался родным отечеством для всех проживающих в нем народов. Это значит, что он за то, чтобы у нас не было ни второго Карабаха, ни второй Чечни!

Этой позиции он придерживался упорно, будучи депутатом Верховного Совета Татарстана прошлого созыва, отстаивал закон о двух государственных языках в нашей республике. Из его программы нам близка его позиция относительно депутатского корпуса. Депутаты должны быть честными, знающими жизнь и законодательную практику, добиваться выполнения принятых законов и постановлений.

Мы решили, вот таких людей и надо выбирать!

Надеемся, что Р.А.Юсупов будет добиваться принятия законов, социально защищающих ветеранов, пенсионеров, работников народного образования, здравоохранения, культуры. Пожелаем академику Р.А.Юсупову успехов в предвыборной борьбе! Только пусть эта борьба будет равной и честной.

Хорошо бы послушать на одном собрании выступления кандидатов по этому округу. Вот тогда бы и видно было, кто есть кто.

Избиратели Московского района:

**А.И.ДАВЫДОВ,** ветеран ВОВ
**З.А.НЕФЕДЬЕВА,** медсестра
**Т.Н.ПАНЯЕВА,** ветеран труда
**Л.Н.СМИРНОВА,** врач

## ЗАКОНОТВОРЧЕСТВО – ДЕЛО КОМПЕТЕНТНЫХ

С большим удовлетворением я восприняла сообщение о том, что кандидатом в депутаты Государственного Совета РТ по Московскому избирательному округу № 5 выдвинут ректор Казанского государственного педагогического университета Р.А.Юсупов.

Рузаль Абдуллазянович – достойный кандидат в депутаты парламента республики. Он – видный ученый, академик, автор многих книг, учебников. Имеет государственные награды.

Р.А.Юсупов имеет большой опыт политической и организаторской работы. Он в течение многих лет возглавлял серьезные участки работы на различных уровнях. В качестве депутата Верховного Совета РТ он принимал активное участие в подготовке и принятии многих законодательных актов. Р.А.Юсупов – разработчик законопроекта о языках народов Республики Татарстан.

На мой взгляд, законотворческой деятельностью должны заниматься видные ученые, юристы, политики. Таким ученым и политиком является Р.А.Юсупов.

И было бы правильно, если бы главы администраций больше усилий сосредоточивали на решении повседневных жизненных вопросов в своих районах, а не проводили время в парламенте, занимаясь якобы законотворческой деятельностью. Это могут сделать компетентные люди.

Я призываю всех жителей района проголосовать за Р.А.Юсупова! Голосуя за него, в нем вы найдете достойного защитника своих интересов!

**Е.В.Малявина**,
жительница Московского района
*"Педагог", февраль 1995 года*

## Я ГОЛОСУЮ ЗА АКАДЕМИКА Р.А.ЮСУПОВА

С Рузалем Абдуллазяновичем Юсуповым – ректором Казанского педагогического университета – я познакомился летом прошлого года. Со своими предложениями зашел в его кабинет, сомневаясь: вдруг откажет. А просил ни много ни мало – открыть в этом учебном заведении новое отделение для подготовки учителей чувашского языка и литературы. Причем до начала вступительных экзаменов оставалось всего лишь две недели.

В свое время Казанский учительский семинарий проводил большую работу по подготовке кадров для чувашских школ всего Волжско-Уральского региона.

К сожалению, за последние 30-40 лет литературная жизнь чувашской творческой молодежи оказалась в застойном положении.

Академик Р.Юсупов внимательно выслушал мои доводы. И решение было принято. За короткое время поступило больше 50 заявлений, на одно место оказалось более двух претендентов.

Новое отделение сегодня успешно функционирует. При активной поддержке Р.Юсупова при университете создается библиотека чувашской литературы.

Р.Юсупов проводит большую работу по укреплению межнациональных отношений. Не случайно он избран председаталем комиссии по национальным вопросам и культуре Верховного Совета. Он принимал участие в разработке законопроекта о языках народов Республики Татарстан.

Вот почему я, чуваш по национальности и педагог по образованию, на предстоящих выборах призываю голосовать за татарского академика – ректора педагогического университета Рузаля Юсупова.

**Б.Тихонов**,
отличник народного просвещения РФ
*"Казанские ведомости", 2 марта 1995 г.*

## ДОСТОЙНЕЙШИЙ ИЗ ДОСТОЙНЫХ

Новый парламент будет успешно решать задачи обновления общества, если будет состоять из принципиальных, компетентных, активных людей, болеющих за судьбы народов республики.

Еще Платон (Древняя Греция V-VI века до н. э.) утверждал, что "власть должна принадлежать философам, мудрецам, так как истинное знание и добродетель доступны только этим редким людям".

Именно к таким людям с большой уверенностью можно отнести ректора нашего Казанского государственного педагогического университета академика Юсупова Рузаля Абдуллазяновича, кандидата в народные депутаты Госсовета РТ. Рузаля Абдуллазяновича выгодно выделяют такие качества, как:

- глубокий аналитический ум и широкая эрудиция ученого;
- инициатива и богатый опыт работы в качестве депутата Парламента РТ;

– энергичность и большая организаторская деятельность по подготовке педагогов – воспитателей детей, за которыми будущее.

От имени ветеранов университета поддерживаем кандидатуру академика Юсупова Р.А. и обращаемся к студентам, преподавателям, сотрудникам университета, работникам народного образования и науки, ко всем жителям Московского района (округ № 5) сделать правильный выбор и отдать свои голоса за Юсупова Рузаля Абдуллазяновича.

***ВЕТЕРАНЫ*: АСЕЕВА Н.К., ЛЕБЕДЕВА Л.А., ЛУКМАНОВ Г.Л., МОРОЗОВ М.И., МУНЬКОВ Н.П., ХУДЯКОВ В.П., ПЕТРОВА Н.И., БИКМЕТОВА Р.М., ГАЗИЗОВ Б.Г., ГАТАУЛЛИН Р.В., ИСХАКОВА М.С.**

## НИЗКИЙ ПОКЛОН ВАМ, РУЗАЛЬ АБДУЛЛАЗЯНОВИЧ

С детства для меня примером был мой учитель – Павлюхин Александр Анатольевич (в прошлом выпускник нашего факультета). Мне всегда хотелось быть хоть чуточку похожей на него, сеять "разумное, доброе, вечное". Мысль о поступлении в педа-

гогический институт, стать учителем иностранного языка запала мне в душу, не давала покоя. Но возможности наши не совпадали с желанием: условия сельской школы, отсутствие учебников, возможность хотя бы краем уха слышать любимый английский язык мешали осуществлению моей мечты.

Но на мое счастье, к нам в село на работу приехал преподаватель из Казанского педагогического института. Какая это была для меня радость! Я узнала обо всех требованиях, которые необходимы для поступления в институт, подготовилась к вступительным экзаменам, вдохновилась и... не поступила. Не сумела набрать достаточно баллов. Рухнула мечта всей моей жизни. Но из самой безвыходной ситуации всегда можно найти выход. Оказывается, есть возможность поступить в институт "по договору". Об этом на собрании абитуриентов говорил ректор института Рузаль Абдуллазянович Юсупов. Этого человека я не забуду никогда. Он по отечески, с участием отнесся к моей проблеме, включил меня в договорную группу, предоставил возможность учиться. Но для учебы нужны были деньги. Платить было, конечно же, нечем, и я призналась в этом с чувством горечи и досады. Но вновь забрезжил спасительный огонек: меня включили в договорную группу с условием, что оплата будет произведена через год. Весь первый курс я старалась изо всех сил, чтобы оправдать то доверие, которое мне оказывали. Оценки у меня были разные – и тройки, и четверки, но, в конце концов, я стала получать и отличные оценки по предметам, изучаемым на инфаке. Год прошел. Мне вновь предстояла беседа с Рузалем Абдуллазяновичем. На сей раз он похвалил меня за отличную учебу и, как оправдавшую доверие, включил в список студентов, не требуя уже "договорных".

Я поняла, что он поверил в меня, в мои силы. А ведь ничто так не вдохновляет, не подкрепляет морально, как доверие. Теперь я никогда не подведу. Сейчас я студентка V курса, нахожусь на педагогической практике в школе. Счастлива, что имею возможность реализовать себя, свои силы. Спасибо за доверие и низкий поклон Вам, Рузаль Абдуллазянович!

**Алевтина Горбач**, студентка V курса.
*"Педагог", февраль 1995 года*

## ОН ГОТОВ ПРИЙТИ НА ПОМОЩЬ

Кажется, совсем недавно мы переступили порог нашего института. Но вот уже пролетели 4 года. Как незаметно бежит время?.. Сколько всего произошло? Самое главное событие – институт стал университетом. А каким было наше 7-ое здание четыре года назад? Полусгнивший пол, полуразрушенный забор перед зданием, некрашеные стены. В общем безрадостный вид, который не настраивал на учебу. За эти годы наши аудитории преобразились: покрасили, побелили, в вестибюле даже сделали мраморный пол. Стало намного уютнее. Во всем этом большая заслуга ректора – Рузаля Абдуллазяновича Юсупова.

Это было сделано в общем для факультета. Но также надо отметить и то, что Рузаль Абдуллазянович старается проникнуться душой к каждому студенту, по мере возможности решить волнующие их проблемы. Лично я обращалась за помощью к нашему ректору неоднократно. Он помогал мне не только морально, но и материально.

Большое ему спасибо и успехов ему во всем!

**Юлия Якимова,**
студентка факультета русской филологии
*"Педагог", февраль 1995 года*

## ИМ НЕ УДАЛОСЬ СОРВАТЬ СОБРАНИЕ

По закону для всех кандидатов в депутаты должны быть созданы равные условия. Однако, как показали мои наблюдения, эти условия с самого начала стали нарушаться. Именно с нарушения началось выдвижение кандидатов в депутаты по Московскому административно-территориальному округу № 5. Могу подтвердить это на примере двух кандидатов. Один из них – глава администрации Московского района И.В.Фаттахов, другой – ректор КГПУ Р.А.Юсупов. Для защиты кандидатуры И.В.Фаттахова были подняты на ноги весь аппарат районной администрации, все предприятия.

В школах срочно были проведены родительские собрания. Кроме того, учителя ходили по домам и собирали подписи, зная, какие могут быть последствия за невыполнение задания.

А вот в ходе выдвижения кандидатуры Р.А.Юсупова я была очевидцем того, как не пускали жителей в школу № 65, хотя и была договоренность о проведении там собрания по выдвижению. После определенных усилий встреча состоялась, но в столовой. Во время встречи люди Фаттахова пытались сорвать ее.

Но им не удалось выявить нарушение и сорвать собрание, так как избиратели хорошо знают Р.А.Юсупова по его предыдущим делам в качестве депутата, высоко оценивают его стремление улучшить жизнь народов республики. Собрание состоялось. Кандидатура была выдвинута.

Я призываю всех уважающих себя избирателей отдать свои голоса за Рузаля Абдуллазяновича.

**Т.Х.Низамутдинова**,
*"Педагог", февраль 1995 года*

## ТУГРЫ ХЕЗМӘТ ИТӘР!

Без, Татарстан Республикасының мәдәният, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелүен чын күңелдән яклыйбыз. Ул халыкка Казан дәүләт педагогика университеты ректоры, күренекле галим, дистәләгән китаплар авторы буларак кына түгел, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе буларак та яхшы билгеле. Аның парламент сессияләрендәге, матбугат битләрендәге, радио-телевидениедәге актуаль мәсьәләләргә багышланган күп санлы чыгышлары принципиаль, төпле фикерле, шул ук вакытта нык уйланылган була. Р.А.Юсупов һәрвакыт халыклар дуслыгын ныгыту, аларның мәдәният, тел һәм диннәрен үстерү өчен тигез шартлар тудыруны яклый.

Без ышанабыз: Рүзәл Юсупов яңа парламентта да республикабызга тугры хезмәт итәр һәм Татарстан халыкларының бәхетле яшәве өчен белемен, көчен һәм бай тәҗрибәсен кызганмас.

**Гомәр Бәширов, Татарстанның халык язучысы, Тукай бүләге лауреаты; Туфан Миңнуллин, драматург, Тукай бүләге лауреаты; Әнвәр Бакиров, композитор, Тукай бүләге лауреаты; Фасил Әхмәтов, композитор, Тукай бүләге лауреаты; Илһам Шакиров, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Тукай бүләге лауреаты; Рафаэль Ильясов, Татарстанның халык артисты; П.П.Бетев, Россиянең халык артисты; Г.С.Ишкова,**

**Россиянең халык артисты; М.И.Мәхмүтов, академик; Ф.М.Пантюшин, Татарстанның халык артисты; Г.М.Первин, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Г.Н.Прытков, Татарстанның халык артисты; А.Я.Славутский, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе.**

*"Ватаным Татарстан", 3 март 1995 ел*

## ТЕЛЕГРАММА

***казань, верховный совет тсср, 7-я сессия, депутатам юсупову р., абдуллину т.***

***УВАЖАЕМЫЕ РУЗАЛЬ ЮСУПОВ, ТАЛГАТ АБДУЛЛИН! ПОСТОЯННО ДЕЙСТВУЮЩЕЕ ЕЖЕНЕДЕЛЬНОЕ СОБРАНИЕ ТАТАРСКОЙ ОБЩЕСТВЕННОСТИ Г.НАБ.ЧЕЛНЫ ВЫРАЖАЕТ ВАМ БЛАГОДАРНОСТЬ ЗА ПОЛИТИЧЕСКУЮ АКТИВНОСТЬ, СМЕЛОСТЬ В ДЕЛЕ УТВЕРЖДЕНИЯ НЕЗАВИСИМОСТИ ТАТАРСТАНА. НАРОД С ВАМИ. МЫ ПОБЕДИМ.***

***ПРИНЯТО НА ЕЖЕНЕДЕЛЬНОМ СОБРАНИИ ТОЦ 21 ОКТЯБРЯ. УЧАСТВОВАЛО 600 ЧЕЛОВЕК.***

**ПРЕДСЕДАТЕЛЬ НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКОГО ТОЦ ТАЗИЕВ ФАИК ГИЛЬМУТДИНОВИЧ**

## РЕСПУБЛИКАНСКАЯ ПАРТИЯ ТАТАРСТАНА

Сейчас, когда СССР распался, и его форпост Коммунистическая партия дискредитировала себя, когда общество переживает болезненный переходный период, нужны такие политические силы, такие общественные объединения людей, которые сумели бы активно содействовать скорейшей стабилизации обстановки в республике и построению прогрессивного, подлинно демократического, экономически развитого, нравственно здорового общества.

Одной из таких сил и призвана стать недавно созданная Республиканская партия Татарстана (РПТ).

Как следует из Программы и Устава, РПТ задумана как партия, преследующая самые гуманные цели и задачи, которые можно было бы сформулировать одной фразой – "служить процветанию Республики Татарстан".

Политическая платформа Республиканской партии Татарстана строится, исходя из интересов большинства населения республи-

ки, которые отражаются в таких основополагающих документах, как Декларация о государственном суверенитете Татарстана, итоги Референдума о государственном статусе Татарстана и Конституции Татарстана.

РПТ считает своей главной задачей всячески поддерживать действия государственных органов, общественных организаций, партий, направленные на реализацию суверенитета, экономической и политической самостоятельности Татарстана, на создание демократического, правового государства и, наоборот, будет выступать против тех, кто препятствует созданию подлинно демократического общества, достижению независимости республики.

В Программе Республиканской партии Татарстана четко очерчены задачи, предусматривающие развитие мощной экономики в республике. Партия считает необходимым для подъема экономики создание условий для проявления инициативы каждым субъектом хозяйственной деятельности, развертывание многообразных форм собственности, внедрение рыночных отношений, утверждение экономической, хозяйственной самостоятельности республики, регионов, а также предприятий, ассоциаций и отдельных граждан. Для оздоровления экономики республики принципиально важна приватизация средних и мелких предприятий, особенно легкой, пищевой промышленности и сферы обслуживания населения. РПТ придерживается принципа “земля должна принадлежать тем, кто ее обрабатывает”. В целях реализации этого принципа правительство должно всемерно поощрять реформирование колхозов и совхозов через акционирование, аренду и т.д., а также посредством развития фермерских хозяйств, кооперативов и других форм хозяйствования.

В специальном разделе Программы РПТ предусмотрены задачи партии по социальной и экологической защите населения республики.

В целях защиты интересов населения партия выступает за устранение всех административных ограничений на право граждан получать доходы в любом размере от деятельности, не запрещенной законом; обеспечение прожиточного минимума нетрудоспособным, малоимущим, учащимся, пенсионерам и др.; создание фондов помощи инвалидам, престарелым, ветеранам и безработным; определение минимального размера заработной платы; осуществление контроля за ценами на основные продукты питания, транспорт, услуги, жилье, лечение и т.д.

Демократическое государство, создание которого является основной целью РПТ, предусматривает обеспечение условий для свободного развития национальных культур, языков, образования и науки. Это положение представляет особую значимость для Республики Татарстан, в которой испокон веков проживают татары, русские, чуваши, мари, удмурты, мордва, украинцы, евреи и другие национальности. Республиканская партия Татарстана строго руководствуется принципами создания возможностей для развития национальной культуры, языка каждого народа и этнической группы, проживающих на территории Татарстана. Партия всемерно поддерживает Закон о языках народов Татарстана, в котором татарский и русский языки объявлены равноправными государственными языками.

За годы советской власти, особенно за последние десятилетия, нравственные устои нашего общества сильно расшатались, многие нормы высокой общечеловеческой морали, которые вырабатывались и накапливались столетиями, были потеряны. В результате этого наше общество сейчас переживает не только экономический кризис, но и падение нравственности. Вот и поэтому Республиканская партия Татарстана одной из своих серьезных задач ставит нравственное оздоровление общества, возрождение и воспитание у членов общества, особенно у молодежи, таких ценнейших качеств, как честность, скромность, уважение старших, чувства любви, сострадания, переживания и т.д.

Партия отвергает насильственные методы деятельности общественных объединений и отдельных граждан, выступает за сохранение и укрепление дружбы народов, интернационализма, понимаемого как солидарность наций, политических и общественных сил, борющихся за приумножение общечеловеческих ценностей, в том числе и национальных культур.

Республиканская партия Татарстана выступает против любых проявлений неуважения одной нации к другой. Любовь к своему народу является естественным чувством каждого человека и важнейшим элементом патриотизма.

Гуманные проявления национального самосознания народов достойны поддержки. В то же время партия осуждает шовинизм и национализм, сеющие раздор и конфронтацию, отрицательно влияющие на сознание людей и общественное настроение.

РПТ считает, что для успешного решения задач, связанных с демократическими преобразованиями общества, всем гражданам,

органам государственной власти, партиям и общественным объединениям республики следует строго руководствоваться положениями новой Конституции Татарстана. Реализация Основного Закона обязательна для всех, и он не подлежит никакой ревизии, с чьей бы то стороны такая инициатива ни исходила.

Республиканская партия Татарстана выражает интересы граждан республики независимо от их национальной, социальной и религиозной принадлежности. В своей деятельности она будет опираться на широкие слои народов Татарстана, рабочих, крестьян, интеллигенцию, работников торговли и обслуживания, прогрессивных предпринимателей. Республиканская партия Татарстана не посягает на программы и идеологические устои других общественных объединений, не стремится к противоборству, желает функционировать в мире и согласии с ними, а по возможности объединить их в одно целое и выступать единым фронтом за демократическое преобразование общества.

Партия с пониманием относится к судьбе коммунистов, обманутых большевистской элитой, тех, кто осуждает деятельность ВКП(б) и КПСС, гуманно и демократично настроен на демократическое преобразование. Она готова принять в свои ряды прогрессивную часть коммунистов, отказавшихся от коммунистической перспективы, признающих цивилизованное, гуманистическое мировоззрение и искренне стремящихся вести свою деятельность в соответствии с Программой и Уставом РПТ. Партия по такому же принципу будет принимать в свои ряды представителей других общественных объединений, в том числе и религиозных.

РПТ рассматривает свою деятельность по преобразованию общества и продвижению к прогрессу как важнейшую задачу, решение которой отвечает интересам населения всей республики. Честно служить своему народу – нет большего счастья!

Руководство РПТ выражает уверенность, что новая Республиканская партия Татарстана будет вносить свою достойную лепту в дело объединения и сплочения многонационального народа Татарстана на такие демократические преобразования, которые в конечном итоге обеспечат гармоничное развитие республики.

**Р.А.Юсупов**, председатель
Республиканской партии Татарстана
*"Татарстан республикасы". – 1993. – №1, май*



Члены Академии наук Татарстана. В первом ряду справа первый – академик Р.А.Юсупов



Аппарат Академии наук Татарстана. В первом ряду слева пятый – вице-президент АН РТ Р.А.Юсупов




Члены президиума Международной тюркологической конференции




На научно-практической конференции по преподаванию татарского языка



Члены отделения гуманитарных наук Академии наук Татарстана



С президентом Российской Академии военных наук, академиком АН Татарстана М.А.Гараевым



На заседании совета по защите докторской диссертации при КГПУ (председатель Р.А. Юсупов). Выступает соискатель Рафис Закиров (ныне проректор Исламского университета). Руководитель – академик Р.А. Юсупов



Рузаль Юсупов – депутат
Казанского горсовета
народных депутатов



Рузаль Юсупов депутат
Верховного Совета Татарстана,
председатель постоянной
комиссии по культуре и
национальным вопросам



Академик Рузаль Юсупов
после награждения
золотой медалью
Академии наук Татарстана.
“За достижения в науке”.
В руках – монография
Р.А. Юсупова, изданная в
Евросоюзе



На сессии парламента Татарстана выступает депутат Рузаль Юсупов



На заседании диссертационного совета под руководством академика Р.А.Юсупова. Выступает оппонент – академик Российской академии наук Э.Р.Тенишев



Председатель Республиканской партии Татарстана Р.А.Юсупов излагает задачи партии. Справа от него член парламента Татарстана (впоследствии России) Фандас Сафиуллин



Заседание политсовета Республиканской партии Татарстана. Выступает член партии, депутат Верховного Совета Рустем Хафизов



На заседании Президиума Верховного Совета Республики Татарстан



Президент РТ М.Ш.Шаймиев встречается с лидерами партии и общественного движения. Слева второй – председатель Республиканской партии Татарстана Р.А.Юсупов

# ЗАЯВЛЕНИЕ РЕСПУБЛИКАНСКОЙ ПАРТИИ ТАТАРСТАНА

Прошел достаточный срок со времени завоевания политического и юридического суверенитета Татарстана. Несмотря на некоторые успехи в его реализации, решающих шагов не сделано: новый статус Татарстана как суверенного государства, субъекта международного права, не признан ни Россией, ни другими государствами. В этом деле руководители республики еще не предпринимали должных мер. У нас нет ни Министерства иностранных дел, ни права устанавливать с другими государствами политических, экономических, торговых и культурных связей, нет таможенной службы. Все остается в компетенции России, значит, все делается с позволения России, центральных властей. Крупные предприятия, правоохранительные органы и многие другие структуры не переведены под юрисдикцию республики. Государственный банк также не принадлежит Татарстану. Не достигнута самостоятельность в области налоговой политики, пошлины, валюты. Большая часть черного золота – нефти по-прежнему бесплатно уходит на сторону. Известно, что основная и самая крупная преграда в реализации суверенитета Татарстана – великодержавная политика России, непризнание права и стремления народов к независимости, продолжение господства пустившего многовековые корни тоталитарного режима. Тому наглядный пример – принижение статуса Татарстана до уровня десятков областей и краев России, отсутствие упоминания о нем как о суверенном государстве, субъекте международного права в проекте новой Конституции России. Возможно, этому причиной являются многократные заявления руководителей Татарстана о “ненарушении целостности России” и их участие в подготовке проекта Конституции РФ. Впрочем, недавнее заявление Президента и Председателя ВС РТ об отказе от участия в работе Конституционного совещания – явление положительное. Но они там, по нашему мнению, вовсе не должны были участвовать. Из выступления на пресс-конференции премьер-министра России В.С.Черномырдина, посетившего Татарстан и строившего планы развития народного хозяйства республики, становится очевидным, что премьер-министр России побывал здесь не просто как гость, но как хозяин, посетивший Тулу, Рязань, Кострому – регионы державной России. Как бы то ни было, кто бы каких препятствий ни чи-

нил, мы приняли Декларацию о государственном суверенитете, за это отдали свои голоса на референдуме и этот новый статус закрепили в Основном Законе – Конституции. В статье 1 Конституции сказано, что “Татарстан – суверенное государство”. А суверенитет – это независимость и самостоятельность. Никто не имеет права нарушать Конституцию. Самая важная и святая задача руководителей Татарстана, особенно Президента, а также парламента и правительства – неутомимая борьба за реализацию Конституции. Мы, руководители Республиканской партии Татарстана, выражаем озабоченность по поводу заключенных в последнее время договоров между Татарстаном и Россией. Особую озабоченность вызывает неопределенность. До сего времени нам не *удалось ознакомиться с текстами* этих договоров. Почему-то они не опубликованы в средствах массовой информации, хранятся в тайне. Это трудно понять. Документы, имеющие судьбоносное значение для Татарстана, не должны скрываться от народа. Из информации премьер-министра РТ М.Г.Сабирова, высказанного на той же пресс-конференции, вытекает, что собственность Татарстана согласно Договору делится на три части, из которых доля Татарстана не кажется преобладающей. Не крах ли это нашего суверенитета? Такое деление в корне противоречит Конституции РТ, Декларации о государственном суверенитете. Ведь в этих документах четко сказано, что земля, недра, предприятия и вообще все богатство Татарстана принадлежит народу?! Непонятно и относительно таможни Татарстана. Будет ли своя независимая таможенная служба Татарстана или она и в дальнейшем останется одним из региональных отделений России? Безусловно, с Россией нужно продолжать переговоры, заключать договоры, сотрудничать и жить в мире. Это бесспорно. Однако мир. дружба, и сотрудничество не должны строиться за счет потери самостоятельности и независимости. Если договоры между Татарстаном и Россией не будут строиться на равенстве и справедливости и будут преследовать цель удерживания народов Татарстана в зависимости, то они не могут служить целям дружбы и согласия между народами. Настоящая дружба и братство могут быть только между равноправными. На пути достижения целей между РТ и РФ придется строить еще не один договор. Хочется надеяться, что в этом естественном процессе правительство и руководство Татарстана не будет делать шагов, наносящих ущерб суверенитету или направленных против Конституции РТ. Для всех нас одна цель –

добиться свободного и равноправного сосуществования с Россией. По твердому убеждению руководства Республиканской партии Татарстана, Президент, Верховный Совет и правительство РТ должны беззаветно служить народу на путях реализации Декларации о государственном суверенитете, Конституции, не уклоняясь от выбранного пути.

**“Татарстан республикасы”**, № 3, Июль,1993 ел

## СӘЛАМ СЕЗГӘ ТАШКЕНТТАН...

***ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫ КАЗАНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПАРТИЯСЕНЕҢ “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ” ИСЕМЛЕ ЯҢА ГАЗЕТАСЫ ЧЫГУЫН ШАТЛАНЫП КАБУЛ ИТТЕМ. МИЛЛӘТЕБЕЗНЕ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ АНЫҢ РОЛЕ БУЛМЫЙ КАЛМАС ДИП УЙЛЫЙМ, ЧӨНКИ ТАТАРСТАННЫҢ РЕСПУБЛИКА ПАРТИЯСЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ИЗГЕ.***

***МИН ҮЗЕМ ТАТАРСТАН ЕГЕТЕ. МАМАДЫШ РАЙОНЫНЫҢ КЕЧЕ КИРМӘН АВЫЛЫНДА ТУЫП-ҮСТЕМ. КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАГАЧ, ТАШКЕНТ КАЛАСЫНДА ИНЖЕНЕР БУЛЫП ЭШЛИМ. ЯКТАШЛАРЫМ БЕЛӘН АРАЛАШЫП ЯШИМ. ТАТАРСТАНДА БАРА ТОРГАН МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ӨЧЕН НӘТИҖӘЛЕ КӨРӘШНЕ ИГЪТИБАР БЕЛӘН КҮЗӘТӘБЕЗ. СЕЗГӘ САБЫРЛЫК, КЫЮЛЫК ТЕЛИБЕЗ.***

**ИЛСУР ГАЗИЗОВ, ҮЗБӘКСТАН**

## ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ЧЫГЫП ГЫЙБРӘТ АЛ

Югары уку йорты укытучысы нәтиҗәле эшлим дисә, аның, үзе укыта торган предметларын яхшы белүдән тыш, дөньяга карашы киң, эрудициясе бай булырга тиеш. Моның өчен ул, илебездәге хәлләрдән генә хәбәрдар булып калмыйча, чит илләрдәге халыкларның да тормышын, яшәү рәвешен күпмедер дәрәҗәдә булса да белергә тиеш.

Шундый уй белән мин, диссертация яклап, материаль яктан бераз гына аягыма басып торырлык хәлгә килгәч, вакыт-вакыт чит илләргә чыгып йөри башладым. Һәм тиздән шуны аңладым: минем бу карарым бик дөрес һәм вакытлы булган икән. Берничә

илдә булып кайтуга ук, минем күп нәрсәләргә карашым үзгәрде, фикерләвем баеды, күңел офыкларым киңәйде.

Минем чит илләргә сәфәр кылуларым 70 нче еллардан бшланды. Элек ике-өч елга бер туристлык путевкалары белән йөрдем, аннары эш белән бара башладым, соңгы елларда яңадан, турист булып, шактый еш йөрим.

Мин, сәяхәтләремне Мисыр, Алжир, Төркиядән башлап, күп кенә Европа илләрендә (Чехословакия, Германия, Италия, Франция, Испания, Португалия, Англия, Швейцария, Голландия, Греция, Болгария, Кипрда), көнчыгыш илләреннән Һиндстанда, Малайзия, Индонезия, Сингапур, Гарәп Әмирлекләре, Иран, Тунис, Япония, Кытай, Вьетнамда, шулай ук Австралиядә, Америкада, Доминикана республикасында, Мексикада булдым.

Мөмкин кадәр күбрәк илләрдә булу үзмаксат түгел, бөтен җиргә дә барып бетереп булмый, аңа вакытың да, акчаң да җитми. Беренчедән, аеруча үзенчәлекле, экзотикалы илләрдә (мәсәлән, Һиндстан, Малайзия, Австралия, Мескика, Доминикана республикасы), икенчедән, цивилизация нык алга киткән һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе югары булган (мәсәлән, Япония, Америка, Германия, Скандинавия дәүләтләре һ.б.) илләрдә булырга тырышырга кирәк.

Төрле илләрдә булганда, мин аларның һәркайсында үзем өчен нинди дә булса кызыклы, әһәмиятле нәрсә, яңалык табам, үз тормышымда файдалану өчен кирәкле нәрсәләрне үзләштерергә тырышам.

Чит илләрдә йөреп, мин үземнең культурамны үстерәм, белемемне арттырам, үз-үземне тоту кагыйдәләрен камилләштерәм, чарлыйм.

Италиядәге, Франциядәге борынгы культура ядкарьләрен, Рим, Флоренция, Венеция, Париж кебек шәһәрләрдәге искиткеч архитектура корылмаларын күреп таң калып йөрдем. Ул илләрдә, андый шәһәрләрдә гомумән һәр нәрсә югары культура белән сугарылган. Бу яктан, әлбәттә, Англия, Германия кебек илләр, аларның башкалалары Лондон, Берлин кебек шәһәрләр дә күпкә калышмый, бәлки бөтенләй калышмый торгандыр.

Культураңны үстерү, рухи халәтеңне баету өчен, барыннан да бигрәк, Европа илләрендә булырга кирәк, мөмкин булганда, әлбәттә.

Мин Римдагы Ватикан музейлары, Париждагы Нотр Дам де Пари (Собор Парижской Богоматери), Лувр кебек сәнгать-архитектура могҗизалары турында сөйләп тормыйм: аларны үзеңә барып күрергә кирәк, хәер, хәзер безнең ил халкы элеккегә караганда шактый күбрәк йөри дә, күрә дә инде.

Немец халкының тырышлыгына, пөхтәлегенә сокланмаслык түгел. Немецлар икенче бөтендөнья сугышында җимерелеп беткән Германияне, Берлин, Дрезден, Лейпциг кебек хәрабәгә калган тарихи шәһәрләрен 20-25 елда аякка бастырганнар, таланган завод-фабрикаларын тиз арада төзеп эшләтә башлаганнар, тормышларын җайга салганнар. Мин анда, беренче мәртәбә җитмешенче еллар башында баргач, бик гаҗәпкә калган идем: урамнар төзек, чиста, һәркайда тәртип, кибетләрендә кием-салым, азык-төлек, бездәге белән чагыштырганда, тулып тора. Җиңелгән, җимертелгән Германия 20–25 елда шундый хәлгә килгән. Моның сәбәбе: немец халкы ул тырыш һәм югары культурага ия.

Минем өчен Германиядә безнең Казан педагогика университетының зур дусты – профессор Чарльз Карлсон чакыруы буенча ун көн “Азатлык” радиостанциясендә эшләп кайтуым аеруча истәлекле булды.

Профессор Ч.Карлсон, башта Казанга берничә тапкыр килеп, безгә студентларны инглиз теленә өйрәтергә ярдәм итеп йөрде (ул үзе америкалы, филолог). Мюнхен шәһәрендә урнашкан “Азатлык” радиостанциясендә Урта Азия, Кавказ халыклары телләрендәге тапшыруларның баш редакторы булып эшли иде, һәм мине үзләренә эшлекле кунакка чакырды. Чыннан да анда мин эшләп йөрдем дияргә була. Миңа, радиостанциягә кереп йөрү өчен, вакытлы пропуск әзерләп бирделәр. Мин анда татар-башкорт телләрендәге тапшырулар редакциясе өчен татарларның, аларның телләренең тарихы, Татарстандагы иҗтимагый-сәяси хәлләр, үзгәртеп корулар, татар культурасы турында берничә тапшыру әзерләп бирдем. Редакция үтенече буенча Кырым татарлары (аларның лидерлары Мостафа Җәмил катнашуында), Себер татарлары (профессор Алишева белән) тормышына, эшләренә багышлап оештырылган туры-дан-туры эфир тапшыруында катнаштым.

Үзләрендә кунакта Татарстан парламенты депутаты, Татарстан республикасы партиясенең председателе, университет ректоры булуын белеп алгач, миңа радиостанциядәге рус, казах, украин, үзбәк телләрендәге тапшырулар редакцияләреннән дә

мөрәҗәгать итеп, миннән интервьюлар алдылар. Миңа, татар радио-телевидениесендә эшләп алган кешегә, бу эшләрнең кыенлыгы булмады. Киресенчә, андагы журналистлар белән аралашу минем өчен кызык та, әһәмиятле дә булды.

Мюнхен шәһәрендә булганда татар халкы өчен күп игелекле гамәлләр кылган үкенечле язмышлы бер кеше белән очрашуым турында сөйләми калсам, үземне гафу итмәс идем. Бу кеше – Гариф Солтан. Аның турында Фәүзия Бәйрәмова "Звезда Поволжья" газетасында шактый тулы һәм гыйбрәтле мәкалә язып чыккан иде. Мин дә бераз гына әйтеп китим.

Гариф Солтан – Башкортстанда туып үскән татар кешесе. Ватан сугышы алдыннан педагогика институтының чит телләр факультетындагы немец теле бүлегендә укыган булган. Әмма укып бетерә алмаган, сугышка алып киткәннәр. Фронтта миллионнарча совет солдатларының фаҗигале язмышына – әсирлеккә дучар була. Немец телен белгәнлектән, аны тәрҗемәче эшенә җәлеп иткәннәр. Ул анда Муса Җәлилне һәм аның иптәшләрен күреп йөргән, ләкин алар белән "Идел-Урал" легионында булмаган. Сугыш беткәч, Америкага китеп, анда университет тәмамлаган, төрле җитди эшләр башкарган, соңыннан, Германиягә Мюнхенга килеп, "Азатлык" радиосында эшләгән.

Безнең илдә әсирлектә булган барлык кешеләргә, тикшерепнитеп тормыйча, сатлык җан дип, кара тамга салу гадәти күренеш булган. Әмма бу дөрес караш, гадел хөкем түгел.

Гариф Солтан – күп телләр белгән, зур белемле, киң кырлы кеше, милләтенең патриоты буларак, гомере буенча татар халкының тигез хокуклы, бәхетле тормышы өчен көрәшеп, абруйлы халыкара оешмаларда, мәгълүмат чараларында, татарларны яклап чыгышлар ясаган, китаплар язган. Кыскасы, бөтен гомерен үз халкының мәнфәгатьләрен яклауга багышлаган.

Мин аның белән Мюнхенда урнашкан "Азатлык" радиосында эшләүче Фәридә исемле ханымның квартирында очраштым. Бик зыялы, тәрбияле, күркәм кеше иде. Төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Татарстан белән бик кызыксынды, туган якларын сагынуын, Казанга кайтып килергә теләге зур булуын әйтте. Ләкин Россия властьларының аны якты күңел белән кабул итүләренә шиге бар иде булса кирәк.

Берничә ел элек инде вафат булган. Шулай итеп, гомер буена диярлек татар халкының матур киләчәге өчен үзен аямыйча

көрәшеп тә, туган якларын кайтып күрә алмыйча мәхрүм булып, якты дөньядан китеп барган. Ачы язмышлы кешеләр күп шул.

Төркиягә барып кайту хәзер Мәскәүгә барып килү белән бер чама. Уңайлы. Безнең халык анда, нигездә, ял итәргә күп йөри. Культура бәйләнешләре да ныгый бара, әлбәттә.

Миңа да анда берничә мәртәбә булырга туры килде. Күбрәк эшлекле сәфәрләр кылып. Шундыйларның берсе аеруча истәлекле булды.

Безнең Татарстан парламенты дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул иткәннән соң, Төркия дәүләте җитәкчелеге безгә, Татарстанга, мөстәкыйль дәүләт кебегрәк итеп карый башлады. Һәм менә Төркия парламенты мине, Югары Совет депутаты һәм милли һәм мәдәният мәсьәләләре комиссиясе председателе буларак, үзләренең иң зур бәйрәмнәре – Республика көне тантаналарында катнашырга чакырды. Анда элекке союздаш республикалар, хәзерге мөстәкыйль Әзәрбәйҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан дәүләтләреннән парламент членнары да килгән иде.

Бәйрәм тамашалары бик зурдан, бик тантаналы булды, әлбәттә. Без Төркия республикасы көненә багышлап уздырылган тантаналы утырышта, аннары хөкүмәтнең кабул итү мәҗлесендә катнаштык.

Табигый ки, безнең өчен, андый нәрсәләрне күрмәгән кешеләр өчен, мондый тамашалар бик мәһабәт, гаҗәеп күренешләр иде. Ләкин минем үзем өчен аеруча әһәмиятлесе Төркиянең премьер-министры (соңыннан ул Президент булды) Сөләйман Демирелнең чит ил кунаклары, журналистлар өчен оештырылган пресс-конференциясендә катнашу булды.

Сөләйман Демирел урта яшьләрдәге, зур пләш башлы, акыллы (бераз хәйләкәррәк) карашлы, зирәк кеше булып күренде миңа. Минем белүемчә, ул инде җитди генә җитәкче эшләрдә эшләп өлгергән көчле сәясәтче иде.

Сорау-җаваплар төрле темаларга, бигрәк тә соңгы вакытларда дөньяда барган сәяси вакыйгалар турында барды. Россиядәге хәлләр турында да сүз булды. Минем үзем өчен бик тә әһәмиятле соравым бар иде. Һәм мин аны әйттем: “Хөрмәтле премьер-министр әфәнде, Сез, ягъни Төркия дәүләте, Татарстанның дәүләт суверенитетын танырга җыенмыйсызмы әле?” Сөләйман Демирел, миңа карап, хәйләкәр генә елмайды да: “Сабыр итегез, Рүзәл бей”,

– диде. Мин аңладым: Төркия ул чагында (һәм хәзер дә) Татарстан өчен Россия белән мөнәсәбәтләрен кискенләштерергә теләми иде.

Төркиягә ул баруымда булган тагын бер гыйбрәтле хәл турында әйтеп китим.

Безне, төрле республикаларның парламент членнарын, самолетка утыртып, Кипрга, аның төрекләр яшәгән өлешенә алып киттеләр. Анда ул чагында Төркиянең сәяси тормышында дәрәҗәсе буенча икенче генә урында торган Ана-ватан партиясенең абруйлы конференциясе буласы, һәм без шунда катнашырга тиеш идек.

Кипрның төрек өлешендә (Төрек Кипры дип әйтү уңайлырак һәм дөресрәк булыр) алган беренче тәэсирем шул: ул аерым дәүләт дип атала гына икән, чынлыкта Төркиянең бер өлеше кебек. Хәлбуки, рәсми статусы буенча ул үзенә бер кечкенә генә мәмләкәт, аның бөтен дәүләт атрибутлары бар. Шулай да без самолетка, таможня процедуралары узып тормыйча, җиңел генә утырып киттек. Халкы – саф төрекләр, әлбәттә. Территориясендә берничә урында төрек гаскәрләре гарнизоннары урнашкан.

Төрек Кипры, Төркиядән башка, бер дәүләт тарафыннан да танылмаган. Безне, ул чагында инде бәйсезлек алган төрки дәүләтләр вәкилләрен (шулар арасына, янәсе, суверен Татарстан вәкиле булып мин дә кереп калдым), Ана-ватан партиясе чарасында катнашу өчен, Кипрга чакыруның да сәяси эчтәлеге бар иде: имеш, яңа мөстәкыйльлек алган төрки республикалар Төрек Кипрын таныйлар.

Ярый, сәясәткә кермичә генә, Кипр кыйссасын сөйләп бетерим. Без анда, өч көн булып, конференция эшендә катнаштык, Кипр буйлап сәяхәт кылдык. Конференция барышында миңа партия председателе Масут Йылмас белән (соңрак ул бер срок Төркиянең премьер-министры булып торды) берничә мәртәбә әңгәмә корып утырырга туры килде. Күркәм кеше булып исемдә калды.

Мин конференциядә Татарстандагы хәлләр турында төрекчә чыгыш ясадым. Кызыксынып тыңладылар кебек. Аннары миңа истәлекле сувенирлар бүләк иттеләр.

Ул конференциядә төрки дөньяда мәгълүм шәхес Төркиядәге Мәрмәр университетының татар профессоры Надир Дәүләт катнашты. Соңыннан ул, күп тапкырлар Казанга килеп йөрде, Татарстан белән әһәмиятле мөнәсәбәтләрдә торды.

Ул чагында Төрек Кипрындагы Америка халыкара университетында безнең Татарстан кызы Зөлфия Бәйрәмова (Кадыйро-

ва) укый иде. Ул, әлбәттә, беренче көннән үк мине эзләп табып, без киткәнче, безнең белән булды, миңа төрле ярдәмнәр күрсәтте. Уңган, күркәм, белемле кыз.

Соңрак миңа ике тапкыр Кипрның грек өлешендә дә булырга туры килде.

Англия, аның башкаласы Лондон турында бик күп сөйләргә мөмкин. Кайбер күренешләр, кечерәк кенә вакыйгаларны тасвирлап узыйм.

Лондонда, утрауда урнашкан дәүләтнең башкаласы буларак, җирләре зур булмаса да, уннарча бик иркен ял парклары бар. Шәһәрдә гомумән яшеллек күп. Лондон өстеннән самолетта узганда, шәһәр зур урман эченә урнашкан кебек күренә. Парклары – халыкның ял итү урыннары: кешеләр, чирәм өстендә иркенләп утырып, ятып ял итәләр. Ләкин үзләреннән соң бер бөртек тә чүп калдырмыйлар. Парклар да, скверлар да, урамнар да чип-чиста. Һәркайда газон, чәчәк. Өйләрнең тәрәзә төпләрендә урам ягыннан чүлмәкле гөлләр асылынып тора. Гөл, чәчәк һәркайда: йортларның подъездларында да, хәтта бензин салу станцияләрендә дә. Хәер, бу көнбатыш илләре өчен хас гомуми күренеш. Мин булган илләрнең барысында да – Германиядә, Испаниядә, Франциядә, Голландиядә һәм башка илләрдә дә шулай гөл-чәчәк эчендә яшәргә тырышалар.

Лондонның гаҗәеп тарихи истәлекле урыннары, мәһабәт биналары турында сөйләп тормыйм. Минем игътибарымны анда бигрәк тә берничә гыйбрәтле хәл җәлеп итте.

Беренчедән, Лондонда безне, Казан педагогика университетының гарәп теле укытучысы Александр Савельевич Михеевны, инглиз теле укытучысы Наилә Заһидовна Бикбулатованы һәм мине, татар халкының күренекле улы, талантлы шагыйрь, зур белемле милләтәшебез Равил Бохараев каршы алды һәм анда, безнең белән еш очрашып, төрле оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә һәрчак ярдәмен күрсәтеп торды.

Лондондагы бер хосусый клубта төрле диндәге кешеләр, даими рәвештә очрашып, әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итәләр икән. Шундый очрашуларның берсенә безне дә чакырдылар. Шундый дустанә, тыныч, бер-берсен хөрмәт итү шартларында узды аларның әңгәмәләре. Сокланырлык. Сөйләшә-сөйләшә, тәмләп, чәй эчтеләр. Безне дә сыйладылар, әлбәттә, һәм миңа да сүз бирделәр. Үзебез белән таныштырып, Татарстаныбыз, Казаныбыз турында инфор-

мация ясадым. Кызыксынып тыңладылар һәм сораулар бирделәр. Безгә җылы мөнәсәбәт күрсәттеләр.

Лондонда, ихтимал, башка шәһәрләрдәдер, ислам динен кабул иткән инглиз кешеләре күп, меңләп санала икән. Берсе белән танышып, хәтта өйләрендә дә булдык: үзе чәйгә чакырды. Урта яшьләрдәге күркәм генә бер ир кеше (мөселманча исеме – Билал) полиция участогында криминалист булып эшли. Өендә чагында намазлар да укый икән. Кызыклы гына әңгәмә ясадык аның белән.

Равил Бохараев Лондондагы Би-би-си радиосында миннән интервью алуны оештырды, Татарстандагы хәлләр турында сорашты. Бу бөтен дөнья өчен эшли торган искиткеч зур радиостанция гаять зур бинага урнашкан, эфирга дистәләрчә телләрдә, шул исәптән рус телендә дә, тапшырулар бирә. Равил ул радио белән хезмәттәшлек итә икән. Эфирга безнең республикабыз, Россия турында материаллар әзерләп бирә.

Бер кызыклы деталь: Англиядә хезмәт өчен түләү шулкадәр югары: миңа, биш минутлык интервью өчен, безнең акчага күчергәндә, минем айлык ректор хезмәт хакы күләмендә гонорар түләделәр. Әле бу азрак кебек тоелды, дигән иде Равил.

Лондонда күргән-белгәннәремнән бер, минем өчен, кызыклы хәл турында сөйләми кала алмыйм.

Бу кыйссам ислам диненең Әхмәдичеләр дигән тармагы турында. Безгә, Равил Бохараев ярдәме белән, бу Әхмәди тарафдарлары белән якыннан танышып, аларның тормышы, тарихлары һәм яшәү рәвеше хакында шактый күп мәгълүматлар алырга насыйб булды.

Лондонның, яшеллеккә төренгән бик матур бер районында җыйнак кына мәчет тора. Бу 1924 елда салынган "Әхмәди" мәчете. Мәчет ишегалдындагы һәм аның тирә-юнендәге икешәр-өчәр катлы биналарда Бөтендөнья "Әхмәди" ислам җәмгыятенең мәркәзе – штабы һәм торак йортлары.

Әхмәдичеләр җәмгыяте – Римдагы Ватикан кебегрәк оешма. Аларның үзләренең куәтле теле-радиостанцияләре эшли, күп санлы дини һәм дөньяви китаплар бастырып чыгаралар. Бу җәмгыятьнең үзенең газета-журналлары да чыга.

Әхмәдичеләр ниндидер дини экстремистлар түгел (бездә хәзер рәсми карашка туры килми торган һәр фикер иясен, һәр оешма-җәмгыятьне шундый исем белән атау гадәткә керде). Алар гадәти ислам тарафдарлары. Тик алар бозылмаган, чын исламны

яклыйлар, дин кабыгына төренеп, асылда Корьәннең катгый кануннарына туры килми торган гамәлләр кылып йөргән кешеләрне тәнкыйтьлиләр. Алар, мәсәлән, кайбер мөселманнарның зур байлыклар туплавын, гаять зур зиннәтле сарайлар төзү белән мавыгуын хупламыйлар, корьәнгә каршы килгән, әхлаксызлыкка китерә торган гамәлләр кылган кешеләрне өнәмиләр.

Әхмәдичеләр җәмгыятенә 12 миллионнан артык кеше керә. Аның дөньяның бөтен почмакларында 127 илдә оешмалары (миссияләре) бар.

Әхмәдичеләр идеяләренең торган саен күбрәк кешеләрнең күңелләрен яулавы, үзенә миллионлаган кешеләрне каратуы нәрсә белән аңлатыла соң? Кешелекле, гадел булулары белән, дип җавап бирергә була бу сорауга.

“Әхмәди“нең бөтен тәгълиматы, яшәеше, асылы аның тарафдарларының кылган гамәлләре – игелеклелек, изгелек белән сугарылган. Әхмәдичеләр мәсьәләләрне көч белән хәл итүгә, җәбер-золымга каршы. Бөтендөнья “Әхмәди” җәмгыятенең башлыгы Хозур хәзрәт Мирза Таһир Әхмәт Лондондагы штабында безнең белән булган әңгәмәләрендә хәзер күп илләрдә барган кан коюлы сугышлар хакында ачынып, аларны тәнкыйтьләп сөйләде.

Әхмәдичеләр күп кенә игелекле гамәлләр кылалар. Алар, мәсәлән, мең бәла белән ут астыннан чыккан 50 Босния мөселманын үзләренә сыендырганнар. Шул ук вакытта Хозур сугыш җәһәннәмендә булган Босния балаларын – нинди милләттән булуларына карамастан – үзләренә бушлай тәрбиягә алган.

Хозур, безнең белән өч тапкыр очрашып, әңгәмә ясады. Әңгәмә радио һәм телевидениедән эфирга тапшырылып барды. Шулай итеп, ул безгә, Татарстан вәкилләренә, зур хөрмәт күрсәтте.

Хозур ул – шундый шәхес: аның белән очрашу өчен Лондонга дөньяның төрле почмакларыннан киләләр, аның янына зур дәрәҗәле кешеләр – күренекле дәүләт эшлеклеләре, хәтта кайбер дәүләтләрнең президентлары, корольләре, премьер-министрлары килә. Гади дин әһелләре, аны күрү өчен, берничәшәр көн көтеп торалар, дип сөйләделәр.

Хозур – мәһабәт, күркәм, зур белемле кеше. Ул берничә чит тел белә, буш вакытларында поэзия белән шөгыльләнә, күп укый икән.

Безнең аның белән әңгәмәләребез төрле темаларга, шул исәптән диннең торышы, мөселманнарның хәле, безнең илдә

(Россиядә) соңгы вакытларда барган сәяси вакыйгалар турында булды. Ул бездәге хәлләрдән шактый хәбәрдар булып чыкты.

Хозур белән әңгәмәләрдән мин шуны аңладым: ул ислам дине кануннарын бездәге кайбер дин әһелләре кебек формаль генә сакламый, бәлки дингә чын күңеленнән ышана һәм башкалардан да шуны таләп итә.

Әңгәмә вакытында мин аңа Татарстанда хәзер дингә игътибарның артуын, яңа мәчетләр салынуын һәм башка яңалыкларны сөйләгәч, ул болай диде: “Мин сезнең илдә, республикагызда булган хәлләр белән таныш. Дингә игътибар арту – яхшы күренеш. Әмма диндә иң мөһим нәрсә – инану. Кешеләрнең чын күңелдән ышанып яшәүләре мөһим”. “Мәчетләрне төзиләр, әмма анда халык йөриме соң? Күпме йөри?”, – дип сорый Хозур һәм соравына үзе үк җавап бирә: “Безнең белүебезчә, сездә әле мәчетләргә халык бик аз йөри. Мәчет булмаска да мөмкин, мәчеттән башка урында да намаз укырга була. Иң әһәмиятлесе: кешеләр инансыннар, ислам кануннарын сакласыннар, аллаһка табынсыннар”.

Менә шундый гыйбрәтле очрашуларыбыз булды Лондонда.

Япониядә булып кайтканнан соң, мин “Мәдәни җомга” газетасында бу илдән алган тәэсирләремне бастырган идем. Ул язмама “Кемнәр дөрес яши? Японнар!” дигән исем куйдым. Минем өчен бу фикер бәхәссез дияргә була. Чыннан да мин белгән һәм күргән илләр арасында һәръяктан да үрнәк булырлык ил ул – Япония. Һәм иң күркәм халык – японнар.

Андагы хәлләрне, тормышны күреп, мин сокланып йөрдем. Японнар – гаять культуралы халык: искиткеч хезмәт сөючән, югары әхлаклы, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклау, көнкүрештәге тәртип, әдәплелек, инсафлылык – бары да югары дәрәҗәдә.

Россия белән чагыштырганда, бик кечкенә генә территория биләп, үзенең табигать байлыклары булмый торып та, халкы бездәгедән аз гына кимрәк булса да, Япония тормышның югары дәрҗәсенә ирешкән. Минем көчемнән килсә, безнең кешеләрнең һәркайсына андагы тормышны күрсәтеп кайтарыр идем. Ни өчен безнең җитәкчеләр андагы яшәү, эшләү, җитештерүне оештыру, транспорт, көнкүреш тәртипләреннән уңай үрнәкләрне безнең илгә кабул итмиләр икән?

Япония һәм аның халкы турында бик озак сөйләргә мөмкин. Әмма бу китапта һәр илне җентекләп сурәтләү бурычы куелмый. Берничә җөмлә белән генә сөйләп китим дисәм, шуны әйтер идем.

Япония ул – шундый ил: анда сине һәркайда һәм һәрчак елмаеп, үзенчәлекле итеп баш иеп каршы алалар, анда бер-береңә тупас эндәшү гадәте юк.

Япониядә бер җирдә дә чүп, пычрак күрмәссең, тузан да юк дип әйтергә була. Анда идеаль чисталык, аларның хәтта туалетларында да искиткеч культура: чын чәчәкләр куелган, музыка уйнап тора, бернинди дә яман ис юк, шуның өстенә, әллә никадәр уңайлыклар, автоматика, югары сервис.

30 миллион халык яши, миллионлаган автомобиль йөри торган Токия урамнарында пробкалар юк диярлек, чөнки юллар идеаль тәртиптә, икешәр-өчәр катлы. Машина йөртүчеләр культуралы. Шуңа күрә аварияләр юк дәрәҗәсендә. Шәһәр урамнарында һәркайда агачлар, газоннар, чәчәкләр. Япониядә җинатьчелек бик аз, булганы да японнарның үзләренеке түгел, чит илләрдән килеп эшләүчеләр арасында. Японнар бик тыйнак, әдәпле, байлык туплау белән мавыкмыйлар. Аларда үзеңнең бай, өстен булуың белән масаю гадәте, башкалардан кием-салым, йорт-җире белән аерылып торырга омтылу күренеше юк.

Мәктәп укучылары матур, пөхтә киенеп, ләкин бер төрле киемдә (бер формада) йөриләр. Японнарда балаларын мәктәпкә үз машиналарында озатып кую белән дә мавыкмыйлар: бер тирәдә (янәшә берничә йортта) яшәгән балалар, җыелып, бергә, җәяү генә баралар, араларыннан өлкәнрәге, калганнары өчен җаваплы булып, күзәтеп, тәртип саклап бара. Аларга куркыныч янамый: җинаять күренешләре юк диярлек.

Япониядә промышленностьның ни дәрәҗәдә алга киткәнлеген, радио-телевидениедән тыңлап-карап, газета-журналлардан укып, күп кеше беләдер, шәт. Автомобильләренә күпләр утырып йөри, телевизорларын күбебез карыйбыз, фән-техника өлкәсендәге казанышларын белеп торабыз. Кыскасы, могҗизалар иле!

Америкада мин Вашингтон университетыннан чакыру буенча булдым. Бу университет Вашингтон штатының административ үзәге Сиэтл шәһәрендә (кайчандыр анда спорт олимпиадасы булган иде). Анда миннән бу университетның укытучыларына һәм аспирантларына лекция сөйләвемне үтенделәр. Лекциянең темасы – “Татарстан Республикасындагы социаль-сәяси хәл”. Кызыксынып тыңладылар, сораулар бирделәр.

Сиэтл – матур, яшел, тыныч шәһәр. Һәркайда спорт мәйданчыклары. Шөгыльләнәләр. Көнбатыш Европа илләрендә дә,

Америкада да, Австралиядә дә – гомумән алдынгы илләрдә спорт белән күп кешеләр шөгыльләнә.

Сиэтлдан ерак кына түгел бер зур күл бар. Су коеналар, көймәдә йөриләр: халык культуралы ял итә. Урта кул зурлыктагы шәһәр булса да, кешеләрнең күбесе үз йортларында тора. Бездәге кебек өчәр-дүртәр катлы, егермешәр бүлмәле коттеджлар түгел, җыйнак кына: ике катлы, 3–4, 4–5 бүлмәле. Өй янында шулай ук кечерәк кенә бакчасы, чирәмлек, агач-чәчәкләр. Чит илләрдә гомумән бездәге кебек, зурдан кубу, күләм, зурлык, зиннәтлелек белән башкаларны шак каттырырга тырышу юк, чама хисе бар: артыгы нигә?!

Безнең татарлар кайларда гына юк: кайсы илгә барсаң да, берничә татар кешесен булса да очратасың. Бу күңелле хәл, әлбәттә.

Хәер, аларның күбесенең чит-ят җирләргә китеп төпләнеп калуы җиңел генә булмагандыр, тормышлары рәхәт булса, туган илләренән китеп бармаган булырлар иде.

Американың мин моңарчы татарлар яши дип ишетмәгән көнбатыш өлешендә, Сиэтл шәһәрендә дә очраттым мин милләттәшләребезне.

Беренчедән, дөньялар гизеп, башта Кытайда, аннары Япониядә яшәп, ниһаять Америкага килеп урнашкан данлыклы Акчуриннар нәселеннән бер гаиләдә булырга туры килде. Үз йортларында (йорт янында бакчалары, аккошлар йөзеп йөри торган бассейннары бар) матур гына яшәп яталар.

Әмма минем өчен тагын да кызыграк язмышлы кешеләр белән танышуым гыйбрәтле булды.

Шәһәр буенча сәяхәт кылып йөргәндә, тамак ялгап алыйм дип, бер кафега керсәм, хезмәт күрсәтүче ике яшь кенә хатын-кыз үзара татарча сөйләшеп тора. Мин дә аларга татарча дәштем, әлбәттә. Миңа да күңелле булды татар кешеләрен очрату, алар да шатланышты, ирләрен дә чакырып алдылар. Мине утыртып сыйладылар, танышып киттек. Кичен, эшләре беткәч, үзләренә кунакка дәштеләр.

Төп хуҗа Фәндүс исемле яшь кенә күркәм бер ир кеше булып чыкты. Аның язмышы нәкъ Рудольф Нуриевныкы кебек.

Фәндүс Пермь өлкәсеннән. Мәктәпне тәмамлагач, хореография училищесында укып, Пермь дәүләт бию ансамблендә эшли башлаган. Бераздан аны армиягә алалар. Армиядән кайткач, яңадан

ансамбльдә эшли. Бервакыт ансамбль Америкага гастрольләргә китеп бара. Концертлар куеп йөри торгач, Сиэтл шәһәренә килеп чыгалар. Ул арада инде боларның кире өйләренә, Россиягә кайтыр вакытлары җиткән була.

Һәм егетнең башында авантюристик план барлыкка килә. Ул, үзләренең группаларыннан аерылып, Сиэтлда кала. Кыю егет була ул, әлбәттә. Хәтта тел дә белмәгән килеш чит илдә торып кала. Тәвәккәл таш яра, диләр. Шунда яшәгән рус кешеләре белән танышып, тормыш корып җибәрә. Тел дә өйрәнә, эш тә, торыр урын да юнәтә һәм тиздән Пермьнән хатыны белән баласын да алдырта. Аннары ире, балалары белән хатынының сеңлесе дә килеп төшәләр. Шулай итеп, Сиэтлда кечкенә генә татар диаспорасын башлап җибәрәләр.

Мин танышканда, Фәндүснең үзенең кафесы бар (хатыны һәм аның сеңлесе шунда эшлиләр) иде инде. Шуның өстенә, үзе тагын бер урында эшли. Квартиралар сатып алганнар.

Дәүләт балаларын бушлай инглиз теленә өйрәтә. Һәр көнне, автобус белән килеп, мәктәпкә алып китәләр, кайтарып куялар.

Менә шундый безнең татарлар: беркайда да югалып калмыйлар.

Мин Америка Кушма Штатларында ике тапкыр булдым. Беренчесендә, әле генә язганымча, Американың Көнбатыш өлешендә – Вашингтон штатында яшьрәк чагымда булсам, икенче тапкырында, шактый олы яшьтә – Американың көнчыгыш ягында. Бу юлы, турист булып, махсус Нью-Йорк, Вашингтон шәһәрләрен һәм Ниагара шарлавыгын карау өчен бардым.

Ниагара шарлавыгы, Нью-Йорктан шактый еракта – Канада чигендә үк икән. Юлы ялыктыргыч булды. Шарлавык исә, әлбәттә, зур, тәэсир калдыра.

Вашингтон – матур шәһәр, Европаның күркәм калаларына охшаш. Кызыклы, истәлекле урыннарда булдык. Ак йорт, Капитолий, данлыклы Азатлык статуясы, астронавтлар музее, андагы луноходлар һәм башка әсәрләндерерлек нәрсәләр күп анда.

Нью-Йорк белән Ниагара арасындагы 700 километрдан артык араны автобус белән узганда шактый күп истәлекле урыннарны күреп бардык. Карап кына киткәндә дә Американың һәрьяклап алга киткән куәтле ил икәнлеген шәйләргә мөмкин.

Мине андагы элек-электән аеруча кызыксындырып килгән нәрсәләрнең берсе небоскреблар иде. Аларның тупланган урыны

– Манхэттен районы. Минем үземә шундагы отельләрнең берсендә берничә төн кунарга туры килде. Андагы 40-50, 60-70 этажлы күккә ашкан йортларны күреп, гаҗәпләнмәскә мөмкин түгел, әлбәттә. Ләкин мин анда яшәмәс идем. Ул биниһая күккә ашкан биналар арасында үзеңне таш базда кебек хис итәсең. Күк йөзенең түбәсен генә күреп яшәргә туры килә анда.

Миңа дөнья читендәге илдә – Австралиядә, Сидней шәһәрендә дә бер татар гаиләсендә булырга туры килде.

Австралия татарларының язмышы болай: аларның бабалары кайчандыр безнең яклардан Кытайга китеп урнашкан булганнар. Аннан төрле сәбәпләр белән кайберләре Япониягә, кайберләре исә Төркиягә, шуннан Австралиягә күчеп китkәннәр. Ул чагында Австралиягә бару иркен булган: бу илгә үзләре чакырып китерә торган булганнар.

Шунысы игътибарга лаек: туган туфракларыннан, Ватаннарыннан аерылып, чит җирләрдә йөзәр елдан артык яшәсәләр дә, Австралиядәге татар гаиләсендә олылары да, яшьләре дә туган телләрендә иркен сөйләшәләр. Казанда – Татарстан башкаласында туып үсеп, ана телләрен белмәгән татарларга бик гыйбрәтле күренеш.

Австралия – яшәү өчен бик яхшы урын. Кенгерә, коала кебек сирәк җәнлекләр яши торган бай табигате бар, җирләре иркен. Сидней шәһәре төзек, матур, яшеллек күп; океан яры буенда урнашкан оригиналь архитектуралы опера һәм балет театры мәһабәт булып балкып тора. Австралиянең башкаласы Канберра урман эчендә яшеллеккә күмелеп утыра.

Халык мул яши. Күбесе үз йортларында тора. Мин булган татар гаиләсен мисал итеп китерергә мөмкин. Гади эшчеләр булып эшләсәләр дә, тормышлары җитешле: үзләренең бакчалы ике катлы йортлары, өй эче дә күркәм, ел саен туганнарына Америкага барып кайталар икән...

Австралиядән кире кайтканда булган бер кызык эпизод исемә төште. Сидней аэропортында самолет көтеп утырабыз. Минем бер коллегам белән сөйләшеп утыруымны күреп, безнең янга шактый өлкән яшьтәге бер абзый килеп утырды. “Сез Россиядәнме, Мәскәүгә кайтасызмы?” – дип, сүз башлады русча. Без уңай җавап биргәч, берөзлексез сөйләп китте. Шул ачыкланды. Моны, ялгыз бабасын, оныгы Мәскәүдән үзе янына алдырган булган. Австралия дәүләте берүзенә ике бүлмәле квартира биргән, зур суммада

пенсия билгеләгән. Ләкин бабай чит җирдә ияләнә алмаган, Ватанын бик сагынып, ташлап кайтып китәргә карар кылган. “Нишлим мин берүзем ике бүлмәле фатирда, нигә миңа шуның кадәр пенсия?” – дип сукрана абзый, – “Сөйләшергә кеше юк, урамда эт тә күрмисең, ишек алларыннан чыгармыйлар...”. Абзый сөйләшергә шулкадәр сусаган булган, самолетта, кайтып җиткәнче, әле берсе, әле икенчесе белән берөзлексез гәпләшеп барды. Ә самолет юлы ерак, 24 сәгатьлек иде.

Кытайда мин ике тапкыр булдым. Икесендә дә университет эшләре белән.

Беренче тапкыр, ике проректор белән бергә, Кытайның иң көньягында, Вьетнам чигендә, Гуанси провинциясенең Гуйлинь шәһәрендә, андагы педагогика университеты ректоры чакыруы буенча булдык.

Гуйлинь педагогика университеты Кытайның иң зур һәм абруйлы югары уку йортларыннан санала. Без анда үзебез өчен уңай үрнәк алырлык нәрсәләрне шактый күп күрдек.

Беренчедән, университет, зур территориягә урнашып, койма белән әйләндереп алынган үзенә күрә бер поселок кебек. Анда уңышлы уку һәм укыту өчен кирәкле бөтен нәрсә дә (инфраструктура) бар. Уку бинаталары, спорт мәйданчыклары, студентлар өчен тулай тораклар, укытучылр өчен квартиралар, ашханә, кибетләр һәм башка нәрсәләр. Гомумән, Кытайның бөтен уку йортлары да, башка күп илләрдәге мәктәпләр һәм югары уку йортлары да, нигездә, аерым поселок рәвешендә корылган: яшәү, уку-укыту процессына бәйләнгән эшләрне башкару өчен кирәкле барлык нәрсәләр дә шунда, бер урында тупланган. Бу бик уңайлы, акыл белән эшләнгән.

Без, килеп төшкәч тә, университет капкасыннан кереп, ректоратка таба барганда, бер бинаның ачык тәрәзәләреннән “Катюша“ны җырлауларын ишеттек. Гаҗәпләнеп елмаеп куйдык. Баксаң, студентлар моны без килешкә махсус оештырганнар икән. Күңелебез булды, әлбәттә.

Соңрак шул ачыкланды: Гуйлинь педагогика университетында барлык студенларга да башлангыч музыка белеме бирелә икән. Миңа бу бик ошады, һәм, кайткач, үзебезнең университетның бөтен факультетларында да “Музыкаль тәрбия нигезләре” дигән курс укыта башладык: һәр студент берәр төрле музыка коралында уйный белергә, музыка нотасын аңларга һәм хорда җырлый белергә

тиеш дигән таләп куйдык. Бу идеяне тормышка ашыру өчен, махсус кафедра оештырдык, музыка кораллары сатып алдык, моның өчен акча, өстәмә вакыт табарга кирәк иде әле. Безгә Мәскәүдән Министрлыктан җибәрелә торган уку планында мондый курс юк иде: без, тәвәккәлләп, үз җаваплылыгыбызга алып эшләдек боларны.

Соңрак әле тагын чын укытучы музыка коралында уйный, җырлый белеп кенә калырга түгел, бии дә белергә тиеш дип, хореография кафедрасы ачтык һәм барлык студентларны да биергә, танцыга өйрәтә башладык. Монысын да (минем инициатива белән) үз ихтыярыбыз, үз белдегебез белән эшләдек.

Гуйлинь университетында безне бик җылы каршыладылар һәм зур хөрмәт күрсәттеләр. Уку йортының эчтәлеге, казанышлары, уку процессын оештыру үзенчәлекләре белән якыннан таныштырдылар. Бу эшләрне оештыруда университетның уку эшләре бүлеге мөдире Чжань әфәнденең хезмәте зур булды. Ул, безнең университетта педагогика буенча стажировкада булып, бездәге уку процессын оештыру тәртибе белән танышып киткән иде. Шунда аның белән якыннан танышып калган идек. Русча да ярыйсы гына белә. Безнең өчен уңайлы булды: безнең анда яшәвебезне турыдан-туры ул оештырды һәм безне һәр җирдә озатып йөрде.

Безне гаҗәпләндерерлек нәрсәләр шактый булды анда. Мәсәлән, бездә әле информатика техникасы яңа керә башлаган гына, аларда инде аны киң кулланалар иде. Университет поселогында берничә спорт мәйданчыгы бар, физкультура дәресләрен шунда гына уздыралар. Ә бездә андый мөмкинлек юк: студентларны физкультура дәресенә төп укыган җирләреннән әллә кайларга йөртергә мәҗбүр була идек.

Әлбәттә, бездә дә укытуны, фәнни эшләрне оештыруда һәм башка өлкәләрдә уңай яклар, казанышлар бар, һичшиксез. Ике якның да казанышларын исәпкә алып, без Гуйлинь педагогика университеты белән Казан педагогика университеты арасында студентлар, укытучылар алмашу, аспирантурада укыту һәм башка мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлек килешүе (договор) төзедек.

Кытайның көньягында, Вьетнам чигендә, табигать бик матур һәм үзенчәлекле: андагы кебек биек зур чүмәлә рәвешендәге тауларны минем башка бер җирдә дә күргәнем юк; таулар арасыннан агып килә торган чиста сулы сай елгалар; Гуйлиньнан ерак түгел

гаҗәеп бер мәгарә бар, үзе матур, үзе зур, эчендә шундый күл бар, хәтта коенырга һәм көймәдә йөрергә мөмкин.

Гуйлинь тирәсендә, ялпак төпле теплоходта елга буйлап сәяхәт кылганда, бер кызык күренешкә тап булдык. Елга буенда үлән ашап йөргән буйволлар вакыт-вакыт елгага кереп китәләр дә суга чумалар. Шактый гына торгач, авызларына бер тотам суүсем эләктереп, аны яр буена алып чыгып, җайлап кына ашыйлар. Ашап бетергәч, тагын кереп китәләр...

Икенче тапкыр мин Кытайга Пекиндагы чит телләр институты чакыруы буенча, аларның вузы белән безнең университет арасында студентларның стажировкаларын оештыру турында договор төзергә бардым. Беренче баруымнан алты-җиде ел гына узуга карамастан, Кытайда уңай якка зур үзгәрешләр булып өлгергән. Бигрәк тә Пекинда яңалыклар күп иде.

Пекинның чит телләр институтында рус теле факультеты, Казан педагогика университетында чит телләр факультеты бар. Бу факультетта минем ректорлык чорында көнчыгыш телләре, шул исәптән кытай теле өйрәтә башлаган идек. Чит телләрне ныграк үзләштерү өчен, ул телләрнең ияләре яшәгән илдә торып, укып, өйрәнеп кайту мәгкулъ. Шуны истә тотып, без, кытай студентларын рус теленә өйрәтү өчен, аларга үзебезнең вузда бер еллык стажировка оештырдык, Пекин институты исә безнең студентларны кытай теленә өйрәтү өчен, шул ук срок белән үзләрендә стажировка оештыра башлады.

Бу система белән эшләү әйбәт нәтиҗәләр бирә. Безнең университет студентлары, инглиз һәм тагын берәр европа теленнән тыш, кытай телен дә ярыйсы ук өйрәнеп чыгалар, һәм кайберләре хәзер уңышлы гына Кытайда яшәп эшли.

Кытай халкының тырышлыгы һәркемгә мәгълүм. Аның соңгы 30–40 елда халык хуҗалыгының һәр тармагында ирешкән уңышлары таң калдыра.

Кытайлыларның гомумән тырыш булуы студентларының укуында да чагыла. Мин бездә стажировка узганнарының үҗәтләнеп укуларын үзем күреп, белеп тордым. Ә Кытайның үзендә, Пекин чит телләр институтының рус филологиясе факультетында укыганнарын анда баргач күрдем. Анда без, Казан кунаклары, хөрмәтенә рус телендә махсус мини спектакль һәм концерт күрсәттеләр. Шактый әйбәт килеп чыкты, рәхмәт төшкерләре!

Пекин институты белән Казан университеты арасында договор төзеп, аңа рәсми рәвештә кул кую процедурасын уздыргач, безне бөек Кытай стенасына алып бардылар. Моннан берничә мең ел элек корылган бу могҗиза – кытай халкының бүгенге искиткеч зур казанышларының символы.

Мин булган илләрдән Гарәп Әмирлекләре үзенә бер аерым урында тора. Бу чүл уртасындагы оазис – әкият иле. Моңа ничек гаҗәпләнмәскә мөмкин: ярты гасыр чамасы вакытта ком чүлендә чәчәк атып утырган дәүләт төзеп куйганнар. Кеше акылы, кеше куллары белән төзелгән могҗиза бу. Бу дәүләтнең уңышларын, зур казанышларын сурәтләп тормыйм: моның хакында хәзер күп сөйлиләр, язалар һәм күрсәтәләр. Безнең ил һәм Татарстан халкы да йөри анда. Тик шуны гына әйтер идем: бу гаҗәеп казанышлар шактый дәрәҗәдә дәүләтнең акыллы җитәкчесе – шәех аркасында барлыкка килгән. Дәүләт башлыгына күп нәрсә бәйләнгән: ул акыллы һәм юньле булса, ил чәчәк ата, акылсыз һәм юньсез булса, ил артка кала, халык җәфа чигә.

Миндә Малайзиягә, Индонезиягә һәм Сингапурга сәяхәтемнән матур тәэсирләр калды. Бу илләрдә соңгы еллардагы күп кенә уңай үзгәрешләрне күрмәскә мөмкин түгел. Алар югары темплар белән алга бара: җитештерү арта, фән-техника, мәгариф алга китә, халыкның тормыш хәле яхшыра бара.

Миңа Малайзиянең башкаласы Куала-Лумпур бик ошады. Соңгы елларда оригиналь архитектуралы матур-матур биналар калкып чыккан. Шәһәр тыныч яши, җинаять, һәлакәтләр сизелми.

Мин малайзиялеләрнең киң күңеллелек, миһербанлылык, ягымлылык кебек сыйфатларга ия булуларына игътибар иттем. Отельләрдә, җәмәгать урыннарында, елмаеп, якты чырай белән каршы алалар, түбәнчелек белән әдәп саклап эндәшәләр һәм сөйләшәләр. Мин бу милләт кешеләренең үз-үзләрен тотышларында, үзара аралашу рәвешләрендә, сөйләмнәрендә, кием-салымнарында һәм көнкүрешләрендә безнең татарларга хас сыйфатлар күрдем. Телевизордан милли спектакльләрен карап утырганда, сөйләмнәренә бик игътибар итмәсәң, татар спектакле бара икән, дип уйларсың: охшашлык шулкадәр зур. Бик ихтимал: бу халык белән татар халкының телләрендә, яшәү рәвешендә, гореф-гадәтләрендә дә охшашлык бардыр. Халыкларның күп җирләргә күчеп йөрүләре, борынгы төрки кабиләләрнең, һуннарның һәм үзәк Азиядәге башка халыкларның якыннан аралашуы табигый күренеш бит. Һәрхәлдә,

бу халыкларның багланышларын, этнографиясен һәм телләренең үзенчәлекләрен өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерер иде.

Гаҗәеп дәүләтләрнең дә иң гаҗәебе ул – Сингапур. Андагы тәртипле, акыллы яшәү турында озак сөйләргә мөмкин. Мин берничә нәрсә хакында гына әйтеп китәм. Башка илләр белән чагыштырганда, кыйпылчык кына зурлыгындагы бу шәһәр-илдә тормыш дәрәҗәсе бик югары. Моның төп сәбәпләре: дәүләтне идарә итү системасында гаделлек, тәртип һәм нык уйлап эш итү. Анда, бездәге кебек гади эшче, укытучы, врач биш-алты, ун-унбиш, иң күбесе унбиш-егерме мең сум, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр исә йөзләрчә мең һәм миллоннарча сум хезмәт хакы алып эшләү күренеше юк. Шуны да искәртеп китим: Япониядә дә, мәсәлән, иң аз алып эшләүче белән иң күп алып эшләүче арасында аерма уртача алты-җиде тапкырдан артмый.

Сингапурда законнар, тәртипләр барлык кешеләр өчен, кемнең кем булуына карамастан, бертигез кулланыла. Хәер, бу югары цивилизацияле илләрнең барысында да, шул исәптән Көнбатыш Европа илләрендә һәм Америкада да шулай дип беләм мин. Бу фикерне расларлык Сингапурда ишеткән бер кызык хәл исемә төшә. Англиядән турист булып килгән бер егет Сингапурда җәмәгать урынында, стеналарга сызып, пычратып, хулиганлык кылып йөргән. Чит ил кешесе дип тормаганнар, тотып алып ябып куйганнар һәм тиешле җәзага тартканнар: ничәдер тапкыр (исәбен тәгаен хәтерләмим) чыбык белән суктырганнар. Англия дәүләте, бу хәлне ишетеп, Сингапур губернаторына зур канәгатьсезлек белдергән: янәсе, хәзерге заманда чит ил гражданына карата нинди кыргыйлык гамәле кылу бу. Губернатор бу рәсми протестка: "Мондый җәза бирү бездә сез хакимлек иткәндә кертеп калдырылган тәртип ул, һәм без аны әшәкелек эшләгән һәркемгә дә карата бертигез кулланабыз", – дип җавап биргән.

Сингапурда җәмәгать урыннарындагы, урамнардагы чисталык, тәртип һәм пөхтәлек искиткеч. Анда чүп ташлау гына түгел, төкергән өчен дә ярыйсы ук суммада штраф салалар икән.

Сингапур – океан буенда урнашкан, зур портлы матур шәһәрдәүләт. Фән, мәгариф алга киткән. Халыкның тормышы мул, җитешле. Хезмәт хаклары югары. Әлбәттә, чагыштырмача ниндидер проблемалары бардыр, бәлки. Кешеләрне торак белән тәэмин итү цивилизалияле хәл ителә. Социаль ипотека гадел, кешелекле системага корылган: аз хезмәт хакы алып эшләгәннәр квартира

өчен өлешчә генә түлиләр яки бөтенләй түләмиләр, уртача алып эшләүчеләргә квартира бик аз гына процент (дүрт-биш процент) белән бирелә, зур хезмәт хакы алучылар өчен кредит проценты сигездән артмый. Нәтиҗәдә барлык гражданнар да уңайлы, яхшы торак белән тәэмин ителгән: яшәргә юньле урыны булмаган кешеләр юк.

Сингапурдан, башка күп алдынгы илләрдән дә, безнең ил өчен үрнәк алырлык нәрсәләр күп, һәм алырга кирәк тә. Соңгы вакытларда җитәкчеләрдән анда барып йөрүчеләр ешайды кебек. Әмма бездәге тормышны оештыруда андагы тәртипләр бик күренми әле...

Үзәк Америкадагы илләрдән миндә Мексика матур тәэсирләр калдырды. Монда сәяхәт кылучылар өчен кызыклы һәм гыйбрәтле нәрсәләр күп. Мексика – борынгы майя культурасы, өч-дүрт мең еллык пирамидалары, матур милли бию-җырлары, джунглилары белән истәлекле ил. Соңгы елларда аның экономикасы күтәрелә бара. Бай илләрдән саналмаса да, хәерчелек юк. Халык әкренләп тормышын җайга сала.

Мине шунысы бигрәк тә кызыксындырды: майя халкында төрки халыклар белән охшашлык шактый нык күзгә ташлана. Галимнәрнең Беринг бугазы районында кайчандыр Азия материгы Америка материгы белән кушылган булган һәм төрки халыклар белән индеецлар аралашып яшәгән, дип фараз итүе ышандырырлык. Моның бер ачык дәлиле – хәзерге төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, майя һәм башка индеец халыклары телләре белән охшашлык булу.

Ял итү өчен, Кариб бассейнында урнашкан Доминикана республикасы бик әйбәт. Миңа анда аеруча нык тәэсир иткән нәрсә – Зәңгәр лагуна (Голубая лагуна). Шул урында американлылар шундый исемдә әйбәт кенә кинофильм төшергәннәр. Табигать искиткеч матур.

Доминикана республикасы – зур сынаулар үткән, тормышы яңа җайланып килә торган дәүләтләрнең берсе. Сәяхәт кылу өчен истәлекле урыннар шактый күп. Кешеләре киң күңелле, күләч йөзле. Материаль хәле ярыйсы, үзләрен тәртипле тота белә торган кешеләр барсыннар, үкенмәсләр.

Әлбәттә, мин чит илләрдә бары да ал да гөл дигән фикердә түгел. Аларның да һәркайсының үз проблемалары бардыр. Халыклары бик яхшы яшәгән дәүләтләр дә, күпчелек халкы авыр

яшәгән илләр дә бар. Мин булган илләрдән, мәсәлән, Мисырда һәм Һиндстанда ярлы кешеләр күп. Моның объектив та, субъектив та сәбәпләре бар, һичшиксез. Бу сөйләшү өчен үзе бер зур тема.

Мин, чит илләргә кылган сәяхәтләремә нәтиҗә ясап, шуны әйтер идем: чит илләргә барып, яхшысыннан да, яманыннан да гыйбрәт алу файдалы.



Подписание договора о сотрудничестве между Казанским педагогическим университетом и Кретейским университетом Франции



С ректором Пекинского института иностранных языков



С ректором Гуйлинского педагогического  университета (Китай)



Беседа с главой ахмадийцев – хозуром Мирзой Тахир Ахмадом (Лондон)



Перед пирамидой Майя (Мексика)



В Доминиканской республике

Душа не стареет
(Доминиканская
республика)





С представителем племени Майя (Мексика)



У вулкана Этна (Сицилия)



У Китайской стены

В Сингапуре





Куала-Лумпурда (Малайзия)



В Бали (Индонезия)



Куала-Лумпур (Малайзия)
на фоне «башен-близнецов»

С Генеральным директором Татагропромстроя Иреком Мунировичем Закировым (Япония).



В Японии





Во Вьетнаме



В Египте



В Италии



В Индии

# ХАТИРӘЛӘР, БӘЯЛӘМӘЛӘР ТӘБРИКЛӘҮЛӘР

## МИЛЛИ МӘГАРИФ САГЫНДА

*Тәрбия һәм белем бирү бер-берсеннән аерылгысыз.*
*Белем бирмичә, тәрбияләп булмый.*
*Һәртөрле белем – үзе тәрбия чарасы*

(Л.Н. Толстой)

Казан шәһәре – Идел буенда яшәгән күп төрле милләт вәкилләренең аң-белемнәре үсеше өчен элек-электән мәгърифәт учагы булып санала. Мондагы фән һәм мәгариф прогрессын XIX гасыр башында ук ачылган Казан университеты югары дәрәҗәгә күтәрә. Соңрак дәвердә университет йогынтысында һәм аның ярдәме белән ачылып эшли башлаган башка югары уку йортларының күренекле галимнәре Россия фәнен яңа биеклекләргә күтәрәләр. Бу вузларда укыган һәм эшләгән төрле халык вәкилләренең якыннан аралашып, дустанә хезмәттәшлек итеп яшәве республикабызда үткәрелә торган дөрес сәясәткә нигезләнә һәм бәрәкәтле нәтиҗәләргә китерә. Моның матур үрнәге Татарстан фәннәр академиясенең һәм чит ил академияләренең академигы, республикабызның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы, профессор Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов күп еллар буе ректор булып эшләгән Казан дәүләт педагогика университеты тарихында да ачык күренә. Киң җәмәгатьчелек Р.А.Юсуповны күренекле зур галим, укыту-тәрбия эшен нәтиҗәле итеп оештыручы җитәкче, икетеллелек, тәрҗемә һәм сөйләм культурасы өлкәләренә караган күп санлы монографияләр, фәнни-популяр хезмәтләр, дәреслек, кулланма, программалар һәм мәкаләләр авторы буларак белә. Аның соңгы елларда басылып чыккан гыйльми-популяр китаплары, публицистика, журналистикадагы активлыгы, радио һәм телевидениедәге ялкынлы чыгышлары, татарча һәм русча газеталардагы бик күп мәкаләләре югары бәягә лаек.

Бу күренекле галим һәм күркәм шәхеснең биографиясе белән танышсаң, анда гыйбрәтле, үрнәк булырлык вакыйгаларга һәм күп игелекле гамәлләргә тап буласың.

Язмыш Рүзәлгә җиңел тормыш әзерләп куймаган, аның гомер юлында авырлыклар һәм киртәләр дә аз булмый.

Рүзәлнең бала чагы Татарстанның Әтнә районындагы Кышкар авылында ишле гаиләдә уза. Бөек Ватан сугышы алдыннан туган бик күп яшьтәшләре кебек, аңа да тормышның ачысын-төчесен, авыр крестьян хезмәтен кечкенәдән үк татырга туры килә: биш малайлы гаиләдәге уртанчы уллары Рүзәл әнисе Лотфикамал апаның төп терәге була, шуңа күрә дә өй эшләренең күбесе аның җилкәсенә төшә.

Укуга омтылышының кече яшьтән үк ифрат зур булуы сәбәпле, булачак галим яшьтәшләреннән бер ел иртәрәк, кышкы каникулдан соң беренче сыйныфка йөри башлый. “Укудан күңеле тиз сүрелер”, – дип көткән олылар, аның һәрвакыт “бишле” билгеләренә генә укуын, мәктәпкә бик дәртләнеп йөрүен күреп гаҗәпләнсәләр, абыйлары-энеләре Рүзәлне өй эшләрендә тырыш булуы өчен яраталар. Җиденче сыйныфны бишле билгеләренә генә тәмамлаган Рүзәл Казан кооперация техникумына укырга керә. Өч елдан аны, унҗиде яше дә тулмаган егетне, Курган өлкәсендәге Усть-Уйка районына товаровед итеп эшкә җибәрәләр. Анда күргән кыенлыклар аның күңелендә нык уелып кала. Озаклямый армиягә китәр вакыты җитә: Рүзәл Памир тауларында чик сакчысы гаскәрләрендә хезмәт итә. Бу чор аның өчен зур чыныгу мәктәбе була. Татар мәктәбендә укып үскән егеткә рус телендә урта махсус белем алу, аннан соң чит җирләрдә эшләү, өч елга сузылган хәрби хезмәт аны төптән уйлап эш итәргә өйрәтә, алдагы гомерендә кирәкле сыйфатлар тәрбияләүдә ярдәм итә.

Рүзәл, Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә үк, киләчәктәге тормышы, кем буласы турында ныклап уйлап куя, катгый фикергә килә: Казанга кайтып, югары белем алу, халкына, Ватанына файдалы гамәлләр кылу. Китаплар дөньясына чумган егет Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына керү бәхетенә ирешә. Марксизм-ленинизм тәгълиматы хакимлек иткән чорда укыган студентлар яхшы хәтерли: КПСС тарихы, философия, политэкономия, атеизм, фәнни коммунизм кебек иҗтимагый фәннәрне үзләштерү булачак филологлардан уку белән җитди шөгыльләнүне, зур көч салуны таләп итә. Университетка керүнең

беренче көннәреннән үк, бишле билгеләренә генә укып барган Рүзәлне баштан ук актив җәмәгать эшләренә җәлеп итәләр. Аны тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре итеп сайлап куялар. Аңа министр приказы белән Ленин стипендиясе бирелә.

Индивидуаль план буенча укып, биш еллык университетны дүрт елда кызыл дипломга тәмамлаган яшь белгечне башта радиога тәрҗемәче итеп, аннары Казан телевидениесенә редактор итеп эшкә алалар. Анда берничә ел эшләгәннән соң Казан дәүләт педагогика институтының ул чактагы ректоры, профессор Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә диссертация язарга аспирантурага керә. Башта кандидатлык, соңрак филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен, диссертацияләр язып яклый. Докторлык диссертациясен Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында яклый. Оппонентлары академиклар М.Шанский, Ә.Р.Тенишев һәм башка мәшһүр галимнәр була. Рүзәл, югары уку йорты укытучысының барлык баскычларын үтеп, аспирант, докторант, ассистенттан алып профессорга кадәр үсә, кафедра мөдире, декан һәм 17 ел буе шушы уку йортында ректор булып эшли.

Р.А. Юсупов җитәкчелек иткән елларда Казан techпединституты зур үзгәрешләр кичерә: аның матди-техник базасы ныгытыла, уку-укыту процессының сыйфаты күтәрелә, факультетлар, кафедралар, фән докторлары һәм профессорлар саны бермә-бер арта, заман таләп иткән яңа белгечлекләр ачыла, уку планнары да фән-техника казанышларына җавап бирердәй итеп үзгәртелә.

Узган гасырның 80-90 нчы елларын Казан педагогика институты (университеты) тарихында яңарыш чоры дип атарга мөмкин. Бу елларда, булачак белгечләрнең белемнәрен яңа дәрәҗәгә күтәрү, алдынгы халыкара тәҗрибәне үзләштерү максатыннан, АКШ, Англия, Германия, Франция, Кытай, Төркия һәм башка илләр белән тыгыз бәйләнешләр урнаштырыла. Бу, бигрәк тә, 1996 нчы елда, Россиядә беренчеләрдән булып, Казан педагогика институтының университет статусын алуына да бәйле. Хәер, университетның төрле милләтләрнең үзара хезмәттәшлеге һәм дуслыгы шартларында эшләргә тиешлеге, аның инде гасыр ярымнар элек үк бөтен Идел буе һәм Урал тирәләре халыкларына югары педагогик белем бирү өчен ачылып, шул заманнарда ук бу уку йортында белем алган яшьләрнең якыннан аралашып яшәвенә нигезләнә. Университетның халыкара дәрәҗәдәге эшләре Бөек Ватан

сугышыннан соң берничә ел буена социалистик илләрдән килгән студентларның укуы белән дә бәйле. Шунысы бәхәссез: 90 нчы елларда исә Казан педуниверситетының чит илләр уку йортлары белән хезмәттәшлеге ректор тырышлыгы белән югарырак баскычка күтәрелә. Аралашып эшләү, уку һәм укыту процессы берничә юнәлештә башкарыла. Шуларның кайберләренә генә тукталып китик.

Югары уку йортының Россия Федерациясендәге башка педвузлар арасында зур абруй казанган чит телләр факультетында, традицион рәвештә укытылып килгән инглиз, немец, француз телләренә өстәп, испан, төрек, гарәп, кытай, япон, һинд, фарсы телләре укытыла башлый. Аларны яхшы итеп өйрәтү өчен, чит илләрдән укытучылар чакыртып алына һәм, студентларның белемнәрен ныгыту максатында, аларны шул илләргә стажировкага җибәрү тәртибе кертелә. Бу система буенча эшләү уңай нәтиҗәләргә китерә: студентлар чит телләрдән югары сыйфатлы белгечләр булып әзерләнә. Мисал өчен: кытай теле бүлегендә укыган берничә татар кызы, Пекиндагы чит телләр институтында практика узып, диплом алгач, Кытайның төрле фирмаларында уңышлы эшлиләр.

1996 нчы елда Рүзәл Абдуллаҗанович, Кытай Халык Республикасы Гуанси провинциясенең Гуйлин педуниверситеты җитәкчелеге чакыруы буенча анда барып, Казан педуниверситеты өчен әһәмиятле килешү төзеп кайта. Шуннан соң, илебездә беренчеләрдән булып, вузның барлык факультетларында да яшь буынга белем һәм тәрбия бирәчәк укытучыларга музыка һәм хореография өйрәтелә башлый.Бу вазыйфаны махсус төзелгән музыка тәрбиясе нигезләре һәм хореография кафедралары башкара.

Университетның рус филологиясе факультетында, махсус кафедра ачып, әзерлек курсларында чит ил студентларын рус теленә өйрәтү эше башлана. Бу гамәл дә уңай нәтиҗәләрен бирә: чит ил студентлары рус теленнән төпле белем алу мөмкинлегенә ия булалар, Казан педуниверсите- тында рус теленнән практика узып, белемнәрен камилләштерү мөмикинлеген алалар һәм Татарстан вузларына укырга керәләр.

Бу чордагы тагын бер үзенчәлекле юнәлешне әйтми булмый: булачак укытучыларның алдынгы илләр мәгарифендәге уңай тәҗрибәне үзләштерүләре максатында, педуниверситет

укытучыларының чит илләрдә стажировка узу тәртибе җайга салына һ.б.

Узган гасырның 90 нчы ел урталарыннан башлап, ректор Р.А.Юсупов тырышлыгы белән югары белемле милли кадрлар әзерләү тарихында беренче тапкыр барлык белгечлекләр буенча ике дәүләт телендә эшли алырдай укытучылар әзерләнә башлый. Аяныч: бу үтә файдалы эш, югары уку йортлары берләштерелгәннән соң, туктатылып калды.

1992 нче елда Республикабыз парламенты Татарстан халыклары телләре турында закон кабул итә. Аны эшләүдә һәм тормышка ашыруда Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов комитет рәисе буларак катнаша, сессия утырышында депутатлар каршында төп доклад белән чыга һәм аны гамәлгә ашыруда зур эш башкара. Шушы вакытта Казан педагогика университетында ректор Рүзәл Юсупов инициативасы белән законны тормышка ашыру йөзеннән, чуаш халкы белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен ныгыту, чуаш яшьләренә туган телләрен укытуда ярдәм итү максатыннан, рус филологиясе факультетында чуаш теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла, һәм анда чуаш теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү эше башлана. Бу гамәл Казан педуниверситеты коллективының демократия принципларын тормышка ашыруында гаять әһәмиятле адымы була.

Мәгълүм булганча, 2021 нче ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар дуслыгы елы дип игълан ителде. Дуслык төшенчәсенең мәгънәсе күп төрле. Татарстан Республикасында аның матур үрнәкләрен табып була.Заманында Россиядә Санкт-Петербург белән Мәскәүдән кала өченче булып ачылган күренекле Казан педагогика университеты илебезгә югары белемле, тәрбияле педагоглар һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерләү белән бергә халыклар дуслыгын ныгыту эшенә дә зур өлеш кертте. Милләтләр арасындагы дуслык турында сөйләгәндә, шуны да белеп тору мөһим: университетта студентларны тәрбияләү эше махсус программа буенча җитди нигездә оештырылып килде. Монда тәрбия эше төрле формаларда – укыту процессында да, махсус чаралар уздыру рәвешендә дә тормышка ашырылды. Яшь белгечләргә тәрбия һәм белем бирү бер-берсеннән аерылгысыз бөтен бер система буларак башкарылды. Хәзерге яшәешне, бүгенге вәзгыятьне исәпкә алганда, югарыда тасвирланган эшләрнең никадәр әһәмиятле һәм актуаль проблема икәнлеге бәхәссез.

Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның бәрәкәтле гамәлләре хәзер дә төрле юнәлешләрдә дәвам итә: иҗтимагый-сәяси өлкәдә ул республикабыз тормышы һәм язмышы, телне, мәдәниятне, милләтне саклау һәм яклау буенча актив эшли, үз сүзен кыю һәм кистереп әйтә торган аксакал (Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты һәм даими комиссия рәисе, 1990 нчы елларда фикердәшләре белән бергә Татарстан Республикасы партиясен төзегән һәм шактый еллар аның җитәкчесе булган шәхес; телара мөнәсәбәтләр, икетеллелек, тәрҗемә теориясенә караган проблемаларны хәл итүдә яшәп килгән кыенлыклар, аларны чишү юлларын эзләү, булганнарын камилләштерү; хәзерге татар әдәби телендәге хаталар, кимчелекләр, аларны бетерергә һәм булдырмаска бурычлы яшь галимнәрне, журналистларны һәм укытучыларны закон таләпләрен, татар мәгарифен яңа баскычка күтәрү кирәклеген исәпкә алып, әзерләү формалары һ.б.).

Бу уңайдан профессор Р.А.Юсуповның халыкара бәйләнешләр, милләтләр дуслыгын ныгытуга караган эшләрен тасвирлаганда, аның чит илләр белән дә тыгыз хезмәттәшлек итүен, Халыкара конференцияләрдә һәм симпозиумнарда катнашып ясаган күп санлы докладларын да исәпкә алу мәгъкуль. Ул –берничә академия академигы. Аңа фән, мәгариф, җитәкчелек һәм җәмәгать эшләрендә күрсәткән казанышлары өчен, 1997 нче елда Американың халыкара биография институты һәм Англиянең Кембридж Халыкара биография Институты тарафыннан “Ел кешесе” дигән мактаулы исем бирелде. Ул үзе хезмәттәшлек иткән илләрдәге мәгариф системаларын өйрәнеп, республикабыздагы белем бирү системасын камилләштерүгә караган фикерләрен матбугатта уртаклашып килә.

Академик Р.А Юсуповның фәнни-методик эшләренең күбесе телебезне өйрәнү һәм өйрәтүгә, яклау һәм саклауга, сафлыгын-чисталыгын үстерүгә багышлаган!Аның андый хезмәтләре исә – бик күп һәм саллы. Рүзәл Юсупов – гыйльми, фәнни-популяр, лингводидактика, публицистика юнәлешләрендә иҗат ителгән 800 гә якын (шуларның 100 гә якыны китаплар) басылып чыккан хезмәтләр авторы. Ул гына да түгел, Р.А. Юсуповның үзенең фәнни мәктәбе бар. Аның җитәкчелегендә 40 ка якын кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланды. Ул 25 елга якын телләрне чагыштырып өйрәнү буенча докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе вазыйфаларын башкарып килде. Аның күп сан-

лы шәкертләре фән өлкәсендә республикабызда һәм аннан читтә уңышлы эшлиләр.

Хәзерге вакытта Рүзәл Юсуповның телебезне куллануга караган җитешсезлекләрнең сәбәпләрен ачыклау, аларны киметү һәм бетерү өчен әһәмиятле эш-гамәлләр турында ихлас күңелдән борчылып язган хезмәтләрен туплаган "Горур булыйк" дип аталган яңа китабының кульязмасы нәшриятта басылырга әзерләнә. Автор анда, бик хәвефләнеп, болай дип яза: "Башка халыклардагы кебек, безнең әдәби телебез татар милләтенең барлык кешеләренә тигез хезмәт итә һәм аларны берләштерү чарасын үти. Төрле җирләрдә яшәүче татар кешеләре, көнкүрештә үз сөйләмнәренең үзенчәлекләре белән, үзләренә генә хас сүзләр, авазлар, грамматик формалар кулланып аралашсалар да, гомуми аудиторияләрдә – укытуда, җыелышларда һәм башка җәмәгать урыннарында, әдәбиятта, сәнгатьтә, матбугатта һ.б. уртак әдәби телдән файдаланырга тиеш. Әдәби телнең бик әһәмиятле вазыйфаларыннан берсе – бердәм телдәге мәгариф, әдәбият, матбугат, радио-телевидение аша җирле диалект сүзләрен әдәби тел сүзләре белән алмаштыра бару".

Чыннан да соңгы вакытларда матбугатта телдән һәм язма сөйләмдә "чәчәк аткан" җитешсезлекләрнең күплеген яклауга һәм аклауга багышланган мәкаләләр күренә башлады. Әмма без, үзебезне мәгърифәтле халык дип таныйбыз икән, хәзерге татар әдәби телен сакларга, аңа тел-теш тидермәскә тиеш, чөнки безнең телебез – бердәнбер! Ул бүген безнең аны саклавыбызга һәм яклавыбызга мохтаҗ. Төрле электрон басмалар, мәгълүмат чаралары хакимлек иткән чорда, әлбәттә, телнең сафлыгын саклау җиңел эш түгел, тик моңа кагылышлы һөнәр ияләре үзләренең әдәби телнең язмышы өчен җаваплы икәнлекләрен һәрдаим истә тотсыннар иде. Академик

Р.А. Юсупов нәкь шушы юнәлештә ифрат күп эшли, зур активлык күрсәтә: радио, телевидениедән дә, басылып чыккан хезмәтләре ярдәмендә дә тел мәсьәләсендә сак булырга өнди. Бу уңайдан инде телгә алынган китабындагы "Әдәби телебезгә реформа кирәкми" исемле мәкаләсеннән аеруча игътибарга лаеклы бер өзек: "Әдәби телебезгә ревизия ясыйсы юк: ул бик әйбәт. Аны яхшылап өйрәнергә, белергә һәм иркен, дөрес кулланырга гына кирәк. Татарларның яртысыннан күбесе үз телендә аралашмый, татарча китап, газета-журналлар укымый, татар мәктәпләренең

саны елдан-ел кими, калганнарында да, хәтта авыллардагы татар мәктәпләрендә дә русча укытуга күчә баралар, рус мәктәпләрендә укыган күп меңләгән татар балаларына туган телләрен өйрәтү ярым-йорты гына башкарыла. Шуның өстенә, иң хәтәре: татар халкының күбесендә милли рух, милли горурлык хисләре түбән яки юк дәрәҗәсендә. Менә шулар хакында күбрәк язарга һәм чаң сугарга кирәк.” Әйе, Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов туган телебезнең “ярым-йорты гына” өйрәнелүенә һәм кулланылуына хаклы рәвештә борчыла.

Сүзебезне бу могтабәр галим, күркәм шәхескә изге теләкләребез белән тәмамлыйк: Рүзәл Юсуповның бөтен күңелен биреп, милләтебезне, телебезне, мәгарифебезне кайгыртып башкарган игелекле эшләре бәрәкәтле булсын, әһәмиятле уй-фикерләре, тәкъдимнәре гамәлгә ашсын. Аңа моннан соң да, сау-сәламәт килеш, халкыбыз, республикабыз өчен файдалы эшләрен уңышлы башкарырга насыйп булсын.

**Ф.Ф. Харисов,**
*педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры,*
*Татарстанның атказанган фән эшлеклесе*

## МӘРХӘМӘТЛЕ УКЫТУЧЫБЫЗ

1990 нчы елның җәендә, бер төркем классташларыма ияреп, Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетына укырга керергә килдем. Бүгенгедәй хәтеремдә: документ тапшыру өчен су буе чират, һәм ул бик акрын бара. Вуз ректоры исеменә гаризаны алдан ук әзер бланкка язып керәсе икән. Бик тырышып шул гаризаны язып ятканда, коридорда абитуриентларның шау-шуы, ыгы-зыгысы кинәт кенә тынып калды. Миңа да кемдер пышылдады: “Ректор килә!”. Уртача гына буйлы, кыска җиңле ак күлмәк кигән мөлаем гына бер абый коридордан сөйләшә-сөйләшә килә, туктап, абитуриентлар, аларның ата-аналары белән әңгәмә корып ала. Башкалар ничектер, мин бераз аптырабрак калдым. Ректорны башкачарак итеп күз алдына китергән идем. Ул зур гәүдәле, күзлекле, (бәлки сакаллы да), костюм-чалбар, галстуктан булырга тиеш, һәм ул шулай гади кешеләр арасында гадәти генә сөйләшеп йөрмәскә дә тиеш кебек. Икенчедән, бу абыйны телевизордан күргәнем бар бит. Ул – депутат. Күптән түгел генә Дәүләт Сове-

ты рәисен сайлауны турыдан туры эфирда күрсәттеләр. Ул трансляцияне мин башыннан ахырына кадәр карадым. Рәислеккә алты кандидатның берсе шушы кеше иде, ләкин ул башта ук бу эштән баш тартып, белдерү ясады. Язылып бетмәгән гариза бланкысына карыйм: профессору Р.А. Юсупову, диелгән. Менә нинди кеше икән ул без укырга керергә йөргән югары уку йортының җитәкчесе. Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповны беренче тапкыр күрүем шулай булды. Әмма ректорның үзе булуына ышанып җитә алмыйм әле: бигрәк гади кеше кебек күренә. Соңыннан аның, дөрестән дә, шулай гади, ярдәмчел, олы җанлы кеше икәнлегенә мин әле күп тапкырлар инандым. Киләчәктә ректор Рүзәл Юсуповның кул астында эшләячәгемне, аның миңа һәм башкаларга да күп игелекле гамәлләр кылачагын ул вакытта күз алдына да китерә алмый идем әле...

Миңа профессор Р.Юсуповның лекцияләрен тыңларга насыйп булды. Беренче курста ул безгә “Сөйләм культурасы нигезләре” фәнен укытты. Газета-журналларда, радио һәм телевидение тапшыруларында күзәтелгән, көндәлек сөйләмдә булган күп хаталарны анализлап, профессор безгә телебезнең никадәр матур, аһәңле булуын, сөйләмебезне кирәкмәгән ясалма сүзләр, алынмалар, калькалар белән бозарга ярамаганлыгын бик ныклап төшендерде. Шушы дәресләр уңаеннан, укытучыбызның кешелеклеген, яхшы күңеллелеген характерлый торган бер истәлек.

Бер дәрес барышында, лекция тыңламыйча, башка бер эш белән шөгыльләнеп утырган бер студентка ул нык кына кисәтү ясады, ачуланды. Шелтә алган егет үзе дә бик борчылды, аның киләчәк язмышы безне – группадашларын да хафага салды: “Их, бетте инде бу бичара, – дип уйладык, зачетын ничек бирер, алга таба укый алырмы-юкмы, ректор кадәр ректорның ачуын чыгарды бит!”. Ләкин, ни хикмәт, профессорыбыз алай үч саклый торган кеше булып чыкмады. Теге егет бу фәннән зачетны да башкалар белән бергә тапшыра алды (студентлар лексиконында бу ситуация “укытучы батырмады, каныкмады” – дип атала), укуын да әйбәт кенә тәмамлады. Әле алай гына да түгел, аны Рүзәл Абдуллаҗанович үз инициативасы белән аспирантурага да алып калды.

Аспирантура дигәннән, мине тел белеме кафедрасына аспирантурага кабул итеп, шул ук кафедрага эшкә алучы да Рүзәл абый булды. Дәүләт имтиханнарын тапшырып йөргән көннәрнең берсендә тулай торак ашханәсендә мине проректор, безне 1-2 курс-

ларда укыткан, без бик хөрмәт иткән укытучыбыз Фираз Фахраз улы Харисов күреп алды һәм, минем хакта җылы сүзләр әйтеп, ректор белән таныштырды. Рүзәл абый минем киләчәккә планнарым белән кызыксына башлады. Яшерен-батырын түгел, диплом алгач, исәбем туган ягыма – Саба районындагы бер мәктәпкә тарих укытучысы булып кайту иде. Бу турыда район мәгариф бүлеге мөдире белән сөйләшү дә булган иде инде. Шул турыда әйттем. Ректор туган ягым, әти-әниләрем, аларның кайда эшләүләре, гаиләдә ничә бала үсүебез – барысын да җайлап кына сораштырды һәм институтта эшләргә яки аспирантурада укырга теләгем юкмы икәнлеген белеште. Инде хәзер, 25 елдан соң, шикләнмичә әйтә алам: бу очрашу тормышымны кискен үзгәрткән бер вакыйга булган. Чөнки Рүзәл абыйның минем белән шулай якыннан кызыксынуы, аталарча сөйләшүе, фикерләре шул дәрәҗәдә ышандырырлык, көчле булган, ашханәдән чыкканда, планнарым инде үзгәргән иде.

Бу сөйләшүнең нәтиҗәсе буларак, 1995 нче елның августында Рүзәл Абдуллаҗанович җитәкләгән тел белеме кафедрасына ассистент булып эшкә урнаштым. Шул елдан башлап, бу зур галим, затлы шәхес белән озак еллар бер коллективта эшләү насыйп булды. Ул елларда Рүзәл Абдуллаҗановичның киң кырлы фәнни-педагогик, административ һәм иҗтимагый-сәяси эшләрен үз күзләрем белән күреп тордым.

Нәкъ шул елда КДПУның татар теле һәм әдәбияты бүлеге ректор инициативасы белән махсус факультет буларак оештырылды. Элек рус филологлары, тарихчылар белән бергә укыган М.Җәлил урамындагы бинада татар филологиясе факультеты үзе генә, тулысынча хуҗа булып калды. Моңа кадәр шактый җайсыз, кысынкы шартларда яшәргә мәҗбүр булган бүлек өчен бу зур куаныч булды.

Яңа факультет оештырылу белән, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү эше яңа баскычка күтәрелде, аларны икенче белгечлек буларак, инглиз теле укытучысы һөнәренә дә өйрәтергә керештеләр. Моның өчен махсус инглиз теле кафедрасы оештырылды, чит телне туган тел аша өйрәтә торган яңа бер фәнни юнәлеш барлыкка килде. Шул ук елларда студентларыбызга журналистика, нәшрият эше дигән өстәмә белгечлекләр дә бирелә башлады. Ректорыбыз Рүзәл Абдуллаҗановичның иҗади тынычсызлыгы, һәрдаим эзләнүле характеры башка юнәлешләрдә дә чагылды: булачак укытучыларга музыка нигезләре, хореогра-

фия кертелә башлады, төрле музыка коралларында уйнарга өйрәнү мөмкинлеге ачылды.

Бүгенге көндә университетта инде Халык театры исеменә лаек булган “Мизгел” яшьләр театры уңышлы эшләп килә. Аның спектакльләре Татарстан телевидениесеннән күрсәтелде, К. Тинчурин, Г. Камал театрлары сәхнәләрендә уйналды. Казан педагогика университетындагы педагоглар театрын барлыкка китерүче дә – ректор Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов. 1996 елда нәкъ менә ул факультетка К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрыннан РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Марсель Җаббаровны чакырып алдырды, аның өчен махсус режиссер ставкасы булдырды. “Авыл хуҗалыгы институтында татар театры күптән эшләп килә, нигә бездә булмаска тиеш, укытучыларга кирәгрәк тә әле ул”, – диде ректор.

Җитәкче буларак, бөтен эшне җаның-тәнең белән бирелеп, сыйфатлы итеп эшләргә, тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, үз-үзеңне, сәламәтлегеңне аямаска, тырыш һәм үҗәт, намуслы һәм игелекле булырга – боларның барысын да безгә Укытучыбыз шәхси үрнәгендә күрсәтте.

Рүзәл Юсуповның университет һәм факультетыбыз үсеше, халкыбызны, телебезне саклау, өйрәнү, үстерү юнәлешендәге күркәм эшләрен бу кыска гына язмада тулысынча яктырту мөмкин түгел. Аларны анализлау түгел, санап кына чыгу да зур урын алыр иде, максатым да ул түгел. Тик шулай да аның миңа, гаиләбезгә һәрдаим хәерхаклы булып, булышып, ярдәм итеп торуына бер-ике генә мисал китерәсем килә.

1999 нчы елны мин өйләнергә булдым. Булачак хатыным Балтач районыннан. Хәзер генә ул студентлар укырга да үз машиналарында гына җилдереп киләләр. Ул вакытта студентлар түгел, шәхси машинасы булган укытучылар да бик сирәк иде. Йоласына туры китереп, “кыз сорарга” кайту өчен, машина кирәк булды. Гариза язып, ректор хозурына киттем. Исәбем – бер көнгә, акчаны хезмәт хакыннан тотып калу шарты белән, университет гаражындагы берәр җиңел машинаны алып тору. Ректор мине бик җылы кабул итте. Монысына шигем дә юк иде. Чөнки аның кул астында эшләүче кешеләргә – дәрәҗәле профессормы ул, яшь кенә ассистентмы, лаборант яки слесарьмы – һәммәсенә итагать һәм хөрмәт белән каравын ишетеп тә, күреп тә белә идем.

Рүзәл абый гадәттәгечә җайлап кына хәлләрне сорашты, факультеттагы вәзгыятьне белеште һәм машина мәсьәләсенә килде: “Москвич” белән кыз сорарга кайту синең кебек егеткә (имеш, вуз укытучысы!) бик килешеп бетмәс, без болай итик: әйдә, минем “Волга ” белән кайтып кил, кызның әти-әнисе, күрше-тирәсе (авылда халык тикшерүчән була) алдында йөзең кызарырлык булмасын, ә мин шәһәр транспортында йөреп торырмын...” – дип мине аптыраушта калдырды. Шунда ук булачак сәяхәт турында шоферына да шалтыратып әйтте, гаризаны да үземдә тотарга, бухгалтериягә бирмәскә кушты. Шулай итеп, булачак хатынымның авылына беренче тапкыр мин ректор “Волга”сында кайтып төштем.

Өйләнү мәшәкатьләре әле моның белән генә бетмәде. Авылда – монысы инде Саба районында – туй үткәрәсе бар. Казаннан кунаклар ташу өчен, тагын машина, бу юлы автобус кирәк. Бу очракта да Рүзәл абый ярдәмгә килде. Ике көн рәттән Казан-Саба маршруты буйлап университет автобусы йөрде, һәм алар өчен дә түләргә туры килмәде, хезмәт хакыннан да тотып калмадылар. “Яшь гаиләгә акча болай да күп кирәк. Туегызга университет ректоратыннан бүләк булыр,” – диде ректор.

Гаиләбезгә күрсәтелгән ярдәм әле моның белән генә дә бетмәде. Хатыным Гөлнара, без өйләнгәндә, 3 нче курста, түләп, ягъни договор буенча укый иде. Моны белгәч, аның 4 һәм 5 кә генә укуын һәм безнең гаилә хәлебезне дә исәпкә алып, ректор аны түләүсез уку (бюджет) бүлегенә күчерде. Шул ук елның көзендә безнең гаиләгә тулай торакның укытучы һәм хезмәткәрләр яши торган блогыннан ике бүлмә дә бирдерде.

Гомумән, бергә эшләгән елларда теге яки бу мәсьәлә белән ректор чагында да, кафедра мөдире булган вакытта да Рүзәл Абдуллаҗанович янына еш керергә туры килде. Чөнки беләсең: ул борып чыгармаячак, киңәш кирәкме, ярдәмме – җаен табачак, булышачак.

Тормышыбызның катлаулы чакларында миңа матди һәм рухи терәк булган Рүзәл абыйга мин бик рәхмәтле. Үзем һәм гаиләбез исеменнән аңа нык сәламәтлек, иминлек, иҗади һәм фәнни уңышлар телибез. Әле тагын күп еллар аның киңәшләрен тыңлап, теләктәшлеген тоеп яшәргә язсын иде.

**Рамил Мирзаһитов**,

*КФУның татар филологиясе бүлеге җитәкчесе, доцент*

## ТОРМЫШЫН ХАЛКЫНА ХЕЗМӘТ ИТҮГӘ БАГЫШЛАДЫ

Без Рүзәл белән, бер авылда туып, бер чишмә суын эчеп, бер партада утырып, үскән егетләр. Үсмер чагыбыз авыр сугыш елларына туры килде. Авылда күп йортларда ачлык хөкем сөрә иде. Яз башында – черек бәрәңге, чирәм чыккач – кузгалак, кычыткан, акбаш, какы, сәрдә яфрагы, тагын әллә нинди үләннәр безнең өчен гадәти ашамлык иде. Шушы авырлыкларга карамастан, без, мәктәп балалары, бер көн дә дәрес калдырмыйча, данлыклы Кышкар мәдрәсәсенә, ягъни мәктәпкә укырга йөрдек.

Беренче сыйныфта ярты ел укыгач, безнең класска Рүзәл Юсупов килеп керде. Тиз арада шул ачыкланды: аның ул вакытта әле укырга керү өчен яше җитмәгән булган. Без, малай-шалай, нәрсәгә ул вакытыннан алда үзенә камыт кидертә икән дип аптырап калдык. Әмма ул безгә караганда акыллырак та, белемлерәк тә булып чыкты. Без, ярты ел укып, юньләп саный да, укый да белми идек әле. Ул беренче көннән үк безнең өчен үрнәк булып китте.

Югарырак сыйныфларга киткәч, кызык та, кызганыч та хәлләр була торган иде. Математика фәнен үзләштерүдә проблемалар күп булды. Монда Рүзәл барыбыздан да аерылып тора иде. Шундый дәресләр күңелдә уелып калган. Математика укытучысы үткән дәрестә өйрәнгән материалны башта такта янына чыгарып, аннары парта янында баскан килеш барыбыздан сорап чыга. Беребездән дә дөрес җавап ала алмагач, мәсьәләне Рүзәлдән чиштерә һәм үткән теманы сөйләттерә дә, барыбызны да өстәмә дәрескә калдырып, Рузәлнең үзен генә кайтарып җибәрә торган иде.

Мәктәптән кайткач, бигрәк тә башлангыч классларда, без, өйдә дәрес әзерләү урынына, тизрәк урамга уйнарга ашкынабыз. Бәлки, белемебезнең сай булуы шуның белән дә аңлатылгандыр. Ә Рүзәл буш вакытын әрәм-шәрәм итми, җиң сызганып дәресен әзерли. Үзеңне мәҗбүр итә алу, ихтыяр көченә ия булу кебек сыйфатлар Рүзәлгә ул вакытта ук хас булган, күрәсең. Яшьлегенә карамастан, ул шул вакытта ук яхшы укырга, белемле кеше булырга дигән максат куя белгән.

Җәйге каникул вакытларында бөтен мәктәп балалары, көчләре җиткәнчә, колхоз эшләрендә катнашалар иде. Рүзәлгә бик җаваплы эш – төнлә ат көтү эшен тапшыралар иде. Ул вакытта бөтен авыл хуҗалыгы эшләре тик атлар ярдәмендә генә башкарылды. Мин

хәтерләгәнчә, бөтен Әтнә районына бер комбайн бирәләр, һәм ул Кышкар басуларына бик сирәк килә иде.

Мәктәп җыелышларында Рүзәлнең исеме гел яхшы яктан телгә алынып килде.

Яхшы сыйфатлар беренче чиратта гаиләдә тәрбияләнә, әлбәттә. Рүзәлнең әти-әнисе тәртипле һәм уңган биш егет үстерделәр. Алар безнең авыл кешеләре өчен үрнәк булдылар. Минем әни ике сүзнең берендә: "Әнә Йосыф Габдуллаҗаны малайларыннан үрнәк ал!" – дип әйтә торган иде. Ата-аналары колхоз эшеннән бушамаганлыктан, өйдәге бөтен эш балалар җилкәсендә булды. Мал-туарны туйдыру ул вакытларда зур проблема иде. Хәзер генә ул колхоз хайван тоткан колхозчыга теләгән кадәр ашлыгын, печәнен, саламын бүлеп бирә. Без үскән заманда, кул арбасына салып, авылдан 5-6 чакрым ераклыктагы кырлардан чүп үләне, сүсән, елгалардан камыш чабып ташый идек. Җитмәсә, еш кына бригадир Чапай (Габделбәр), сагалап торып, шулай җәфаланып җыеп алып кайткан печәнне колхоз фермасына бушаттыра иде.

Яз көне бәрәңге бакчасын казырга һәм бәрәңге утыртырга беренчеләрдән булып Рүзәлләр (абыйлары белән) чыга. Аларның бакчалары авылда төрле яктан күренеп тора. Бу хәл – авыл халкы өчен беренче сигнал, һәм бөтен бакчаларда эш кайный башлый.

Авырлыкларга карамастан, уку еллары бик тиз үтеп китте. Җиденче сыйныфны тәмамлап, төрлебез төрле якка таралыштык. Классташлар арасында тик Рүзәл генә бөтен предметлардан имтиханнарны гел бишлегә бирде һәм яхшы укуы аркасында, русча да белмәгән килеш, Казандагы кооперация техникумына барып кереп, аны уңышлы тәмамлады. Безнең Рүзәл белән дуслык бервакытта да өзелеп тормады. Ул техникумда укыган чорда, мин, һөнәр училищесын тәмамлап, авиация заводында эшләдем. Рузәлнең ул вакытларда матди хәле бик авыр иде. Шуңа күрә мин аңа бераз ярдәм дә итә торган идем. Безнең очрашулар, күңелле әңгәмәләр мин яшәгән тулай торакта уза иде.

Армиядән соң Рүзәл университетта, мин авиация институтында (КАИ) укыдым. Студент еллары да үтеп китте. Без Рүзәл белән атна саен очрашып, киләчәк тормыш турында планнар корып, киңәшләшеп яшәдек. Билгеле, яхшы киңәшләр, акыллы фикерләр күбрәк Рүзәлдән чыга иде.

Университет студенты буларак, Рүзәл икенче курслардан башлап лекторлык вазифасын үти башлады. Ул, лекцияләр укып, Әтнә, Арча районнарының күп кенә авылларын йөреп чыкты. Кышкы каникулның бер көнендә Рүзәлне кичке сәгать җидегә Симетбаш авылына чыгыш ясарга чакырдылар. Симетбаш белән Кышкар арасы өч чакрым. Иптәш итеп Рүзәл мине дә алды. Без, чаңгы киеп, ярты сәгатьтә Симетбаш клубына барып җиттек.

Рүзәл уңышлы чыгыш ясады, алкышлап, рәхмәтләр әйтеп озатып калды аны халык. Бәхетсезлеккә каршы, без кайтырга чыгуга, бик каты буран башланды, һәм без юлдан язып адаштык. Төне буе авылны эзләп, тәмам хәлдән таеп, таң атканда гына Кышкарга кайтып кердек. Бер уйлап карасаң, нәрсәгә кирәк булган болай җәфаланып йөрү Рүзәлгә, җитмәсә әле – бушка, бер тиенсезгә. Бөтен хикмәт шунда: ул бөтен тормышын халыкка хезмәт итүгә багышлады, фидакарь зат булды.

Кызганыч, яшь вакытлар бик тиз узып китә икән. Шулай минем өчен көтмәгәндә генә Рүзәл өйләнеп тә куйды. Зур итеп туй ясадылар. Мин хәзер берүзем калдым. Шулай итеп, миңа да башлы-күзле булырга вакыт җитте. Озак та тормыйча, мин дә үземә ошаган бер кыз таптым, Асия исемле, һәм кечкенә генә туй ясап (ул вакытта мин дә, Асия да студентлар идек), без дә тормыш итә башладык. Хәзергә кадәр без Рүзәлләр белән дус булып яшибез.

Бүгенге көндә Рүзәл – киң эрудицияле, танылган галим, татар халкы, аның теле, мәдәнияте өчен җан атып йөргән кешеләрнең берсе. Күп санлы дәүләт бүләкләре, фәнни дәрәҗәләр, мактаулы исемнәр – аның күп еллык намуслы, фидакарь хезмәте нәтиҗәсе. Киләчәктә дә зур уңышлар насыйп булсын аңа.

**Фоат Гомәров,**
*ТАССР торак-коммуналь*
*хуҗалыгының атказанган хезмәткәре*

## АНЫҢ ТОРМЫШЫ ГЫЙБРӘТЛЕ

Без гаиләдә биш малай үстек, Рүзәл абый – уртанчы, мин аннан кечерәге – дүртенчесе.

Безнең авыл яшәү өчен бик уңайлылардан түгел: болыны да, урманы да юк, елгасы да инеш кенә. Кырыс географик шарт сугыш елларындагы һәм аннан соңгы кыен тормышны тагын да катлау-

ландыра иде. Рүзәл абый белән минем яшь арасы якын булганлыктан, авырлыкларны без аның белән бергә кичердек.

Түбән классларда укыган чакта ук, без җәйләрен көненә икешәр мәртәбә кул арбасы белән печән алып кайта идек. Болын, урман булмаган-лыктан, бер кул арбасы печән җыеп алу да безнең өчен җиңел эш түгел иде. Ерак басуларга барып, ерганак төпләреннән, тау кырыйларыннан, кырдагы сука тимәгән җирләрдән уч-уч кына чабып җыя идек без аны. Ашлык арасыннан чүп үләне җыеп та тутырырга туры килде арбаны. Колхоз җитәкчеләре шулай җәфаланып тапкан печәнне алып кайтуны да тыялар, шуңа күрә аны өйгә кача-кача гына алып кайта идек. Бер сыерны, ике-өч сарыкны кыш буена туйдырып чыгарга җитәрлек итеп печән әзерләү күбрәк ун яшьләрендәге Рүзәл абый белән минем өскә йөкләнгән иде. Бу бурычны үтәү бездән күп тырышлык таләп итте, җитмәсә, ул вакытта тамак та тук түгел, гел ашыйсы килеп, эч суырып тора.

Көндезләрен һәм кичләрен, казан астына ягып, суын кайнатып, әнинең, эштән кайтып, берәр нәрсә пешергәнен көтеп торабыз. “Берәр нәрсә” дигәне гадәттә бәрәңге яки сепаратордан чыккан (аертылган) сөттән пешерелгән аш була иде. Ит-май, күкәй кебек ризыклар зур бәйрәм көннәрендә генә, әле анда да бик аз гына эләгә торган иде.

Ипине бәрәңге кушып салдылар. Ул чи, лыҗырдап тора һәм саф оннан пешерелгән ипидән күпкә тәмсезрәк була иде, әлбәттә. Бер мич ипигә тимерче алачыгында эшләткән ике зур чиләк бәрәңге уабыз. Бу эш Рүзәл белән Наил абыйларга йөкләтелгән була. Наил Рузәлдән дүрт яшькә олырак булганга, аңа җиңелрәк булгандыр. Әмма Рүзәл абыйга бик кыенга туры килә иде. Аның, бәрәңгене кадак белән тишеп ясалган угычтан уганда, бармаклары умырылып, ертылып бетә иде. Бер атналар узып, бармаклар тазарып кына килгәндә, ипи бетә, яңадан бәрәңге уар вакыт җитә. Гаиләдә кызлар булмаганлыктан, бөтен өй эшләре безнең өстә булды. Ул эшләрнең аеруча истә калганы – идән юу. Хикмәт шунда: ул чакта авылда малайларның идән юу гадәте юк иде, алар безнең идән юганга көлеп карыйлар. Шунлыктан абый белән (ул өй идәнен юса, миңа өй алды белән баскыч эләгә), идән юганда, кеше килеп кереп күрмәсен дип, капканы бикләп куя идек. Без өй эшләренең барысын да диярлек Рүзәл абый белән бергә башкардык.

Тыштагы эшләргә килгәндә, иң истә калганнары – җылы абзардан (кыш көне бик салкын булганда, бозау белән сыер,

бәрәннәре белән сарыклар шунда торалар иде) тирес чыгару, бакча казу, бәрәңге утырту, төбенә өю һәм аны алу.

Бура абзардан тирес чыгару иң авыр эшләрнең берсе булгандыр. Тирес кыш буе таптала, куптарып алуы бик авыр – көч җитми. Олырак булгач, абый тиресне сәнәк белән куптарып, мин носилкага төяп торам, аннары аны лапас артына чыгарып, пөхтәләп өеп куябыз.

Ул арада бакча да кибеп җитә, унбиш сутый җирне көрәк белән казып чыгарга кирәк. Бу да безнең өстә: әти белән әни колхоз эшендә, олы абыйлар ул чакта авылдан китеп барганнар иде инде.

Безнең бакча тау кырыенда булганлыктан, һәрвакытта да аны кул белән эшкәртәбез: кул белән казыйбыз, утыртабыз, кул белән төбенә өябез, казып алабыз. Шул нык истә калган: абый мине эшкә үгетләп-юмалап алып чыга иде, әйдә, энем, күршеләр эшләп бетерәләр, безгә алардан калышырга ярамый, дип. Мин абыйны тыңлыйм, бергәләп тырышып эшлибез һәм бакча эшләрен күршеләргә караганда алданрак тәмамлап куябыз. Әти-әни, Рүзәл абый мине кечкенәдән үк шулай эшкә өйрәтмәгән булса, мин, ихтимал, тормышта зур уңышларга ирешә алмаган булыр идем.

Авылда бөтен эшләр дә ат белән башкарыла иде. Кыш көне кырдан чанага төяп салам ташу, яз җиткәч, колхоз фермасыннан кырга тирес чыгару, җәен, су буеннан вак таш төяп, юл төзәтү, саман кирпеч сугу, привод (“привад” ди идек) белән ашлык суктыру, басудан әвенгә көлтә ташу, эскерт өю кебек эшләрнең күбесендә (укудан буш вакытларда) Рүзәл абый белән миңа да катнашырга туры килде.

Җәйге каникул вакытында без башкарган колхоз эшләренең берсе – көндезләрен, ә кайчакта төннәрен дә ат көтүе көтү. Кич эштән бушагач, атларны төнге көтүгә чыгаралар. Без бервакыт Рүзәл абый белән төнге ат көтүенә йөрдек. Абый үзен ничек хис иткәндер, әмма мин бик курка идем, чөнки төн караңгы, күреп бетереп булмый, кайчак атлар таралыша, көтүдән качып та китkәлиләр. Ул елларда авыл тирәсенә еш кына бүреләр дә килә иде. Көтүгә колынлы атларны да чыгаралар. Аларга бүреләр ташлану хәлләре дә булгалады.

Менә без шулай Рүзәл абый белән эштә чыныгып үстек.

Бу малайлар, өйдә генә ятмыйча, нигә колхоз эшенә дә йөргәннәр дигән сорау туарга мөмкин. Ул вакытта колхозда хезмәт көненә эшлиләр иде, әти белән әни эшләгән хезмәт көне биш ма-

лайны туйдырырга җитми, шуңа күрә җәйге каникулда, укудан буш башка вакытларда, колхоз эшләренә катнашып, безнең гаиләгә тигән хезмәт көненең санын арттыра идек. Ә бу, көз көне ашлык җыеп алгач, һәр хезмәт көненә бүлеп бирелгән арыш яки бодайга ярыйсы гына өстәмә дигән сүз.

Җиде классны тәмамлагач, Рүзәл абый Казанга укырга китте. Бергә уйнап, эшләп үскәнлектән, ул киткәч, күңелсезрәк, авыррак булып калды. Шуңа күрә абыйның кышкы һәм җәйге каникулда авылга кайтуын мин бик көтеп ала идем. Безнең йортка өстәп эшләнгән бик кечкенә генә өебез бар иде. Утын җитмәгәнлектән, аны кунаклар килгәндә генә җылыттык. Рүзәл абыйның кышкы каникулга кайтыр вакыты җиткәч, әниләрдән рөхсәт сорап, мин кечкенә өйне җылыта башлыйм. Ул кайткач, якын дуслар, малайлар белән шунда очрашып утыра торган идек. Абый Казан, укуы турында сөйли, бу бик күңелле, шатлыклы көннәр булып истә калган.

Рүзәл абый кечкенәдән үк инициативалы, сәләтле оештыручы булды. Техникумның беренче курсын тәмамлап, җәйге каникулга кайткач, абый әйтә: “Әйдә, дус малайларны җыеп, буа буып куйыйк”, – ди һәм без, арба белән вак таш, чыбык-чабык, чирәм кантарлары ташып, инешнең тар һәм тирән урынын сайлап, зур гына буа буып куйдык. Инеш суыбыз җәелеп үзенә күрә кечерәк бер күлгә әверелде. Әлеге эшне без – малайлар башкарып чыкканга олыларның ышанып та бетәселәре килмәде. Бу бөтен авыл халкы өчен бер шатлыклы вакыйга булды.

Рүзәл абыйның күркәм сыйфатлары турында күп сөйләргә мөмкин. Аның тормышы бик гыйбрәтле. Мин аның белән горурланам, иң якын күргән, булдыклы, кешелекле абыем, дип мактанып сөйлим мин аның турында.

**Әнәс Юсупов,**
*икътисад фәннәре кандидаты*

## ТЕЛЕБЕЗНЕ САКЛАУЧЫ ҺӘМ ЯКЛАУЧЫ ГАЛИМ

Соңгы елларда журналистлар, язучылар телендә “Юсупов феномены” дигән төшенчә кулланыла башлады. Берәүләр Рүзәл Юсуповны тел галиме, югары уку йорты җитәкчесе дип санаса; икенчеләр – татар теленең сафлыгы өчен көрәшүче, яклаучысы, дип

исәпли. Бу күренекле шәхеснең туган телебезнең дөреслеген кайгыртып язуы һәм сөйләве бик күптәннән, студент елларыннан ук килә. “Социалистик Татарстан” газетасының 1964 нче елгы 23 май санында аның “Төгәлсезлекләр күңелне борчый” дигән мәкаләсе басылып чыга.

Озак еллар дәвамында филология өлкәсендә тулы бер юнәлешне колачлап эшләгән, телләрнең үзара бәйләнеше, тәрҗемә теориясе, икетеллелек мәсьәләләрен өйрәнүдә ныклы, эзлекле караш булдырган галим ул Рүзәл Юсупов, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, вице-президенты, атказанган фән эшлеклесе, Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле җәмәгать эшлеклесе.

Чорыбыз, тарих тудырган Рүзәл Юсупов кебек уңган, зирәк замандашларыбыз үзләре шул ук тарихның яңа сәхифәләрен язалар. Татар халкының прогрессы өчен көрәшнең иң авыр елларында да сынатмаган, игелекле эшләр башкарган милләттәшләребез алар: Рүзәл Юсупов, Марат Мөлеков, Туфан Миңнуллин, Фәндәс Сафиуллин һәм башка кайберәүләр. Шулар турында уйланганда инглиз публицисты Эван Макколлның сүзләре искә төшә: “Сезнең буын коточкыч сугыш кыенлыклары кичерде, әмма сезгә беркайчан да хезмәтне хурлык дип, кешеләрнең бер-берсен ятрауларын балаларча беркатлылык, дип әйтмәделәр, сезгә беркайчан да... беркем дә... кешелекнең табигый кануны – сугыш, дип тукымады. Сезне беркем дә... яшәүне соңгы өметсезлек дип өйрәтмәде...”

Зур мәгънәгә ия бу фикер, нәкъ безнең буынга – Юсуповлар буынына атап әйтелгән. Чөнки бездән соңгылар инде башкачарак... Алар яшәүнең мәгънәсен, барыннан да бигрәк, байлык туплауда күрә. Ә безнең буын ул – кыю, авырлыклар алдында тез чүкми торган, гомерләрен лаеклы хезмәт белән бизәп, башкаларның язмышын кайгыртып, хаклык өчен көрәшеп, киләчәккә карап яшәүчеләр. Академик Рүзәл Юсупов – шундыйларның берсе!

Җәмгыятьнең лаеклы кешесе булу өчен зур белем туплау кирәклеген бик яшьли аңлый Рүзәл. Аның балалык һәм яшүсмер чоры авыр сугыш 1әм сугыштан соңгы елларга туры килә.

Фронтта каты яраланып, госпитальгә эләккән әтиләреннән хат килеп төшә... Моннан элегрәк, һәлак булды, дигән хәбәре килгән булган бит. Исән икәнен язган хатны алуга, әниләре елап җибәрә. “Шатлыктан да елыйлар икән”, – дип уйлап куя Рүзәл, бер әнисенә, бер абыйларына карап.

Фәкыйрьлектә узган еллар артта кала. Рүзәл, җидееллык мәктәпне "биш"ле билгеләренә генә тәмамлап, техникумга кереп укырга карар кыла. Авылдагы үтә кырыс тормыш шартларында ата-анасының аны Казанга озата бару мөмкинлеге дә булмый. Рүзәл берене тапкыр берүзе шәһәргә юл тота. Әти-әнисе өйрәтеп җибәргән адрес: "Колхоз базары янындагы түгәрәк баганалы капкалы йортта Зөләйха апа". Озак эзли ул апаны Рүзәл: андый йортлар шактый күп булып чыга. Ниһаять, Зөләйха апаларына барып ирешә. Аннары, уку йортын эзләп йөри торгач, кооперация техникумына юлыга. Аның исеменә төшенеп бетмәсә дә, документларын шунда тапшыра. Шулпй итеп, әле 14 яше дә тулмаган Рүзәлнең мөстәкыйль тормышы башланып китә.

Рус телен ипилек-тозлык кына белгән малайга нык тырышырга туры килә. Техникум аның өчен үзенә күрә кырыс тормыш мәктәбе була. Яшәү чыганагы – бары тик стипендия. Авылдан ярдәм көтеп булмый, үзләре дә бик авыр яшиләр.

...Әле унҗидесе дә тулмаган яшь белгечне Курган якларына товаровед итеп җибәрәләр. Менә шулай татар балалары еракларга сибелә шул. Ассимиляцияләүнең бер ысулы булгандыр ул, күрәсең. Яшь кеше иленнән, туган җиреннән аерылып китә. Ул, үз телендә сөйләшмәгәч, әкренләп динен дә, телен дә оныта. Татар дигән исеме генә кала. Балалары, оныклары яшәешендә анысы да юкка чыга... Рүзәлгә дә чынбарлык әнә шундый язмыш әзерләгән була. Әмма аны алда башкача тормыш, яңа җирләр – армия хезмәте көтә.

Рүзәл чик буе гаскәрендә, башта – Памирдагы Хорог шәһәрендә, аннары Сталинабадта хезмәт итә. Хорог биек таулар арасында урнашкан, болытлар янында ук. Уку-өйрәнү отряды каршында түбәсе күккә ашкан "Коммунизм пиг"ы. "Коммунизм"ны күрсәтәләр анда егетләргә. "Армиядәге хәлләр төшкә керсә, әле дә куркып уянабыз" – дип искә алалар Памирда хезмәт иткән егетләр.

Рүзәл Юсуповны, Хорогтагы әзерлек курсын бик яхшы күрсәткечләр белән генә тәмамлаганлыктан, башка берничә солдат белән, Сталинабадка сержантлар әзерли торган мәктәпкә җибәрәләр...

Курганда чагында да, армиядә хезмәт иткәндә дә аз санлы халыкларга кимсетеп карау, аларны "нацмен" дип йөртүләре Рүзәлнең күңелендә үз халкына, туган теленә булган җылылык, үз халкы

белән горурлану хисләрен көчәйтә генә. Без – татарлар, кемннән ким? Моннан мең еллар элек беренчеләрдән булып чуын койган, канализацияләр төзегән, күп илләр белән бәйләнешкә кереп, хөрмәт-дан казанган, югары мәдәнияткә ирешкән бабаларыбызның токымы кемнән ким булырга тиеш? Халкыбызга карата тупаслык кылган, безне “нацмен”, “чаплашка” дип йөртүче кайбер бәндәләрдән кай җиребез ким? Халкыбыз көчле, тигез хокуклы булырга тиеш, үзен кимсетергә, мыскылларга юл куярга тиеш түгел. Ә моңа бары тигез хокук алганда гына ирешергә мөмкин...

Рүзәлнең Курганда ук барлыкка килгән, югары уку йортында белем алырга кирәк, дигән уе армиядә куәтләнә төшә. Ул Казан дәүләт университетындагы тарих һәм филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укырга дигән ныклы фикергә килә.

...Августның кояшлы эссе көннәре. Өсләренә солдат гимнастеркасы, аякларына кирза итек кигән егетләр берәм-берәм Казан университетының ак колонналары янына җыелалар. Бүген керү имтиханнарының соңгысы... Егетләрнең күбесе имтиханнарын яхшы билгеләренә биргән. Инде укырга керүләре белән котларга да була кебек. Тик аларның йөзе борчулы. Солдат хезмәтен үтәп, тормышның ачысын-төчесен татырга өлгергән егетләрнең икесе чит телне буйсындыра алмаган. “Югыйсә, башка фәннәрдән имтиханнарны “дүрт”кә, “биш”кә генә тапшырганнар, – дип ачына Рүзәл. – Боларга ничек тә булышырга иде”.

– Ә ничек? Безне кем белә монда?

– Әгәр дә ректорга керсәк? Солдат хәлен аңламый калмас.

– Егетләр! – ди Рүзәл, нәрсәдер исенә төшкәндәй. – Әгәр дә Диләрә апа  Тумашева белән сөйләшеп карасак?!

– Теге сөйкемле апаны әйтәсеңме?

– Әйе, безнең группаны ул туплый бит.

Шуны гына көткән диярсең, колонналар арасыннан елмаеп Диләрә ханым Тумашева үзе килеп чыга.

– Сез монда икән, ә мин сезне химкорпустан эзләп йөрим тагын, – ди Диләрә апалары. Аннары, авыр сулап, дәвам итә: – Кирәк бит, иң ышанычлы, иң уңган егетләрем чит телне биргәндә абынганнар, кычытканы да юк, ичмасам, үзегезне чәбәкләргә!

– Ярар, акланмыйк! Алай дисәң, менә бу егетләр – Юсупов, Зыятдинов, Асылгәрәевләр солдатта булмаган дисезме?!

Гаепле егетләр, кызарып, башларын түбән ия.

– Ярар, үткән эшкә – салават. Сезнең турыда мин ректоратта да, кабул итү комиссиясендә дә аяк терәп сөйләштем, – диде Диләрә Гарифовна, – безнең бүлектә укырга лаеклы егетләр, үрнәк группа тупларга телим, булышыгыз, дидем, каршы килмәделәр.

Аннары Диләрә Гарифовна күзләрендә инде өмет чаткылары чагыла башлаган егетләргә эшдәште:

– Хәзер үк чит телләр кафедрасына барыгыз, анда сезне көтәләр.

Чынлап та, пофессор Диләрә Тумашева туплаган группа һәрвакыт һәм һәркайда үрнәк булды. Уку барышында яхшы укыганнары, республика хуҗалыкларына булышканнары, Казан “Оргсинтез” заводы төзелешендә зур булышлык күрсәткәннәре өчен, күп тапкырлар җиңүче булып чыкты, берничә тапкыр зур призларга лаек булды.

Ул чакта комсомол бик актив иде. Башта факультетның комсомол оешмасы секретаре булып тарих бүлеге студенты Индус Таһиров эшләде. Ул оста оештыручы иде. Рүзәл аның идеология буенча урынбасары булды. Индус Таһиров югары курска күчкәч, аның урынына Рүзәл Юсуповны секретарь итеп сайлап куйдылар.

“Мин үзебезнең группа студентларыннан уңдым”, – дип искә ала Рүзәл үзенең “Хәтирәләремне яңартып” дигән китабында, – бездә җитди, эшлекле, сәләтле егетләр-кызлар иде. Горурланмаслык та түгел. Аларның барысы да күренекле һәм күркәм шәхесләр булдылар”.

Укуда Рүзәл дәрәҗәсенә ирешүчеләр бик сирәк булгандыр. Ул гел “биш”кә генә укыды һәм Ленин стипендиаты булды. Яңа программа һәм кыскартылган план буенча укып, Рүзәл, Ленар һәм Фарсель биш елны дүрт елда тәмамлап, Татарстан телерадиокомитетында эшли башладылар. Тынгысыз Рүзәл Юсупов фикердәшләре белән Татарстанның Республика партиясен оештырды һәм рәисе булды, партиянең “Татарстан республикасы” дигән газетасын чыгаруга иреште. Партия үз тирәсенә Татарстанның мөстәкыйльлеге, халкыбызның мул тормышта яшәве өчен үзеннән җитди өлеш керткән замандашларыбызны туплады.

Рүзәл Юсуповның зур активлыгын, нәтиҗәле эшләрен күреп, халкыбыз аны Татарстанның Югары Советына депутат итеп сайлады. Ул парламентның даими комиссиясе (хәзер комитеты) рәисе, президиум әгъзасы булды. Аның чыгышларын халык йотлыгып тыңлый, ул күтәргән проблемалар зур игътибарга лаек иде.

Рүзәл Юсупов турында дистәдән артык китап басылып чыкты. Аның үзенең 500 дән артык фәнни-публицистик мәкаләләре, алтмышка якын монография, дәреслек һәм уку ярдәмлекләре дөнья күрде. Аның җитәкчелегендә 35 кеше кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклады.

Мин үземнең "Яшәү мәгънәсе", "Тернистый путь к звездам" дигән китапларымда, газеталардагы мәкаләләремдә сабакташым Рүзәл Юсуповның балачагын, яшьлек елларын, гомумән, тормыш юлын тулырак яктыртырга тырыштым. Шушы көннәрдә аңа 80 яшь тула. Без, аның группадашлары, Рүзәлне олуг юбилее белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез, аңа сәламәтлек, гаилә бәхете, халкыбызның мөстәкыйльлеген, телебезне саклау юлында нык-лык, иҗади удышлар телибез!

Зур ихтирам белән, группадашлары исеменнән –

**Фарсель Зыятдинов**,
*профессор, язучы*
*"Безнең гәҗит", 5 сентябрь, 2018 ел*

***Редакциядән**: Рүзәл Юсупов – редакциябезнең дә даими кунагы, авторы. Аны телебезнең сафлыгы, милләтебезнең язмышы борчый. Юбилярны газетабыз укучылары исеменнән котлыйбыз һәм милләтебезне, ватаныбызны игелекле эшләре белән сөендереп, бик озак имин, сәламәт яшәвен телибез!*

## ЗУР ГАЛИМ, МИҺЕРБАНЛЫ КЕШЕ

*Әле кайчан гына без, бер төркем егетләр һәм кызлар, Казан дәүләт университетына укырга керү өчен кабул итү имтиханнары биреп йөргән идек. Арабызда солдат гимнастеркаларын салырга өлгермәгәннәр дә, берничә ел эшләп килгәннәр дә һәм минем шикелле яңа гына мәктәп партасыннан аерылып чыкканнар да бар.*

Үзен тыйнак кына тоткан бер егет белән әңгәмә корып җибәрдем. Югары уку йортына килгәнче, Әтнә районындагы Кышкар авылы мәктәбенең 7 сыйныфын тәмамлагач, Казан кооперация техникумында укыган, аннан соң Курган өлкәсендәге Усть-Уйка райпотребсоюзында товаровед булып эшләгән. Бу чакта әле аңа 17 яшь тә тулып җитмәгән булган. Аннары өч ел Таҗикстанда чик буе гаскәрләрендә хезмәт иткән. Бу егет Рүзәл Юсупов исем-

ле иде. Гаҗәбрәк хәл: татарча 8-10 классларда укымаган булса да, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә карар кылган. Аның фамилиясе кабул ителгәннәр исемлегендә баллары буенча иң югарыда тора иде.

Бу вакыйгадан соң инде күп еллар узды, ул вакыттагы абитуриентларның күбесе республикабызга, илебезгә игелекле хезмәт итеп, абруйлы кешеләргә әверелде. Безнең белән бер төркемдә укыган Равил Фәйзуллин, мәсәлән, һәркемгә мәгълүм халык язучысы, Фарсель Зыятдинов – күренекле галим, икътисадчы, агроном, шагыйрь, журналист, Фирдәвес Гарипова, Флера Баязитова, Әнвәр Шәрипов – фән докторлары, профессорлар. Безнең группадашлардан атказанган эшлеклеләр, депутатлар һәм башка шундый асыл затлар да булды.

Рүзәл Юсупов университетта гел “биш“кә генә укыды. Биш еллык уку планын дүрт елда үтәп, башкаларныкыннан аермалы буларак, филолог-тәрҗемәче дигән квалификация алып чыкты.

Шуның өстенә, Рүзәл укуның беренче көннәреннән үк җәмәгать эшләренә кереп чумды. Беренче курста ук аны факультет комсомол оешмасы секретареның (хәзерге академик И.Таһировның) урынбасары итеп, ә икенче курстан тарих-филология факультетының комсомол секретаре итеп сайлап куйдылар.

Рүзәл, бөтен факультет күләмендә җаваплы вазифа башкарса да, группа эшләреннән дә читләшмәде. Безнең группа тырышып уку белән бергә нинди генә җәмәгать эшләрендә катнашмады. Җәйге каникул вакытларында колхозларга булышу, төзелешләрдә эшләү, көзләрен бәрәңге алу, авылларда бушлай концертлар кую... Безнең группа үзе бер концерт бригадасын тәшкил итте, барыбыз да җырладык та, биедек тә. Рүзәл гармунчы да, биюче дә иде. Шуның өстенә ул концерт алдыннан авыл халкына халыкара хәл турында лекция сөйли торган иде.

Төркемдәшләрдән Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов һәм Рүзәл Юсупов өчесе бер-бер артлы Татарстан радиосында эшли башладылар. Рүзәлгә монда чираттагы зур сынауны узарга туры килде. Аны тәҗрибәсез килеш тәрҗемәче итеп алдылар. Бер ай дигәндә ашыгыч эфир хәбәрләрен, алдан язып тормыйча гына, русчадан татарчага тәрҗемә итеп, машинисткага әйтеп бастырырга өйрәнеп җитәргә кирәк иде. Рүзәлне тәрҗемәче итеп радиога штатка алдылар. Хәер, ана бу эштә озак эшләргә туры килмәде, аны телевидениегә пропаганда редакциясенә редактор итеп күчерделәр.

Анда тагын яңа эш. Монысын да үзләштерде Рүзәл һәм берничә ел анда уңышлы гына эшләп килде. Телевидение журналисты һөнәре аның алдагы зур һәм җаваплы эшләре өчен бик файдалы булды.

Рүзәл Юсуповның университеттагы диплом эше җитәкчесе М.Зәкиев аңа, дипломын яклагач ук, аспирантурада калырга тәгъдим иткән иде. Әмма, Рүзәл берничә ел эшләп алырга кирәклеген әйтеп, рәхмәтен белдереп, бу тәгъдимнән баш тартты. Һәм менә Мирфатыйх Зәкиев, Казан педагогика институты ректоры булып эшли башлагач, аны үзенә аспирантурага чакырып ала. Рүзәл Юсуповның алдагы гомеренең күп өлеше шушы югары уку йорты белән бәйле була.

Югары уку йортында булган хезмәт баскычларының барысын да уза: ассистент, өлкән укытучы, доцент, декан урынбасары, декан. Ә инде 1982 елда Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында докторлык диссертациясен яклап кайтканнан соң, аңа тагын да зуррак эш йөклиләр: Казан педагогика институтының ректоры итеп билгеләп куялар.

Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов бу җаваплы вазифаны 17 елга якын фидакарьләрчә үтәп килә. Ул җитәкчелек иткән чорда Казан педагогика институты сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да нык алга китә.

Рүзәл инде ярты гасырдан артык вакыт татар теле гыйлеменең иң әһәмиятле өлкәсендә – туган телебезне саклау һәм үстерү тармагында ару-талуны белмичә хезмәт итә. Аның русчадан татарчага тәрҗемә итү, телләрне чагыштырып өйрәнү, дөрес сөйләм, татар телен укыту мәсьәләләренә багышланган 500 ләп фәнни хезмәте, шул исәптән 60 тан артык монография, дәреслек, уку ярдәмлекләре дөнья күрде. Ул соңгы елларда инде өлкән яшьтә булуга карамастан, ял итү турында уйламый, һәр елны икешәр-өчәр китабы чыгып, дистәләгән мәкаләләре басылып тора. Телебезнең торышын, андагы проблемаларны хәл итү юлларын күрсәтеп, туган тел язмышы өчен борчылып язган ялкынлы мәкаләләре даими рәвештә татар һәм рус телләрендәге матбугатта урын ала. Шушы көннәрдә кенә Татарстан китап нәшриятында аның “Вопросы теории и практики перевода” дигән зур күләмле китабы басылып чыкты.

Рүзәл Юсупов белән бергә эшләгән иптәшләре аның кешелекле, мәрхәмәтле, күркәм шәхес булуын сөйлиләр. Рүзәлнең коллегаларына, иптәшләренә игътибарлы, миһербанлы, аларның гозерләрен үтәргә әзер торган зат булуына мин үзем дә шаһит. Ул

ректор булып эшләү дәверендә авыр хәлле күп студентларга ярдәм итә: матди хәлләре кыен тырыш укучыларга стипендия бирү, килешү нигезендә укыганнарны уку өчен түләүләреннән азат итү һәм башка төрле игелекле гамәлләр башкарыла ректор тарафыннан. Монда эшләүчеләр еш кына: “Без эшкә бәйрәмгә килгән кебек киләбез”, – дип әйтә торган иделәр.

Мин сабакташым Рүзәлнең зур галим, зирәк җитәкче һәм миһербанлы кеше, Татарстан халыкларының бәхетле яшәве, үз халкының югары культурасын, камил туган телен саклап, алга баруы өчен кыю көрәшче булуына шатланам. Аны булачак юбилее белән котлап, сау-сәламәт килеш, иҗат уңышлары белән рухланып яшәвен телим! Бу котлауларыма, изге теләкләремә бүтән сабакташларым да һәм Рүзәлне белгән, аның рәхим-шәфкатенә дучар булган меңнәрчә башка кешеләр дә кушылыр дип уйлыйм.

**Әнвәр Шәрипов,**
*профессор, шагыйрь,*
*“Ватаным Татарстан”, 18 июль, 2018 ел*

## С ОТКРЫТЫМ ЗАБРАЛОМ

В школе мы наизусть знали эти тургеневские строки: “во дне сомнений, во дни тягостных раздумий о судьбах моей родины, – ты один мне поддержка и опора, о великий, могучий, правдивый и свободный русский язык! Не будь тебя – как не впасть в отчаяние при виде всего, что совершается дома? Но нельзя верить, чтобы такой язык не был дан великому народу”. Этой осенью исполнится ровно двести лет со дня рождения Ивана Сергеевича Тургенева.

Столь же искренне и убежденно в отношении своего родного, татарского языка может сказать доктор филологических наук, академик АН РТ Рузаль Юсупов, всю свою творческую жизнь посвятивший его изучению в неразрывной связи и соотнесении с другим государственным языком Татарстана – русским. Для него эти языки – как два равнонесущих крыла птицы. Из множества высказываний философов и мыслителей о роли языков в судьбах человечества наиболее емким и точным ему видится определение педагога-демократа К.Д.Ушинского: “В языке одухотворяется весь народ и вся его родина… Язык есть самая живая, самая обильная и прочная связь,

соединяющая отжившие, живущие и будущие поколоения народа в одно великое, историческое, живое целое”.

Судьба уготовила Рузалю Абдуллазяновичу нелегкую, но интересную и интеллектуально емкую жизнь. В ней удачно сочетаются эффективная научно-педагогическая деятельность, плодотворная административная работа и активное участие в общественно-политических событиях. Та триединая парадигма была предопределена суровым деством и юностью, которые сформировали в нем крепость духа, целеустремленность и упорство в достижении желанной цели.

Он разделил участь многих тысяч сельских мальчишек военных и послевоенных лет, познавших сполна все тяготы и лишения скудной жизни многодетных семей, отцы-кормильцы которых воевали в это время на фронте. Рузаль, работая в летние школьные каникулы на колхозном поле, был для семьи серьезной опорой. И чем труднее была реальность, тем страстнее мечтал он о дальнейшем образовании после местной татарской семилетки.

Эта мечта побудила тринадцатилетнего подростка, практически не знавшего русского языка, отправиться в одиночку на свой страх и риск из глухой деревеньки в Казань Похвальная грамота за семилетку давала ему право быть принятым без вступительных экзаменов в авиационный или механико-технологический техникум. Но прием в них закончился, остался лишь только что открытый и оттого мало кому известный кооперативный техникум. Смутно представляя, что это за профессия “товаровед”, подросток подал туда документы: возвращаться ни с чем в деревню он посчитал для себя постыдным. Снимая частный угол и перебиваясь лишь на скудную стипендию, Рузаль упорно постигал учебный курс, прилагая максимум усилий и прилежания к овладению прежде всего русским языком.

Распределение было всесоюзным, и на самостоятельную работу Юсупов был направлен в один из райпотребсоюзов Курганской области. Через три года, по достижении девятнадцати лет, был призван на армейскую службу. Родившееся у него еще на Курганщине желание избрать смыслом и содержанием всей последующей жизни служение татарскому языкознанию и культуре окончательно созрело в пору службы пограничником в предгорьях Таджикстана. Оно и привело парня после армии в Казанский государственный университете на отделение татарской филологии. Унаследованные

от родителей завидное трудолюбие, потребность каждое новое дело для себя исполнить наилучшим образом помогали Рузалю Юсупову и успешно учиться, и быть активистом-общественником. Подтверждением тому были получаемая им Ленинская стипендия (самая престижная и высокая для студенчества СССР), избрание секретарем комсомольской организации историко-филологического факультета. Занимаясь по индивидуальному плану, он уже с четвертого курса начал работать на Казанском радио и телевидении – сначала переводчиком, затем журналистом, редактором одного из ведущих отделов.

Работа в пору учебы в аспирантуре над диссертацией "Некоторые вопросы перевода с русского языка на татарский" определила одно из ведущих направлений в научных изысканиях Рузаля Юсупова – "Теория и практика перевода". Эта тема исподволь переросла в более широкую – в сопоставительное изучение разноструктурных языков. Докторской диссертации под названием "Общее и специфическое в лексико-фразеологической системе русского и татарского языков", которую соискатель защитил в совете при Институте русского языка АН СССР, выступавшие оппонентами Н.М.Шанский, Э.Р.Тенишев, В.В.Иванов, А.А.Юлдашев и другие признанные ученые-лингвисты дали высокую оценку.

Вся постуниверситетская жизнь Рузаля Абдуллазяновича оказалась связанной с Казанским пединститутом, где он последовательно прошел все ступени вузовской служебной лестницы – от преподавателя до ректора. Период его ректорства – 1986–2002 годы ознаменовался заметным ростом института в количественном и качественном измерении. По рейтингу он вошел и прочно удерживал место в первой десятке среди ста педагогических вузов страны, поднявшись на новый качественный уровень в подготовке школьных учителей. Вдвое возросло количество факультетов и кафедр, значительно увеличился контингент студентов и преподавателей, были введены новые специальности, открыт филиал в Набережных Челнах, из года в год расширялись международные связи вуза, существенно окрепла его учебно-материальная база. Закономерным следствием этих достижений стало получение вузом статуса педагогического университета.

По всей тезисности данных строк нельзя не сказать о том, как ректору удавалось решать финансовые вопросы жизни вуза при глубоком экономическом кризисе в стране тех лет. Будучи феде-

ральным, КГПУ должен был финансироваться Москвой, но та лет пять-шесть кряду смогла выделять деньги только на зарплату сотрудникам и стипендии. Но и в этот период, когда материальная база многих других вузов понесла большой урон, педуниверситет продолжил развиваться. На какие средства? На спонсорские деньги друзей Рузаля Абдуллазяновича, малопроцентные кредиты. Ценой большого риска он ввел дифференцированную систему оплаты за обучение с учетом баллов абитуриентов на вступительных экзаменах, а также оценок на летней экзаменационной сессии, что не было предусмотрено общепринятыми правилами для вузов. Этот шаг был направлен на социальную поддержку обучающихся и стимулирование качества учебы. По инициативе Рузаля Юсупова был предпринят целый комплекс мер по социальной защите преподавателей, прежде всего малообеспеченных. Многим из низкооплачиваемых преподавателей без ученой степени, работников хозяйственной службы была предоставлена возможность проживать в служебных квартирах и общежитиях вуза за символическую плату.

По своей природе Рузаль Юсупов – человек с ярко выраженной общественной активностью. В течение многих лет преподавательскую работу он совмещал с интенсивной общественной, неоднократно избирался секретарем парторганизации факультета, членом партком педниститута, был членом бюро Бауманского райкома КПСС. Будучи ректором, он возглавлял постоянную комиссию по образованию Казанского горсовета народных депутатов, а став депутатом Верховного Совета РТ, руководил постоянной комиссией парламента по национальным вопросам. Ему довелось принимать участие в решении многих судьбоносных для Татарстана вопросов – в разработке проекта закона о языках и отстаивании его важнейших положений, подготовке проекта Декларации о государственном суверенитете республики, а также проекта ее Конституции.

На памятной сессии Верховного Совета РТ 30 августа 1990 года первым пламенным выступлением в поддержку Декларации была речь депутата Рузаля Юсупова. Как человеку с прямолинейным характером, не боящемуся открыто высказывать свое мнение, ему не раз приходилось вести жаркие споры по острым вопросам, вызывая огонь на себя своей принципиальной позицией.

Кажется, годы не властны над этим человеком, от природы наделенным стойким бойцовским характером. Свой восьмидесятый день рождения ученый-лингвист встречает за привычным письменным столом, обдумывая строки очередной публицистической статьи в защиту родного татарского языка. *“С открытым забралом” – так говорят о человеке, выражающем свою позицию убежденно и открыто, во всеуслышание, прямым текстом, не подлаживаясь под меняющуюся конъектуру”.* Все, кто давно и близко знает профессора, академика АН РТ, заслуженного деятеля науки, лауреата Государственной премии Татарстана в области науки и техники Рузаля Юсупова, не сомневаемся, согласятся с нами в том, что именно это фразеологическое выражение наиболее полно и точно отражают суть его натуры.

**Шамиль Мулаянов**,
*ветеран журналистики,*
*заслуженный работник культуры РТ*
*“Республика Татарстан”, 13 сентября 2018 г.*

## “МӘГЪРИФӘТ, ДӘҮЛӘТ, ТУГАН ТЕЛ”

*Академик Рүзәл Юсуповның әле быел гына “Сүз” нәшриятында дөнья күргән* ***“Мәгърифәт, дәүләт һәм туган тел”*** *дигән китабын онытылып укып чыктым һәм һич арттырмыйча әйтә алам: аннан тормыш-яшәешебездәге бик күп сорауларга җавап таптым. Россия күләмендә генә түгел, байтак чит ил фәнни даирәләрендә дә танылган олпат галим зур тетрәнүләргә дучар ителгән җәмгыятебезнең халәтен, бу катлаулы вәзгыятьтән чыгу юлларын күрсәтә.*

Әлеге хезмәт, тәмам битарафлыкка чумып, мәрткә китмәгәннәр өчен (татары гына түгел, чуашы, марие, урысы һ.б.) өстәл китабы булырлык һәм аннан теләгән һәркем, үзенә кирәк чагында, мәгълүмат җыя вә тиешле ориентирны билгели ала. Ошбу әсбап “гадиләр” өчен дә, төрле дәрәҗәдәге чиновниклар һәм дәүләт тотучы ирләр өчен дә (әгәр укысалар) файдалы булыр иде. Мәҗмуга татар һәм урыс телләрендә язылган, киң катлау укучыларга адресланган.

Күренекле галим язмаларының әүвәлге өлешендә илнең икътисади һәм халыкның социаль хәленә күзәтү ясаса һәм бәяләмәсен

бирсә, тора-бара җәмгыятьнең үсешен бары тик мәгърифәт һәм тәрбия ысуллары аша гына чынга ашыру мөмкинлеген дәлилли. “Хәзер илебез икътисади һәм рухи кризис кичерә, һәркемгә мәгълүм: хакимият ияләре узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле, дәүләтне үзгәртеп корабыз дип, илне шактый нык бөлгенлеккә төшерде, халыкның матди хәлен авырайтты, шуның өстенә кешеләрнең рухи тормышында да тискәре күренешләр арта, әхлак дәрәҗәсе түбәнәя бара”, – дип борчыла ул.

Нык таралган, соңгы елларда бигрәк тә үрчеп киткән формализм, бюрократизм, кәгазь волокитасы. Бу күренеш, бернинди дә тоткарлыкка очрамыйча, көннән-көн искиткеч күләмдә җәела бара. Кирәкле конкрет эш эшлисе урында, күпме вакыт, энергия бер дә кирәксез, мәгънәсез статистик мәгълүматлар, план-отчетлар, чиксез күп төрле информация әзерләүгә, җыелыш-утырышлар уткәрүгә сарыф ителә. Кирәкмәгән эш белән күпме генә сәламәт яшь белгечләр шөгыльләнеп утырмый? Соңгы вакытларда төп көчне эшнең сыйфатын яхшыртуга, нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтәсе урында, структур үзгәрешләр кертү, форма яңарту белән мавыгу гадәткә керде. Бу бөтен илгә һәм халык хуҗалыгының барлык өлкәләренә, шул исәптән безнең республикага да хас,- ди гомеренең күпчелек өлешен югары белем бирүгә багышлаган белгеч. Моннан берничә ел элек, югары хакимиятләр әмере белән, Казан педагогика университетын әүвәл республика карамагындагы ике югары уку йорты – Татар гуманитар һәм Татарстан-Америка региональ институтлары белән кушып, бер вуз – Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетлары оештыруның да ахыр чиктә соңгысының Казан (Идел буе) федераль университетында “йотылуы” белән тәмамлануын әйтеп сызлана Рүзәл ага.

Казан педагогика университетының (элекке пединститут) 140 еллыгы уңаеннан язылган “Мөгаллимнәр мәктәбе” дип исемләнгән бүлек тә игътибарга лаек. “Илебездәге зур һәм бай тарихлы мәгълүм югары уку йорты – Казан педагогика университеты 1876 елда, Санкт-Петербург һәм Мәскәү институтларыннан кала өченче булып, Казан укытучылар институты исеме белән оештырыла. Шул вакыттан бирле ул, шанлы юл узып, бихисап күп санлы югары квалификацияле белгечләр – педагогик хезмәт осталары, мәгариф җитәкчеләре, галимнәр һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерли торган шөһрәтле уку йортына әверелә. Еллар узу белән аның исеме берничә тапкыр үзгәрсә дә, асылы, эчтәлеге бертөрле булып – мәгърифәт,

фән һәм мәдәният эшенә хезмәт итү булып кала”, – дип яза 1986-2002 елларда пединститутны (1994 елның 18 ноябреннән педуниверситет) җитәкләгән Рүзәл Юсупов. Чынлыкта, ул педуниверситетка җитәкчелек иткән елларда уку йорты чын мәгънәсендә уңай якка зур үзгәрешләр кичерә: илдә Михаил Горбачев башлаган реформалар фонында моның өчен ким дигәндә зур оештыру сәләтенә, корыч ихтыяр көченә һәм үҗәтлеккә ия булырга кирәктер дип беләм. Аңарда ошбу сыйфатларның барысы да тупланган, күрәсең, югыйсә, чагыштырмача кыска вакыт эчендә вуздагы кафедралар саны 30дан 60ка, факультетлар 15тән 30га җитмәс иде. Ректорның аерым кешеләр, тулаем коллектив белән уңышлы эшләвенең янә бер сере, аларны бер тән, бер җан итеп туплый алуында, кемнең кем булуына карамастан, һәр инсани затны бердәй якын күреп (кирәк икән, хәленә кереп, ярдәм кулы сузып) аралашуында дип әйтергә тулы нигез бер, чөнки аны һаман да сагыналар, хөрмәт итәләр. “Казан педуниверситетын бетерү аркасында, бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты белгечләре әзерләү эшенә зур зыян килде. Бу белгечлекләр буенча белем алучылар саны берничә тапкыр киметелде һәм укыту сыйфаты түбәнәйде. Соңгы вакытларда югары белемле татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләүнең торышы хакында борчылып сөйләүчеләрнең арта баруы очраклы хәл түгел”, – ди ул, өзгәләнеп. Шулай да аек акылның өстен чыгуына өмет өзмәвен дә белдерә ул.

Татарстан хоккей командасының җиңүе уңаеннан республикабыз Президенты Рөстәм Миңнеханов: “ЦСКА – яхшы уйный торган команда, тик безнең “Ак барс” аны да җиңде”, – дип горурлануын белдерде. Шул чагында ирексездән башымда: “И-их, милли мәгарифебез турында да шулай мактанып әйтерлегебез булса икән”, – дигән уй туды, югыйсә әлегә киресенчә – республиканың югары җитәкчелеге дә, ТР парламентындагы 100 депутатыбыз, РФ Дәүләт Думасындагы Татарстаннан сайланган 15 депутатыбыз да авызларына су капкан: татар телен, мәгарифен яклап югары мөнбәрдән ник бер сүз әйтсеннәр!

“Татарстан Президентына, парламентына һәм Дәүләт Думасының Татарстаннан сайланган депутатларына тиешле үзәк органнарга татар мәктәпләрендә бердәм дәүләт имтиханнарын (чыгарылыш имтиханнарын) русча бирүне туктатып, элеккечә туган телдә тапшыруга кире кайтуны таләп итеп мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр дә бу мәсьәләне уңай хәл итеп булмый икән,

татар мәктәпләрен саклап калу һәм тагын да арттыру максатында, безнеңчә, мондый чаралар күрү мәгъкуль”, – дип милли мәгарифнең тупикка килеп терәлгән халәтеннән чыгу юлын күрсәтә академик. “Нәрсә эшләргә?” дигән сорауны моннан гасыр ярым элек чамасы олуг фикер иясе Н.Г.Чернышевский да куйган. Ошбу сөаль Россиядә һаман да ачык кала. Аңа җавапны сәясәтчеләр, җәмәгать вә дәүләт эшлеклеләре, галимнәр табарга тырышкан һәм тырыша. Татарның иң мәртәбәле һәм зыялы затларыннан берсе – Рүзәл ага Юсупов та бу риторик сорауга җавап бирергә алына һәм, миңа калса, аны таба да. Бүгенге катлаулы вәзгыятьтә республикадагы татар мәктәпләренең күпләп ябылуы һәм урысча укытырга күчкән вә инде күптән урыс телендә белем бирә торган мәктәпләрнең эшчәнлеге фонында, ничек итеп булса да туган телдә укытуны мөмкин күләмдә саклап калырга, Конституцияне яклауга юнәлдерелгән аның киңәшләре. Күп төрле проблемаларны һәм аларны чишү юлларын санап чыкканнан соң, олуг галим: “Барлык телләр дә, шул исәптән татар һәм рус телләре дә төрле милләт халыкларының бер-берсен күрә алмау һәм ызгышу коралы булмасын, үзара татулык һәм дуслыкны ныгыту чарасы булып хезмәт итсен. Татарлар башка халыкларга, аларның телләренә һәм мәдәниятләренә һәрвакытта да хөрмәт белән карады һәм карый, рус телен аралашу теле буларак өйрәнәләр һәм, гомумән алганда русларның үзләреннән начар белмиләр, шуңа күрә үз телләренә, культураларына да башка халыклар тарафыннан шундый ук караш булырга тиеш дип саныйлар”, – дигән дөрес һәм гадел нәтиҗә ясый галим.

“Законнар бозылмасын” дигән бүлек, алдагы өлешләрдә бәян иткәннәрнең логик дәвамы буларак, язманың фикри тукымасын тагын да ныгыта һәм үстерә. Игътибар итегез, академик: “Милли мәктәпләрдә БДИны рус телендә бирү ул – милли уку йортларын һәлакәткә илтү чарасы. Шуңа татар мәктәпләрендә шуның аркасында русча укытуга күчә баралар. Шушы хәл дәвам итсә, мәдәниятебез үсеше өчен азык биреп торган татар мәктәпләре дә бетәргә мөмкин. Россия буенча чыгарылган 309 нчы боерык нигезендә милли мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарын рус телендә бирү – федераль хакимиятнең законсыз һәм ялгыш гамәле. Бу мәсьәләдә дә РФ Конституциясе һәм мәгариф турындагы закон бозыла”, – дип яза ул. Чыннан да РФ Конституциясенең 68 нче

маддәсендә: “Россиянең барлык халыкларына да туган телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү хокукы гарантияләнә”, – диелгән.

Конституциянең 6 нчы маддәсендә акка кара белән : “РФ гражданнары төп гомуми белемне туган телләрендә алу хокукына ия”, – дип язылган. “Аңлашыла булса кирәк: федераль хакимиятнең дә, җирле хакимиятнең дә республикабыздагы мәктәпләрдә татар теле укытуга мөнәсәбәтләре уңай һәм кайгыртучан булырга тиеш. Татар мәктәпләренең уңышлы эшләве һәм татар балаларын туган телләренә нәтиҗәле итеп өйрәтү – татар халкының цивилизацияле милләт булып яшәвенең нигезе”, – дигән нәтиҗә чыгара ул ахырда.

Күптән түгел бер төркем депутат РФ Дәүләт Думасы каравына Россиядә яшәүче урыс булмаган милләт балаларына туган телләрен ихтыяри рәвештә укытуны законлаштыра торган закон проекты тәкъдим итте. Әгәр аны кабул итсәләр, милли телләрне укытуны мәктәпләрдә закон буенча факультатив дәрәҗәсендә калдырачаклар. Моңа һич юл куярга ярамый! Ата-аналар, милли узаңы булган татарлар, ошбу милләтләрне бетерү омтылышына каршы чыгыйк, РФ һәм РТ президентларына мөрәҗәгать итеп имзалар җыйыйк! Бу уңайдан, РФ һәм Дәүләт Думасы Рәисе В.Володинга протест белдереп, РТ парламенты хат юллады инде.

**Фирдәвес Хуҗин**,
*язучы, җәмәгать эшлеклесе*
*“Ватаным Татарстан”, 16 май, 2018 ел*

## ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА ӘҺӘМИЯТЛЕ ХЕЗМӘТ

*Татарстандагы тәрҗемә тарихы белән танышасыгыз киләме? Рәхим итегез! Мондый чыганак бар. Академик Рүзәл Юсуповның “Вопросы теории и практики перевода” (Казан, 2018, 352 бит) китабы шуңа нисбәтле мәкалә белән башланып китә. Язмада татар әдәбиятының русчага тәрҗемә ителүе турында кызыклы мәгълүматлар бирелә.*

Рүзәл Абдуллаҗан улының бу өлкәдәге хәбәрдарлыгы тәрҗемә мәсьәләләре белән гомер буе шөгыльләнүеннән килә. Казан дәүләт университетында студент чакта башлаган фәнни эшчәнлеген ул аспирантурада укыган, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклаган, татар теле белеме кафедрасына

җитәкчелек иткән, Татарстан Фәннәр академиясенә академик булып сайланган елларда да күз уңыннан югалтмый. Бу темага Казан дәүләт педагогика университеты ректоры булып эшләгәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вазифасын башкарганда да тугрылыгын саклый. Татар һәм рус халыкларының матур әдәбияттагы, иҗтимагый-сәяси матбугаттагы рухи байлыгы белән бүлешүгә үзеннән саллы өлеш кертә. Профессор, “Татарстан халыклары телләре турындагы закон” проектын эшләүдә катнашып, республика парламентында милли мәсьәләләр һәм мәдәният комиссиясенә (1990–1995) җитәкчелек итеп, икетеллелек шартларында бер үк дәрәҗәдә сөйләшү, язу, аралашу практикасын гамәлгә кертүне рәсмиләштерү өчен сәяси ныклык күрсәтә.

Иң әүвәл, тәрҗемәне борынгы һәм мөһим эшчәнлеккә санаган галим, җәмәгать эшлеклесе гомуми теоретик мәсьәләләрне бәян итә. Тәрҗемәнең максаты, үзенчәлеге, сыйфаты, тәрҗемәченең иҗадилыгы, грамматика кагыйдәләре, стилистика... турында сүз алып бара. Әдәби әсәрләрне татарчадан русчага, русчадан татарчага һәм башка телләргә күчергәндә һәрбер җөмләгә ябышып ятмаска өнди. Аның “җырлап торуына” ирешү өчен ирекле фикер йөртүне хуплый. Әйткәнен дәлилләү өчен: “Алай түгел, болай ул”, – дип төрле мисаллар китерә. Беррәттән исем-фамилия, кушамат, география атамасы, йолдызлар, оешмалар исеме белән эш йөрткәндә, миллилекне сакларга, төгәллектән ераклашмаска киңәш итә...

Тел белгеченең матур әдәбият, вакытлы матбугат белән танышып, хаталарны тотып, кимчелекләрне кисәтеп, болай ачык дәрес үткәрүе даими рәвештә бара. Әгәр китапның “Файдаланылган әдәбият” исемлегенә күз төшерсәк, монда авторның “Тәрҗемә теориясенә кереш” (1972), “Тәрҗемә һәм тел культурасы” (1978), “Әдәп башы тел: икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре” (2000), “Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре” (2011), “Дөрес тәрҗемә итик” (2015), “Телебезне ялгыш тәрҗемәдән саклыйк” (2016)... дигән хезмәтләре искә алына. Күренгәнчә, академикның тәрҗемәгә өйрәткән гыйльми әсәрләре байтак. Хаталанмас өчен, аларны кулга алырга, җентекләп укырга, дустанә киңәшкә колак салырга гына кирәк.

**Хәмзә Бәдретдинов**,

*журналист*

“Мәдәни җәмга”, 20 июль, 2018 ел

# СОКЛАНМЫЙ МӨМКИН ТҮГЕЛ

Кайберәүләр аның фән сукмагындагы үрләрне бер-бер артлы җиңел генә яулавына, һаман үсә баруына шикләнебрәк карадылар. Янәсе, югарыдагы даирәләр арасында ныклы терәге бар бугай. Әмма Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында бергә укыган сабакташлары өчен генә теге “сер” ачык иде. Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов боларга бары тик үзенең тырышлыгы, уңай мәгънәдәге үҗәтлеге, әлбәттә, олы акылы белән иреште. Университетны Ленин стипендиаты булып тәмамлаган егеттән киләчәктә зур галим чыгасына берәү дә шикләнми иде.

Аның шундый дипломы белән Министрлар Советы каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение дәүләт комитетына тәрҗемәче булып эшкә китүе генә сәер кебек тоелган иде. Әлеге комитетта өч ел эшләде, анда редактор булды. Әмма журналист хезмәте аны үз эченә алып кереп китмәде. 1967 елда ул Казан дәүләт педагогика институтында аспирант иде инде. 1970 елда кандидатлык, 1982 елда докторлык диссертациясен (әле кайда диген, Мәскәүдә, СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында!) зур уңыш белән яклап, ул үзенә ышанычны тулысы белән аклады.

“Алма агачыннан ерак төшми” дигән мәкаль бар бит. Әтнә районының борынгы тарихлы Кышкар авылында да, Юсуповлар турында сүз чыкса: “Аларның нәселләре шундый шул...” – дип кенә куялар. Баксаң, Рүзәлнең әтисе Абдуллаҗан агай Кышкар мәчете мөәзине Йосыфҗан улы икән! Әнисе Лотфикамал да тирәякта үзенең акыллылыгы, уңганлыгы белән дан тоткан. Менә ул гыйлемгә омтылып, тәртипле һәм тәрбияле булып үсүнең “җеп очы” кайда икән!

Юсуповлар – биш бертуган, барысы да ир-егетләр. Авылдагы матур гадәт буенча алар күп еллар бер-берсен “дәү абый”, “кечкенә абый”... дип йөртәләр. Ә Рүзәл Абдуллаҗан улының туганнар арасындагы мондый исеме ничек дип уйлыйсыз? Шәкерт абый! Аңа бу кушаматны кечкенәдән үк гел бишлегә укуы өчен такканнар. Рүзәлнең киләчәген билгеләгән кебек була.

Без укыган елларда, югары уку йортына кергәндә, өстенлек урта мәктәптән соң кайда да булса эшләгән егет-кызларга бирелә иде. Ә бу яктан Рүзәл Юсупов һәркемнән аерылып торды. Ул, Казан кооперация техникумын тәмамлап, Курган өлкәсенең Усть-Уйский райпотребсоюзында эшләргә дә өлгергән инде. Аннары чик

буе гаскәрләрендә өч ел хезмәт иткән. Җитмәсә менә дигән гармунчы, балта остасы һәм ташчы да икән әле. Казанның Северный бистәсендә туганнары белән бергәләп зур кирпеч йорт салганнар болар. Һәм шунда җыелышып яшәгәннәр. Шуңа күрә факультетта аның абруе зур булды. Бу акыллы, тырыш, сабыр студент егет белән танылган профессорлар да ничектер хөрмәт итеп, кул биреп күрешә иде. Шулай икән, аның матур киләчәгенә кем генә шикләнсен?

Тәрбия эше – киң кырлы, төрлечә рәвешле һәм төрле ысуллар, алымнар ярдәмендә башкарыла торган гамәл. Аларның барысын да яктыртуны ният итеп куймыйча, кайбер аеруча әһәмиятле, гомум кабул ителгәннәре турында әңгәмә корырбыз.

Хәзер гомумән Россиядә тәрбия эше канәгатьләнерлек түгел. Бу фикерне бүгенге көндә илебез тормышында тискәре күренешләрнең күп булуы раслый. Промышленностьта җитештерүнең шактый зур өлеше таркатылды, авыл хуҗалыгы да көннән-көн тарала, миллионнарча гектар җирләр чәчелми кала. Халык эшләүдән биздерелде. Азык-төлекнең күп өлеше чит илләрдән кертелә. Инфляциянең өзлексез күтәрелеп, бәяләрнең туктаусыз артып торуы аркасында халыкның тормыш дәрәҗәсе түбәнәя бара. Шул ук вакытта илдәге миллиардерларның саны елдан-ел күбәя, иң зур хезмәт хакы белән иң кечкенә хезмәт хакы арасындагы аерма йөзләрчә, меңнәрчә тапкырга җитә. Миллионнарча, миллиардларча сумнар урлау, коррупция, башка күп төрле җинаять кылу хәлләре гадәти күренешкә әверелә бара. Россия хакимиятенең чит илләр белән урынсыз ызгышка керүе, ялгыш сәясәт үткәрүе аркасында илнең икътисади һәм сәяси чолганышта (изоляциядә) калуы да яхшыга алып бармый.

Яшьләрнең үз-үзләрен тотышындагы, яшәү рәвешендәге күңелсез күренешләрнең шактый киң таралган булуы, кайбер урта

һәм олы яшьтәге кешеләрнең дә тупас кыланышлары, тәрбиясезлеге гайрәтне чигерә.

Кыскасы, тиз арада, ашыгыч җитди чаралар күреп, җәмгыятебез әгъзаларының рухи тормышын яхшырту, югары цивилизацияле, мәгърифәтле итү бурычы тора. Бу бурычны уңышлы үтәми торып, Россияне дөньядагы алдынгы илләр сафына бастырып булмаячак, чөнки халыкның рухы, әхлагы сәламәт булмаса, аның матди тормышы җитешле, мул булмаячак, шулай ук гомумән илнең мораль мохитен чистартмый, тазартмый, культурасын күтәрми торып, аның иктисадын тиешле дәрәҗәгә җиткереп, матди байлыкларын туплап, халыкның тормышын яхшыртып булмаячак.

Дәүләт, тәрбия белән шөгыльләнүне иң әһәмиятле, иң ашыгыч бурыч итеп санап, бу эшне бөтен ил күләмендә югары баскычка күтәрү максатын күздә тоткан комплекслы программа буенча гамәлгә ашырырга тиеш.

Бу программада тәрбия эшенең бөтен дөнья практикасында тупланган нәтиҗәле тәҗрибәсе исәпкә алыну шарт. Монда шунысы әһәмиятле: программа киң колачлы булсын, ягъни ул һәртөрле аудиторияне – кечкенә балалардан алып олыларга кадәр халык катламнарын күздә тотып эшләнергә тиеш. Шул ук вакытта анда төрле халыкларның бу өлкәдәге милли үзенчәлекләре дә чагылыш тапсын. Әлбәттә, гомум дәүләт күләмендәге тәрбия эшенең комплекслы программасына өстәмә рәвештә урыннарда – республика, өлкәләрдә – җирле халыкның үзенчәлекле сыйфатларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып төзелгән милли тәрбия программалары да булуы мәгъкуль.

Хәзер әлегә хыялыбыздагы шушы тәрбия программасының төзелешен һәм эчтәлеген кузаллавыбызны бәян итик.

Бу программаның төзелеше вертикаль һәм горизонталь юнәлешләрдә болайрак булыр, дип фараз ителә. Аның горизонталь юнәлешен гаилә тәрбиясе, балалар бакчаларындагы, мәктәпләрдәге, урта һәм югары махсус уку йортларындагы тәрбиягә, ата-аналарның үзләрен дә тәрбияләүгә һ.б. багышланган бүлекләре, вертикаль юнәлешен исә әхлак тәрбиясе, хезмәт тәрбиясе, физик тәрбия, эстетик (сәнгать), экологик, патриотик тәрбия, үзеңне тота белү, әдәп кагыйдәләрен өйрәтү һәм башка шундыйрак төрле бүлекләр тәшкил итәр. Һичшиксез, тәрбиянең мәгълүм төрләре, нигездә, әле санап киткән һәм башка коллективларның барысына

да карый, ягъни аларның һәркайсында да күпмедер дәрәҗәдә урын алып тора, ләкин алар һәр аудиториянең яшь, җенес, милли һ.б. үзенчәлекләре исәпкә алынып кулланыла.

## ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ

Тәрбиянең күп төрләре арасында иң әһәмиятлесе, хәлиткече – әхлак тәрбиясе. Әхлаклылык – һәр халыкның иң беренче, иң мөһим, биологик кешене иҗтимагый кеше итә торган сыйфаты. Әхлак, кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләре нормасын һәм принциплары җыелмасын белдерә торган төшенчә буларак, кешелек җәмгыятенең, цивилизациянең нигезен тәшкил итә торган нәрсә дияргә була.

Әхлаклылык төшенчәсе кешеләрдәге гаделлек, намуслылык, игелеклелек, миһербанлылык, ихтирамлылык, турылыклылык, әдәплелек, ата-анаңны, балаларыңны, туганнарыңны, туган илеңне, телеңне, халкыңны ярату, хөрмәт итү дигән саф күңеллелек сыйфатларын белдерә. Шулай ук кешеләрдә, аларның мул тормышта, тыныч, бәхетле, гадел, намуслы яшәүләре өчен әһәмиятле хезмәт сөючәнлек, чисталык, тәртиплелек, хайваннар һәм үсемлек дөньясына, табигать байлыкларына, матди һәм рухи хәзинәләргә сакчыл караш, зыян китермәү, кешене рәнҗетмәү, аңа физик һәм рухи зарар китермәү, чит милеккә кагылмау, урламау, авыру, гарип, мохтаҗ, ярлы кешеләргә ярдәм итү, кунакчыллык, башка милләт кешеләренә дустанә мөнәсәбәт кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү югары мәгърифәтле кешелек җәмгыятенең иң мөһим вазыйфаларына керә.

Дәүләтнең тәрбия эше программасы шундый итеп төзелергә тиеш: кешеләрдә әле санап киткән сыйфатларны тәрбияләү һәм саклау аларның бала чагыннан алып бөтен гомерләре буена гамәлгә ашырылып торырга тиеш. Тәрбия – дәвамлы процесс. Балалык чагында, яшь чакта яхшы тәрбия алган акыллы кеше бөтен яшәве барышында үз-үзен тәрбияләү белән шөгыльләнә һәм шулай итеп, үзен мәгърифәтлелек – культуралылыкның тиешле дәрәҗәсендә тота.

Бу югары таләпләргә җавап бирерлек тәрбия тезисларын уңышлы гамәлгә ашыру мөмкинме икән соң, моның өчен җитәрлек шартлар бармы безнең илдә, безнең республикада? Бу риторик сорауга *бар!* дип җавап бирергә мөмкин. Күпмеседер җитмәсә, аны

булдырырга мөмкин. Тик моның өчен безнең дәүләт һәм республикабыз тиешле җитәкчеләренең теләкләре, ихтыяры һәм, илебезне алдынгылар сафына бастыру өчен, халык, бигрәк тә балалар, яшьләр арасында нәтиҗәле тәрбия чаралары күрергә кирәклекне аңлаулары кирәк.

Уңай сыйфатлар балаларда, гадәттә, беренче чиратта гаиләдә тәрбияләнә, әлбәттә. Ләкин бу бик җаваплы һәм кирәкле эшне гаиләгә генә тапшырып калырга ярамый. Чөнки ата-аналарның үзләренең дә күбесе, үз вакытында тиешле тәрбия алмаган булганлыктан, балаларына дөрес тәрбия бирергә сәләтле булмый. Шулай булгач, балаларга мәктәпкәчә учреждениеләрдә һәм мәктәпләрдә лаеклы тәрбия кылуны дәүләт органнарына йөкләргә туры килә.

Менә бу мәсьәләдә безнең илдә хәзер проблемалар шактый күп һәм җитди.

***Балалар бакчалары проблемалары***. Беренчедән, алар ата-аналары йөртергә теләгән барлык балаларга да җитми. Икенчедән, алар өчен түләү зур һәм ул елдан-ел арта бара. Бу исә аз акча алып эшли торган ата-аналарга бик авырга туры килә. Өченчедән, безнең илдәге балалар бакчаларында тәрбия бирүне яхшырту ихтыяҗы бар. Моның Татарстанга караганы бигрәк тә шуннан гыйбарәт: безнең республикадагы балалар бакчаларында татар балаларын туган телләренә өйрәтү мәсьәләсе, нигездә, хәл ителми. Димәк, гомумән татар телен өйрәтү һәм саклау бурычын үтәүгә зур комачаулык шушы учреждениеләрдә үк барлыкка килә.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч классларда уку яшендәге балаларны аналары өйләрендә үзләре тәрбияләсә, бигрәк тә яхшы булыр иде, әлбәттә. Алдынгы илләрдә бу шулай эшләнә дә. Аларда, ана баласын кечкенә чагында яхшылап тәрбияли алсын өчен, дәүләт аңа җитәрлек күләмдә пособие биреп тора.

Безнең илдә әлегә андый мөмкинлек юк, дәүләттә хәзергечә идарә итү системасы хөкем сөргән очракта тиз генә булмас та. Дәүләтнең моның өчен акчасы юк, дип санала. Әмма безнең ил бай һәм анда акча аз түгел, аны акыллы итеп тота белергә һәм, кирәкмәгән урынга җибәреп, әрәм-шәрәм итмәскә генә кирәк. Кечкенә балалы аналарга пособие бирү өчен генә түгел, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, фән өлкәләрендә эшләүчеләрнең яшәү һәм эшләү шартларын яхшыртуга акча табу өчен, чыганаклар бар. Европа союзы һәм Америка белән мөнәсәбәтләрне җайга салып, икътисади чолганыштан чыгу һәм җитештерүне тергезү, алга

җибәрү, дәүләт милкен урлауга, коррупциягә каршы нәтиҗәле көрәшү, налог алуның прогрессив системасын кертеп (бу башка барлык илләрдә дә диярлек шулай эшләнә), ай саен күп миллионнарча сумлап табыш ала торган кешеләр исәбенә экономия ясау, чамасыз зур дәүләт идарәсе, чиновниклар аппаратын киметү, артык күп акча алып хезмәт иткән һәм эшләгән хәрби кешеләрнең, депутатларның һәм җитәкчеләрнең хезмәт хакын, оборона чыгымнарын азайту (чамасыз нык кораллану юньлегә алып бармаячак), чит илләрдәге хәрби базаларны, гаскәрләрне бетерү, Сириядәге хәрби операцияләрдә катнашмау. Ныклабрак уйлансаң, теләк булса, дәүләт байлыгыннан үз халкың, хезмәт халкы өчен файдаланырлык башка чыганаклар да табарга була.

Мин совет чоры мәктәбендә, урта һәм югары уку йортларында белем алган һәм тәрбияләнгән, соңгы елларда вузда эшләгән кеше буларак әйтә алам: ул вакытларда балаларны, яшьләрне укыту һәм тәрбияләү, хәзергегә караганда, дөресрәк һәм нәтиҗәлерәк иде.

Соңгы чирек гасырда, мәгариф системасында, бер-бер арты реформалар ясыйбыз дип, укыту-тәрбия эшенең эчтәлегенә һәм сыйфатына зур зыян китерделәр.

Беренчедән, укыту программасыннан укучыларның тиешле аң-белем алуына, дөньяны танып белүен формалаштыруга юнәлтелгән астрономия, ботаника, дарвинизм нигезләре кебек фәннәр төшереп калдырылды.

Икенчедән, укыту процессында төп игътибар бердәм дәүләт имтиханнары бирелә торган предметларга гына юнәлтелә. Укытуның беренче максаты шушы фәннәрне генә өйрәтүгә кайтып кала. Аңлашыла ки, мондый хәл укучыларны киң эрудицияле, тулы белемле кешеләр итеп әзерләргә мөмкинлек бирми. Яшь егет һәм кызлар мәктәптән тормышка яхшы әзерлекле булып чыксыннар өчен, аларның укыту программасындагы барлык фәннәрне дә әйбәт үзләштерүләре мөһим.

Өченчедән, хәзер укыту процессында балаларны тәрбияләүгә мәгариф органнары һәм мәктәп җитәкчеләре тарафыннан игътибар кимегән һәм моның өчен аларның җаваплылыгы йомшарган. Бу элекке мәктәп программаларын, уку планнарын һәм дәреслекләрне, мәгариф органнарының уку йортларына бирелгән күрсәтмәләрен, куелган таләпләрен, аларның эшләү стилен хәзергеләр белән чагыштырганда ачык күренә.

Элегрәк булачак укытучылар, педагогика институтларында һәм университетларында белем алганда, мәктәптә нәтиҗәле тәрбия эше белән шөгыльләнерлек итеп әзерләнәләр иде. Ул студентлар, махсус тәрбия чараларын үткәрергә өйрәтелүдән тыш, үзләре укыган һәр предметның тәрбия бирерлек элементларын табып, аларны мәктәп дәресләрендә балаларны тәрбияләү өчен файдалану күнекмәләре алдылар, мәктәптә практика узганда, методистлар алардан барлык фәннәрдән дә һәр дәрестә тәрбия бурычын үтәүләрен таләп иттеләр. Һәм студентлар практикаларында, соңрак укытучы булып эшли башлагач та, дәресләрендә, тәрбия максатын куеп, аны үтәүгә ирешәләр иде. Хәзерге укытучылардан мондый эш таләп ителми. Хәлбуки, һәр предметның һәр темасында тәрбиянең кайсыдыр төренә караган күпмедер материал табарга мөмкин һәм дәрестә аннан файдаланырга кирәк тә.

Соңгы елларда мәктәпләрнең 4-5 классларында Россиянең мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган программа һәм дәреслек буенча “Дөньяви этика нигезләре” ( “Основы светской этики”) дигән предмет укытыла башлады. Бу уңай күренеш, кирәкле эш. Дәреслектә әхлак тәрбиясенең яхшылык эшләү, намуслылык,җаваплылык, гаделлек, түземле булу, миһербанлылык, гафу итә белү, ярату кебек төрләре турында башлангыч белем бирелә.

Бу предметка, аның дәреслегенә карата мондый теләкләр белдерү урынлы булыр иде. Беренчедән, анда тәрбиянең барлык әһәмиятле формалары да бәян ителми. Икенчедән, мәгълүмат түбән класс укучылары өчен катлаулы итеп бирелгән. Өченчедән, иллюстрация материалларын хәзерге тормыштан алып һәм популяррак формада бирү мәслихәт.

Татар мәктәпләре өчен бу фәннән дәреслек юк. Димәк, Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгы якын арада тәрбиянең иң әһәмиятле төрләреннән тулы мәгълүмат бирерлек, “Әхлак һәм әдәп дәресләре” кебегрәк исемдә, тормыштан алынган гыйбрәтле мисаллар белән, татарча дәреслек бастырып чыгарырга тиеш. Балаларны тәрбияләү өчен гаять әһәмиятле бу предмет татар балаларына үз телләрендә укытылырга тиеш,әлбәттә.

Хәзер яшьләрне мәктәптә тәрбияләү мәсьәләсендә борчылдырырлык, җитди уйландырырлык нәрсә шуннан гыйбарәт: соңгы бер-ике дистә елда илдә киң җәелгән базар мөнәсәбәтләре, бизнес, эшмәкәрлек, лидерлык күренешләре Россия тормышында өстенлек ала барган чорда, бу мөнәсәбәтләр, бу күренешләр яшь

буында югары әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләүгә комачаулык итә, дигән фикер белдерә кайбер укытучылар. Хәзер мәктәптә балаларның күңеленә миһербанлылык, гаделлек, намуслылык кебек гомумкешелек изге сыйфатлар сеңдерәсе, укучыларда гуманитар һөнәрләргә мәхәббәт уятасы урында күбрәк эшмәкәрлектә, бизнеста ничек уңышка ирешү мөмкинлекләре, ни рәвешле капитал туплау, сәләтләрен булдыру турында сүз алып барыла, диләр алар. Бу хәлне мәктәп тормышындагы уңай тенденция дип әйтеп булмыйдыр. Яшь буынны беренче чиратта алу-сату, табыш алу өлкәсендәге конкуренциядә җиңеп чыгу рухында түгел, бәлки җитештерү, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм фән өлкәләрендә, игелекле хезмәт итеп, югары казанышларга ирешү ихтыяҗы рухында тәрбияләргә кирәктер.

Мәктәптә һәм югары уку йортларында укучы яшьләрнең үзләрен тотышында еш күзәтелә торган ямьсез күренешләр – тупаслык, сүгенү, иҗтимагый транспортта барганда өлкән яшьтәге кешеләргә урын бирмәү кебек әдәпсезлек, дорфалык, хәмер һәм наркотик куллану, хулиганлык, әйләнә-тирәдәге милекне, табигатьне бозу, пычрату һәм башка шундый культурасызлык галәмәтләре күңелне рәнҗетә һәм борчуга сала. Бу гаиләдә дә, балалар бакчасында, мәктәптә һәм урта, югары махсус уку йортларында да тәрбия белән тиешле дәрәҗәдә шөгыльләнмиләр дигән сүз. Үзем эшләгән югары педагогика уку йорты мисалында әйтә алам: элек студентлар арасында тәрбия эше комплекслы программа буенча бит җитди һәм нәтиҗәле башкарыла иде, хәзер алай түгел.

Бүгенге яшь буынга югары әхлак тәрбиясе бирүдә зур комачаулык ясаган нәрсә – телевидениедә, интернетта тормышның тискәре якларын күпертеп күрсәткән, җинаять, әдәпсезлек күренешләре белән сугарылган кинофильмнар, тапшырулар. Кайсы гына фильмга күз салсаң да, караклык, сугышу, атышу-үтерешү. Әйтерсең, бу яшьләрне агрессивлык, урлашу, көч куллану һәм башка төрле юньсезлек юллары белән көн күрү рухында тәрбияләү өчен махсус эшләнә. Ни өчен тормышның матур якларын, кешеләрнең яхшы сыйфатларын күрсәткән, юморлы, җыр-биюле уңай тәрбия бирә торган фильмнар эшләп күрсәтмәскә?! Ни өчен Россия телевидениесе каналларында күбрәк халыкара низагларны, сугыш-тарткалашларны, һәртөрле җинаять күренешләрен пропагандалый торган, шуның өстенә, фактларны тупас бозып күрсәткән тапшырулар бирәләр?

Россия мәгълүмат чаралары безнең Татарстанлыларның фикеренә колак салмас, әлбәттә. Һич югында республикабызның тиешле җаваплы кешеләре үзебезнең радио-телевидение программаларында, матбугат материалларында мәгълүмат чараларының тәрбияви роле турында уйлансыннар иде. Безгә бу чаралар ярдәмендә халыкта, бигрәк тә балаларда һәм яшьләрдә, татарларның күп гасырлык күркәм сыйфатларын тәрбияләү максатын күздә тотып эш итәргә кирәк.

Элекке чорларда безнең әби-бабайларыбыз, ата-аналарыбыз кылган тәрбиядә объектив сәбәпләр аркасында булмаган, әмма хәзерге заманда уңышлы яшәү, нәтиҗәле эшләү өчен бик кирәкле бер сыйфат турында әйтеп китик.

Без үскәндә татар крестьяны гаиләсендә туып-үскән хөр фикерлелек, җәмгыятьтә кешеләр белән уңышлы аралашу өчен кирәкле кыюлык, үзеңне, оялмыйча иркен тота белү сыйфатын тәрбияләү җитмәде. Өйгә берәр олы кеше керүгә, без малайларны “почмак якка” (бүлмә тактасы артына) куып кертәләр, олылар сүзенә катнашу тыелган иде. Гомумән, без үскәндә тыюлар күп булды.

Нык фикерле булу, мәсьәләгә үз карашыңны, тартынмыйча, түрәләргә ошамаса да, курыкмыйча әйтә белү сыйфаты безнең хәзерге җәмгыять кешеләренең күбесенә хас түгел.

Җитәкчеләр сүзенә, ул дөрес булмаса да, һәрвакыт риза булып, аны җөпләп утыру, һәртөрле форумнарда (җыелыш, утырыш, сессия, конференцияләрдә һ.б. түрәләрнең фикерләренә һичсүзсез, уйлап та тормыйча риза булу, аларның һәр сөйләгән сүзләрен, карарларын яклап кына тавыш бирү – хәзерге заманның, дөресрәге, безнең җәмгыятьнең бәласе ул. Кешеләрдәге илебезнең артка калуына китерә торган начар сыйфаларның берсе – пассивлык, битарафлык менә шушы инде.

Туры сүзлелек, кыюлык, үз фикереңне әйтә белү, принципиальлек гадәтләрен ата-аналар балаларында кечкенәдән үк тәрбияләсен иде: мондый сыйфатлар аларга гомер буена бик кирәк булачак.

Бездә шулай ук балаларга, яшьләргә җәмгыятьтә үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен (кешеләр белән аралашу этикеты, хатын-кызлар белән мөгамәләдәге әдәп нормалары һәм башка шундый нәрсәләр) өйрәтү җитми.

Кешеләрнең табигатеннән килә, нәселеннән бирелә торган бер җитди проблема бар. Ул җәмгыять төзелешенә дә, халыкларның

үзара мөнәсәбәтенә, объектив сәбәпләргә дә карамый, бәлки кешенең холкына, асылына, шәхси дөньясына салынган эчке сыйфатына бәйле.

Сүз күп кешеләрдә хөкем сөргән хөсетлек, үз тирәсендәге кешеләрнең, хезмәттәшләренең, кайчакта хәтта бик якын кешеләренең дә уңышларын, казанышларын күрә алмау, күпсенү сыйфаты турында бара.

Көнләшү – хәзерге җәмгыятьтә киң таралаган, әшәке күренеш кешелек җәмгыятендә һәрвакыт булгандыр. Әмма ул безнең илдә соңгы берничә дистә елда аеруча нык тамыр җәйде, куркыныч төс алды.

Хөсетлек күпме кешеләрне авыруга сабыштыра, гарип итеп калдыра, хәтта үлемгә китереп җиткерә, күпме кешеләрне нахакка гаепләнүгә дучар итә, яраткан эшен ташлап китәргә мәҗбүр итә. Без мондый хәлләрне еш күреп, ишетеп торабыз.

Кеше – берәр җитәкче дип әйтик – тырышып эшләп йөри, уңышлары арта, абруе, даны күтәрелә бара. Хезмәттәшләре арасыннан кемдер яки кемнәрдер моңа тыныч кына карап тора алмый, көнләшә һәм аны пычрату юлын эзли, мәкер кора. Кайчакта аның мәкере нәтиҗәгә ирешми, фаш ителә. Ләкин һәрвакытта да алай булмый: эзәрлекләнә торган кеше юньсез(ләр) корган агулы үрмәкүч оясыннан чыгу әмәлен таба алмый, бутала, һәм хәшәрәт аның канын эчә: кешене, нинди дә булса ясалма гаеп табып, эшеннән алалар, кайчак төрмәгә дә утыртып куялар...

Монда еш кына шунысы кызык һәм кызганыч була: теге кешегә этлек эшләп йөрүчеләрнең башында, гадәттә, аңа ничә еллар мәдхия укып, ялагайланып, аның якын дуслары булып йөргән бер-ике бәндә тора. “Дустымнан сакла, ходаем, дошманымнан үзем дә сакланырмын” дигән гыйбарә дөрес ул.

Барлык кешеләр дә шулай төсләрен үзгәртә ала торган хамелеон кебек була икән дип уйларга кирәкми, әлбәттә. Әмма сарык тиресе ябынган бүреләрдән сакланырга кирәк. Данлыклы чех патриоты Юлиус Фучик: “Кешеләр, сак булыгыз!” – дип, хак сүз әйткән.

... Җитәкче эшенә ике төрле юл белән ирешәләр.

Беренчесе: теге яки бу кеше үз белгечлеге буенча намус белән, тырышып эшли, тәҗрибә туплый һәм, җитәкче урыны бушагач, аны шул урынга тәкъдим итәләр. Монысы гадел, табигый юл.

Икенчесе: кайсыдыр бер кеше хезмәт юлының башында ук җитәкче булуны яшәвенең максаты итеп куя һәм, бу максатына ирешү өчен, берни алдында да туктап калмый, бернинди чарадан да баш тартмый, зур гаделсезлек, әшәкелекләр эшләүдән дә чирканмый. Бу әйбәт юл түгел, әлбәттә.

Безнең арада да яши андый кешеләр. Андый кеше башта, җитәкчесенең ышанычын аклау өчен, бик тырыша, максатына ирешү өчен, барлык мөмкинлекләрен дә эшкә җигә, үзен түбәнсетүдән дә, шефын күккә чөеп мактаудан, аңа яхшы атлы булып кыланудан да тартынып тормый. Һәм тиздән, үзенең башта ук куйган максатына ирешү өчен, үзе ялагайланып йөргән җитәкчесенә яла ягып, башкаларны котыртып һәм башка төрле җүнсезлекләр эшләп, аны урыныннан төртеп төшерә һәм аның урынына үзе менеп утыра. Соңыннан исә аны, җае чыкса, таптап та китәргә мөмкин.

Хәзерге безнең илдәге кыргый капитализм чорында андый кешеләр шактый күп, һәм аларның саны арта бара. Аңлашыла ки, мондый төр кешеләрдән сак булырга, аларны вакытында күрә белергә өйрәнү һәм моңа балаларыңны, якыннарыңны да өйрәтү зарур.

Безнең илдә, гомумән, эшлекле, төпле акыллы һәм бай тәҗрибәле кешеләрнең кадерен белү һәм алардан нәтиҗәле файдалана белү җитми. Кадрлар сәясәтендә ялгышлар күп, һәм шуның аркасында Россия, шул исәптән Татарстан да, тиешенчә уңышлы алга бара алмый.

Әһәмиятле урыннардагы җитәкчеләрне иң лаеклы кешеләр арасыннан сайлап алып түгел, бәлки барыннан да бигрәк танышбелешлек, туган-тумачалык принцибына нигезләнеп билгеләп куялар. Безнең республикада үзебездә җитди җитәкчеләр булып эшләрлек, үз халкына зур файда китерерлек берничә лаеклы кеше читкә китеп барырга мәҗбүр булды. Шул ук вакытта кайбер җаваплы урыннарда эшлеклелек сыйфатлары буенча биләгән урыннарына туры килми торган кешеләр утыра.

Кадрлар сайлап алуда мондый сәясәт дәвам иткәндә, безнең илнең уңышлары зур булмаячак. Совет чорында кулланылышта булган "Бар нәрсәне дә кадрлар хәл итә" дигән лозунгны хәзер "Кадрлар лаеклы булганда гына, бар нәрсә дә уңышлы хәл ителә" дип, үзгәртеп кулланырга кирәктер.

## ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ

Әле берничә дистә ел гына элек барлык уку йортларында да хезмәт тәрбиясенә, ягъни балаларны, яшьләрне эшкә, бигрәк тә физик эшләргә, кул көче һәм осталыгы белән башкарыла торган, көндәлек тормыш өчен иң кирәкле һөнәрләргә өйрәтүгә зур игътибар бирелә иде.

Хезмәт күнекмәләре, беренчедән, мәктәпләрдә күп еллар махсус хезмәт дәресләре рәвешендә бирелеп килде. Бу дәресләрдә малайлар яшәүләре өчен кирәкле техник һөнәрләр – слесарь, токарь, фрезеровщик, столярлык эшләрен, автомобиль, трактор кебек машиналар төзелешен һәм аларны эшләтү, йөртү кагыйдәләрен үзләштерәләр, кызлар исә йорт-җир, гаилә өчен әһәмиятле эш төрләренә – тегү-чигү, аш-су әзерләү кебек хезмәтләргә өйрәнәләр иде. Шуның өстенә, авыл укучылары, ял, каникул вакытларында мәктәпкә бүлеп бирелгән җир участокларында яшелчә, җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнеп, кыр эшләре кызу вакытта колхоз-совхозларга булышып, физик эш күнекмәләре алдылар. Хезмәтләре өчен аларга азмы-күпме акчалата яки матди түләү дә каралган иде.

Урта һәм югары махсус уку йортларында укучылар шулай ук авыл хуҗалыгына, промышленность предприятиеләренә, төзелеш оешмаларына булышып, уку биналарында, тулай торакларда үз-үзләренә җыештыру, чистарту, төзекләндерү кебек хезмәт күрсәтеп килделәр. Һәм бу акыллы, дөрес уйланылган хезмәт тәрбиясе иде.Ләкин узган гасырның 80 нче еллары азагыннан, ил хуҗалыгының барлык тармакларында башланган үзгәртеп корулар (аларны таркату, сүтү дип атау дөресрәк булыр иде) шаукымына ияреп, мәгариф өлкәсендә дә төрле мөгез чыгарулар, бөтенләй кирәкмәгән, төптән уйланылмаган үзгәртүләр башланды. Шул исәптән уку йортларындагы вакыт сынавын узган тәрбия системасын да боздылар. Нәтиҗәдә хәзер инде физик хезмәткә күнекмәгән, бик кирәкле гади кул эшләренә йөз чөереп карый торган яшьләр үсеп җитте. Безнең тормышта бер чиктән икенче чиккә ташланулар еш булып тора: бүген мәктәптә укучыга, кулына чүпрәк тоттырып, берәр җирне сөртеп алырга кушсалар да, кайбер ата-аналар җәнҗал куптара.

Хәзерге мәктәп программасында элеккеге кебек хезмәт дәресләре юк, аны технология дәресләре белән алыштырганнар.

Тик анда физик хезмәт, көндәлек тормыш өчен кирәкле һөнәрләргә өйрәтмиләр, информатиканы үзләштерү белән шөгыльләнәләр.

Балаларга, яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирү – хәзерге заманның җитди проблемаларыннан берсе, һәм ул бөтен тәрбия эшенең бик әһәмиятле өлешен тәшкил итә. Дәүләт, комплекслы тәрбия планын төзегәндә, яшь буынны хезмәткә күнектерү ихтыяҗын гамәлгә ашыруның конкрет юлларын, ысулларын билгеләүгә аеруча зур игътибар итәргә тиеш. Җәмгыятьнең киләчәк уңышы хәзерге буынга алмашка килгән яшьләрнең хезмәт итәргә ни дәрәҗәдә әзерлекле булуына бәйле.

Дөньядагы матди һәм рухи хәзинәләр, байлыклар кешеләрнең физик һәм акыл хезмәтләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Димәк, хезмәтнең бу ике төре дә мөһим, һәм яшь буынны аларның икесен дә башкарырлык итеп әзерләү бурычы тора. Яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирү проблемасы турында сөйләгәндә, барыннан да бигрәк аларны физик хезмәткә, кул көче белән башкарыла торган эшләргә, ягъни һәр төрле һөнәр иясенә дә гомере буенча кирәкле көнкүреш эшләренә әзерләү ихтыяҗы күздә тотылырга тиеш.

Балаларны, яшьләрне максатлы рәвештә физик хезмәткә күнектерү, өйрәтүнең аеруча әһәмиятле булуы менә нәрсә белән аңлатыла.

Беренчедән, яшь организмның сәламәт булып җитлегүе өчен, аңа уртача авырлыктагы физик көч түгү, ягъни физик киеренкелеккә дучар булу, икенче төрле әйткәндә, физик эш белән шөгыльләнү кирәк.

Икенчедән, хәзерге фән, техника алга киткән заманда кешенең уңышлы яшәве ихтыяҗларын торган саен күбрәк техника-автоматика җиһазлары, приборлар башкара, димәк, мускул көче белән эшләнә торган эшләрнең саны көннән-көн кими бара. Бу исә, аңлашыла ки, яшьләрнең физиологик яктан нык, камил булып формалашуына тискәре йогынты ясый. Физик хезмәт белән шөгыльләнмәү яшьләр организмына гына түгел, олы кешеләрнең дә нормаль физиологик халәте өчен заралы.

Җир сөреп, иген игеп, мал-туар асрап, мичкә утын ягып, өйгә чишмәдән су ташып яшәгән крестьяннарның кечкенәдән үк йорт эшләренә булышып үскән балалары физик тәрбияне табигый шартларда җитәрлек алалар, шунлыктан алар авырлыкларга да чыдамрак, физик яктан ныграк, эшкә әрсезрәк булалар. Һәм кечкенәдән үк көнкүреш өчен кирәкле төрле һөнәрләрне үзләштерәләр.

Үзәкләштерелгән җылытулы, кайнар һәм салкын су килеп тора торган йортларда яшәп, азык-төлекне кибетләрдән генә алып кайтып ашап көн күрүче шәһәр һәм поселок кешеләренең балаларына физик тәрбия бирү мөмкинлекләре бик аз, әлбәттә. Шуңа күрә шәһәр балалары, гадәттә, гомумән алганда, физиологик яктан авыл балаларына караганда, йомшаграк, физик авырлыкларга тизрәк бирешә торган булалар. Күп егетләрнең сәламәтлекләре буенча армия сафларында хезмәт итәргә яраксыз дип табылуы да шактый дәрәҗәдә аларның вакытында тиешле хезмәт күнегүләре һәм физик тәрбия алмаган булулары белән аңлатыладыр.

Соңгы елларда, кеше тормышына ташкын булып интернет килеп керү аркасында, балалар да, яшь егет һәм кызлар да тулысынча компьютер әсирлегенә төшеп бетә баралар, кайбер балалар һәм яшьләр көннәр-төннәр буена экран каршыннан китми. Бу хәлнең аларның психикасына һәм физик халәтенә зур зыян китерүе бәхәссез.

Шушы хәлне исәпкә алып, мәгариф органнарының, мәктәпләрнең җитәкчеләренә, ата-аналарның, укытучыларның акылын, көчен туплап, балаларга хезмәт тәрбиясе бирүнең нәтиҗәле юлларын табарга, бәрәкәтле чаралар күрергә туры килә.

Беренчедән, матбугат, радио-телевидение чараларын җәлеп итеп, ата-аналарга балаларына хезмәт тәрбиясе һәм гомумән тәрбия бирү белән максатчан, нәтиҗәле шөгыльләнергә кирәклекне төшендерү мөһим. Моның өчен гаиләдә малайларга да, кызларга да йорт һәм өй тирәсе эшләре (өйне җыештыру, кер юу, ашарга әзерләү, савыт-саба юу, тегү-чигү эшләре, кибеттән азык-төлек алып кайту, кар көрәү, утын кисү, утын яру һ.б.), бакча эшләре бар. Бу мәсьәләдә ата-аналарның күбесендә балаларына, авырлык килер дип куркып, эш кушмау, аларны артык иркәләү тенденциясе хөкем сөрә. Бу ялгыш караш. Эшләп кеше үлми дигән әйтем бар, артык авыр эш булмаганда, әлбәттә. Киресенчә, бары хезмәткә күнегеп, физик эшкә өйрәнеп үскән балалар һәм яшьләр генә чын кешеләр булып формалаша. Бу аксиома.

Мәктәпләрдә, кичекмичә укыту-өйрәтү программасына хезмәт дәресләре кертеп, укучыларны уңышлы яшәү өчен һәрвакыт кирәкле берничә һөнәргә өйрәтергә кирәк.

Җирле хакимият иярәре мәктәпләргә күпмедер күләмдә җир участоклары биреп, яз-җәй, көз көннәрендә укучыларны билгеле

бер вакыт шунда яшелчә, җиләк-җимеш үстерү эшләрендә эшләтү тәртибе кертелсен иде. Моның файдасы зур булачагы бәхәссез.

Тагын бер җитди проблема – югары классларда укучыларны җәйге каникул вакытында түләүле эш белән тәэмин итү. Авыл җирендә моның авырлыгы юк: анда эш күп – кырда, фермада, яшелчә, җиләк-җимеш бакчасында һ.б. Бу эшне оештыру авыл һәм мәктәп җитәкчеләре өстенә төшә. Хәер, авыл балаларының шәхси хуҗалыкларында да эш җитәрлек була. Тик монда ата-аналарның балаларына йорт, хуҗалык эшләрен эшләткәндә педагогик такт һәм чама хисен онытмаулары мөһим.

Шәһәр шартларында укучыларга җәйге каникул вакытында эш табу кыенгарак туры килә, әлбәттә. Ләкин бик тырышсаң, моның да чарасын күрергә мөмкин. Шәһәрдәге предприятиеләрдә вакытлыча мәктәп укучылары өчен ниндидер бик катлаулы булмаган җитештерү цехлары ачарга була. Шәһәрне яшелләндерү оешмаларында, почта бүлекләрендә, сәүдә предприятиеләрендә югары класс укучылары башкарырлык эшләр булырга мөмкин. Шәһәр хакимияте әһелләренә мәгариф министрлыгы һәм шәһәр, район мәгариф бүлекләре җитәкчеләре белән бергәләп хәл итәлергә тиешле үтә әһәмиятле мәсьәлә бу. Мәктәп балалары каникул вакытларында үзләре генә калырга тиеш түгел: яки берәр төрле эш белән мәшгуль булсыннар, яки мәктәп янындагы, шәһәрдән читтәге лагерьларда булсыннар (анда да олырак яшьтәге балалар ял итеп кенә ятмасын, һәр көнне берникадәр нинди дә булса файдалы эш башкарсын).

## ЭСТЕТИК ТӘРБИЯ

Укучыларга эстетик тәрбия бирү мәсьәләсенә килгәндә, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләренә шуны искәртү мәгъкуль булыр: татар мәктәпләренең укыту программаларындагы музыка дәресләренә бирелгән вакытның бик азы гына татар музыкасы белән таныштыруга файдаланыла. Бу һич кенә дә риза булырлык хәл түгел. Бәхәссез: программада каралган сәгатьләрнең күпчелеге татар музыкасын өйрәнү өчен булырга тиеш. Татарстандагы татар балалары үз халкының музыкасын мөмкин булганча тулы итеп үзләштерергә хаклы. Халык музыкасы, халык көйләре – туган тел кебек үк, милләтнең рухын, җанын тәшкил итә торган

иң әһәмиятле нәрсәләрнең берсе, һәм аны яшь буынга өйрәтү, аңа мәхәббәт тәрбияләү – республика мәгарифенең изге бурычы.

Мәктәптә балаларны музыка белән генә түгел, сәнгатьнең башка төрләре белән дә кызыксындыру, мавыктыру – игелекле эш. Шуңа күрә эстетик тәрбия биру өчен, класстан тыш сәгатьләрдән файдалану да уңай нәтиҗә бирер иде. Сәнгать балаларның, яшьләрнең күңелләрен савыктыра, сафландыра. Аны яраткан кеше, гадәттә, әшәке гамәлләр кылмый.

Татарстанда яшьләрне дә, олыларны да эстетик тәрбияләүгә караган бер җитди проблема шуннан гыйбарәт. Безнең татар эстрадасы җырчыларының да һәм татар тамашачыларының да шактый өлешенең эстетик зәвыгы дәрәҗәсен күтәрү ихтыяҗы бар. Бу хакта матбугатта да язылып тора: ил гизеп йөргән күп санлы концерт төркемнәрендә катнашкан татар артистларының (аларның артистлыклары ни дәрәҗәдәдер?!) җырлау осталыгы, үз-үзләрен тотышлары, кием-салымнары, җырларының мәгънәсе, дөресрәге мәгънәсезлеге, көйләренең күңелгә ятышлылыгы дәрәҗәсе чын сәнгатьне аңлый торган тамашачыда канәгатьсезлек тудыра. Түбән сыйфатлы җырчыларны тыңларга һәм карарга йөргән тамашачыларның эстетик зәвыгы һәм таләпләре дә тиешле югарылыкта түгелдер, күрәсең, дигән нәтиҗәгә киләсең.

“Курай”, “Татар радиосы”ннан, өлешчә “Болгар” радиосыннан көн-төн тапшырыла торган, хәзерге буа буарлык сандагы көй чыгаручылар, такмак язучылар тарафыннан иҗат ителгән җырларны тыңлап торсаң гарьләнәсең: шушымы инде безнең музыкабыз, хәзерге музыка сәнгате кая бара һәм кая барып җитәр, дип уйлыйсың.

Начар сыйфатлы җырлар тыңлаучыда, тамашачыда түбән зәвык, дөресрәге, зәвыксызлык тәрбияли. Һәм, икенче яктан, шул сыйфатсыз концертларга халыкның йөрүе, талымсызлыгы зәвыксыз чыгыш ясаучы артистларны дәртләндереп, илһамландырып тора.

Мәдәният министрлыгы бу хакта уйлансын һәм татар эстрадасының, радио-телевидениесенең түбән сыйфатлы, зәвыксыз чыгышлары белән татар культурасының дәрәҗәсен төшерүен туктату өчен чаралар күрсен, рухи азыгыбызның пычрануына юл куймасын иде.

Мин үзебезнең театр сәнгатенә һөнәри бәя бирергә батырчылык итмим: бу үзенчәлекле, катлаулы өлкә. Шулай да берике генә шәхси фикеремне әйтми кала алмыйм. Безнең татар

спектакльләрендә уйнаучыларга тавышны артык күтәреп, кычкырып сөйләү, кайчак кирәкмәгән шау-шу чыгару хас кебек. Һәрхәлдә миңа шулай тоела. Аннан килеп, сәхнәдә декорацияләр артык гади, күңелсезрәк. Күрәсең, акча җитми торгандыр.

Пьесаларның эчтәлегенә килгәндә, хәзерге тормышның катлаулы, авыр, актуаль яклары, гаделсезлек күренешләре, милләт, тел, мәдәният мәсьәләләре яктыртылган сәхнә әсәрләре юк диярлек. Театрда хәзерге тормыш проблемалары да күрсәтелсен, драматурглар кыюрак һәм активрак булсын иде.

## ПАТРИОТЛЫК ТӘРБИЯСЕ

Россиядә патриотлык тәрбиясенә зур игътибар бирелә. Яшьләргә мондый тәрбия бирү өчен, дәүләт күп миллионлаган, миллиардлаган сум акча сарыф итә. Шуңа да карамастан, бу мәсьәләдә һәр очракта да тиешле нәтиҗәгә ирешелми. Мәсәлән, күренекле армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең әйтүенә караганда, бүгенге көндә безнең илдә 200 меңләп егет, төрле сылтаулар табып, армия хезмәтеннән качып йөри икән.

Әмма хәзерге вакытта милләт җанлы кешеләрне борчый торган проблемаларның берсе ул – татар халкы патриотлыгы, икенче төрле әйткәндә, татарларның милли рухы, милли горурлыгы мәсьәләсе.

Хикмәт шунда: соңгы елларда Россия хакимиятенең милли сәясәт үткәрүдә уйланылмаган адымнар ясавы, халыкларның ирекле үсүенә, алга баруына комачаулый торган карарлар кабул итүе нәтиҗәсендә, кайчандыр үзенең дәүләте булган, бай тарихлы, югары культуралы татар халкының телен саклау, өйрәнү һәм үстерү кыенлаша бара. Бу турыда тулырак итеп алдагы бүлекләрдә сөйләнер. Билгеле бер объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында үз телендә сөйләүче татарларның саны кими бара, шулай ук татар мәктәпләренең шактые оптимизация сылтавы белән ябыла, татар мәктәпләрендә – шәһәрдә дә, авылда да – русча укытуга күчә баралар. Бу татар теле һәм, димәк, татар халкының үзе өчен дә җитди драматик күренеш. Монда иң үкенечле һәм куркыныч хәл шул: балаларын үз телендә укыта торган мәктәпкә бирүдән баш тарткан ата-аналар күбәя бара. Бу, әлбәттә, гаять катлаулы, четерекле проблема. Ата-аналарны бу проблемада көчләргә ярамый: алар закон буенча балаларын үзләре теләгән телдә укытырга һәм

тәрбияләргә хаклы. Проблеманы, беренчедән, татар мәктәпләренең эшен, укытуның сыйфатын яхшыртып, абруен күтәреп, икенчедән, ата-аналар белән идеология, тәрбия эше үткәреп, милли мәсьәләдә аларның психологиясенә уңай йогынты ясап, төгәлрәк итеп әйткәндә, аларның үзләрендә һәм балаларында милли горурлык, милли патриотлык хисләре тәрбияләп кенә хәл итәргә мөмкин.

Ата-аналарда һәм балаларда гына түгел, гомумән барлык татар кешеләрендә милли горурлык тәрбияләү – хәзерге вакытта иң әһәмиятле эш. Татар халкының киләчәктә алдынгы милләт буларак яшәве шактый дәрәҗәдә менә шушы изге бурычның үтәлүенә бәйләнгән. Мәсьәләнең тамыры шунда: безнең татарларның психологиясендә күп гасырлар дәвам итеп килгән империячел социаль-тарихи шартларда, патша хакимияте изүендә, рус шовинизмы мохитендә яшәү нәтиҗәсендә үзен түбәнсетеп, кимсетеп тою рухы тәрбияләнгән. Шушы рух өлкән һәм урта буын кешеләрендә үзен бүген дә сиздерә. Кайберәүләрнең, бигрәк тә балаларның, яшьләрнең, мин татар дип, күкрәк кагып әйтергә тартынып торулары, татарларның руслар белән чагыштырганда, үзләрен түбәнрәк дәрәҗәле, ягъни “икенче сортлы” кешеләр итеп тоюлары – ерак әби-бабайларыннан ук күчеп килгән яман чир.

Бәлки, минем болай кимсенү, түбәнсенү турындагы фикерем ялгыштыр. Ялгышсам, әйбәт булыр. Әмма бездә, татарларда, гомумән алганда милли горурлык, милли патриотлык җитмәвенә иманым камил. Моны расларлык күп дәлилләр китерергә мөмкин.

Ничек тәрбияләргә икән соң бу милли горурлык хисләрен безнең халыкта? Моның нинди юллары бар? Мин бу гаять мөһим бурычны гамәлгә ашыруны болайрак күз алдына китерәм.

Беренчедән, бу төшенчәне совет чорында хаксыз тискәре мәгънәдә кулланылган милләтчелеккә тиңләштерергә кирәкми. Милләтчелек ул – үз милләтеңне кайгырту, хөрмәтләү, ярату, кадерләү дигән сүз. Милли горурлык исә, исеменнән үк күренгәнчә, үз халкыңның, милләтеңнең лаеклы булуын, башкалардан берьяктан да һич кенә дә ким булмавын тою, аның зур тарихы, бай культурасы, горурланырлык казанышлары, күркәм сыйфатлары булуын белеп, канәгатьләнеп, шатланып яшәү.

Милләтчелек, милли горурлык төшенчәләре һич кенә дә, үз халкыңны өстен куеп, башкаларны түбәнсетү, кимсетүне күздә тотмый. Үз милләтеңне башкалардан югары кую, калганнарның

үсешенә, прогрессына юл бирмичә, аларны басып тоту – колониаль дәүләттә хакимлек иткән халык сыйфатын чагылдыра торган шовинизм. Бу төшенчә совет власте елларында *бөек рус халкы, бөек рус теле, олы туган* кебек исемнәр белән шактый нык кулланылышта булды. Бу күренеш соңгы елларда безнең илдә, яңадан җанланып, көчәя бара. *“Россия руслар өчен”, “Дәүләт оештыручы халык ул – руслар”, “Рус теле – Россиядәге барлык халыклар өчен туган тел дәрәҗәсендә”* кебек лозунглар көннән-көн күбрәк ишетелә. Православие динен чамасыз артык пропагандалау, милли мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарын рус телендә алу, милли телләрне уку планнарына кертеп укытуны тыю һәм үзәк властьларның башка шундый логикага туры килми торган гамәлләрен шовинизм чагылышы дип бәяләми мөмкин түгел.

Менә шуңа күрә дә безгә милли мәнфәгатьләребезне тагын да ныграк кайгыртырга туры килә, менә шуңа күрә дә җитди рәвештә халкыбызда милли горурлык хисләре тәрбияләү мәсьәләсе килеп баса.

Уңышлы, бәхетле яшәешебез өчен зур әһәмиятле бу милли патриотлык хисләрен тәрбияләү гомуми тәрбия эшенең мөһим өлешен тәшкил итәргә тиеш. Бу эш күп төрле җитди чаралардан гыйбарәт. Мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында Татарстан һәм татарлар тарихын, шулай ук аларның культуралары тарихын укыту, бу тарихи материалларны популяр формада мәгълүмат чараларында – матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында яктырту, татар халкының һәм республикада яшәүче башка милләт вәкилләре тормышының төрле өлкәләрендәге – мәдәнияттәге, сәнгатьтә, әдәбиятта, фәндә, спортта, хәрби өлкәдәге һ.б. зур казанышларын, хезмәттәге, фронттагы батырлыкларын пропагандалау зарур. Бу изге эштәге төп бурыч – татарларның бай тарихлы, югары мәдәниятле, тәрбияле, әхлаклы, тырыш, хезмәт сөючән, максатчан, белем алуга омтылышлы халык булуын балаларның да, яшьләр һәм олыларның да зиһененә сеңдерү.

Халык үзенең тарихын белергә тиеш. Бу аксиома. Бу шартны гамәлгә ашыру өчен нинди чаралар күрергә кирәк?

Татар халкының үткәнен гади тел белән, гади халык аңларлык (популяр) итеп сурәтләгән җыйнак тарих китаплары кирәк. Шөкер, соңгы елларда Татарстан фәннәр академиясенең тарих институты җентекләп язылган, зур күләмле тарих китаплары чыгарды. Бу әйбәт. Әмма алар махсус аудитория өчен язылган катлаулы, фәнни

әдәбият. Болардан тыш, әле әйтелгәнчә, кечерәк күләмле популяр китаплар да кирәк. Аларның бәяләре арзан, тиражлары зур булырга тиеш, һәм аларны, халык кызыксынып укырлык итеп пропагандалау, рекламалау юллары да уйланылган булсын.

Аннары, шул китапларга нигезләнеп, сәнгатьле итеп, тарихыбызга багышланган телевидение һәм радио тапшырулары(махсус рубрикалар белән), документаль фильмнар эшләп, аларны халыкка ирештерү бурычы куелырга тиеш. Мондый тапшыруларга һичшиксез И.Р.Таһиров, Р.С.Хәкимов, Ф.Ш.Хуҗин, Д.М.Исхаков кебек күренекле тарих галимнәренең чыгышлары да керер дип фараз итәргә кирәк.

Халкыбызның объектив тарихын популяр формада мәктәп укучыларына җиткерү бурычы да көн үзәгендә торыр дип уйлыйсы килә.

Халыкка аның чын, дөрес тарихын нәтиҗәле итеп өйрәтү максатына ирешү өчен башка төрле чаралар да бар, әлбәттә. Мәсәлән, кызыксынган кешеләр өчен Татарстанның, татарларның тарихын яктыртуга багышланган лекторийлар, шәһәр, район аудиторияләрендә зур галимнәр белән очрашулар оештырырга мөмкин.

Мондый чараларны үткәрү реаль. Алар артык зур финанс чыгымнары таләп итми, һәм безнең республикада моның өчен тиешле фәнни һәм иҗади мөмкинлекләр җитәрлек.

Балаларны, яшүсмерләрне халкыбызның бай мәдәни хәзинәсе, югары әхлак нормалары, матур гореф-гадәтләре белән таныштыру, аларны шундый рухи мирас үрнәкләрендә тәрбияләү бурычы хөкүмәтнең бөтен гуманитар эшенең, аерым алганда, махсус тәрбия, мәдәният, мәгариф, фән өлкәләрендәге эшләренең эчтәлегенә салынган булырга тиеш.

Халыкны татарларның җитештерүдә, фән, мәдәният, спортта, илне саклауда һәм башка өлкәләрдә зур казанышлар яулаган аеруча абруйлы кешеләре белән таныштыру, аларны калку, матур, күтәренке итеп күрсәтү милли горурлык тәрбияләүнең бик әһәмиятле өлешен тәшкил итә. Кызыклы, үрнәк тормыш юлы узган күркәм кешеләрне үтемле, тәэсирле чаралар ярдәмендә пропагандалау татар халкының үзләрен бөек милләт дип йөргән башкалардан һич кенә дә ким кешеләр түгел, лаеклы милләт икәнлеген раслау өчен нәтиҗәле чара булачак.

Безнең мәшһүр кешеләребез бик күп. Алар тормышның бөтен өлкәләрендә дә бар. Дөньякүләм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани, зур дин галиме Габделнасыйр Курсави, бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри, хәзерге заманның бөтен дөньяга мәгълүм галимнәре Роальд Сәгъдиев, Камил Вәлиев, Роберт Нигъмәтуллин, Рәшит Сүнәев һәм башкалар, бөек шагыйребез Габдулла Тукай, күренекле язучыларыбыз Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники, Аяз Гыйлаҗев, Габдрахман Әпсәләмов, Таҗи Гыйззәт, Кәрим Тинчурин, бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшев, ил күләмендә дан казанган Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, бөтен дөньяга мәгълүм Софья Гобәйдуллина, дөнья сәхнәләрен гөрләткән опера йолдызлары Альбина Шаһиморатова, Аида Гарифуллина, спорт батырлары: теннисчы Марат Сафин, Динара Сафина, олимпия чемпионнары Ләйсән Үтәшева, Алинә Кабаева, гроссмейстр шахматчылар Гата Камский, Алисә Галләмова, хәрби начальниклар: армия генераллары Мәхмүт Гәрәев, Рәшит Нургалиев, Бөек Ватан сугышы чорындагы бөтен совет армиясе штабы начальнигы армия генералы Антонов, өч йөздән артык Советлар Союзы геройлары, күп кенә Социалистик Хезмәт геройлары, космонавтлар отрядында әзерләнеп, үкенечле хәлләр аркасында гына космоска китә алмый калган батырлар да бар татарлардан.

Безнең каһарман шәхесләребез бөтен Россиягә, дөньяга сибелгән. Аларның бик күбесен халык белми. Мәсәлән, Кытай халык республикасы председателе Мао Цзе Дун хөкүмәтендә иң югары постларның берсен биләгән Буа районында туып үскән якташыбыз Борһан Шаһиди үзе генә дә ни тора!

Татар халкы үзенең бөек улларын һәм кызларын белсен, аларны сакласын һәм алар белән горурлансын өчен, Татарстан хөкүмәте бу мәсьәләдә бер система буенча махсус чаралар күрсен иде. Бөтен дөньяга таралган андый шәхесләрне барларга, алар турында мәгълүмат тупларга һәм аннары аларны, әйтеп киткән ысуллар белән кичекмичә халыкка җиткерү эшенә керешү зарур.

Хәзерге техника, интернет алга киткән заманда моны эшләү авыр түгел, һәм ул артык зур чыгымнар да таләп итмәячәк. Бу бик тә кирәкле, изге эш. Моның бер генә мисалын китерим.

Моннан берничә ел элек Татарстанның фәннәр академиясе шушы юнәлештә бер әһәмиятле адым ясады – Россиядәге, чит илләрдәге күренекле татар галимнәрен җыеп, конгресс уздырды. Миңа ул чакта, Татарстан фәннәр академиясенең вице-президен-

ты буларак, бу эшне оештыруда һәм башкаруда актив катнашырга туры килгән иде. Мин анда җыелган моңарчы без белмәгән күп кенә зур галимнәрне, күренекле шәхесләрне күреп гаҗәпләндем дә, шатландым да. Әлбәттә, без анда элекке СССРның, чит илләрнең төрле җирләрендә яшәп иҗат иткән күркәм затларның барысын да чакырып, җыеп бетерә алмадык әле. Ләкин килгән кадәресе дә сокландырырлык иде.

Менә шундый һәм башка төрле тиешле чаралар күреп, халыкның аңында уңай үзгәрешләр барлыкка китереп, күңелендә һич югында берникадәр дәрәҗәдә генә булса да милли горурлык тәрбияләүгә ирешсәң, бу киләчәктә татар халкын, аның мәдәниятен һәм телен саклап калуның ышанычлы нигезе булыр иде. Әмма безнең Татарстан җитәкчеләре бу турыда уйламаса, татар халкын саклап алга җибәрүне үзләренең изге бурычлары дип санамаса, Мәскәү әйткәнне генә тыңлап эш итсәләр, татар милләтенең, үз дәрәҗәсен саклап, лаеклылар сафында алга барачагына шикләнеп карарга туры килә.

Менә бу әле сүз алып барган милли горурлык хисләрен халыкка, бигрәк тә яшь буынга сеңдереп булса, безнең татар кешеләрендә үз туган теленә кадерләп, яратып карау сәләтен дә тәрбияләп булыр иде. Ихтимал, күп кенә урта буын кешеләрен, ата-аналарны “нәрсәгә ул татар теле?” дигән караштан арындырып булыр иде. Балаларда, яшьләрдә дә туган телләрен өйрәнү, белү теләге, аңа хөрмәт белән карау хисләре тәрбияләү мөмкин булыр, бәлки. Бүгенге көндә президентның да, премьер-министрның да, башка дәүләт җитәкчеләренең дә изге бурычы – һәр татар кешесенә, бигрәк тә ата-аналарга һәм алар аша, мәктәп көче белән балаларга “Туган тел ул – атаң-анаң, туган җирең, ватаның кебек үк кадерле нәрсә һәм шуңа күрә аны белү һәркем өчен фарыз” дигән хакыйкатьне төшендерү, телебезне саклап үстерү өчен кулдан килерлек барлык чараларны да күрү. Үз халкыннан йөз чөермәгән һәркемдә телебез бетсә, без үзебез дә халык, милләт булып яшәүдән туктаячакбыз дигән фикер хөкем сөрергә тиеш.

Үзәк хакимият милли горурлык, туган халкыңа, телеңә хөрмәт тәрбияләү белән шөгыльләнгән кешеләрне милләтчелектә гаепләр, дип куркырга кирәкми. Милләтчелек – үз милләтеңне ярату, хөрмәт итү һәр кешегә хас сыйфат булырга тиеш. Үз милләтен хөрмәт итмәгән кеше нинди кеше була ул? Аны чын кеше дип атап

буламы икән?! Бу бит атаң-анаңны, туган җиреңне чит, ят итү, аннан ваз кичү белән бер.

Милләтчелек хисе, үз милләтеңне хөрмәт итеп, аны саклау, алга җибәрү, прогресска илтү теләге, кирәк булганда, шуның өчен үзеңне аямау, көчеңне сарыф итү башка милләт халыкларына, аларның телләренә, мәдәниятләренә, гореф-гадәтләренә, диннәренә каршы булу, аларны өнәмәү дигән сүз түгел. Башка халыкларга хөрмәт белән карау, дустанә мөнәсәбәттә булу – һәр тәрбияле кешенең әһәмиятле сыйфатларыннан берсе. Үзенекеннән бүтән милләтләргә кырын карау, аларны кимсетү, җәберләү – тәрбиясез, юньсез кешегә хас сыйфат.

Татарлар гасырлар буена башка халыклар белән тату яшәгәннәр, хәзер дә шулай яшиләр һәм моннан соң да шулай яшәрләр. Әмма хәзер алар зур, хәлиткеч сынау алдында торалар – үзләренең йөзләрен, ягъни үз милләтен, аның телен, мәдәниятен саклап кала алырлармы һәм күпмегә кадәр саклап тора алырлар? Бу беренче чиратта аларның (безнең) үзләреннән (үзебездән) тора. Татарстан дәүләте җитәкчеләре, милли җанлы кешеләр булсалар, бу мәсьәләнең уңай хәл ителүенә ярдәм дә итә алалар, битараф булып калып, тоткарлык та ясый алалар. Бу аларның вөҗданына һәм тәрбиялелеге дәрәҗәсенә бәйләнгән.

Язмамның туган тел язмышына кагылышлы өлешен дөнья күләмендәге зур галим академик Р.И.Нигъмәтулинның бу мәсьәләгә караган искәрмәсе һәм тәкъдимнәре белән тәмамлыйсым килә.

“Шәһәрләрдә яшәүче башкортлар белән татарларның үз телләрен начар белүләре – бик начар күренеш”, – ди Роберт Искәндәрович. Һәм ул һичшиксез хаклы.

*“Татарстанда һәм Башкортстанда, шулай ук Россиянең башка республикаларында да татар, башкорт һәм илебездәге башка телләрнең үсеше өчен шартлар булдырырга кирәк һәм милли телләрдә укытыла торган мәктәпләрнең кубәюенә һич кенә дә борчылырга ярамый, – ди ул. – Кешеләрнең милли телләрен өйрәнүләренә ярдәм итеп торырга кирәк. Этнослар (милләтләр) арасындагы татулыкның нигезе – “Һәрбер тел ул – рухи бүләк” дигән хакыйкатьне аңлауда. Аз санлы халыкларның телләренә гамәлдә булып калу авыр, ләкин алар сакланып калсын өчен, кулыңнан килерлек бар нәрсәне дә эшләргә кирәк. Россия Федерациясендәге барлык телләрнең дә дәүләт күләмендәге әһәмияте һәм илдәге*

*этникара гармониянең, интеллектуаль көчнең мөһим нигезе менә шушыннан гыйбарәт".*

Үзе дә рус, татар, башкорт, инглиз телләрен бик яхшы белгән һәм барлык халыкларга да зур хөрмәт белән караган бу олуг галим милли телләрнең кыйммәтле рухи мирас икәнлеген, әлбәттә, бик дөрес аңлый.

Һичшиксез, милли патриотлык, горурлык тәрбияләү эше нык уйлап, саклык белән, башка милләт вәкилләренең күңелләренә тимәслек, аларның да милли горурлык хисләренә кагылмаслык итеп, халыклар дуслыгын саклау һәм ныгыту шартларында башкарылырга тиеш. Бу эштә төп принцип шул: барлык милләт халыклары да – күп яки аз санлы булуларына карамастан – тигез хокуклы, сан ягыннан иң кечкенә, хәтта берничә йөз генә исәпләнгән халыклар да, җәмгыятьнең лаеклы әгъзалары булып, үз телләрен, мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү өчен тырышып яшәргә хаклы. Татарларның башка халыклар белән дусларча хезмәттәшлек итеп яшәү тәҗрибәсе бай. Бу аның күркәм сыйфатларының берсе.

Татар ата-аналарына балаларын үз телләрендә укыта торган мәктәпләргә бирү ихтыяҗын аңлатканда, аларның менә бу милли патриотлык һәм горурлык хисләренә йогынты ясап, изге максатка ирешүдә ул хисләрдән оста файдаланырга кирәк.

Милли горурлык турында сөйләгәндә шуны истән чыгарырга ярамый: аерым бер халыкның, шул исәптән татарларның да, милли горурлыгы төшенчәсе гомуми дәүләтнең, илнең патриотлыгы төшенчәсенә каршы килми, алар бер-берсен баета, тулыландыра гына. Үз иленнең патриоты булу ул – шушы илдә яшәүче һәр кешенең гражданлык бурычы. Безнең татар халкы һәркайчан һәм һәркайда Россиянең патриотлары булды. Бөек Ватан сугышында йөзләрчә татарларның Советлар Союзы Герое исеменә лаек булуы – моның ачык мисалы.

Халыкта үз милләтеңнең патриоты булу сыйфатын тәрбияләү эшендә республика, шәһәр, район, авыл, предприятие, оешма, уку йорты һ.б. җитәкчеләре үзләре үрнәк күрсәтергә тиеш, бары шул чакта гына бу эш югары нәтиҗәле булачак. Республиканың төрле дәрәҗәдәге татар җитәкчеләре, татар мәктәбенең ролен күтәрү өчен чаралар күргәндә, татар ата-аналарын, балаларын туган телебездә укыта торган мәктәпләргә бирергә өндәгәндә, үз балаларын да шул мәктәпләрдә укытырга кирәклеген онытмаска тиеш. Бу уңайдан

узган гасырның 50 нче елларында Татарстанның партия өлкә комитеты секретарьлары С.Д.Игнатьев белән К.Ф.Фасеевның, татар мәктәпләренең эшен яхшырту мәсьәләсе белән шөгыльләнгәндә, партия, дәүләт органнарында эшләгән татар җитәкчеләрен балаларын укырга милли мәктәпләргә бирергә теләмәүләре өчен тәнкыйтьләүләре гыйбрәтле күренеш.

Соңгы чирек гасырда безнең республикада татар мәгърифәтен үстерү, халыкның милли рухын ныгыту өчен җаваплы кешеләрнең гафу ителмәслек җитешсезлеге ул – Татарстан халыклары телләре турындагы закон нигезендә рус мәктәпләрендә татар телен өйрәтү бурычын үти алмаулары. Бу мәктәпләрдә укучы балалар, шул исәптән татар балалары, әти-әниләре, әби-бабайлары өйрәтмәсә, 11 ел буена атнасына берничәшәр сәгать татар теле дәресләрендә утырып, шушы телдә дөрес, матур итеп, иркен сөйләргә һәм язарга өйрәнә алмыйлар. Бу мәгарифне оештыручылар өчен гафу ителмәслек хәл, республиканың күп миллионлаган сум әрәм акчасы. Бигрәк тә үкенечлесе шул: бу мәктәпләрдә укып чыккан татар балалары да (алар исә бик күп) үз телләрен яхшы итеп өйрәнеп чыкмыйлар.

Бу хәлнең сәбәпләре: дөрес методика белән укытмау, шулай ук ялгыш методикага корылган дәреслекләрдән файдалану, югары органнарның укытуның сыйфатлы булуын таләп итмәүләре һ.б. Кыскасы, рус мәктәпләрендә татар теле укытуны тиешенчә оештыра алмау яки оештырырга теләмәү, әллә бу эшне кирәкле нәрсә дип санамау аркасындамы, бу мәктәпләрдә белем алган күп меңнәрчә татар балалары туган телләреннән мәхрүм калалар һәм нәтиҗәдә, татар мәдәниятен, тарихын белгән, үз халкы өчен тулы кыйммәтле кешеләр булып чыга алмыйлар. Монда инде милли горурлык сыйфаты турында сөйләп тә торасы юк. Бик үкенечле хәл бу. Безнең хакимият ияләре моның татар халкы өчен нинди зур югалту икәнлеге турында уйланмыйлар булса кирәк.

Бу уңайдан бөек педагог К.Д.Ушинскийның гыйбрәтле сүзләрен искә төшерү урынлы булыр иде. Ул “Туган тел” дигән хезмәтендә болай дип язган: “Халыкның теле югалса, ул халык үзе дә юкка чыга, халык теле саклanganда гына яши”.

Республикабыз мәктәпләрендә – татар мәктәпләрендә дә, рус мәктәпләрендә дә – укыту шундый итеп оештырылырга тиеш: татар балалары туган телләрен яхшы өйрәнеп, татар халкының һәм Татарстанның тарихын, шулай ук татар мәдәниятен белеп

чыксыннар. Үз Конституциясе, башка мөһим законнары булган, күпчелек халкы референдумда дәүләт суверенитетын яклап чыккан, һәр елны табышының иң зур күпчелеген (700 миллиард сум) Мәскәүгә биреп барган Татарстан республикасының яшь буынны югары культуралы, цивилизацияле тормышка әзерлекле, эрудицияле һәм иң әһәмиятлесе – үз халкының, республикадагы титуллы милләтнең патриотлары итеп әзерләргә бөтен хокуклары да бар. Республика җитәкчеләренә бу хокуклардан кыю рәвештә файдаланырга кирәк, ләбаса.

## ДИНИ ТӘРБИЯ

Аңлатмалы сүзлекте ***дин*** атамасына мондый билгеләмә бирелә: Дин – табигатьтән өстен торып, аны идарә итә торган көчләрнең (мәсәлән, аллаларның, рухларның, фәрештәләрнең һ.б.ш.) булуына ышану; Шундый ышануга нигезләнгән һәм фәнгә каршы килә торган карашлар, күзаллаулар системасы. Бу, диннең асылына дөрес аңлатма.

Хәзерге замандагы һәр укымышлы, аек акыллы кеше аңлыйдыр: дин бик борынгы заманнарда кешеләр дәһшәтле табигать көчләренең ничек барлыкка килүен аңлый алмаган, алардан куркып торган чакларда барлыкка килгән: алар табигать күренешләрен, дөньядагы бөтен нәрсәләрне, ягъни бөтен дөньяның үзен, ниндидер табигатьтән өстен билгесез көчләр (мәҗүсиләр динендә) яки бер чиксез кодрәтле алла (ислам динендә) барлыкка китергән, дип ышанып яшәгән.

Дин, мистикага, ягъни табигатьтән өстен серле көчләргә, аллаларга (яки бер генә аллага) ышануга корылган күренеш буларак, фәнгә каршы килә. Димәк, дөньяга бер-берсенә капма-каршы ике караш – фәнгә нигезләнгән дөньяви караш һәм күреп, сизеп, тоеп булмый торган чиксез кодрәтле ниндидер нәрсәнең барлыгына ышануга нигезләнгән дини караш. Хәзерге фән-техника искиткеч югарылыкка күтәрелгән, адәм заты галәмдәге икенче планеталарга юл токкан, кибернетика-информатика дигән могҗизалар иҗат иткән XXI гасырда кимендә урта белемгә яки югары белемгә ия булган кайбер кешеләрнең аллага ышаныпмы, ышанмыйча гынамы гыйбадәтханәгә йөрүләре бик тә сәер һәм аңлашылмый торган күренеш.

Кешенең гомумән дингә һәм нинди дингә ышануы яки ышанмавы һәркемнең үз ирегендә. Бу ирек безнең дәүләтнең төп законы – Конституциясе тарафыннан саклана. Дин тоту, аллага ышану һәр кешенең шәхси, интим өлкәсе.

Әмма соңгы елларда Россиядә хакимият ияләре динне (нигездә, христиан динен) үзләренә шулкадәр якынайттылар, аңа шулкадәр игътибар артты: дин инде дәүләт белән кушылып бара, ул һәртөрле дәүләт эшләренә актив катнаша. Патриарх Кирилл – дәүләтнең җитди зур форумнарында һәрвакыт иң хөрмәтле кунак, президент һәм премьер-министр белән үзен аларның тиңдәше, коллегасы кебек итеп тота. Телевидениедә христиан динен пропагандалауга багышланган махсус канал бар. Анда бу дин әһелләре даими рәвештә бик иркенләп, озаклап вәгазь укыйлар һ.б.

Ул гына да түгел: христиан дине сабакларын мәктәпләрдә өйрәтүгә әзерлек эшләрен башлап җибәрделәр. Бу эш мәктәп программасына “Дини культураларның нигезләре” предметын кертү рәвешендә гамәлгә ашырыла. Патриарх Кирилл мәктәпләрдә “Христиан дине культурасы” дигән предмет укытырга кирәк, ди.

Батюшкаларның (попларның) армия сафларында хезмәт итүчеләргә карата “освящение” дигән чиркәү йолалары үткәрүе, вәгазьләр сөйләве гадәти күренешкә әверелә бара булса кирәк. Мондый чараларның барысы да христиан дине исеменнән башкарыла.

Нинди хәл инде бу!? Дәүләт күрә торып тупас рәвештә төп законны боза бит! Конституциядә акка кара белән дин дәүләттән аерылган һәм дини берләшмәләр закон каршында тигез, дип язылган.

Безнең илдә, гаҗәп хәл, элек-электән бер чиктән икенче чиккә ташлану хөкем сөрә. Кайчан гына әле “Дин – халык өчен әфьюн ул” дигән лозунг белән мәчетләрне, чиркәүләрне җимереп йөрделәр, муллаларны, попларны сөргенгә сөрделәр, хөкем иттеләр, төрмәләргә яптылар. Әле хакимияттән шул ук коммунистлар китеп бетмәгән хәзерге заманда исә адым саен чиркәү, мәчет калкып тора. Дин әһелләре иң хөрмәтле кешеләр булып китте.

Дин халыкның дөрес, матур, мул яшәвенә ярдәм итсә, гаделсез сугышларга каршы чыкса, әйбәт булыр иде. Ләкин хәзерге динне алга сөрүчеләрнең гамәлләре гаделлеккә корылган дип әйтерлек нигез юк. Бу хакта күп сөйләргә, кызып-кызып сүз көрәштерергә була. Күп кенә попларның да, мулла-хәзрәт дип атап йөртелгән

кешеләрнең дә күбесенең изгелекләрен раслау кыен. Алар арасында динем өчен дип түгел, көнем өчен дип кенә йөрүчеләр аз түгел.

Аннан килеп, безнең илдә төрле диннәргә бертигез караш булмау да гаделлек принципларына туры килеп бетми. Һәркайда христиан дине пропагандалана, күтәрелә, аның халыкка таралуы өчен иң яхшы шартлар тудырыла. Мәскәү шәһәрен генә алып карыйк. Анда алтын гөмбәзләре белән йөзләрчә (меңнәрчә булмаса!) чиркәүләр ялтырап тора, шул ук вакытта берничә миллион мөселманга өч-дәрт мәчет бар, яңа мәчет салырга урын бирмиләр.

Диннәр асылы (нигезе) буенча гаделсез сугышларга каршы булырга, халыкны татулыкка, тынычлыкка өндәргә тиеш. Ә менә Чечен республикасында Россия гаскәрләре йөзләрчә мең гаепсез халыкны кырганда, христианнарның патриархы да, мөселманнарның мөфтие дә, башка күренекле дин әһелләре дә гаделсез сугышка тискәре карашларын белдермәделәр һәм хәзер дә белдермиләр.

Россиядә диннәр элек-электән хакимият яклы булган. Русь патша һәм православие дәүләте булды. Хәзерге Россиянең дә эчтәлеге шундый була бара. Ислам дине әһелләре дә бервакытта да хакимияткә, бик кирәк булса да, тәнкыйть сүзе әйтмәсләр.

Заманында әби патшаның, таш мәчетләр салырга рөхсәт биреп, ислам дине әһелләренә кайбер уңайлыклар булдыруы аның аларны яратуы түгел, бәлки алар аның үзенә турылыклы булып хезмәт итсеннәр учен эшләнгән. Һәм чыннан да мөселман хәзрәтләре вәгазьләрен патша хәзрәтләренә сәламәтлек теләүдән башлый торган булганнар, хәзер дә шулайрак булса кирәк. Патшаларның исә нинди булганлыклары, халыкка нинди “рәхәтлекләр” күрсәткәнлекләре һәм патша Россиясенең халыклар төрмәсе дип йөртелгәнлеге тарихтан яхшы билгеле.

Хәзерге Россиядәге христиан дине башлыкларының сәер гамәлләре аларның изгелек юлында булуларына зур шик тудыра. Мәсәлән, бу көннәрдә православие әһелләренең коточкыч җинаятьләр кылган Явыз Иванны (Иван Грозныйны) аклап маташулары – башка сыймаслык хәл.

Бүгенге православие түрәләренең әхлак сыйфатларын чын христиан дине тәгълиматлары кушкан мораль нормаларына туры килмәвен расларлык фактлар бар. Газеталар патриарх Кириллның Кырымда берничә гектар гүзәл табигатьле урында зиннәтле сарае белән биләмәсе барлыгы турында язып чыкканнар иде.

“Новая газета” 2016 елның ноябрь аендагы саннарының берсендә Казандагы һәм Татарстандагы православие башлыгы Феофанның шулай ук дин әһелләренә хас булмаган ямьсез гамәлләре турында зур мәкалә бастырып чыгарды.

Ислам дине түрәләренең дә кайберләренең байлык артыннан куу белән бәйләнешле чын дин тәгълиматына каршы килә торган эшләрен ишетеп, белеп торабыз.

Хәзерге хакимият иярләренең православие дине әһелләренең гамәлләренә мөкиббән китеп, чиксез күп санлы кыйммәтле чиркәүләр, монастырьлар салуга, төзекләндерүгә, башка төрле дини корылмаларга икътисади кризис шартларында да зур суммалар тотуы гаҗәпләндерә. Бер генә мисал: мәгълүм булганча, Россия дәүләте Парижның үзәгендә 4672 квадрат метр зурлыкта Россиянең рухи-культура православие үзәге төзеп куйды. Бу корылманың бәһасе – 160–175 миллион евро.

Илебез халкының тормыш хәле көннән-көн начарая барганда, чит илдә шундый кыйммәтле дин үзәге төзүне аклап булырмы икән?

Төрле дин вәкилләре үзара тату яшәсен, берсен-берсе хөрмәт итсен, ягъни китап сүзе белән әйткәндә, толерантлы булсын дибез. Бу, һичшиксез, дөрес тәгълимат. Әмма кайчакта бу тезисның гамәлгә ашырылуында да аңлашылмый торган хәлләр килеп чыга. Күптән түгел Мәскәүдә Русь илендә беренче православие динен таратучы булып саналган Владимир князьгә бик тантаналы шартларда кыйммәтле һәйкәл ачылды. Һәм менә ни гаҗәп: бу тантанада зиннәтле мөселман мөфтие киемендә мөселманнарның башлыгы Тәлгать әфәнде Таҗетдин да катнашты. Христиан динен таратучыга һәйкәл кую тантанасында ислам дине башлыгы катнашу дөрес һәм кирәк булдымы икән!

Дини хисләр алар – бик индивидуаль, һәркемнең күңел түрендә ята торган нәрсә, ул бернинди дә гомумиләштерелә торган күренеш була алмый. Аны идарә итәргә тырышу, дәүләт структурасына кертергә омтылу зур ялгыш. Россия, шул исәптән Татарстан да, әлбәттә, дөньяви дәүләт булырга тиеш. Дәүләт дин өчен бернинди дә, бер тиенлек тә чыгымнар тотарга тиеш түгел. Хәзер исә, мәгълүм булганча, хөкүмәтнең дини оешмаларга, чиркәүләргә әле генә әйтеп киткәнчә, зур суммаларда төрле ярдәмнәр күрсәтүе гадәти күренеш була бара.

Кызык хәл: безнең Татарстанда дини даталарның кайсы көннәрдә бәйрәм итәсе президент указы белән хәл ителә, шулай ук

дәүләт башлыгы, хөкүмәт җитәкчесе һәм спикер халыкны дини бәйрәмнәр белән тәбриклиләр. Бу аларның вазыйфаларына керәме икән?

Бу мәсьләдә инде бер тапкыр искә алынган А.Н.Сокуровның фикерләре бик гыйбрәтле. “Мәгърифәт идеяләре белән сугарылмаган дини принциплар һәм дини идеяләр мәгърифәт идеяләреннән югары булган җәмгыять – иң кыргый җәмгыять, – ди ул. – Мин дини китапларны бервакытта да мәгърифәт идеяләреннән югары куймаячакмын”.

А.Н.Сокуров бер динне икенчеләреннән өстен куюның никадәр куркыныч икәнлеген кисәтә: “Әгәр дәүләт бер динне (мәсәлән, православиене) башкалардан әһәмиятлерәк дип саный икән, моңа, мәсәлән, мөселманнар озак түзеп тормаячак. Теләсә кайсы дини сугыш милли яки сәяси принциплар буенча бәрелешләрдән күп тапкырлар куркынычрак. Иң куркыныч сугыш ул – дини сугыш. Анда килешү юк. Анда бары тик үлем генә”. Мөселманнар дөньясы белән бәйләнешле гаять җитди проблемаларны төрле төп диннәрнең лидерлары җыелып сөйләшеп, килешеп кенә хәл итә ала, ди Александр Николаевич. Аның фикеренчә, бүгенге көндә Россиядә дин дәүләттән аерылган булса, хәзерге проблемаларның күбесе булмас, ягъни террорчылык та хәзергечә җәелмәс иде. Бу яман күренешнең көчәя баруының сәбәбе дингә сәяси трибуна бирелүдә, динне мәгърифәттән өстен куюда. “Динне дәүләттән аерыгыз, сүздә генә түгел, чыннан да аерыгыз, – ди ул, – Конституциядә язылганча яшәгез. Конституциядә матур язылган. Ә менә нигә православие башлыгы хәрби көчләрнең генераль штабы утырышларында катнаша? Алай булгач, нигә анда мөфти юк, башка дин башлыклары юк? Ник алай? Самолетны изгеләштерүне (освящение, окропление) ничек аңларга? Без үзебезнең инженерларга ышанмыйбызмы ни? Безнең мәгърифәткә ышанычыбыз беттеме ни? Әллә ул әйберләр кеше кулы белән ясалмаганмы? Кешедән җаваплылыкны алырга вакыт җитмәгәндер бит әле. Без җинаятьчеләр – без Конституцияне таптыйбыз. Без дөньяви дәүләт булудан туктамадык. Мәгърифәтлелек табигатьтән өстен, серле, билгесез көчләргә (мистикага) ышанудан ерак торганда гына була ала”.

Күренекле фикер иясенең бу сүзләре белән килешми мөмкин түгелдер.

Дини тәрбия турындагы бүлекне йомгаклап, шуны әйтергә кирәк. Безнең илдә, безнең республикада халыкка бер динне дә

көчләп тагу һәм балаларны дәүләт мәктәбендә дингә өйрәтү булырга тиеш түгел. Дин тоту, аллага ышану – һәркемнең шәхси эше, һәм кешенең эчке дөньясына кагылышлы күренеш. Аңлашыла ки, шул ук вакытта дингә, аллага чын күңелдән ышанган, инанган кешене тыярга да беркемнең дә хакы юк.

## ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ

Тәрбиянең күп төрләре арасында тагын бер бик әһәмиятлесе – экологик тәрбия.

Экология сүзенең берничә мәгънәсе бар. Шуларның берсе – безнең хәзерге сөйләмебезнең темасына караганы – бөтен табигатькә, тереклек һәм үсемлек дөньясына, кешелек иҗат иткән барлык материаль һәм рухи хәзинәләргә культуралы мөнәсәбәт, сакчыл караш.

Экологик югалтуларның, һәлакәтләрнең кешеләрнең яшәү рәвешенә бәйлеләре, ягъни аларның тискәре, ялгыш гамәлләре аркасында килеп чыкканнары, һәм кешеләрдән бәйсезләре, ягъни табигать катаклизмнары дигән төрләре була. Кешеләрнең акылсызлык, тәрбиясезлек гамәлләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән экологик бозылулар, зыяннар безнең көндәлек тормышыбызда чиксез күп төрле формаларда һәм күләмнәрдә булып тора. Язмабызның бу бүлегендә экологик зыяннарның, нигездә, шушы төрләре хакында сөйләрбез. Мәсәлән, җаваплы кешеләрнең тәрбиясезлеге, ваемсызлыгы аркасында һәр елны миллионнарча гектар урманнарны, меңнәрчә торак пунктларны яндыру, җитәкчеләрнең ялгыш экологик сәясәт үткәрүе, галимнәр, белгечләр белән киңәшләшмичә, аларның фикерләренә колак салмыйча, административ стиль белән эш итүләре нәтиҗәсендә шулай ук миллионнарча гектар болыннарны, уңдырышлы җирләрне, авыл, шәһәрләрне су астында калдырулары, кыйммәтле тарихи ядкарьләрне җимертү һәм башка шундый корткычлык гамәлләре аркасында килеп чыккан зур югалтулар шундый субъектив факторларга карый.

Безнең илдә табигатьне саклау эше начар оештырылган һәм кешеләрнең экологик культурасы да түбән. Моның биниһая күп мисалларын үзебез һәр көнне күреп тә, ишетеп тә, мәгълүмат чараларындагы хәбәрләрдән белеп тә торабыз. Мәсәлән, соңгы елларда Татарстанның башкаласы Казан шәһәрендә генә дә берничә урында кемнәрнеңдер шәхси мәнфәгатьләрендә күкрәп үсеп утырган зур агачларны кисеп ташладылар. Елга, күл, диңгезләрдә тыелган

вакытларда һәм ярамый торган урыннарда күпләп балык, башка төрле кыйммәтле су җәнлекләрен тотып, урман-кырларда шулай ук вакытлы-вакытсыз, аулау тыелган җәнлекләрне, киек кошларны атып, аулап, табигатькә никадәр зыян салалар!

Үзебез яши торган табигатьне, мохитне пычрату, бозу, зарарлау хәлләре сөйләп бетергесез. Елга-күлләрне теләсә нәрсә ташлап чүпләү, пычрату, су буйларында, урман-аланлыкларда, ял итеп утырганнан соң, бөтен калдык-чүпләрен шунда ташлап калдыру – бездә гадәти күренеш. Ничек шулай үзең ял иткән гүзәл табигатьне хайваннарча пычратырга мөмкин!

Мин һәр көнне кичләрен (һәм төннәрен дә) Кабан күле буеннан йөреп кайтам. Анда ял итәргә чыккан халыкның, гадәттә, барысы да диярлек яшьләр була. Күбесенең, шул исәптән кызларның да, авызларында сигарет, кулларында сыра шешәсе... Сүгенеп сөйләшү, иләмсез акырып көлү, утырып ял итә торган эскәмияләр янында көнбагыш кабыклары, тәмәке төпчекләре...

Соңгы елларда Татар академия театрыннан алып Вахитов мәйданына кадәрге арада Кабан күле буен төзекләндерделәр, матурайттылар. Бу мәсьәләдә шәһәр хакимиятенә афәрин! Шуннан ни булды дип уйлыйсыз? Ике-өч елда берничә эскәмияне, берничә чүп урнасын кубарып алып киттеләр. Бер-ике урында хәтта юлга түшәлгән вак декоратив кирпечләрне дә сүтеп алганнар!

Мондый кыргыйлык гамәлләре кылган кешеләр кимендә урта белемле. Гаиләләрендә тиешле тәрбия булмаган инде аларга – монысы аңлашыла. 11 ел буена мәктәптә нинди тәрбия биргәннәр икән аларга, күпме дә булса биргәннәрме икән аны?! Гаиләсендә, балалар бакчасында һәм уку йортында да яхшылык белән тәрбияләп булмый икән, хокук саклау органнары тиешле чаралар күрсеннәр: милициядә бик күп кеше эшли, зур хезмәт хакы алалар, җәмәгать урыннарында күбрәк булсыннар, тәртип сакласыннар, хулиганнарны тотып, җавапка тартсыннар.

Экологик тәрбияне балаларга кечкенәдән үк үтемле формаларда һәм нәтиҗәле итеп бирү зарур. Әлбәттә, бу тәрбиянең иң кулай урыны – гаилә. Ата-ана, бала аңлый башлаган вакыттан ук, аны ярамый торган гамәлләр кылмаска күнектерергә, чисталыкка, пөхтәлеккә, әйберләргә зыян китермәскә, агач-үсемлекләрне, чәчәкләрне сындырмаска, өзмәскә, эт-мәчеләрне, кош-кортларны, йорт хайваннарын тилмертмәскә, җәфаламаска һәм башка күп нәрсәләргә өйрәтергә тиеш.

Бу мәсьәләдә безнең татар гаиләләре үрнәк булырлык иде. Әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз, зур укымышлы булмасалар да, әдәп кагыйдәләренә уңышлы, үтемле итеп өйрәтеләр. Безнең өчен ярамый торган нәрсәләрнең исемлеге зур булды. Балаларда (кайчак олыларда да) әдәплелек тәрбияләү (экологик тәрбия дә шуңа карый) көнкүрештәге бик күп ярамый торган кечкенә генә гамәлләр кылудан тыела белергә күнегүдән башлана. Мәсәлән, өйдә юынганда (олылар – кырынганда) краннан суны чама белән генә, кирәгенчә генә агызырга, бүлмәләрдә кирәксезгә ут яндырып тотмаска, өйдә урамда йөргән аяк киеме белән йөрмәскә, берәр кеше эшләгәндә яки укыганда, аңа комачауламаска һ.б.ш.

Татар халкында элек-электән балаларда, яшьләрдә, ә кайчакта олыларда да, һәр нәрсәгә сакчыл караш, әйберне, малны юкка әрәм итмәү, исраф итмәү сыйфатын тәрбияләү игътибар үзәгендә торган. Ипинең валчыгын да ташламаска, ялгыш идәнгә, җиргә төшсә, җыеп алырга өйрәттеләр безне әниләр. Мондый тәрбияне халыкның элекке авыр тормышы белән бәйләп карарга мөмкин. Алай гына да түгелдер, бәлки. Әмма ничек кенә булмасын, бик кирәкле һәм дөрес тәрбия булган бу.

Ә менә хәзерге балаларда һәм яшьләрдә мондый тәрбиялелек җитми. Аларның күбесе ипинең дә, гомумән һәр төрле ризыкның да кадерен белми. Үкенечле хәл бу. Гаиләдә дә, анда булмаса, балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә дә тәрбияләргә кирәк балаларда һәм яшьләрдә ризыкның кадерен белү сыйфатын. Моны оста педагогик алымнар белән гамәлгә ашыру мәгъкуль: һәр ипи сыныгына, һәртөрле ашамлыкка, шулай ук шәһәр суүткәргечләрендәге чистартылган суга күпме кешеләрнең хезмәте кергәнлекне, күпме акча түгелгәнлекне, икмәкне үстерүнең нинди авыр эш икәнлеген сөйләргә, дөньяда миллионнарча кешеләрнең ачлыктан интегүләрен аңлатырга кирәк.

Экологик тәрбия кешеләрдә миһербанлылык булдыру белән тыгыз бәйләнештә тора. Миһербанлы булу ул – һәр нәрсәгә, барлык җанлы нәрсәләргә дә, табигать бүләк иткән үсемлекләргә дә яратып, кадерләп карау, аларны безнең дөньябызны тулы, җитешле, матур итәргә барлыкка китерелгән һәм алар да яшәргә, үсәргә тиешле, хаклы нәрсәләр буларак, сакларга, аларны кирәксезгә бетерү, юкка чыгару белән шөгыльләнмәскә бурычлы булуыбызны аңлау һәм шуңа омтылу.

Һәр милләт, һәр халык балаларында тумыштан ук шундый сыйфатлар тәрбияли, ягъни аларны миһербанлы итеп үстерә алса, дөнья идеаль булыр иде. Идеаль нәрсә була алмый, әлбәттә. Әмма моңа омтылырга, якынаерга тырышырга кирәк, һәм, һәр ата-ана балаларына дөрес тәрбия бирә белсә, без һәрхәлдә идеаль хәлгә якын булыр идек.

Баланың бик кечкенәдән, аңлый башлаган вакытыннан ук, хайваннын, кош-кортның да, хәтта вак кына бөҗәкнең дә тәне, кагылсаң, имгәтсәң, кешенеке кебек үк авырта, шуңа күрә без аны рәнҗетергә тиеш түгел, әгәр дә без шулай эшлибез икән, бу безнең тарафтан зур әшәкелек була дигән уй сеңдерергә кирәк. Кайбер ата-аналар кебек, мәсәлән, кечкенә баласына урамда барганда яки башка урында тик кенә торган эткә-мәчегә нәрсә белән булса да сугарга, нәрсәдер бәрергә яки үсеп утырган куакны сындырып, үсемлекне, чәчәкне өзеп алырга, ул бәләкәй, аңламый бит әле, дип, ирек куярга һич кенә дә ярамый. Зурайгач, соң була. Баланы тугач та тәрбияли башларга кирәк. Яшь ана, баласы туып ярты ел узгач, аны ничек тәрбияләргә икән дип, тәҗрибәле педагогтан киңәш сораган, ди. Педагог аңа: “Сез инде нәкъ ярты елга соңга калгансыз”, – дип җавап биргән.

Тереклекияләренең берсенә дә зыян китермәү, барысын да кадерләп саклау идеясе кайбер илләрдә, мәсәлән, Һиндстанда шактый алга киткән. Мин ул илдә беренче тапкыр булганда, гаҗәп күренешкә тап булган идем. Авызына марля кебегрәк тукыма бәйләвеч (повязка) каплаган бер һинд кешесе, кечерәк кенә сапլы себерке кебек нәрсә белән барган җирен үз алдыннан себерә-себерә, әкрен генә атлап килә. Соңрак мин тагын берничә шундый кешене очраттым. Мин мондый гаҗәп хәлнең сәбәбен сорашып белдем. Болар Һиндстандагы күп төрле диннәрнең берсенә караган кешеләр икән. Ул дин тәгълиматы буенча, дөньядагы бер генә җан иясенә дә зыян китерергә ярамый. Янәсе, авызны капламый йөрсәң, очып барган чебен-черки анда эләгеп һәлак булырга мөмкин. Йөргәндә алдыңнан юлны себереп бармасаң, җирдәге нинди дә булса бөҗәкне, ялгыш басып, таптап үтерергә мөмкин бит.

Хәзер инде үзем дә шул һинд кешеләре кебегрәк булып барам. Җәйге кичләрне (төннәрне дисәм, дөресрәк тә булыр) көндез утырып эшләп арып, ял итеп кайтырга чыккач, яңгыр явып узганнан соң, асфальт өстендә шактый күп санлы суалчаннар сузылып ята.

Мин, аларга басмас өчен, аларны аралап-аралап атлыйм. Шундый матур гына итеп, әкренләп, шуыша-шуыша баралар гөнаһсыз җан ияләре! Ничек итеп шуларны таптап, сытып китәргә мөмкин инде! Юлда яткан башка төрле бөҗәкләрне дә таптамаска тырышам. Өйдәге үрмәкүчләрне дә үтермим. Яшәсеннәр, алар безгә зыян китерми бит, киресенчә, безне борчый торган чебен-черкиләрне, пәрәвезләренә чорнап, әсирлеккә төшерәләр.

Барлык илләрдәге халыклар балаларын миһербанлы итеп тәрбияли алсалар, дәүләтләр, төрле халыклар арасындагы кан койгыч сугышлар да булмас яки бик аз гына булыр иде, бәлки. Андый сугышлар дәүләт җитәкчеләренең каты бәгырьле, миһербансыз, үз илләре кешеләрен дә, башка илләрнекен дә кызгана белмәүләре, аларга да, үзләре кебек үк итеп, аларның да яшәргә хокуклары бар һәм аларның да яшиселәре килә бит, дип карамаулары аркасында килеп чыга. Югыйсә, төрле аңлашылмаучылык, ризасызлык хәлләрен дәүләт җитәкчеләре, очрашып, сөйләшеп, аңлашып, хәл итә алырлар иде.

Бу уңайдан хәзер Сирия һәм кайбер башка гарәп илләрендә барган сугышларның мәгънәсезлеге һәм гаделсезлеге хакында берике фикер әйтеп китәсе килә.

Сириядә инде ничә ел сугыш бара, ничә мең гаепсез, тыныч тормыш кешеләренең гомере өзелгән, күпме халык җәфа чигә. Һәм бу мәхшәрнең ахыры күренми. Минемчә, андагы сугышка чит илләрнең катнашуы дөрес түгел: суверен, мөстәкыйль дәүләт үз проблемаларын үзе хәл итәргә тиеш. Сириядә, ул тирәдәге башка гарәп илләрендә дә, хөкүмәт гаскәрләре белән, рәсми мәгълүмат чаралары хәбәр иткәнчә, террорчылар арасындагы гына сугыш түгел, берничә ел буена хөкүмәт гаскәрләре белән сугышырлык террорчылар булмый. Аларда хөкүмәт гаскәрләренә каршы ниндидер сәяси көчләр көрәшә, һәм ул хәрби көчләр аз санлы да, көчсез дә түгел. Анда чит ил самолетларының бомбага тотуы юлы белән тынычлык урнаштырып булмаячак. Киресенчә, гаепсез корбаннар саны көннән-көн арта гына барачак. Кара-каршы якларның җитәкчеләре килешүгә ирешкәннән соң, сайлау үткәреп, яңа дәүләт башлыгын билгеләп куйсыннар. Һәм чит илләр катнашыннан башка, үзләре теләгәнчә, үз тәртипләре белән яши башласыннар Әнә Колумбиядә хөкүмәт гаскәрләре белән аларга каршы отрядлар, ничә ел сугышканнан соң, үзара килешүгә ирешә алганнар бит. Гарәпләр дә шулай эшләсен.

Бу мәсьәләдә инде искә алынган А.Н.Сокуровның фикере игътибарга лаек. Ул менә нәрсәләр ди: "*ИГИЛ (Россиядә тыелган оешма) тарихы ул хәзер хәрби тарих кына түгел инде, ул идеологик тарих, шул ук вакытта ул шундый бер "дини большевизм". Совет большевизмы үзенең идеологиясен бөтен дөньяга көчләп таратырга маташты, шуңа күрә аны бөтен дөнья белән бастырырга тырыштылар. Булдыра алмадылар, ул үзе җан бирде. Коточкыч сынаулар аша, сугышлар аша узды, ләкин барыбер җан тәслим кылды.*

*ИГИЛ белән көрәш, минем фикеремчә, ди ул, – яңа дини идеологик көрәш. Бомбага тотып, аларның ачуларын гына ныграк чыгарачаксың.*

*Бик җитди зур проблема... Бөтен зур диннәрнең әһелләренә, җыелышып, бу бөтен дөнья проблемасы турында фикер алышырга кирәк. Ә аларның сөйләшер сүзләре күп инде... Һәм бу ИГИЛга нәрсәдер кирәк икән, әгәр дә алар үзләренең "идеаль" дәүләтләрен төзергә телиләр икән, әйдәгез, карап карыйк: үзләре яшәгән географик кысаларда ни эшли алырлар икән алар. Бу эволюцион юлларны үтеп карасыннар: хөкүмәтләрен оештырсыннар, эш урыннары, транспорт булдырсыннар, үзләренең мәчетләрен салсыннар... үз дәүләтләрен төзесеннәр. Әгәр дә инде Иске дөньядагы тормышны юкка чыгарырга дигән карарга киләләр икән, ул чакта без үзебезне үзебез сакларбыз*".

Көнчыгыш Украина (Донбасс, Луганск) мәсьәләсендә дә әле әйтеп киткән сәясәт булырга тиеш: Украина халкы үз проблемаларын үзе хәл итсен, чит илләр катнашмасын. Шулай булса, анда тынычлык тизрәк урнашачак. Мондый очракларда русларның "третий лишний" дигән әйтелмәсен кулланып эш итү хәерле булыр.

Экология төшенчәсе төрле халыклар, этносларның, аларның милли культуралары, телләре, традицияләре һәм гореф-гадәтләренең саклануы мәсьәләсенә дә карый.

Һәрбер халык, сан ягыннан кечкенә генә этнос та – үзенең мәдәнияте, теле белән уникаль күренеш, һәм төрле сәбәпләр аркасында аның берсенең генә дә булса да яшәүдән туктавы – бөтен дөнья цивилизацисе өчен күпмедер дәрәҗәдә югалту. Бу мәсьәлә күп милләтле Россия өчен аеруча актуаль, чөнки монда патша заманнарыннан алып әлегә кадәр милли сәясәт дөрес үткәрелми, барлык халыклар һәм этносларның ирекле яшәве, алга баруы өчен тигез, гадел шартлар булдырылмаган: соңгы берничә дистә елда гына да безнең илдә берничә аз санлы халык юкка чыкты һәм

хәзер дә берничә милләт бетерелүгә дучар ителгән. Димәк, Россия милләтләр яшәеше мәсьәләсендә җитди экологик югалтулар кичерә.

Кешенең экологик тәрбияле, ягъни сакчыл табигатьле булуы яки булмавы аның гомумән культуралы яки культурасыз булуына карый. Безнең илдә әле халыкның гомуми культура дәрәҗәсе тиешле югарылыкта дип әйтеп булмый, димәк, дәүләт алдында күп кешеләрнең гомуми культурасын күтәрү бурычы тора. Бу дәүләт тарафыннан кабул ителәсе комплекслы тәрбия эше программасында күздә тотылырга тиеш.

Сер түгел: безнең халыкның психологиясендә дәүләт милкенә, гомуми байлыкка саксыз караш, ваемсызлык шактый көчле әле. Күп кешеләрдә бу мәсьәләдә татарча әйткәндәге "үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел", русчадагы "моя хата с краю" принцибы шактый нык чагылыш таба. Мондый хистән халык, никадәр тизрәк арынып, кешелек иҗат иткән һәртөрле матди һәм рухи хәзинәләрдә дә, табигать тарафыннан барлыкка китерелгән байлыкларда да минем өлешем дә бар дип, аларны үзенеке кебек итеп сакларга омтылу, кадерләп тоту хисенә ия булса, безнең ил байлыгы шулкадәр тизрәк зур югалтулардан сакланачак һәм арта барачак.

Кешеләр, элементар саклану чараларын күреп, тиешле кагыйдәләрне, инструкцияләрне үтәп яшәсәләр, янгын чыгу, су басу, зур аварияләр кебек күпме бәла-казалардан котылып калырга мөмкин булыр иде. Ил буенча һәр елны булып торган күп меңнәрчә андый һәлакәтләр кешеләрнең җавапсызлыгы, ваемсызлыгы, үз вазыйфаларына төкереп караулары аркасында килеп чыга бит.

Экологик тәрбиягә һәм гомумән культурага безгә алдынгы Европа илләреннән һәм Япониядән, Сингапур кебек көнчыгыш илләреннән өйрәнергә, алардагы уңай үрнәкләрне кабул итәргә кирәк.

Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап, чит илләр белән багланышлар җанланып киткәч, безнең инфраструктураны күтәрү өчен, көнкүреш уңайлыклары, дизайн һәм башка кайбер мәсьәләләрдә Европа дәүләтләреннән файдалы үрнәкләр кабул ителде, ләкин әле болар гына җитәрлек түгел. Культура мәсьәләсендә Европа илләреннән, бигрәк тә Германиядән, үрнәк алырлык нәрсәләр күп.

Япония – халкының әдәплелеге, әхлаклылыгы, үз-үзен тотышы, шәһәр-авылларының төзеклеге, чисталыгы, матурлыгы һәм башка сыйфатлары буенча күп илләр һәм халыклар өчен үрнәк (фән-техниканың югары дәрәҗәдә торуы да һәркемгә мәгълүмдер). Бу уңайдан кайбер фактларны гына булса да искәртеп китү артык булмастыр.

Халкы Россиянекеннән бераз гына азрак булган бу илдә, территориясе безнекеннән йөзләрчә мәртәбә кечерәк булса да, кешеләр яшәгән һәр җирдә яшеллек бар. Егерме миллионнан артыграк халык яши торган Токио урамнарында да агачлар, чәчәк клумбалары үсеп утыра. Япониядә чүп түгел, хәтта тузан да юк: чисталык шул дәрәҗәдә. Күп миллионлаган автомобиль йөри торган бу илдә аварияләр булмый диярлек, чөнки машина йөртүчеләр дә, җәяү йөрүчеләр дә югары культуралы, тәрбияле. Хәтта автомобиль юллары тукталышындагы туалетлардагы чисталыкны һәм матур итеп бизәлешне күреп гаҗәпләнми калу мөмкин түгел.

## ФИЗИК ТӘРБИЯ

Балаларның, яшьләрнең таза-сәламәт булып үсүләре, олыларның исә сау-сәламәт яшәүләре өчен физик тәрбиянең зарурлыгы бәхәссез.

Безнең илдә бөтен халыкның физик яктан тәрбияләнүе гомумән алганда түбән дәрәҗәдә. Бу эшкә дәүләт тарафыннан да игътибар җитми, бу мәсьәләдә халык үзе дә пассив.

Кешеләрнең үз ихтыяры белән, махсус зур матди чыгымнарсыз гына физик культура белән шөгыльләнүенә килгәндә, Кытайны үрнәк итеп алырга була. Анда бу өлкәдә халык бик актив, аңлы эш итә. Бер мисал. Иртән иртүк шәһәр парклары, елга, күл буйлары, тротуарлар кулларына магнитофон, кенәри кошлы читлекләр тоткан меңнәрчә кешеләр белән тула. Магнитофон музыкасына, кошлар сайравына барысы да, үзләре теләгәнчә, физик күнегүләр эшли. Берникадәр шулай шөгыльләнгәннән соң, кайберәүләр шул тирәдәге агачларга барып сылана, агачны кочаклап яки аркасын терәп, сөялеп тора: шулай итеп, аннан көч ала, янәсе. Кытайның көньягындагы Гуйлинь шәһәре кешеләре исә иртәнге физкультура урынына шәһәр кырыендагы биек чүмәлә рәвешендәге кечкенә тауларга менеп төшәләр.

Көнбатыш Европа илләрендәге шәһәрләрдә күп урыннарда волейбол, баскетбол, футбол уеннары өчен махсус әзерләнгән спорт мәйданнары бар, һәм анда һәрвакыт халык була.

Күп илләрдәге мәктәпләр һәм югары уку йортлары койма белән әйләндереп алынган аерым кампусларда урнашкан. Аларда уку, эшләү, спорт белән шөгыльләнү өчен бөтен шартлар бар. Кытайда, мәсәлән, шул ук территориядә уку йорты белән бергә студентларның тулай тораклары, укытучылар яши торган йортлар, китапханә, кибет, ашханә, кафелар, спорт мәйданнары һәм уку, яшәү, ял итү өчен кирәкле башка нәрсәләр урнашкан.

Укучылар, студентлар берничә дәрестән соң бер-ике сәгать спорт белән шөгыльләнәләр дә, яңадан классларга, аудиторияләргә кереп утырып, укуларын дәвам иттерәләр. Шунда ук өйгә бирелгән эшләрен башкаралар, мөстәкыйль эшләр белән шөгыльләнәләр һ.б. Бик акыллы оештырылган: утырып уку-язу физик күнегүләр, спорт белән аралаштырып башкарыла.

Советлар Союзында да күпчелек (массовый) халык спорты өчен шартлар күбрәк иде. Мәктәпләрдә, урта һәм югары махсус уку йортларында, спорт җәмгыятьләрендә, спорт клубларында укучы балалар, студент егетләр һәм кызлар, түләүсез инвентарьлар белән тәэмин ителеп, спорт белән түләүсез шөгыльләнделәр. Шәһәрдәге күп йортларның ишек алларында балалар өчен хоккей мәйданчыклары оештырыла иде. Хәзер мондый нәрсәләр юк. Спорт белән шөгыльләнү түләүлегә әверелде. Гади халыкның исә моңа акчасы җитми. Бу хәл балаларның, яшьләрнең тиешле физик тәрбия алуына мөмкинлекне нык чикли. Кечкенәдән үк, телевизор каршыннан китмичә, физик культура, спорт белән, шулай ук физик эш белән шөгыльләнмичә үскән балаларның һәм яшьләрнең сәламәтлеге нык була алмый шул.

Димәк, комплекслы тәрбия эше программасында физик тәрбиягә зур урын бирелергә һәм, бу тәрбия нәтиҗәле булсын өчен, тиешле чаралар күрелергә, мөмкинлекләр булдырылырга тиеш.

## ЗАГОВОРИТ ЛИ КАЗАНЬ НА ТАТАРСКОМ?

Вопрос этот – риторический, но очень значимый. Ответ на него мог бы послужить своего рода индикатором положения с родным языком татар и их отношения к нему.

Поскольку я ставлю такой вопрос, должен высказать свои соображения, связанные с ответом на него. Соображений же, или мыслей, нередко беспокойных, даже тревожных, по поводу сегодняшнего положения татарского языка у меня много (разумеется, наверное, не только у меня). Их стало особенно много в этом году, объявленном для народов Татарстана Годом родных языков.

Меня постоянно обуревают мысли о том, произойдут ли в скором будущем позитивные изменения в духовной жизни татар, прежде всего и самое главное: предвидятся ли положительные сдвиги по оздоровлению обстановки с татарским языком, по повышению его престижа. Придаст ли Год родных языков импульс упрочению позиций родного языка татар? По предположению, этот год должен быть началом серьезных перемен в языковой жизни, стать переломным в коренном улучшении деятельности национального образования, оказывать содействие расширению сферы употребления татарского языка, благотворно воздействовать на то, чтобы татары, все-таки, станут свободно общаться на своем родном языке и на улицах Казани появятся люди, беседующие между собой на татарском языке.

Учитывая, что в последнее время в Татарстане предпринимаются определенные действия по оздоровлению обстановки с татарским языком, можно было бы вести речь о симптомах проявления благосклонного отношения отдельных руководителей республики к родному языку татар и желания их содействовать сохранению и развитию этой сокровенной сути народа.

Обнадеживающие мысли были выражены в выступлении Р.Н.Минниханова в печати о положении татарского языка, как положительный шаг в решении языкового вопроса следует рассматривать создание комиссии при Президенте республики по сохранению и развитию татарского языка под руководством зам. председателя Госсовета М.Г.Ахметова, а также проведение ряда мероприятий, посвященных Году родных языков. На первый взгляд может показаться, что наконец-то по-настоящему взялись за исправление положения на языковом фронте. Однако если заглянуть глубже на конкретные результаты реализации этой жизненно важной проблемы, проанализировать итоги прошедшей первой трети этого памятного года, то, как нам кажется, особенно обольщаться достигнутым пока еще не приходится.

Не чувствуется никаких признаков повышения активности в общении татар на родном языке, кажется, не проявляется и стремления у них к усилению такого общения. Досадно, но удручающий факт: больше половины татарского населения республики не общается на родном языке.

Нет ощутимых изменений в системе обучения детей-татар своему родному языку, направленных на достижение большей эффективности в преподавании этого предмета, сохраняются серьезные проблемы в национальном образовании. После разгромных перемен в преподавании татарского языка в общеобразовательных учебных заведениях по распоряжению центральных властей, количество татарских школ намного сократилось и продолжает сокращаться, качество обучения татарского языка в сохранившихся национальных школах ухудшается, в них идет процесс перехода к обучению на русском языке, и есть основание полагать, что внимание соответствующих государственных органов к учебным заведениям с татарским языком обучения не усиливается.

Количество соплеменников, читающих татарские газеты и журналы очень небольшое: тиражи республиканских газет и численность подписчиков на них мизерные. Это свидетельствует о том, что сфера употребления татарского языка в этом отношении очень узкая и нет признаков ожидаемого ее расширения.

Таким образом, строгий взгляд на положение и объективный анализ создавшейся ситуации с употреблением, изучением татарского языка, владения им нашими соплеменниками неизбежно приводят к неутешительному выводу о том, что состояние и перспективы родного языка татар в настоящее время не может не вызывать у здравомыслящих людей серьезной обеспокоенности и тревогу. Следовательно, надо об этом говорить во всеуслышание и не следует представителям властных структур пытаться в целях успокоения народа завуалировать ситуацию, смело и честно признавать серьезность создавшегося положения с татарским языком, объективно показывая накопившиеся проблемы, заниматься нахождением путей и средств безотлагательного их решения.

Вопрос о сохранении родного языка татар назрел и, можно сказать, даже перезрел. Сейчас требуется принятие государством кардинальных мер для исправления положения – для сохранения татарского языка, восстановления былого престижа его.

Что же можно и нужно сделать для этого, какие действенные меры надлежит принимать государственным органам, и какое участие в реализации этих мер должно принимать само татарское население – все, кто испытывает гражданскую ответственность за сохранение и развитие своего родного языка, национальной культуры и в конечном счете самих себя как достойных представителей своей нации.

Реализация задачи сохранения и развития татарского языка в настоящее время – дело первостепенной важности для республики, основа благополучного существования татарского народа как передовой, развитой нации. И на решение этой задачи должно быть направлено основное внимание государства Татарстана, широко используя имеющиеся силы и средства его.

В чем, на наш взгляд, должны проявляться конкретно действия государства в этих целях?

Приступать к реализации этой важнейшей проблемы следует с разработки и принятия глубоко продуманной комплексной программы сохранения и развития татарского языка. В ней должны быть предусмотрены все вопросы, имеющие отношение к употреблению, изучению и сохранению родного языка татар. Думается, что к составлению данной программы будет предшествовать серьезная подготовительная работа – обстоятельное изучение с помощью специальной комиссии с широким охватом всевозможных проблем состояния татарского языка. Деятельность этой комиссии будет плодотворной, если она будет состоять из высококвалифицированных специалистов: ученых-филологов, опытных педагогов, психологов и т.д.

В разработанной силой опытных специалистов программе развития татарского языка были бы освещены все важнейшие аспекты данной проблемы и определены конкретные задачи повышения престижа родного языка татарского народа. Каковы они в нашем представлении?

Самое главное: всеми силами и средствами добиться создания развитой системы национального образовании. В этой связи предстоит по сути пересмотреть и совершенствовать деятельность общеобразовательных школ с татарским языком обучения, ставя целью повышение ее эффективности. Этим учебным заведениям следует оказывать первостепенное внимание. Они должны быть лучшими во всех отношениях – и по обеспеченности высокопро-

фессиональными преподавательскими кадрами, и по учебно-материальной базе (добротные, красивые учебные помещения с современным учебно-техническим оборудованием, со спортивными залами и площадками, плавательным бассейном и т.д.).

Качество знаний обучающихся в этих учебных заведениях по всем предметам должно быть на высоком уровне, что может быть достигнуто при правильной методике обучения, соответствующем контроле за знаниями и высокой требовательности за качество как к преподавателям, так и обучающимся. При этом особое внимание следует обращать к системе преподавания родного языка, которая должна основываться на коммуникативной методике. Учебный процесс в татарских школах должен быть организован на таком уровне, чтобы по качеству знаний их учащиеся ни по одному предмету, в том числе и по русскому и английскому языкам, не уступали учащимся лучших русскоязычных школ.

Что касается создания лучших, элитных татарских школ, в наших выступлениях в печати неоднократно напоминалось о том, что правительству республики необходимо в срочном порядке заняться созданием таких учебных заведений. Их надо строить в кратчайшие сроки, как строили, например, за несколько месяцев специальные больницы в связи с распространением ковида (коронавируса). Учитывая темпы происходящего в последние годы подрыва системы национального образования, необходимо ежегодно строить хотя бы по одной-две элитные татарские школы в Казани и других городах, не менее по одной – в каждом районном центре или крупном поселении сельского района. 2021 год как Год родных языков пришелся бы для этого весьма кстати. Но это предложение о строительстве новых учебных зданий для татарских школ, как и другие предложения по повышению престижа родного языка, не доходят до ответственных лиц, к сожалению, у нас не принято внимать к голосу масс, однако хотя бы иногда надо бы.

Изучение и расширение функций татарского языка предполагает еще один весомый резерв. Это – сфера обучения татарскому языку учащихся русских школ Татарстана, в которых около половины обучающихся составляют дети татар. Одна из серьезных задач руководителей республики заключается в том, чтобы этот многотысячный контингент татарской молодежи вооружить знаниями своего родного языка. Как известно, благородное дело по изучению татарского языка в школах с русским языком обучения в соответ-

ствии с законом о языках народов Татарстана по сути провалилось: за более чем четверть века, потратив огромные средства и большое количество урочного времени в течение 11 лет, многотысячной армии выпускников русских школ так и не удавалось овладеть татарским языком в той мере, чтобы свободно и правильно общаться на ней. Бесспорно: это очень серьезная недоработка Министерства образования республики. Долг нынешнего министра со своим аппаратом – срочно поправить это непростительное упущение своих предшественников, в кратчайшие сроки всех учащихся-татар в русских школах охватить действенным изучением татарского языка с тем, чтобы они по окончании учебного заведения могли правильно, свободно говорить и писать на своем родном языке.

Эта задача в нынешних условиях сопряжена с таким непростым обстоятельством. Речь идет о пассивном, равнодушном, и даже негативном отношении у значительной части татарского населения ко всему своему национально составляющему – языку, культуре и т.д. Стыдно признаваться, но это весьма досадный факт.

Наиболее наглядно и неприглядно это проявляется в том, что в городах, особенно в Казани – столице Татарстана, на улицах и других общественных местах татары между собой общаются в основном не на родном языке. Это парадокс, и такое поведение их трудно объяснять, это, разумеется, не может не шокировать людей, уважающих свою нацию.

Сейчас многие родители-татары не желают отдавать своих детей учиться в татарские школы, а некоторые родители детей, обучающихся в русских школах, не изъявляют особого желания, чтобы они посещали уроки татарского языка.

Впрочем, такой поступок этих людей можно объяснить двумя факторами. Во-первых, из сознания даже нынешнего поколения татар не совсем стерлись пережиточные явления жизни многих предыдущих поколений в условиях царского режима, а также советского периода, когда господствующей считалась лишь одна нация, а все остальные, в том числе татары – второстепенными, второсортными. Это постыдное явление, к сожалению, в определенной степени наблюдается и в наше время. Такое уничижительное положение малочисленных народов перед “старшим братом”, царствовавшее в течение многих веков, отзывается, видимо, у некоторых людей и в наше время. Признание себя, как и всего своего народа, перед неким господствующим народом второстепенным приводило и при-

водит также к согласию считать свой язык второсортным, языком более низкого уровня и отсюда появление некоего чувства стыда общаться в общественных местах на родном языке. Такое унижение себя и своего родного языка, разумеется, не простительно никому. Во дворе уже XXI век, век цивилизации, и всем, даже самым малочисленным народам, впору себя чувствовать равными среди других и вести себя подобающим образом. Как все народы равные, достойные, так и их языки равноценные, важные и нужные.

Что касается нежелания родителей-татар обучать своих детей на татарском языке и родному языку, тут проявляется, кроме равнодушного отношения к своему национальному, еще и их прагматизм, связанный с предстоящим обучением своих чад в вузе. В этом вопросе присутствует два фактора. Первый – это то, что из-за ряда непопулярных мер центральных властей по отношению к нерусскоязычным школам (система сдачи ЕГЭ для выпускников национальных школ только на русском языке и их зачисление в вузы по оценкам, полученным на выпускных экзаменах, что действительно может несколько затруднять их поступление в вузы и т.д.). Второй – психологический фактор – не всегда оправданная тревога родителей в связи с поступлением своих детей в высшие учебные заведения. Но как показывает практика, сейчас в национальных школах те предметы, знания по которым при зачислении в вузы являются решающими, преподаются по таким же программам и в основном в тех же объемах, что и в русскоязычных учебных заведениях, и для успешно обучавшихся в национальных школах при поступлении их в вузы по сути не должно быть особых сложностей.

Но тем не менее, как уже говорилось, сеть татарских школ надо расширять и уровень их деятельности следует повышать.

В то же время одной из первостепенных задач руководства республики и общественных институтов остается серьезная целенаправленная идеологическая работа по воспитанию у соплеменников чувств собственного достоинства, национального духа и национальной гордости. К реализации этой важнейшей миссии должны быть мобилизованы все силы и средства: учебные заведения, печать, радио-телевидение, учреждения культуры и т.д., широко используя богатый наглядный материал из примечательной истории татарского народа, из жизни многих замечательных людей татарской национальности: известных в стране и мире выдающих-

ся деятелей культуры, науки, героев фронта и труда, прославленных военачальников, спортсменов и т.д.

Свою заметку хочется закончить выражая надежду, что трудолюбивый, целеустремленный татарский народ с добрыми делами и традициями не позволит потеряться своей национальной идентичности, родному языку и культуре, сумеет сохранить себя как передовую нацию. В заключение осмелюсь высказать некоторые пожелания и предложения в адрес уважаемых руководителей республики.

Учитывая архиважность принятия действенных мер в целях содействия развитию духовной жизни татарского народа, как и других народов, сохранению родного языка, развитию культуры, национального образования, а также необходимость более оперативного и действенного решения национально-гуманитарных вопросов, целесообразно иметь в штате Кабинета Министров республики должность заместителя премьера-министра Татарстана по национальным вопросам, а также должность заместителя министра образования и науки по национальному образованию.

В развитие положительного опыта выступления Президента республики в печати по проблемам татарского языка добрым жестом стало бы обращение Р.Н.Минниханова к народу Татарстана со своими весомыми наставлениями и рекомендациями по сохранению и развитию родного языка как первоосновы татарской нации.

## ГОРУР БУЛЫЙК

Халкыбыз уңышлы алга барсын, хәлиткеч гамәлләрне нәтиҗәле рәвештә тормышка ашырсын өчен ул туган телендә, дөрес һәм матур итеп, иркенләп сөйләсен һәм сөйләшсен, балаларын, теләгәнчә, үз телләрендә тәрбияләсен, укытсын, татарча газета-журналлар, китаплар укысын, сыйфатлы итеп әзерләнгән мәгънәле радио-телевидение тапшыруларын тыңласын һәм карасын өчен, кайчан тулы шартлар, мөмкинлекләр булыр һәм булырмы икән?

Хәзерге вакытта туган телебезнең, кирәгенчә, иркен кулланылмавын, аны балаларга, яшьләргә өйрәтү өчен һәм гомумән халкыбызның милли рухы һәрчак хөр, нык һәм күтәренке булсын өчен җитәрлек шартлар булмавының төп сәбәпләреннән берсе үзебезнең милли горурлыгыбыз җитенкерәмәүдә, үзебезне кимсетелгән, түбәнсетелгән милләт кешеләре итеп тоярга күнеккән,

шулай ук хаксыз рәвештә бездән югарырак хәлдәге дип уйлаган башка бер халык теләгән һәм үзәк хакимият әмерләрен үтәргә бик күндәм булуыбыздадыр. Фикеребезне кайбер гыйбрәтле хәлләр, күренешләр, вакыйгалар белән дәлилләргә тырышып карыйк.

Безнең халыкның ирекле, бәхетле, шатлык-куанычлар белән, телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап гомер кичерергә тулы хокукы бар. Бу хокукны ул күп гасырлар буена тәрбияле, күркәм, һәр яктан күпләргә үрнәк булырлык итеп яши белүе белән яулап алган. Аның үзенең алдынгы дәүләте булган, югары культурасы, камил теле, матур традицияләре бар. Татарлар – тырыш, әдәпле, сәләтле, кирәк чакта Ватан өчен үзен аямыйча көрәшә торган халык.

Күптән түгел Россия Федерациясе Конституциясенең төзәтелгән басмасында рус теле Россия дәүләтен төзегән халык теле дип язу, димәк, бу дәүләтне бары руслар гына оештырган дип исәпләү – бу олы гамәлдә башка халыкларның, шул исәптән татарларның да, өлеше юк икән дип раслау – Россия тарихын тупас бозу һәм руслардан башка халыкларны санга сукмау, кимсетү. Татарларның күп гасырлар буена Россия гаскәрләре сафында батырларча көрәшеп килүе, Икенче бөтендөнья сугышында йөзләрчә мең татар солдатларының яу кырында шәһит китүе, йөзләрчә хәрбиләрнең Советлар Союзы Герое исеменә лаек булуы, Россиянең элекке башкаласы Санкт-Петербургны төзегәндә меңнәрчә татарларның коточкыч авыр шартларда эшләве һәм күбесенең һәлак булуы, Ватан сугышы вакытында татар хатын-кызларының, картлар һәм яшүсмерләрнең, ярым ач килеш, фронт өчен дип, үзләрен аямыйча фидакарьлек белән эшләүләре, Донбасс, Кузбасс шахталарында меңнәрчә татарларның күмер чабулары, татар хатын-кызларының урман кисүләре, сазлыкларда торф чыгарулары татар халкының Россия дәүләтен төзүдә һәм саклауда зур өлеше барлыгын күрсәтмиме ни?! Саный китсәң, андый хәлләр исәпсез күп. Татарлар, тырыш халык буларак, һәрвакыт иң авыр дәүләт эшләрен башкарып килгәннәр.

Россиянең матди-техник һәм гуманитар куәтен арттыруда күпме генә татарлар катнашмаган! Татарларның йөзләрчә зур галимнәре илнең фәнен үстерүдә, промышленностен алга җибәрүдә, оборонасын ныгытуда катнашкан һәм катнаша, дөнья күләмендә дан казанган дистәләрчә сәнгать әһелләре – композиторлар, опера-балет артистлары, рәссамнар, язучылар Россия мәдәниятенең алтын фондына лаеклы өлешләрен керткәннәр һәм кертәләр.

лай кимсетелгән хәлдә булуы аркасында, татарларның күбесе үз телләрен начар белә яки бөтенләй белми башлаган, һәм күп татар ата-аналары балаларын туган телләренә өйрәтә алмаслык хәлгә килгән. Менә шушы бик аяныч хәлне исәпкә алып, үз милләтенең саклануы һәм теленең иркен кулланылуы өчен җаваплы республика җитәкчеләре үзләренә шушы бик әһәмиятле ике бурычны куеп эш итәргә тиеш: кичектермичә, милли мәктәпләрне арттырып, татар укучыларына туган телләрен укытуның дәрәҗәсен күтәрү һәм урта буын кешеләренең дә туган телләрен яхшылап өйрәнүе өчен мөмкинлекләр булдыру.

Шулай итеп, без, балаларга гаиләдә туган телләрен өйрәтүнең зур әһәмияткә ия булуын инкарь итмичә, ана теленнән тулы белем бирүнең төп формасы уку йорты дигән нәтиҗә ясыйбыз. Хакыйкать шул: туган телен нәкъ менә гомуми белем бирү һәм махсус урта, югары уку йортларында өйрәтү нәтиҗәсендә яшь буын камил әдәби телне үзләштерә ала. Халыкның әдәби телгә ия булуы исә – аның алдынгы милләт дәрәҗәсенә ирешүенең бер шарты. Димәк, татар халкының алдынгы милләт булып уңышлы рәвештә алга баруының нигезе – аның татар уку йортларында өйрәтелә торган әдәби телгә ия булуы.

Мең еллык татар әдәби теленең саклануы өчен милли мәгарифнең уңышлы алга баруы мөһим. Хәзер, руслардан башка күп халыкларның телләренеке кебек, татар теленең дә кулланылышы, төрле киртәләргә очрап, кими барганда, хакимиятнең иң әһәмиятле бурычларыннан берсе – кичектермичә, татар мәктәпләренең элекке ролен торгызып, алар эшенең сыйфатын яңа дәрәҗәгә күтәрү. Татар телендәге уку йортларының, барыннан да бигрәк гомуми белем мәктәпләренең, гимназия, лицейларның уңышлы эшләвенә ирешеп кенә татар телен, милли мәдәниятне, матур гореф-гадәтләрне, традицияләрне һәм ахыргы исәптә милләт буларак халыкның үзен дә саклап калырга мөмкин.

ЮНЕСКОның Генераль секретаре мөрәҗәгатендәге *“...практик файдасын күрерлек барлык башка оешмаларга бөтен телләргә, бигрәк тә юкка чыгу куркынычы янаган телләргә, индивидуаль һәм коллектив тормышның бөтен очракларында да хөрмәт белән карау, ярдәм итү һәм аларны саклау мәнфәгатьләрендә кылган гамәлләрен активлаштырырга”* дигән сүзләрне безгә, бөтен татарларга һәм татарстанлыларга да, бик җитди рәвештә кабул итеп, туган телебезнең авыр хәлдә булуы уңаеннан чаң сугарга кирәк.

Кайбер идеологларның, янәсе, үзеңне татар итеп санау өчен татар телен белү шарт түгел, үзеңне шул халыкныкы итеп тою һәм ислам дине тарафдары булу да җитә, татар теле мәңге яшәячәк дип тәкрарлауларын тыңлап, үзеңне тынычландырырга ярамый.

Милләтләр турындагы теориядән хәбәрдар булу зарур. Анда милләтнең төп атрибуты (билгесе) тел диелә. Шулай ук күренекле фикер ияләренең халык туган теле булганда гына яши, теле югалса, ул үзе дә юкка чыга дигән сүзләренә колак салырга кирәк.

Хакыйкать шул: безнең телебезгә тиз арада гына югалу куркынычы янамаса да, аның сыйфаты, әдәби нормалары җитди бозылып, ул ниндидер бер суррогат (зәгыйфь), калька теленә әверелергә мөмкин. Бу безнең милләттәшләребезнең шактый күбесенең фәкыйрь, корама телдә сөйләүләрендә, сөйләшүләрендә күренә. Һәм, моңа татар телендәге матбугатны укыганда, радио һәм телевидение тапшыруларын тыңлаганда һәм караганда инанасың. Бу чараларның теле еш кына тупас ялгышлар, әдәби нормалардан тайпылышлар белән сугарылган була.

Халыкара туган көн алдыннан татар халкына, бигрәк тә аның, билгеле бер сәбәпләр аркасында, үз милләтенә тиешле илтифатлык күрсәтмәгән өлешенә, шундый теләкләребезне ирештерергә булдык: борынгы тарихлы, югары мәдәниятле, күркәм традицияләргә һәм хәерле гореф-гадәтләргә ия, хезмәтчел һәм югары әхлаклы халкыбызның язмышына игътибарлы, ихтирамлы булыйк һәм миллилек сыйфатларыбызны – туган телебезне, мәдәнитяебезне һ.б. яклау һәм саклау өчен кулыбыздан килерлек бар гамәлләрне дә кылыйк. Бу изге максатка ирешү өчен, туган телебезне яхшы итеп белик һәм ул телдә иркен аралашыйк, гаиләдә һәм мәктәптә балаларга ана телләрен өйрәтик, татарча әдәбият, газета-журналлар укыйк, телевидение, радио тапшырулары карыйк, тыңлыйк, татар театрларына йөрик һәм милләттәшләребез белән үз телебездә сөйләшик.

Республика җитәкчеләре, икенчел дәрәҗәдәге, әһәмияте аз чаралар үткәрү белән мавыкмыйча, халкыбызны туган телләреннән яхшы белемнәр белән коралландырсыннар, аларның үз телләрендә аралашуларын гадәткә кертү чараларын күрсеннәр, милли мәктәпләрнең эшләрен тамырдан яхшыртып, балаларга һәм яшьләргә татар телен укытуның нәтиҗәлелеген арттыруга ирешсеннәр иде.

Татарстан хөкүмәте, татар теленең язмышы барыннан да бигрәк татар мәктәбе ярдәмендә хәл ителәчәген истә тотып, мил-

ли уку йортларына иң кирәкле нәрсәләр итеп карарга тиеш. Татар мәктәпләре бөтен яктан да: укыту-матди базасы буенча да, югары квалификацияле укытучылар белән тәэмин ителүе белән дә, укытуның сыйфаты буенча да иң яхшылар булсын. Гамәлдәге татар уку йортларының эшен камилләштерергә һәм яңа, абруйлыларын да булдырырга кирәк. Аларда укыту һәм тәрбия бирүнең дәрәҗәсе алдынгы рус мәктәпләренекеннән калышмаска тиеш. Республиканың һәр район үзәгендә кимендә берәр, ә зур шәһәрләрдә берничә иң яхшы мәктәп ачарга кирәк.

Рус мәктәпләрендә укучыларга, аеруча татар балаларына, татарча укытуны тамырдан яхшырту да – Татарстанның мәгариф министрлыгының иң мөһим бурычы.

Татар уку йортларының эшен яхшырту һәм балаларга татар телен укытуның сыйфатын күтәрү белән шөгыльләнгәндә, республиканың җаваплы хезмәткәрләренә үзәктәге җитәкчеләрнең канәгатьсезлегеннән куркып калырга түгел, үз дәрәҗәләрен саклап, законнар барлык кешеләр тарафыннан да үтәлергә тиеш дип, кыю итеп әйтә белергә кирәк.

Россия Федерациясенең, республикаларның конституцияләре һәм башка законнары буенча барлык гражданнар да туган телләрен өйрәнергә һәм иркен кулланырга, балаларын да үз телләренә өйрәтергә, республика органнары исә милли мәгарифне үзләре теләгәнчә оештырырга хаклы.

Татарларның бер өлешенең үзенең милли сыйфатларына – теленә, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә һ.б. пассив һәм илтифатсыз караштa булуы белән бәйләнешле тагын бер җитди проблема ул – халык арасында кешеләрнең милли рухын, үзләрен лаеклы шәхесләр итеп тою һәм халкы белән горурлану хисләрен ныгытуга юнәлтелгән аңлату-идеология эшен гамәлгә ашыру зарурлыгы. Бу гаять әһәмиятле эш уку йортларын, мәгълүмат чараларын, әдәбият, сәнгать әсәрләрен җәлеп итеп һәм бай тарихыбызны, мәдәният хәзинәләрен тулы һәм матур итеп күрсәтеп, татар халкының күп санлы күренекле шәхесләре үрнәгендә югары дәрәҗәдә башкарылырга тиеш.

Язмабызны татар халкының лаеклы уллары, кызлары, республика җитәкчеләре туган телебезне, рухи мирасыбызны саклау өчен көч-куәтләрен аямыйча, акылларын җигеп, тиешле чараларны күрерләр һәм үзләрен алдынгы милләт вәкилләре итеп танытырлар дигән өмет белән тәмамлыйбыз.

# Р.А. ЮСУПОВНЫҢ ГЫЙЛЬМИҺӘМ ПУБЛИЦИСТИК ХЕЗМӘТЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ

# ПЕРЕЧЕНЬ НАУЧНО-ПУБЛИЦИСТИЧЕСКИХ ТРУДОВ Р.А. ЮСУПОВА

## МОНОГРАФИЯЛӘР, ФӘННИ-ПОПУЛЯР БАСМАЛАР ҺӘМ УКЫТУ ЯРДӘМЛЕКЛӘРЕ

## МОНОГРАФИИ, НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫЕ ИЗДАНИЯ И УЧЕБНЫЕ ПОСОБИЯ

1. *Көтәбез, сезне, укытучыбыз.* – Казан: Тат.китап нәшр., 1968.

2. *Тәрҗемә теориясенә кереш* (Методик кулланма). – Казан: КДПИ, 1972.

3. *Тәрҗемә мәсьәләләре.* – Казан: Татар. китап нәшр., 1975. – 128 б.

4. *Тәрҗемә һәм тел культурасы.* – Казан: Татар. китап нәшр., 1978.–128 б.

5. *Теория и практика перевода.* Программа для студентов отделения “Русский язык с педагогикой”. – Казань: КГПИ, 1978.

6. *Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков.* – Казань: Таткнигоиздат, 1980. – 256 с.

7. *Төрле структуралы телләрдәге гомумилек.* Махсус курс буенча методик ярдәмлек. – Казан: КДПУ, 1981.

8. *Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү.* Методик ярдәмлек. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – 136 б.

9. *Төрле структуралы телләрдә гомуми элементлар.* Махсус курс буенча методик күрсәтмә. – Казан: Казан пед. институты, 1984.

10. *Теория и практика перевода.* Программа. – М.: Мин-во просвещения СССР, 1984.

11. *Теория и практика перевода.* Программа для педвузов. – Л.: Просвещение, 1985.

12. *Икетелллелек һәм сөйләм культурасы.* – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – 214 б.

13. *Введение в теорию и практику перевода.* Учебное пособие. – Казань: КГПИ, 1988. – 96 с.

14. *Рус мәктәпләренең I–X класслары өчен татар теле һәм әдәбияты программасы.* – Казан: Татар. мәгариф министрлыгы, 1989. (автордашлар: Н.Х.Нәбиуллина, Х.Г.Фәрдиева).

15. *Татар теле. Унберьеллык урта мәктәпнең 5 классы өчен дәреслек* (Татарский язык. Учебник для 5 класса средней школы). – Казан, 1991. – 214 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

16. *Задачи совершенствования учебно-воспитательного процесса.* – Казань: КГПИ, 1991.

17. *Итоги и перспективы.* – Казань: КГПИ, 1992.

18. *Новые подходы к преподаванию литературы.* – Казань: КГПИ, 1992.

19. *За повышение уровня подготовки педагогических кадров.* – Казань: КГПИ, 1992.

20. *Инсафлының теле саф.* – Казан: КДПИ, 1993. –164 б.

21. *За подготовку высокоэрудированных специалистов.* – Казань: КГПИ, 1994.

22. *Татар теле. Унберьеллык урта мәктәпнең 5 сыйныфы өчен дәреслек.* – Казан: Мәгариф, 1995. – 214 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

23. *Татар теле. Рус мәктәбенең 8 сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек.* – Казан: Мәгариф, 1995. – 238 б. (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

24. *Татарский язык в русскоязычной аудитории. Пособие для старшеклассников русских школ.* – Казань: Магариф, 1995. – 503 с. (соавтор – А.Ш.Асадуллин).

25. *Программа для практических занятий по татарскому языку в русскоязычной аудитории.* – Казань: Магариф, 1995. (соавтор – А.Ш.Асадуллин).

26. *Программа по татарскому языку для V–XI классов русских школ.* – Казань: Магариф, 1995. – 24 с. (соавторы: З.Н.Хабибуллина, Р.А.Асылгарева, К.З.Зиннтуллина).

27. *Татарский язык в русскоязычной аудитории.* – Казань: Магариф, 1995. – 206 с. (соавтор – А.Ш.Асадуллин).

28. *За новое качество подготовки педагогов.* – Казань: КГПИ, 1996.

29. *Җылы сүз җан эретә. Дөрес сөйләм турында язмалар.* – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – 159 б.

30. *Рус мәктәпләрендә укучылар өчен татар теле программасы (I–XI сыйныфлар*). – Казан: КДПУ, 1997.

31. *За повышение уровня подготовки специалистов.* – Казань: КГПУ, 1997.

32. *Задачи по усилению воспитательной работы со студентами.* – Казань: КГПУ, 1998.

33. *Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре. Укытучылар өчен ярдәмлек.* – Казан: Мәгариф, 1998. – 150 б. (автордаш – Ш.Ә. Әсәдуллин).

34. *Задачи по усовершенствованию учебно-воспитательного процесса.* – Казань: КГПУ. 1998.

35. *Татар теле. Рус урта гомуми белем мәктәбенең 8 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек.* – Казан: Мә гәриф, 1999. – 207 б. (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

36. *О задачах по совершенствованию системы подготовки педагогических кадров.* – Казань: КГПУ, 1999.

37. *Татар теле. Татар урта гомуми белем мәктәбенең 5нче сыйныфы өчен дәреслек.* – Казан: Мәгариф, 2000. – 167 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

38. *Әдәп башы – тел. Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре.* – Казан: КДПУ, 2000. – 218 б.

39. *Икесен дә яхшы бел.* – Казан: Мәгариф, 2000. – 191 б.

40. *Синтагматические отношения лексических единиц русского и татарского языков.* – Казань: КГПУ, 2002. – 178 с.

41. *Казанский государственный педагогический университет за 5 лет.* – Казань: КГПУ, 2002. – 20 с.

42. *Сөйләм культурасы: Әдәби тел нормалары. Студентлар өчен программа.* – Казан: КДПУ, 2003.

43. *Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. Фәнни-популяр язма.* – Казан: Татар. китап нәшр., 2003. – 222 б.

44. Сөйләм культурасы курсыннан мөстәкыйль эшләр өчен методик кулланма. КГПУ-Казан, 2004.

45. *Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек.* – Казан: Мәгариф, 2005. – 232б. (автордашлар: В.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

46. *Сөйләм культурасы. Методик кулланма.* – Казан: ТДГПУ, 2005.

47. *Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода.* – Казань: ТГГПУ, 2005. – 227 с.

48. *Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи.* – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 384 с.

49. *Татар теле. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек.* – Казан: Мәгариф, 2006.

50. *Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы.* – Казан: ТДГПУ, 2007. – 193 б.

51. *Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы.* – Казан: Татар. китап нәшр., 2008. – 239 б.

52. *Общее и специфическое в разноструктурных языках.* – Казань: ТГГПУ, 2009. – 298 с.

53. *Теория и практика перевода.* – Казань: ТГГПУ, 2010. – 366 с.

54. *Татарский язык для 8 класса.* – Казань: Мәгариф, 2010.

55. *Татар теле. Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек.* – Казан: Татар. китап нәшр., 2011 (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

56. *Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре.* – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

57. *Тәрҗемә мәсьәләләре.* – Казан: КФУ, 2012. – 254 б.

58. *Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре.* – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – 287б.

59. *Мәгърифәт үзәкләре тарихыннан (Из истории центров просвещения).* – Казан: “Сүз”, 2014. – 226 б.

60. *Дөрес тәрҗемә итик.* – Казан: ТФА Тарих институты, 2015. – 216 б.

61. *Телебезне ялгыш тәрҗемәдән саклыйк.* – Казан: ТФАның Тарих институты, 2016. – 291 б.

62. *Матбугат һәм эфир теле.* – Казан: ТФА Тарих институты, 2017. – 318 б.

63. *Просвещение, нация, государственность.* – Казань: АНТ, Институт истории, 2017. – 179с.

64. *Мәгърифәт, дәүләт һәм туган тел. За прогресс нации.* Казань: “Слово”, 2018. – 253 с.

65. *Вопросы теории и практики перевода.* Казань: Таткнигоиздат, 2018. – 352 с.

66. *Общее и специфическое в разноструктурных языках.* Рига: Lambert Academic Publisching, 2018 – 293 с.

67. *Сохранение родного языка – долг каждого. Телебезне саклау – һәркемнең изге бурычы.* Казань: “Слово”, 2019. – 207 с.

68. *Туган тел һәм мәгърифәт. Родной язык и образование.* Казань: “Слово”, 2020. – 271 с.

69. *Мәгърифәт юлыннан.* Дорогой просвещения. Казань: “Слово”. 2020, – 575 с.

70.*Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм.* Перевод и культура речи. Казан: “Сүз”, 2020, – 367 б.

71. *Туган тел. Милли мәгариф. Родной язык. Национальное образование.* Казань: “Слово”, 2021. – 275 с.

72. *Туган тел –милләтнең нигезе. Родной язык – фундамент нации.* Казань: “Слово”, 2021, – 256 с.

73. *Горур булыйк. Быть достойными сынами своего народа.* Казань: “Слово”, 2022, – 303 с.

## БАСЫЛЫП ЧЫККАН МӘКАЛӘЛӘР

## ОПУБЛИКОВАННЫЕ СТАТЬИ

1. **Букет выброшенных цветов:** О современной молодежи // Ленинец. – 1961. – 2 дек.

2. **Төгәлсезлекләр күңелне борчый** // Соц. Татарстан. – 1964. – 23 май.

3. **Чигенгән үлем:** [Ватан сугышы Герое, легендар катюшалар командиры якташыбыз Барый Юсупов турында] // Соц. Татарстан. – 1966. – 25 февр.

4. **Давылда туганнар:** [Атказанган укытучы Мәрьям Зәйнуллина турында] // Соц. Татарстан. – 1966. – 5 ноябрь.

5. **Доктор Гөлсем:** [Казандагы “Спартак” аяк киемнәре берләшмәсе врачы Г.Рәхмәтуллина турында] // Соц. Татарстан. – 1967. – 7 апр.

6. **Икмәк пешерү остасы** [С.Мөхетдинов турында] // Соц. Татарстан. – 1967. – 7 июнь.

7. **В раймаг за покупкой:** [О работе Высокогорского райпо] // Сов. Татария. – 1967. – 13 июля.

8. **Авторитет депутата:** [О председателе Нижнемактаминского поселкового совета Альметьевского района А.Г.Авзаловой] // Сов. Татария. – 1967. – 17 авг.

9. **Арчалылар үрнәге:** [Райпотребсоюзның сәүдә комплексы эше турында] // Соц. Татарстан. – 1967. – 9 авг.

10. **Кеше исән калды:** [Казан медицина инструментлары заводы турында] // Яшь ленинчы. – 1967. – 18 окт.

11. **Партком һәм реформа:** [Казан электр конструкцияләре заводы партия оешмасының эше турында] // Соц. Татарстан. – 1967. – 31 гыйнв.

12. **Эшләре игелекле:** [“Спартак” аяк киемнәре берләшмәсенең хатын-кызлар советы эше турында] // Соц. Татарстан. – 1967. – 11 февр.

13. **Туган тел үсеше:** [Рецензия китапка: Зәкиев М.З. Туган тел үсеше. – Казан: Татар. китап нәшр., 1967. – 84 б.] // Сов. мәктәбе. – 1968. – № 12. – 57 б.

14. **Ленин исемендә:** [Казан җитен комбинаты турында] // Яшь ленинчы. – 1968. – 17 гыйнв.

15. **Аяк киемең кайда эшләнгән?:** [“Спартак” аяк киемнәре комбинаты турында] // Яшь ленинчы. – 1968. – 24 июль.

16. **Белмәмеш татарча сөйләшә** // Казан утлары. – 1969. – № 6.

17. **Күпләргә үрнәк:** [Арча районының Жданов исемендәге колхозы комбайнчысы Ә.Сафин турында] // Соц. Татарстан. – 1969. – 21 авг.

18. **Лагерьның бер көне:** [Казанның Бауман комсомол райкомының Осинники авылы янында урнашкан хәрби-спорт-хезмәт лагере тормышы] // Соц. Татарстан. – 1969. – 2 авг.

19. **Шат яши колхозчылар:** [Арча районы Кышкар авылының колхоз рәисе К.Сабирҗанов турында] // Соц. Татарстан. – 1969. – 19 авг.

20. **Некоторые вопросы перевода с русского языка на татарский:** [Автореф. дисс. на соискание ученой степени канд. филол. наук] / КГПИ. – Казань, 1970. – 24 с.

21. **Тәрҗемәдә алынмалар куллануның кайбер мәсьәләләре** // Вопросы тюркологии. 1970. – С. 194-206.

22. **Полнее использовать особенности родного языка** // Совет мәктәбе. – 1970. – № 1. – С. 25.

23. **Перевод как разновидность билингвизма** // Вопросы тюркологии. 1970. – С. 56-73.

24. **Туган тел таләпләре** // Соц. Татарстан. – 1971. – 4 февр.

25. **Развитие татарского перевода** / КГПИ // Вопросы татарского языкознания. – Казань, 1971. – С. 150-163.

26. **Семинары переводчиков:** [Лекционными и семинарскими занятиями руководит преподаватель КГПИ Р.А. Юсупов] // Сов. Татария. – 1971. – 12 дек.

27. **Ашаганың аш булсын** // Соц. Татарстан. – 1972. – 21 июль.

28. **О терминологии в школьных учебниках:** Конференция по та- тарскому языкознанию, посвященная 50-летию СССР / ИЯЛИ – КГПИ. – Казань, 1972. – С. 90-93.

29. **Вопросы периодизации развития татарско-русского двуязычия** // Проблемы двуязычия и многоязычия / АН СССР, Ин-т рус. яз., Ин-т языка и литературы АН Туркменской ССР. – М.: Наука, 1972. – С. 152-155.

30. **Кирәкле сүзлек** // Соц. Татарстан. – 1972. – 25 июль.

31. **Борынгы культура илендә:** Мисыр гарәп республикасына сәяхәт тәэсирләре // Яшь ленинчы. – 1973. – 25 авг.

32. **Пирамидалар илендә:** турист язмасы // Татарстан яшьләре. – 1973. – 8 апр.

33. **Пирамидалар илендә.** Ерак җирләрдән кайткач / Соц. Татарстан. – 1973. – 10 апр.

34. **Геройлар дөрес сөйләшсен:** Әдәби телебез турында уйланулар // Соц. Татарстан. – 1973. – 23 сент.

35. **Общественные функции русского и национального языков** //Коммунист Татарии. – 1974. – № 8. – С. 68-72.

36. **Рус теле һәм милли телнең иҗтимагый функцияләре** // Соц. Татарстан. – 1974. – 22 авг.

37. **Сөйләмебез матур булсын** // Соц. Татарстан. – 1974. – 3 окт.

38. **И туган тел, и матур тел** // Татарстан яшьләре. – 1974. – 24 окт.

39. **Классик әсәр татар телендә:** [Л.Н.Толстойның “Казаклар” повестеның татар телендә басылып чыгуы уңаебелән] //Соц. Татарстан.– 1975. – 2 март.

40. **Халыкның олы ихтирамы** // Татарстан яшьләре. – 1975. – 24 май.

41. **Сөйдергән дә тел...** // Соц. Татарстан. – 1975. – 6 июнь.

42. **Эфир теле** // Соц. Татарстан. – 1975. – 16 сент.

43. **Рус һәм татар телләрендә интерференция мәсьәләләре:** Татар телен укыту мәсьәләләре / КДПИ. – Казан, 1975. – 190-200 б.

44. **Проявление общего и спецификического в формировании татарско-русского двуязычия** // Развитие двуязычия в процессе обучения в национальной школе РСФСР: Тезисы докладов научной конф. (Нальчик, 11 – 13 мая, 1976 г.). – М., 1976. – С. 50-53.

45. **Проявление общего и специфического в переводах** /КГПИ //Вопросы тюркского языкознания. – Казань, 1976. – с.81-97.

46. **Р.А. Юсупов һ.б. тәрҗ.** – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 560 б.

47. **Тәрҗемә турында сөйләшү:** [КДПИның өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты Р.А. Юсупов тәрҗемәнең сыйфаты һ.б. мәсьәләләргә тукталып уза] // Соц. Татарстан. – 1977. – 14 дек.

48. **Тел тарихы – халык тарихы ул:** [Рец. китапка: Зәкиев М.З. Татар теленең барлыкка килүе. – Казан, 1977] // Соц. Татарстан. – 1978. – 16 февр.

49. **Шул ук** // Сов. тюркология. – 1978. – №3. – 97-100 б.

50. **Телебез ничек барлыкка килгән:** [Рец. китапка: Зәкиев М.З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. – Казан, 1978] // Сов. мәктәбе. – 1978. – №6. – 61-62 б.

51. **Шул ук** // Сов. тюркология. – 1978. – №3. – 97-100 б. – Рус телендә.

52. **Зәңгәр экран теле** // Соц. Татарстан. – 1978. – 9 февр.

53. **К истокам татарского языка** // Сов. Татария. – 1978. – 28 февр. – Соавтор К.З.Зиннатуллина.

54. **Некоторые общие и специфические морфологические явления русского и татарского языков** // Вопросы татарского языкознания / КГПИ. – Казань, 1978. – С. 84-106.

55. **Важный фактор общественного развития:** [Рец. на кн. Э.М.Ахунзянова "Двуязычие и лексико-семантическая интерференция". – Казань, 1978] // Сов. Татария. – 1979. – 12 окт.

56. **Укучыларның тел культурасын үстерү өчен** // Сов. мәктәбе. – 1979. – №1. – 11-12 б.

57. **Развитие двуязычия в Татарии** // Пути развития национально-русского двуязычия в нерусских школах РСФСР. – М.: Наука, 1979. – С. 117-118. – Соавтор М.З.Закиев.

58. **Тел-әдәбиятны яхшы өйрәтү өчен** // Соц. Татарстан. – 1979. – 30 май.

59. **Синонимы в русском и татарском языках:** Проблемы типологии татарского и русского языков / КГПИ. – Казань, 1980. – С. 141-151.

60. **Общее и специфическое в словосочетаниях русского и татарского языков** // Совет мәктәбе. – 1980. – №6. – С. 43-45.

61. **Особенности сочетаемости слов в русском и татарском языках** // Совет мәктәбе. – 1981. – №6. – С. 37-39.

62. **Двуязычие и взаимодействие русского и татарского языков:** Актуальные вопросы грамматики и стилистики татарского языка / Казан. филиал АН СССР. – Казань, 1981. – С. 113-119.

63. **Общее и специфическое в переносном употреблении слов контактирующих языков** (на материале русского и татарского языков) // Сов. тюркология. – 1981. – №1. – С. 30-36.

64. **Кирәкле хезмәт:** [Рец. китапка: Байрамова Л.К. Русско-татарский фразеологический словарь языка В.И.Ленина. – Казань, 1980] // Сов. мәктәбе. – 1982. – 10-31 б.

65. **Общее и специфическое в лексико-семантической и фразеоло-гической системе русского и татарского языков:** (10.02.01): (10.02.06): Автореф. дис. на соискание ученой степени доктора филол. наук. – М., 1982. – 36 с.

66. **Чәчәк ата туган телебез** // Сов. мәктәбе. – 1982. – №12. – 33-37 б.

67. **Взаимодействие русского и татарского языков и развитие в них общих элементов** // Взаимовлияние и взаимообогащение языков

народов СССР (По материалам автономных республик Поволжья и Приуралья) / КГПИ. – Казань, 1982. – С. 15-20.

68. **Нинди телдә сөйләшәсең?** / /Сов. мәктәбе. –1983. –№ 12. – 22-25 б.

69. **Беренче тапкыр:** [Ф.Г.Гарипованың “Татарстан гидронимнары сүзлеге”нә рецензия] // Соц. Татарстан. – 1984. – 14 сент.

70. **Тел күрке – сүз** // Ялкын. – 1984. – № 2. – 29 б.

71. **Сүзләр бәйләнеше** // Ялкын. – 1984. – №3. – 39 б.

72. **Сүзләр дуслаша аламы?** // Ялкын. – 1984. – №4. – 26-27 б.

73. **Сүзләрне үзара бәйләү чаралары** // Сов. мәктәбе. – 1984. – №6. – 19-21 б.

74. **Кушымча гына димә** // Ялкын. – 1984. – №6. – 30 б.

75. **Методика преподавания лингвосопоставительных дисциплин в национальных педвузах при подготовке учителей русского языка: Научно обоснованные рекомендации по методике преподавания лингвистических дисциплин в национальных педвузах:** Сб. трудов / НИИ ПРЯНШ Академии педагогических наук. – М., 1984. – С. 3-17. – (Соавтор М.З.Закиев).

76. **Әткәм-әнкәм мирасы:** [Туган телебезне саклау] // Соц. Татарстан. – 1985. – 21 февр.

77. **Туган як тарихыннан:** [Рец. китапка: Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан, 1984] // Сов. мәктәбе. – 1985. – №5. – 61 б.

78. **Шул ук** // Сов. тюркология. – 1985. – №5. – 82-83 б. (Рус телендә).

79. **Историко-филологический** // За педагогические кадры. – 1986. – 14 мая.

80. **Җаваплылык арта бара:** [Укыту-тәрбия мәсьәләләре] // Соц. Татарстан. – 1986. – 31 авг.

81. **Тәрҗемә турында сөйләшәбез** // Казан утлары. – 1986. – №5. – 177-179 б.

82. **Телебез тарихы турында:** [Рец. китапка: Хаков В.Х. Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20-30 нчы еллар). – Казан, 1985] // Сов. мәктәбе. – 1986. – №10. – 59-60 б.

83. **Шул ук** // Сов. тюркология. – 1986. – №5. – С. 100-102. (Рус телендә).

84. **Лексические средства выразительности в русском и татарском языках** // Вопросы структуры татарского языка: Межвуз. сб. науч. трудов / КГПИ. – Казань, 1986. – С. 3-21.

85. **Фразеологизмнар – телебезнең җәүһәрләре** // Сов. мәктәбе. – 1986. – №11. – 19-21 б.

86. **Работать лучше, вносить новое** // За педагогические кадры. – 1987. – 17 сент.

87. **Перестройка – веление времени** // За педагогические кадры. – 1987. – 29 апр.

88. **Учебный год стартовал** // За педагогические кадры. – 1987. – 23 сент.

89. **Дөрес кулланабызмы?** // Соц. Татарстан. – 1987.

90. **Положение о кафедрально-школьном комплексе** // Межвуз. сборник науч. трудов / КГПИ. – Казань, 1987. – С.7. (Соавтор Я.И.Ханбиков).

91. **Счастливого старта всем первокурсникам!** // За педагогические кадры. – 1988. – 31 авг.

92. **Мирфатых Закиевич Закиев:** К 60-летию со дня рождения // Сов. тюркология. – 1988. – №5. – С. 113-114. (Соавторы: Э.Р.Тенишев, Ф.А.Ганиев).

93. **Проблемы языка и происхождения волжских татар:** [Рец. на кн.: Закиев М.З. Проблемы языка и происхождения волжских татар. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 303 с] // Сов. тюркология. – 1988. – №4. – С. 116-117. – Соавтор Ф.Г.Гарипова.

94. **Рус мәктәбендә татар теле укыту:** максат һәм бурычлар // Сов. мәктәбе. – 1988. – №5. – 2-7 б.

95. **Сөйләшү әдәбе** // Казан утлары. – 1988. – №2. – 172-176 б.

96. **Принимать и выпускать лучших** // Сов. Татария. – 1988. – 28 апр.

97. **Проблемы обучения татарскому языку в русских школах** // Сов.мәктәбе. – 1988. – № 8. – С. 18.

98.**Подготовкабудущихучителейкобщественно-политической работе в процессе изучения психолого-педагогических дисциплин** // Подготовка будущих учителей к воспитательной работе в школе: Межвуз. сб. науч. трудов / КГПИ. – Казань, 1988. – С. 6-14.

99. **Иптәшлек, хезмәттәшлек аша:** [Заман мәктәбенә заманча укы тучылар] // Соц. Татарстан. – 1989. – 1 март.

100. **Резервы есть:** [О ходе перестройки на истфаке КГПИ] // За педагогические кадры. – 1989. – 14 марта.

101. **Демократизация и гуманизация:** [Доклад делегата Всесоюз. съезда работников народного образования ректора КГПИ Р.А. Юсупова на партсобрании ин-та] // За педагогические кадры. – 1989. – 4 февр.

102. **Укыту-өйрәтүдән башларга** // Соц. Татарстан. – 1989. – 31 дек.

103. **В обстановке переосмысления ценностей:** [О совершенствовании учебно-воспитательного процесса в КГПИ] // За педагогические кадры. – 1990. – 22 ноября.

104. **И пролетел год...** // За педагогические кадры. – 1990. – 26 дек.

105. **Милли мәктәпкә йөз белән** [КДПИ ректоры мәгариф системасындагы кайбер проблемалар турында ] // Татарстан яшьләре. – 1990, 13 февр.

106. **Наша боль и надежда:** [К образованию ТССР] // Вечерняя Казань. – 1990. – 31 авг.

107. **Подготовке педагогических кадров – творческий подход:** [Опыт работы Казан. пед. ин-та] // Коммунист Татарии = Татарстан коммунисты. – 1990. – №1. – С. 61-65. (Соавторы: М.Галеев, М.Тутаев).

108. **Главный вопрос повестки дня** // Сов. Татария. – 1990. – 31 авг.

109. **Проблема, не терпящая отлагательств** // Сов. Татария. – 1990. – 17 марта.

110. **Тагын күпме көтәргә?** // Соц. Татарстан. – 1990, 1 март.

111. **Татарстанга – дәүләт суверенитеты** / [Татарстанның халык депу таты Р.А. Юсуповның Татарстан Югары Советының 1990 елның 30 августы утырышында ясаган чыгышы] // Ватаным Татарстан, 1990, 31 авг.

112. **Гарәп илләренә юл:** [КДПИ карамагындагы “Татарстан – Гарәбстан” дуслык һәм мәдәни элемтәләр җәмгыяте оештырылу уңае белән] // Соц. Татарстан. – 1991. – 11 дек.

113. **Читәләмастында:** [Татарстанның мөстәкыйльлегенә карата] // Әлмәт нурлары. – 1991. – 2 сент.

114. **Ходай Тәгалә, ипи-бәрәңге һәм без** // Шәһри Казан. – 1991. – 15 окт.

115. **Хыяллар матур, ниятләр изге** // Шәһри Казан. – 1991. – 23 гыйнв.

116. **Культурологический аспект подготовки будущего учителя** // Культура и педагогика. – Хабаровск, 1991. – С. 19-20. (Соавтор З.Г.Нигматов).

117. **Беренче адымнар** // Ватаным Татарстан. – 1992. – 29 авг.

118. **Максат – бердәм эш итү** // Ватаным Татарстан. – 1992. – 1 дек.

119. **Организация и методика учебного процесса, физкультурно-оздоровительной и спортивной работы:** Тезисы докл.

2-й науч.-метод. конф. – Казань, 1992. – 104 с. – В содержании автора Р.А. Юсупов и др.

120. **Мөгаллим туган телен белсен** // Шәһри Казан. – 1992. – 9 гыйнв.

121. **Татар халкының язмышын хәл итә торган законнарның берсе** // Мәгариф. – 1992. – №9. – 15-17 б.

122. **Как показывает жизнь** // Вечерняя Казань. – 1992. – 9 янв.

123. **Взаимопонимание – залог благополучия** // Сов. Татария. – 1992. – 24 дек.

124. **Икеләнүләргә урын юк** // Ватаным Татарстан. – 1992. – 28 окт.

125. **Педвуз заглядывает в завтра:** [О предстоящих нововеяниях в деятельности ректората КГПУ] // Известия Татарстана. – 1992. – 15 апр.

126. **Новые подходы к преподаванию литературы** / КГПИ. – Казань, 1992. – 23 с.

127. **Закон Республики Татарстан "О языках народов Республики Татарстан"** (проект) / Верховный Совет РТ. – Казань, 1992. – Соавторы: Ф.А.Ганиев, М.З.Закиев.

128. **Чын тигезлек. Башка юл юк** // Шәһри Казан. – 1992. – 21 май. – (Автордаш Ф.Зыятдинов).

129. **Битараф булмыйк:** [Россия референдумына багышлана] // Ватаным Татарстан. – 1993. – 23 апр.

130. **Билингвизм: шаг от теории к практике:** [Обсуждение Закона о языках] // Изв. Татарстана. – 1993. – 1 дек.

131. **Конституция – якты маяк ул** // Шәһри Казан. – 1993. – 6 нояб.

132. **Нет большего счастья** // Татарстан Республикасы. – 1993. – 21 май.

133. **Җәмгыятьнең тоткасы – мәгърифәт** // Ватаным Татарстан. – 1993. – 1 сент.

134. **Ватан-ана улларына өн сала** // Ватаным Татарстан. – 1993. – 24 ноябрь.

135. **Ыгы-зыгы тудыру кемгә кирәк?** // Шәһри Казан. – 1993. – 7 гыйнв.

136. **Безгә кыю милиция кирәк** // Ватаным Татарстан. – 1993. – 23 гынв.

137. **Иман – илаһи көч** // Татарстан Республикасы. – 1993. – Июль.

138. **Күршең теле ят булмас** // Шәһри Казан. – 1993. – 11 дек.

139. **Дуслыкка – тигезлек аша** // Шәһри Казан. – 1993. – 27 апр.

140. **Образование: время перемен** // Сов. Татария. – 1993. – 6 апр.

141. **О насущных проблемах образования** // Мәгариф. – 1993. – №3. – С. 18-19.

142. **“Азатлык” радиостанциясендә ун көн** // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 29 июль.

143. **Волжские булгары и их исторические наследники:** [Рец. на кн.: Закиев М., Кузьмин-Юманади Я. Волжские булгары и их потомки: Монография. – Казань: ГЭНИ, 1993. – 159 с] // Татарстан. – 1994. – №1 – 2. – С. 121-122.

144. **Камиллекнең чиге юк:** [Институтта уку алымнарын һәм про граммаларын яңарту] // Мәгариф. – 1994. – №2. – 9-10 б.

145. **Киләчәккә ышаныч:** [КДПИның КДПУ исемен алу уңае белән] // Мәгърифәт. – 1994. – 17 дек.

146. **Мое кредо – дать человеку шанс** // Молодежь Татарстана. – 1994. – 29 дек.

147. **Не просто смена вывески:** [Казан. пед. институт преобразован в пед.ун-т] // Респ. Татарстан. – 1994, 24 ноября.

148. **Новое в содержании и организации высшего педагогического образования:** Материалы Всерос. науч.-практ. конф., 23-24 ноября 1993 г. / Казан. пед. ун-т. – Казань, 1994. – 154 с.

149. **Россиядә икетеллелек: уйдырмалар һәм чынбарлык** // Шәһри Казан. – 1994. – 6 окт.

150. **Рухи яңарыш юлында** // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 6 сент.

151. **Хәерле юл, яңа университет!** // Мәгърифәт. – 1994. – 17 дек.

152. **Киләчәккә ышаныч белән** // Мәгърифәт. – 1994. – 17 дек.

153. **С верой в будущее** // Педагог. – 1994. – Дек.

154. **Первоочередные меры:** [Выступление на сессии ВС РТ председателя РПТ Р.А. Юсупова] // Татарстан Республикасы. – 1994. – 21 июль.

155. **Парламент будет удобным и послушным** // Вечерняя Казань. – 1994. – 1 авг.

156. **Белем – тормышның терәге** // Шәһри Казан. – 1994. – 4 окт.

157. **Рухи яңарыш юлында** // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 2 сент.

158. **Белемгә һәм кешелек мәрхәмәтенә ышанам** // Ватаным Татарстан. – 1994. – 6 дек.

159. **Сәясәт саф булсын** // Шәһри Казан. – 1994. – 23 июль.

160. **Заман сынавында сынатмыйк** // Ватаным Татарстан. – 1994. – 7 окт.

161. **Сила науки** // Магариф. – 1994. – №1. – С. 6.

162. **Развитие двуязычия в Татарстане в новых социально-поли-тических условиях** // Межнациональные отношения в России: история и перспективы / АН РТ. – Казань, 1994. – С. 128-130.

163. **Акыл өстенлек итсен:** [Чечняда булган канлы бәрелешләр уңаен нан] // Ватаным Татарстан. – 1995. – 7 гыйнв.

164. **Белем һәм игелеклелек көченә ышану** // Мәгариф. – 1995. – №1. – 52-53 б.

165. **Верю в торжество разума:** [Рассказывает депутат Верховного Совета республики Р.А. Юсупов] // Республика Татарстан. – 1995. – 1 марта.

166. **Проблемы языка и методики преподавания** // Магариф. – 1995. – №3. – С. 30. (Соавтор Л.З.Шакирова).

167. **Татар теленә хөрмәт арта** // Шәһри Казан. – 1995. – 26 апр.

168. **Университет – Казанский педагогический** // Татарстан дулкынында = На волне Татарстана. – 1995. – 20-26 февр.

169. **Хакимият үз бурычын башкарсын** // Шәһри Казан. – 1995. – 28 февр.

170. **Новый статус обязывает** // Педагог. – 1995. – Февраль.

171. **Киләчәгебезгә өметне югалтмыйк**//Ватаным Татарстан. – 1995. – 30 авг.

172. **Аек акыл кирәк** // Шәһри Казан. – 1995. – 7 гыйнв.

173. **С верой в светлое будущее** // Татарстан Республикасы. – 1995. – 30 дек.

174. **Отказаться от шаблона** // Педагог. – 1995. – № 4.

175. **Тагын бер кат – сыйфат** // Мәгърифәт. – 1995. – 18 ноябрь.

176. **Программа по татарскому языку для V-XI классов русских школ.** – Казань: Магариф, 1995. – 24 с. – Соавторы: З.Н.Хабибуллина, РА.Асылгараева, К.З.Зиннатуллина.

177. **За новое качество подготовки педагогов** / КГПИ. – Казань, 1995. – 12 с.

178. **Двуязычие и гармонизация межнациональных отношений в Татарстане** // Возрождение культуры России: язык и этнос. – СПб., 1995. – С. 31-68.( Соавторы: М.З.Закиев, Л.К.Байрамова).

179. **Развитие двуязычия в Республике Татарстан:** [Материалы Всероссийской научной конф. “Проблемы двуязычия в современных условиях”] / КГПИ. – Казань, 1995. – С. 3-5.

180. **Аек акыл кирәк:** [Чечня вакыйгалары уңае белән] // Бөгелмә ава зы. – 1996. – 4 апр.

181. **Бүгенгесе ышанычлы, киләчәге өметле:** [КДПУга 120 ел тулу уңае белән] // Ватаным Татарстан. – 1996. – 13 ноябрь.

182. **Главная школа республики:** [К 120-летию КГПУ] // Респ. Татарстан. – 1996. – 15 ноября.

183. **Закон ничек үтәлә?** // Ватаным Татарстан. – 1996. – 24 дек.

184. **Гөлләр кадере – күзләрдә:** [КДПУга 120 ел тулу уңае белән] // Сөембикә. – 1996. – №12. – 6-7 б.

185. **Дустыбызның якты истәлегенә:** [Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры Р.К.Беляевның вафат булуы уңае белән] // Ватаным Татарстан. – 1996. – 27 июль.

186. **Конституция Татарстана вдвое превзошла американскую. По поправкам** // Время и деньги. – 1996. – 5 ноября. – С. 10. (Соавт. Р.Железнов).

187. **Педагогларның туган йорты:** [КДПУның 120 еллыгы уңае белән] // Мәгърифәт. – 1996. – 15 ноябрь.

188. **Принципы гуманизма – основа народной педагогики:** Тезисы докл. III Междунар. науч.-практ. конф. “В будущее, сохраняя народные педагогические традиции” (Арск, 21-23 мая 1996 г.). – Казань, 1996. – 187 с. (В содерж. авт. Р.А. Юсупов и др).

189. **Не терять оптимизма!** // Педагог. – 1996. – Январь.

190. **Фәнни һәм педагогик үзәк:** [КДПУга 120 ел тулу уңаеннан] // Мәгариф. – 1996. – №10. – 2-4 б. ( Автордаш Җ.Нигъмәтов).

191. **Самая главная школа** // Педагог. – 1996. – Ноябрь.

192. **Настоящий учитель должен уметь все** // Учитель. – 1996. – 1 окт.

193. **Казанский государственный педагогический университет** // Татар иле. – 1996. – №42.

194. **Василий Алексеевич Богородицкий как тюрколог** // ВА.Богородицкий – выдающийся ученый и педагог: [Материалы республ. науч.-практ. конф.] // Казань, 1996. – 92 с.

195. **Закон “О языках народов Республики Татарстан”:** проблемы его реализации // Бюллетень Академии гуманитарных наук. – СПб., 1996.

196. **Актуальные проблемы двуязычия в Республике Татарстан:** Материалы межрегион. научно-практ. конф. в честь 110-летия со дня рождения Г.Тукая “Преподавание яз. и лит. в условиях претворения в жизнь закона РТ “О языках народов РТ”] / АН РТ, М-во образования и др. – Наб. Челны: [ИНПО]. – 1997. – 196 с.

197. **Актуальные проблемы современного филологического образования и развития творческих способностей учащихся:** [Тезисы респ. научно-практ. конф, 4-5 марта 1997 г., Казань] / Ин-т повышения квалификации кадров РТ, шк. № 122, Казань]. – Казань, 1997. – 156 с.

198. **Башың начар эшләсә – акча түлә!** [КДПУга керү имтиханнарын тапшыруда яңалык] // Татарстан яшьләре. – 1997. – 17 апр. (Автордаш Ф.Харисов).

199. **Сездә нинди хәлләр бар:** [II Бөтендөнья татар конгрессына багышланган] // Татарстан яшьләре. – 1997. – 26 июль.

200. **Тел ул – халык байлыгы:** [Тел сафлыгы] // Ватаным Татарстан. – 1997. – 31 окт.

201. **Югары белемсез милләт- киләчәксез:** [Вузара гыйльми-методик совет рәисе итеп билгеләнү уңае белән] // Туган тел ("Мәгърифәт" газетасына махсус кушымта). – 1997. – Август, №1. – 11 б.

202. **Белгеч булсын белемле** // Мәгърифәт. – 1997. – 4 окт.

203. **Высшее образование – основа прогресса** // Мәгариф. – 1997. – №1. – С. 10-11.

204. **Телләр турындагы законны гамәлгә кертү** // Фән һәм тел. – 1997. – №1. – 16-17 б.

205. **Где искать хороших людей** // Казанские ведомости. – 1998. – 12 сент.

206. **Дөрес сөйлик, дөрес языйк** // Мәгариф. – 1998. – №4. – 68-71 б.

207. **Педагогик югары уку йортларында татар теле** // Мәгариф. – 1998. – №9. – 71-75 б.

208. **Тормыш юашларны өнәми** // Республика. – 1998. – 18 февр. – 1-7 б.

209. **Суверенитет не роскошь, а средство выживания** // Образование. – 1998. – Сент.

210. **Развитие двуязычия в Татарстане в новых социально-политических условиях** // Проблема самодостаточности этносов: теоретико-методологические вопросы. – Казань: Изд-во Казанск. ун-та, 1998.

211. **Преподавание на татарском языке в педагогических вузах Республики Татарстан:** Материалы республ. конф. / Кабинет Министров РТ. – Казань, 1998. – С. 12-22.

212. **Некоторые вопросы реализация закона "О языках народов Республики Татарстан"** // Н.К.Дмитриев – выдающийся тюрколог и педагог / КГПУ. – Казань, 1998. – С. 24-27.

213. **Главная цель – подготовка высококвалифицированных педагогов:** Итоги 1998/99 учебного года и задачи по улучшению учебно-воспитательного потенциала / КГПУ. – Казань, 1999. – 32 с.

214. **Лингводидактический аспект преподавания иностранных языков:** Сб. научн. ст. / Казан. пед. ун-т. – Казань, 1999. – Вып. 3. – 170 с. (В содерж. авт. Р.А. Юсупов и др.).

215. **Кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүче галим:** [КДПУ проректоры Җ.Г. Нигъмәтовка 60 яшь тулу уңаеннан] // Мәгариф. – 1999. – №10. – 56 б.

216. **Духовный кризис опаснее экономического:** [Воспитание подрастающего поколения специалистов] // Казанские ведомости. – 1999. – 29 июня.

217. **Не ломать, а строить** // Педагог. – 1999. – Декабрь.

218. **Быть взыскательней, действовать масштабней** // Педагог. – 1999. – Сентябрь.

219. **Государственные языки и развитие народов Республики Татарстан** // Лингводидактический аспект преподавания иностранных языков / КГПУ. – Казань, 1999. – 32 с.

220. **Государственные языки и развитие народов Республики Татарстан:** [Выступл. на пленар. заседании науч. конф. 22-27 авг. 1999 г. Прага.] // Педагог. – 1999. – Сентябрь.

221. **Слово о хорошем человеке:** [Видному ученому М.Х.Хасанову 70 лет] // Мәгариф. – 2000. – №6. – С. 25.

222. **Оныту мөмкин түгел** // Ватаным Татарстан. – 2000. – 29 авг.

223. **Укытучылар укытучысы без** // Таһир-Зөһрә. – 2000. – 17 сент.

224. **Некоторые итоги подготовки педагогических кадров** // Этнопедагогические традиции формирования культуры межнациональных отношений: Материалы VII Междунар. науч.-практ. конференции. – Казань, 2000. – С. 3-7.

225. **От ректора** // Музыка и педагогика: Сб. статей / КГПУ. – Казань, 2000. – С. 3-21.

226. **Текст выступления депутата Р.А. Юсупова на второй сессии Верховного Совета Татарской Автономной Советской Социалистической Республики двенадцатого созыва:** [Из стенограммы сессии] // Венера Якупова. 100 историй о суверенитете. – Казань: Идел-Пресс, 2001. – С. 163-164.

227. **Организатор активной дидактики:** [К 75-летию академика М.И.Махмутова] // Татарские края. – 2001. – Апрель (№ 16). – С. 4; Июнь (№23). – С. 2.

228. **Фәнни-педагогик белем чишмәсе** // Мәгариф. –2001 –№10.– 10-12 б.

229. **Казанский педагогический университет сегодня** / Педагог. – 2001. – Ноябрь.

230. **Die Position als Fremdsprache in Universitaten der Republik Tatarstan: (Состояние изучения немецкого языка как иностранного в университетах Республики Татарстан)** // Mehr Sprache – merhrsprf Deutsch in Tatarstan. Zeitschriftfür Deutschleher – min Deutsch – Luzern, 2001.

231. **Задачи по усилению воспитательной работы со студентами** // Формы и методы воспитательной работы в вузе / КГПИ. – Казань, 2001. – с. 3-5.

232. **Озын юл, нурлы юл:** [Казан дәүләт педагогика университетына 125 ел] // Казан утлары. – 2001. – №10. – 102-107 б.

233. **Нур өстенә нур өстәп** // Мәгърифәт. – 2001. – 3 ноябрь.

234. **Максат – киләчәкнең өметен һәм таянычын үстерү:** [КДПУның 125 еллыгына карата] // Шәһри Казан. – 2001. – 30 ноябрь.

235. **Мәгърифәт нуры сибеп:** [Казан педагогика университетының 125 еллыгын каршылап] // Ватаным Татарстан. – 2001. – 30 ноябрь.

236. **Современная языковая ситуация и некоторые проблемы развития двустороннего двуязычия в республике** // Теория и практика обучения татарскому языку как неродному в условиях новой языковой ситуации: Материалы респ. науч.-практ. конф. / КГПУ. – Казань, 2001. – С.3-5.

237. **Татар һәм рус телләренең лексик-семантик системаларындагы үзенчәлекләр** // Мәгариф. – 2002. – №10. – 74-76 б.

238. **Учитель должен получать не менее пяти тысяч** // Казанские ведомости. – 2002. – 4 окт.

239. **Цель одна – взрастить педагога:** [О деятельности Казанского педагогического университета с 1986 по 1992 год] // Педагог. – 2002. – Октябрь.

240. **Deutsch an der Universiteten der Republik Tatarstan** // Deutsch in Tatarstan. Zeitschriftfür Deutschleher. – Kazan, 2002.

241. **Сөйләм культурасы: әдәби тел нормалары:** [Студентлар өчен программа] / КДПУ. – Казан, 2003. – 12 б.

242. **Проявление общего и специфического в переносном употреблении слов русского и татарского языков:** Межкультурная коммуни кация. Типология языков. Теория перевода // Материалы II Междунар. науч. конф. – М.; Казань, 2004. – С. 320-326.

243. **Күп теллелек һәм тел культурасы:** Материалы науч.-практ. конф. “Полилингвизм и система профессионального образования

в Республике Татарстан” / Набережночелн. госпединститут. – Наб. Челны, 2004.

244. **Сөйләм культурасы.** – Мәгариф. – 2004. – №9. – 15 б.

245. **Культура речи: проблемы изучения и сохранения языковых норм (на материале татарского языка)**: Материалы Междунар. симпозиума “Типология аргументной структуры и синтаксические отношения” (11-14 мая 2004 г., Казань) / Казан. гос. университет. – Казань, 2004. – С. 347-348.

246. **Дәресләрдә тәрбия мәсьәләләре** // Мәгариф. – 2005. – №6. – 7-9 б.

247. **Воспитание студентов при обучении татарскому языку** // Актуальные проблемы башкирского, тюркского и сопоставительного язы кознания. – Уфа, РИО БашГУ, 2005. – С. 222-228.

248. **Сөйләм культурасы:** Методик кулланма / ТДГПУ. – Казан, 2005. – 37 б.

249. **Двуязычие и культура речи:** Сопоставительная филология и по лилингвизм: диалог культур / КГУ – Казань, 2005. – С. 319.

250. **Воспитание студентов при обучении родному языку** // Наука в Татарском гуманитарно-педагогическом университете / ТГГПУ. – Казань, 2005.

251. **Соотношение имен существительных русского и татарского языков** // Актуальные проблемы обучения татарскому языку в русской школе / ТГГПУ. – Казань, 2005. – с. 203-205.

252. **Неуемность – качество настоящего ученого** // Республика Татарстан. – 2005. – 5 авг.

253. **Пример высокой интеллигентности** // Тюркология: история и современность. – АН РФ, ТГГПУ, Казань, 2006.-с.10-14.

254. **Проявление общего и специфического в синонимах русского и татарского языков** // Тюркология и современность. – АН РФ ТГГПУ, Казань, 2006. – с.179-189.

255. **Милләтебез горурлыгы (Гордость нации)**. – Шәһри Казан. – 2006. – 2 июль.

256. **Яшь рухлы аксакал булсак иде (Не стареть душой).** – Мәгърифәт. – 2006. – октябрь.

257. **Соотношение антонимов русского и татарского языков** // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы. – Казань: ТГГПУ, 2006.

258. **Туган телебез ни хәлдә? (Проблемы родного языка)** // Ватаным Татарстан. – 2006. – 14 январь.

259. **Ничек эндәшергә? (Как обращаться?)** // Ватаным Татарстан. – 2006. – 1 март.

260. **Татарская лингвистика и образование** / Вестник ТГГПУ, 2006, №6. – Казань: ТГГПУ, 2006.

261. **Ана рус буламы? Яки Азияне Асия дип йөртә башлыйкмы** // Ватаным Татарстан. – 2007. – 16 июнь.

262. **Общие свойства языков как отражение всеобщего характера мышления**. / Актуальные вопросы татарского языкознания. – Выпуск 5. – Казань: ИЯЛИ АН РТ. – 2007.

263. **Телне саклауда башбаштаклык хөкем сөрә (О нарушениях норм татарского языка)** // Ватаным Татарстан. – 2007. – июнь.

264. **Гносеологические аспекты соотношения общего и специфического в разноструктурных языках**. / Сборник научных статей. – Казань: Гуманитария, 2007.

265. **Общие свойства разноструктурных языков как отражение всеобщего характера мышления / Билингвизм как явление межкультурной коммуникации: реалии и перспективы:** Международная научно-практическая конференция (Казань, 2007, 21-22 сентября). – Казань: ТГГПУ, 2007.

266. **Общность фразеологизмов разноструктурных языков** (на материале русского и татарского языков). – М.: Российский гуманитарный университет, 2007.

267. **О сопоставительном изучении синонимов русского и татарского языков** // Языковые и культурные контакты народов республики Башкортостан в условиях двуязычия. – Уфа: Башкирский гос.университет, 2007.

268. **Средства массовой информации и нормы татарского литературного языка** // Сборник научных статей. – Казань: АН РТ, 2007.

269. **Ориентализмы в лексике и фразеологии болгарского языка** (в сопоставлении с татарским языком). – М.: МГУ им. М.В.Ломоносова, 2008 (в соавторстве с Л.К.Байрамовой и Т.Яруллиной)

270. **Ике тел лексик сурәтләү чараларының үзара нисбәте (Соотношение лексических средств выразительности разноструктурных языков)** // Сборник избранньгх трудов членов АН РТ. – Казань: АН РТ, 2008.

271. **Сохранение родного языка – долг каждого** // Материалы 2-ой научно-практической конференции “Сохранение и развитие родного (татарского) языка”, посвященный Международному Дню родного языка. – М.: Московское общество татарской культуры “Туган тел”, 2008.

272. **Проявление общего и специфического в парадигмических отношениях слов русского и татарского языков** // Сборник научных статей “Тенишевские чтения – 2008”. – Казань: ТГГПУ, 2008.

273. **Проблемы сохранения родного языка** //Языковые уровни и их анализ. – Казань: ТГГПУ, 2008.

274. **Рус телендә сөйләшүче укучыларны татарчага өйрәтү мәсьәләләре**// Милли мәдәният. – Казань: ИЯЛИ АНТ, 2008.

275. **Чит тел кебек өйрәтик яки яңа буын дәреслекләр кирәк**. – Ватаным Татарстан. – 2008. – декабрь.

276. **Кайсы болын матуррак:** 12 февраль – Халыкара Туган тел көне уңаеннан татар теле турында. – Ватаным Татарстан. – 2008. – 20 февраль.

277. **Хезмәт иясе – хөрмәт иясе:** (Профессор Ф.Ф.Харисовка 55 яшь тулу уңаеннан) // Фән һәм тел. – 2008.

278. **Рус мәктәбендә укучыларга татар телен өйрәтү** // Мәгариф.– 2009. – №9.

279. **Татар мәктәпләрендә туган тел укыту һәм дәреслекләр** // Мәгариф. – 2009. – №12.

280. **Слова разных языков, соответствующие в основном значении, и эквивалентные слова**. // Сб.: "Экономика, право и культура в современных условиях в Российской Федерации и Республике Татарстан". – Москва: Российский государственный гуманитарный университет, 2009.

281. **Кем ул изге Вәли, яки туган телебезне һаман җәберлиләр** // Ватаным Татарстан. – 2009. – 17 февраль.

282. **С татарского на русский и обратно** // Республика Татарстан.– 2009. – 21 февраля.

